АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Дрожжаное*

КАЗАНЬ · 2016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

*Чүпрәле*

КАЗАН · 2016

УДК 39(470.41)+008(470.41)
ББК 70(2Р354)
М 48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

**Редколлегия:**

***К. М. Миңнуллин** (рәис), **А. Ф. Җәләлов, Д. Б. Рамазанова, М. Х. Вәлиев, И. Р. Шәрипов***

**Төзүче һәм фәнни мөхәррир**
***М. З. Вәлиева***

**М48 Милли-мәдәни мирасыбыз: Чүпрәле.** – Казан, 2016. – 408 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; тугызынчы китап).

ISBN 978-5-93091-163-3

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән чираттагы китап Чүпрәле төбәгендә яшәүче милләттәшләребез, аларның гореф-гадәтләре, тел үзенчәлекләре турында бай мәгълүмат бирә. Бу җыентыкта борынгы ташбилгеләр, шәҗәрәләр, тарихи шәхесләргә багышланган язмалар да урын алды. Шулай ук анда җирле халыкның авыз иҗаты, җыр-моңнары, осталарның кул эшләре, авыллар тарихы белән танышырга мөмкин. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең тикшеренү-эзләнүләрен туплаган әлеге басма үз укучыларын табар һәм андагы язмалар һәркемдә зур кызыксыну уятыр, дип ышанабыз.

**ISBN 978-5-93091-163-3**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016

## СҮЗ БАШЫ

Соңгы елларда татар халкын, аның борынгы заманнарга барып тоташкан бай тарихын, мең еллар буена чарланып килгән туган телен, үзенчәлекле сәнгатен һәм мәдәниятен күп белгечләр катнашлыгында бергәләп өйрәнү буенча Татарстан Фәннәр академиясе институтлары тарафыннан әһәмиятле чаралар уздырыла. Шуларның зур кызыксыну уята торганнарыннан берсе – халкыбыз яши торган төрле төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештыру. Мәсәлән, шундый экспедицияләр 2009 елдан башлап Татарстанның Актаныш, Апас, Кукмара, Чүпрәле һ.б. районнарында, Мари Эл, Удмуртия республикаларына, Түбән Новгород, Омск, Оренбург, Әстерхан һ.б. татарлар яши торган күп кенә өлкәләрдә уздырылды.

Бу экспедицияләрдә тел галимнәре, фольклорчылар, археографлар, тарихчылар, музыка һәм сәнгать белгечләре катнашты. Нәтиҗәдә теге яки бу төбәктә яшәүче татарларның тарихы берьюлы, берничә аспектта өйрәнелде. Бу исә һаман да үсештә-хәрәкәттә булган мәдәни-тарихи мирасыбызның ерак тамырларына тирәнрәк үтеп керүдә гаять әһәмиятле адым булып тора.

Шунысы әһәмиятле, әлеге төбәкләрдә тупланган материаллар нигезендә фәнни китаплар язылды, кайберләре инде басылып та чыкты. Әйтергә кирәк, бу хезмәтләр халыкта да, фән дөньясында да зур кызыксыну уятты һәм алар инде сирәк очрый торган библиографик китаплар рәтендә урын алды.

Иң элек шуңа игътибар итик: җирле халык үзенең тарихы, тел һәм мәдәният үзенчәлекләренә битараф түгел. Шуңа күрә галимнәребез кайсы төбәккә экспедиция белән барып чыкса да, аларны ачык чырай, якты йөз белән каршы алу өстенә, үзләрендә сакланган милли-рухи хәзинәләре белән теләп уртаклашалар. Димәк, туган телебезне өйрәнү һәм саклау, күркәм йолаларыбызны барлау һәм киләсе буыннарга тапшыру зарурияте алар өчен дә мөһим. Болар исә татарларның тарихын, рухи һәм матди мәдәниятләрен актив рәвештә, тирәнрәк итеп өйрәнүнең бик вакытлы, кирәкле гамәл икәнен раслый.

2012 елның җәендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Чүпрәле районына алдарак әйтеп үтелгән комплекслы экспедицияләрнең нәүбәттәгесе уздырылды. Анда дистәгә якын галим бәрәкәтле бай материал туплады һәм бу китапта да тупланган фактларга анализ тәкъдим ителә.

Иделнең уң ягында төрки халыклар безнең эрага кадәр үк яшәгәннәр, дигән фикер тарихчыларның хезмәтләрендә көннән-көн раслана килә. Шулай да тарих чоңгылларының өйрәнелеп җитмәгән урыннары кала бирә әле. Бу юнәлештә башкарасы эшләр гаять күп.

Тарих дәвамында берсен-берсе алыштырып торган катлаулы вакыйгалардан Чүпрәле төбәге дә читтә калмаган. Бу тирәләрдә болгарлар һәм аларның дәвамчылары – татарлар – яшәгән, чуаш авыллары да булган. Иң әүвәл Болгар дәүләтенең җимерелүе, аннары Казан ханлыгының яулап алынуы халыкның бер өлешенең, тынычрак урыннар эзләп, чукындырудан качып һәм җирле булу теләге белән көнчыгышка, Урал тирәләренә күчүенә китергән. Рус дәүләтенең көньякка һәм көнчыгышка таба киңәя барган чикләрен саклау максатыннан, Чүпрәле якларына күрше төбәк халыклары да күчереп утыртыла. Болар барысы да Чүпрәле төбәге татарларының теленә һәм рухи-матди мәдәниятенә үзенчәлек керткән. Укучыларга тәкъдим ителә торган әлеге басмада бу мәсьәләләр төрле яклап яктыртыла.

Чүпрәле якларының халык авыз иҗаты әсәрләренә, борынгы язма истәлекләргә бай булуын аңлаган галимнәребез бу төбәкне күптәннән үз иткән. 1945 елда ук инде Х. Ярми, Х. Гатина һәм Г. Разин (Гомәр Бәширов) Кече Чынлы авылында булып, әкият, дастан, бәет үрнәкләре язып алганнар. 1955 елда биредә Х. Ярми, М. Зәбиров һәм К. Миңнекиева халык иҗатын туплаган

җыентыкларны баетырдай гүзәл әсәрләр тапканнар. 1960 елларда диалектолог галимнәрдән Л. Арсланов, 1980–1990 елларда З. Садыйкова, 2000 елларда Д. Рамазанова белән Ф. Баязитовалар барып, шактый күп материал җыеп кайталар. 1994 елда М. Әхмәтҗанов Кече Чынлы авылы зиратындагы борынгы ташъязмаларны тикшерә.

Бу юлы исә галимнәребез әлеге төбәктә комплекслы экспедициядә булып, бүгенге көнгә кадәр халык күңелендә сакланып калган мирасны барладылар, соңгы еллардагы үзгәрешләргә игътибар итеп, яңа үзенчәлекләр теркәделәр. Мәсәлән, диалектологлар Д. Рамазанова һәм Ф. Баязитова тел үзенчәлекләрен өйрәнделәр. Алар үзләре алып кайткан җирле сөйләм үрнәкләрен, гореф-гадәт һәм йолаларны чагылдырган лексиканы тикшерү-өйрәнү нәтиҗәләрен әлеге җыентыкка кергән мәкаләләрендә шактый тулы яктырталар.

Шушы төбәктә яшәгән каллиграф Камалетдин Кәшәви турында һәм тарихи ташбилгеләр белән бәйле мәгълүматлар археограф М. Әхмәтҗанов хезмәтләрендә урын ала. Аспирант И. Муллин мәкаләсендә эпиграфик истәлекләр тасвирлана.

Археографик мирасны өйрәнүче галимнәр Р. Исламов һәм С. Галимов экспедициядән шактый кулъязма китап алып кайттылар. Чүпрәле төбәгендә сакланып калганнар арасында «Китаб әнмүзәҗ», «Мөхәммәдия», «Шәрхел-фәраизес-сираҗия», «Әл-һәдия», «Гайнел-гыйлем тәрҗемәсе», «Коръән» һәм төрле эчтәлектәге кулъязма китапларның да булуы бу төбәк тарихының борынгы чорларга барып тоташуын раслый.

Халык авыз иҗаты җәүһәрләрен туплау һәм өйрәнү юнәлешендә галимә А. Садыйкова тикшеренүләр алып барды. Әлеге экспедиция барышында ул татар фольклорының хәзерге торышына күзәтү ясый. Галимә үзенең мәкаләсендә гасырлар дәвамында татар халкының аерылгысыз юлдашы булган бәет-мөнәҗәт чыгару традициясенең бүген дә дәвам итүен искәртә.

Институт экспедицияләрне яшь галимнәр тәрбияләү эшендә дә нәтиҗәле файдалана. Югары уку йортларында белем алучы сәләтле студентлар – булачак аспирантларыбыз – экспедиция материаллары буенча фәнни мәкаләләр, конференцияләргә чыгышлар әзерлиләр. Бу китапка да аларның өлеше керде. Казан университетының филология һәм сәнгать институты студенты З. Шакирова мәкаләсендә, мәсәлән, ырымнар хакында шактый кызыклы мәгълүмат бирелә.

Декоратив-гамәли сәнгать һәм матди мәдәният өлкәсендәге тикшеренүләрне Казан университетының филология һәм сәнгать институты студенты И. Фәррахова алып барды. Аның мәкаләсендә шушы як халкының агачтан чокып ясау сәнгате һәм башка тасвирый, декоратив-гамәли сәнгать төрләре, традицион мәдәният яктыртыла. Өйләр төзелешендә, җиһазлар ясауда борынгы һәм хәзерге заман бизәкләренең үрелеп баруы чагыла. Яшь белгеч үз хезмәтләрендә бу төбәктә мәчетләрнең үзенчәлекле бизәлешенә аеруча басым ясый.

Шушы як халкының борынгыдан килә торган көнкүреш йолалары, гореф-гадәтләре, уеннары хакындагы кызыклы мәгълүматлар үзе дә шушы төбәктә туып-үскән, бүгенге көндә Казан университеты профессоры И. Гафаров мәкаләсендә урын ала.

Авыллар тарихы, аларның килеп чыгышы, атамалар этимологиясенә бәйле кызыклы мәгълүматлар белән Чүпрәле районының җирле тарихчысы Р. Субаев хезмәте аша танышырга мөмкин.

Йомгаклап әйткәндә, укучыларга тәкъдим ителә торган әлеге басмага шушы төбәктәге татарларның тарихилыкны саклап яшәүләре, җирле осталарның, халык талантларының иҗат җимешләре белән тормыш-көнкүрешләрен бизәргә омтылулары хакындагы язмалар кертелде. Чүпрәледә көн күрүче татарларның үткәне һәм бүгенгесе хакында шактый тулы фәнни мәгълүмат бирә торган бу китап барлык милләттәшләребезгә дә кызыклы булыр, дип ышанасы килә.

**_Ким Миңнуллин,_**
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры*

# КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

*Марсель Әхмәтҗанов*

Халкыбыз тарафыннан меңъ ел дәвамында кулланылып килгән гарәп язуы күп гасырлык тарихында сәнгать осталары тудырган.

Гарәп язуы нигезендәге куфи, сөлес, тәгъликъ, татар тәгъликы стильләре меңләгән кульязмалар, китаплар аркылы безнең заманнарга хәтле килеп җиттеләр.

Фәнни мәгълүматларга караганда, гарәп язуының егермеләп төре бар. Аларның күбесе Алтын Урда һәм аннан соңгы татар ханлыклары диваннарында (канцелярияләрендә) һәм мәдрәсәләрдә «яшәп», милли бәйсезлегебезне югалткач, күбесе гамәлдән төшеп калып, нигездә тәгъликъ, сирәгрәк сөлес ысуллары гына XX гасырның беренче яртыларында да кулланылып килгәннәр.

1787 елда Ислам дине Русиядә рәсми диннәрнең берсе булып танылгач, татар мәктәп-мәдрәсәләр системасы барлыкка килә һәм аларның сыйфат ягыннан үсеше башлана.

XIX гасырда татар мәдрәсәләренең укыту программаларына «хөснел хат», ягъни матур язу, буенча да дәресләр кертелә. Бу дәресләрне махсус хәзерлеге булган хәлфәләр алып бара.

Каллиграфия буенча тирән белемле кешеләрнең берсе – **Камалетдин Кәшәви** (Камалетдин бине Сәйфетдин бине Габденнасыйр бине Мортаза бине Йуныс). Аның ата-бабалары Буа өязендәге Кәшә авылында имамнар булып хезмәт иткәннәр. Камалетдин 1832 елда туып, 1906 елның 28 мартында Казан шәһәрендә вафат булган[1].

[1] Ризаэддин бине Фәхретдин. Асар. Өченче һәм дүртенче томнар. Казан: Рухият, 2010. 313 б.

Заманында ул Буа шәһәрендә дамелла Габделвахид бине Габдеррахман (1852 елда Буа шәһәрендә үлгән һәм күмелгән), Казанда Байморад бине Мөхәррәм (1786–1889), Таһир бине Сөбханкол әл-Питраксый (1774–1864) кебек остазлардан белем алган.

Камалетдин яшьлегендә, Казанда Байморад Мәңгәри һәм Шиһабетдин Мәрҗани мәдрәсәләрендә укып чыккач, хаҗга барып, Мәккәдә һәм Мисырда шактый озак яши, анда белемен тагын да күтәрү өстендә эшли. Аннары, Казанга кайтып, Шиһабетдин Мәрҗанинең мәрхүм шәкерте Гыясетдин бине Хәбибулланың тол калган хатынына өйләнә. Шуннан соң аны Себер якларына чакырып алалар, ул анда Төмән шәһәре янындагы Манчыл карьясендәге мәдрәсәдә белем бирә. Аннан кайтып, Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә каллиграфия укыта.

Безгә Камалетдин Кәшәвинең мәдрәсәдә дәреслек итеп тоткан, үзе ясаган палеографик альбомын табарга туры килде. Бу җыентыкка шул альбомнан хаттат эшләреннән үрнәкләр тәкъдим итәбез.

Камалетдин хәзрәт 1880 елларда Татарстанның бүгенге Чүпрәле төбәгенә керә торган Шәһморза (Шәйморза) авылларының берсендә имам була. Шунда 1885 елда аның улы, киләчәктә күренекле каллиграф һәм рәсем сәнгате буенча фәнни хезмәтләр язучы Сәлах Камал туа.

Камалетдин Кәшәви улы Сәлахетдинне дә каллиграфия сәнгатенә мәхәббәтле итеп тәрбияләгән. Мәдрәсә тәмамлаганнан соң ул Казандагы Айтуганов училищесына кереп укый. Аннары Ливанга китеп, Бәйрут университетында югары белем ала[1]. Аннан кайткач, 1910–1920 елларда Оренбург шәһәрендәге «Хөсәения» мәдрәсәсендә эшли. Әлеге мәдрәсәне 1920 елда Көнчыгыш халыкларының мәгарифе институты итеп үзгәртеп коргач, анда 1920–1924 елларда рәсем, сызым, татар тарихы, «мәгълүматы мәдәния» предметларын укыта. 1918 елдан башлап Сәлах Камал Оренбург төбәгендә укытучыларның җәйге курсларда белемен күтәрү комитеты директоры булып эшли. 1919 елда шундый курсларны Бозаулык шәһәрендә оештыруда катнаша. Аның фидакарьлеге белән Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсе музеен оештыру эше башлана.

Оренбургта эшләү дәверендә ул Самарадан Ташкентка хәтле булган бөтен тимер юл станцияләренең исемнәрен гарәп хәрефләре

[1] Рәхимкулова М. Сәлах Камал // Совет мәктәбе. 1986. № 12. 57 б.

белән татарча язып чыга, Оренбургта 1923 елда вафат булган татар язучысы Шакир Мөхәммәдевнең каберенә таш куя.

1924 елда Сәлах Камалны, татар мәдәниятен саклау, өйрәнү эшеннән аерып, Хива шәһәренә үзбәк мәгарифен күтәрергә җибәрәләр. Ул монда укытучылар әзерләү, атеистик пропаганда, пионер отрядлары төзү буенча эш алып барырга мәҗбүр була.

Талантлы педагог 1927 елда Казанга кайта, Татар педагогия училищесында һәм Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәдә эшли.

Казанда аның фәнни-педагогик хезмәтләре басыла башлый. Мәсәлән: «Мөхтасар имла мөгаллиме» (дөрес язу буенча кыскача дәреслек), «Мөселманча әлифба һәм үрнәкләр», «Тарихы ислам атласы», «Гакаид» (дин), «Мәгълүматы мәдәния вә фәния», «Тарихы ислам», «Ибтидаи мәктәбләрдә кул эшләре», «Әвәләү эшләре» (пластик измәләрдән сыннар һ. б. ясау), «Декоратив эшләр», «Рәсем эшләре» (мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен), «Кәгазь эшләре» (башлангыч мәктәп укытучылары өчен), «Мәктәпкәчә тәрбия җитәкчеләренә һәм беренче баскыч мәктәп укытучыларына сынлы сәнгать эшләреннән кулланма» һ. б. Аларның кайберләре үзләренең әһәмиятләрен бүген дә югалтмаган, хәтта шул типтагы бердәнбер татарча кулланма булып тора.

С. Камал Казандагы Лобачевский исемендәге фәнни китапханәдә саклана торган татар, гомумтөрки, гарәп, фарсы телендәге кульъязмалар фондын системага салуга зур көч куйган.

Сәлах Камал Казан шәһәрендә 1954 елның 18 февралендә вафат була.

Чүпрәле төбәгеннән чыккан, мирасыбызны саклауга һәм өйрәнүгә өлеш керткән Камалетдин бине Сәйфетдин һәм аның улы Сәлах Камал мираслары татар мәдәниятен өйрәнүчеләр өчен дә кыйммәтле чыганак булып тора.

* * *

Чүпрәле төбәге – татар мәдәнияте өчен хезмәт иткән байтак затлар биргән җир. Алар арасында хезмәтләренең әһәмияте ягыннан бөтен Идел буеның тарихы өчен кыйммәте зур булган ачышлар ясаган **Әхмәтшакир (Әхмәт) Баһаветдин улы Булатов** та бар.

Әхмәт ага гарәп язуында сакланган байтак борынгы чыганакларны фәнни әйләнешкә кертте.

Ул 1901 елның 14 маенда Татар Убие авылында туа. Уналты яшенә кадәр авыл мәдрәсәсендә белем ала. 1920–1923 елларда

Кызыл Армия сафларында, 1923–1924 елларда Бохарада Дәүләт иминлеге органнарында хезмәт итә. 1931 елда Мәскәүгә укырга китеп, Совет дәүләт төзелеше институтында белем ала. Аны тәмамлагач, Дагстан Республикасының Үзәк башкарма комитетына җаваплы инструктор эшенә җибәрелә.



Әхмәт Баһаветдин улы Булатов

Әхмәт ага 1938–1939 елларда СССР Халык Комиссарлары Советы каршындагы Дәүләт комитеты баш идарәсенең тарихи карталар бүлегендә редактор вазифасын башкара. 1940–1941 елларда Мәскәүдә Дәүләт тарих музеенда борынгы татар һәм мөселман илләре акчаларын өйрәнүче, тасвирлаучы булып эшли. 1941 елның 5 июлендә үз теләге белән Мәскәү ополчениесенә хезмәткә китә. Мәскәүдән ул Йошкар-Ола шәһәренә эвакуацияләнүче 25 нче колонна башлыгы итеп билгеләнә. Шунда, сәламәтлеге какшау сәбәпле, запаска чыга, Казанга кайтып, 1942–1968 елларда Татарстан Китап палатасы директоры булып эшли. Монда ул беренче татар музыка белгече Хәлимә Ибраһим кызы Терегуловага өйләнә. Аларның Али исемле талантлы уллары бар иде, ул бала дөньядан иртәрәк китеп барды. Казанда Әхмәт Булатов, Китап палатасында эшләү белән бергә, үзенең элек алган белем нигезләренә таянып, Татарстан Дәүләт музее хәзинәләреннән йөзләгән борынгы татар акчалары коллекциясенә тасвирлама яза. Әхмәт аганың борынгы акчалар өйрәнүгә багышланган мәкаләләре фәнни җыентыкларда да дөнья күрә[1]. Шулай ук аның XII гасыр гарәп географы Идрисинең борынгы картасына багышланган мәкаләсе дә басылып чыга.

Шулай да Әхмәт Булатовның фәнгә керткән иң зур хезмәте булып XIV гасыр татар ташбилгеләрен өйрәнүгә багышланган мәкаләләре тора. Ташбилгеләрне өйрәнү белән Әхмәт ага сугыш елларында да шөгыльләнә. Ул Татарстанның Тау ягындагы Олы

[1] Халиков А. Х. Булатов А.Б. Мало-Атрясинский монетный клад XIV – начала XV в. (Предварительное сообщение) // Известия Казанского филиала Академии наук СССР. 1957. № 2. С. 197–199.

Әтрәч һәм Чулман аръягындагы Илдерәк авылларының XIV гасырдан калган татар зиратларындагы ташбилгеләрне, шулай ук хәзерге Тәтеш районына керә торган Ямбакты авылы зиратындагы Алтын Урда дәвере ташбилгеләрен дә өйрәнә. Олы Әтрәч зиратында ул вакытта 14 ташбилге сакланган була. Хәзергәчә бары 11 генә ташбилге сакланып калган.

Әхмәт ага гомеренең соңгы елларында, татар телендәге музыка кораллары атамалары тарихы белән кызыксынып, борынгы әсәрләрне өйрәнде. Нәтиҗәдә ул татар музыка коралларының дүрт йөздән артык атамаларын туплаган иде. Кызганыч ки, аның бу кыйммәтле хезмәте дөнья күрмичә, галимнең шәхси архивында калды.

Безгә аның 1970 елларда XIII гасырның күләмле ядкаре – борынгы татар телендәге «Гарибнамә» әсәренең кулъязмасын текстологик өйрәнүе дә мәгълүм иде. Әхмәт аганың кулында бу әсәрнең җиде кулъязмасы турында мәгълүматлар туплануын һәм алар буенча фикерләрен бәян иткән кулъязмалары барлыгын да хәтерлим.

Ә. Булатовның татар тарихыннан мәгълүм Гәүһәршат исемле дәүләт эшлеклесе (Ибраһим хан кызы) хакында пьеса язганын да искә алып үтү кирәктер.

Әхмәт ага 1982 елның 7 сентябрендә Казан шәһәрендә вафат булды. Аның архив материалларын җәмәгате Хәлимә апа, саклар өчен, Тел, әдәбият һәм тарих институты Мирасханәсенә тапшырган иде. Алар Мирасханәнең ул чактагы фәнни хезмәткәре З. Шәйхисламов тарафыннан тасвирланды һәм хәзер архивта саклана. Әлеге кулъязмалар 541 төпкә тупланган. Алар арасында мәдәни-тарихи мирасыбызга бәйле бик күп чыганаклар бар.

Бу төбәктә узган гасырларда каләм тибрәтеп шигырь-мәрсияләр, хикәятләр язган, тарихлар күчергән каләм һәм фикер осталары арасында **Вәлиулла Әлкәев-Чүпрәле** дигән шагыйрь дә бар. Аның исемен, беренче буларак, Зәйнәп ханым Максудова кайтарды[1]. Дөрес, моңарчы аны Ш. Мәрҗанигә багышланган сәхифәләрнең берсендә телгә алганнар, әмма «Казан байларын яклаучы» дигән ярлык белән тамгалап, биографиясенә һәм иҗатына тукталып тормаганнар.

Зәйнәп ханымның мәкаләсендә дә узган мираска карата шул заманда хөкем сөргән вульгар социологизм йогынтысы сизелә.

[1] Максудова З. Шагыйрь Вәлиулла Чүпрәле // Казан утлары. 1970. № 8. Б. 156–157.

Шулай да ул кайбер кызыклы фактларга ачыклык кертә. Әйтик, Вәлиулла Яңа Чүпрәле авылында 1830 елларда мулла гаиләсендә туган. Балалык елларын ул шул авылда үткәргән. Башлангыч белемне әтисе һәм бабасыннан, авыл мәктәбендә алган. Уку-язу юлында белеме шомаргач, әтисе аны Казанда «Зәңгәр мәчет» мәхәлләсендәге мәдрәсәгә укырга урнаштырган (Казанда хәзерге Нариман урамындагы 98 нче йорт). Вәлиулла Чүпрәле бу мәдрәсәдә көнчыгыш телләрен, ислам шәригате хөкемнәрен, билгеле бер күләмдә урыс телен дә өйрәнеп, теләсә кайсы мәхәлләдә имам һәм мөдәррис булырлык дәрәҗәгә ирешә.

Мәдрәсәдә уку дәверендә Вәлиулла матур әдәбиятны да ныклап үзләштерә, бигрәк тә Шәрекъ шагыйрьләренең мирасы белән таныша. Шул ук вакытта Идел буенда сакланып калган татар поэтик мирасын өйрәнү белән дә шөгыльләнә, үзе дә шигырьләр яза башлый. Казанда аның шигырь сәнгате турында фикер алышырлык дуслары булганлыгы мәгълүм. Аларның берсе атаклы татар шагыйре Гали Чокрый.

Ләкин Вәлиулла шагыйрь буларак Казанда иҗат итеп яшәү мөмкинлекләрен күрми, халыкка мәгърифәт таратырга дип, авыл җирлегенә юл тота. Туган авылына кайтып, кечкенә генә мәктәп-мәдрәсә ача, балаларга сабак бирергә алына. Ул бу эштә үзенең чын педагоглык талантын күрсәтеп, сөекле остазга әйләнеп китә.

Вәлиулла Әлкәев ачык фикерле, мәгърифәтне күтәрергә кирәклекне аңлаган кеше була. 1854 елгы Кырым, 1878 елгы урыс-төрек сугышлары нәтиҗәсендә мөселманнарга карата милли-дини изүнең көчәюе дә шагыйрьгә тәэсир иткән, аның карашларын киңәйткән. Ул шул вакытларда Шиһабетдин Мәрҗанинең «Назурател-хак» (1870) китабына мөнәсәбәтле ризасызлык белдергән кадимчеләргә дә каршы чыга:

Хосус дәмулла Шиһаб тик әкябир,
Табылса бу заман, белгел аны пир!
Безем тикләр йөри мыек кабартып,
Бәлеш буына сакаллар агартып...[1]

Бу шигырьдә татар дөньясында танылган ике тип мулла сурәте күз алдына килә. Беренчесе белеме белән киң танылган пир, ягъни остаз, икенчесе исә мөселман дөньясының көндәлек ихтыяҗларын

---

[1] Максудова З. Шагыйрь Вәлиулла Чүпрәле. Б. 157.

үтәүче гади авыл имамы. Вәлиулла, әлбәттә, Мәрҗани шәхесен күтәрү өчен, үзе кебек гади муллаларга артык түбән бәя куя. Бу очракта авыл укымышлысына мондый бәя бирү белән ризалашасы килми.

Вәлиулла Чүпрәле шигырьләрендә гүзәл фразеологик әйтелмәләр дә аз түгел. Бу инде XIX йөз урталарында татар әдәби теленең үз хәзинәләре хисабына байый баруын күрсәтүче билгеләр:

Йитәр инде, сәлям язмага мул-мул!
Бүтән сүз яз, йә язмактан күтәр кул! –
дигәч, китте зиһен бар да таралып:
Мишәр чумарасы илә каралып ...

Бу шигырьдә татар авылы тормышының бай этник сурәтләре тасвирланган. Эш шунда ки, татар халкында кемгәдер хат язганда, әле XX гасыр урталарына кадәр дә аның яртысын таныш-белешләргә сәлам юллаулар алып торган. Вәлиулла Чүпрәле исә кыскалыкта – осталык дигән фикерне алга сөрә, озын сәламнәр укып, зиһен таралудан зарлана. Бу зиһен чуалуны белдерү өчен арыш камырыннан ясалган, пешкәндә тарала торган «мишәр чумары» дигән фразеологизмны куллана һәм шул рәвешчә шигырьдә образлылыкны арттыра.

Шигырьнең икенче дүртьюллыгында да кызыклы күренешләр чагылып ала:

Алай да башка кидем кәләпүшне,
Зиһен бир! – дип, аңа кылдым хорушны.
Кигәч кәләпүшне, җыелды зиһен,
Гүйә күз алдына килде дә Казан...

Бу юлларда да авыл күренешләре чагыла. Ирләр XIX йөз урталарында татар авылларында кәләпүш киеп йөргән. Шигырь юлларына «яхшы» сүзе урынына «хорушны» (хорошо) дигән урыс сүзе дә килеп керә. Бу очрак Габделҗаббар Кандалыйның дүрт тел сүзләре катыштырып язган «Чикләвек бәһасе» шигырен хәтерләтә:

Че хоше мән меайәд
Тарильда орех.
Вә ни ләм йөэкәл,
Булырса грех[1].

Тәрҗемәсе:

Күңелемә хуш килә *(фарсычадан)*
Тәлинкәдәге чикләвек *(урысчадан)*

---

[1] Чикләвек бәһасе // Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 103.

Әгәр ашалмаса, *(гарәпчәдән)*
Булыр гөнаһ *(татарча һәм урысчадан).*

Башка бер дүртьюллыктан мисал:

Ачубән укыдым тизүк хатны,
Язылмыш Сафа Хәмзиннең вафаты.
Һушым китте, каләм төште кулымнан,
Аера алмадым уңымны сулымнан.

Бу дүртьюллыкта шагыйрьнең Казанда Сафа Хәмзин дигән якын дусты булганлыгы аңлашыла, ул бу югалтуны бик авыр кичергән. Кулыбызга Вәлиулла Әлкәевнең күләмлерәк җыентыгы әлегә кергәне юк. Ләкин шунысы ачык, ул инде 1870 елларда ук чын шагыйрь булып җитешкән, үз заманындагы проблемалар белән өртелгән шигырьләр язган.

Татар мәгарифе тарихында тирән эз калдырган шәхесләрнең тагын берсе – Шиһабетдин бине Мәрҗәни шәкерте **Сафиулла бине Габдулла**. Сафиулла хәзрәт Сембер ягындагы Чынлы авылында туган. Башта ул үз авылында, аннары Буа мәдрәсәсендә белем бирә. Соңыннан Казанга килеп, Шиһабетдин Мәрҗани мәдрәсәсендә укыта. Биредә ул зур абруй казана, Сафиулла хәзрәттән сабак алмаган шәкерт сирәк була. Сафиулла хәзрәт соңыннан «Мәрҗания» мәдрәсәсенең мөдәррисе булып тора һәм Ш. Мәрҗанинең олы кызы Галиягә өйләнә.

1880 елларда Сафиулла хәзрәтне Бүкәй Урданың (хәзерге Казакъстан җирләре) башкаласы Хан Урдасына чакыралар, ул үзе укыта торган шәкертләрен җыеп, андагы мәдрәсәне көчәйтү максатыннан китә. Хан Урдасындагы мәдрәсә 1841 елда ачылып, укыту татар мәдрәсәләре программасы буенча барган.

Сафиулла хәзрәтнең Хан Урдасындагы мәдрәсәдә актив укыту эше башлап җибәрүе христиан миссионерларын хафага сала. Алар мондагы административ ресурсларны эшкә җигеп, татар хәлфәләрен мәдрәсәдән куу кампаниясе оештыралар, чөнки патша хөкүмәтенең законнары буенча, татарларга казакълар арасында укыту эшләре белән шөгыльләнү тыелган була. Сафиулла хәзрәт шәкертләре белән Казанга кайтырга мәҗбүр була, анда беренче мәхәлләгә имам була, шулай ук Мәрҗани мәдрәсәсендә дәрес бирә башлый. Аның «Коръән» басмаларының корректоры булып эшләгәнлеге дә мәгълүм.

Гомеренең соңгы елларында Сафиулла хәзрәт икенче мәчеттә имам һәм мөдәррис дәрәҗәсендә җитәкчелек итә.

Ул 1926 елның 19 гыйнварында Казан шәһәрендә үлә һәм Яңа Бистә зиратына күмелә.

**Ташларның да тамыры бар**

Төбәктәге ташбилгеләр (кабер ташлары) әлегә хәтле яхшылап өйрәнелмәгән. Бу өлкәгә күренекле татар тарихчысы Миркасыйм Госманов беренчеләрдән булып беркадәр игътибар күрсәтә. Ул 1968 елгы археографик экспедиция вакытында Зур Чынлы авылында җирле тарихчы, Г. Алимов ярдәмендә авыл зиратындагы бер кызыклы ташбилгене өйрәнә. Аны 1909 елда авыл имамы Хәйрулла Госманов үзе эшләп, язып куйган була[1].

М. Госмановның бу хактагы мәгълүматы тулы булмаганлыктан, 2001 елның 17 июлендә безгә ул ташбилгене махсус барып өйрәнергә туры килде.

Ташбилге Зур Чынлы зиратында ачык җирдә тора. Ул ак доломит ташны уеп эшләнгән. Үлчәме – 16 × 37 × 140 см. Ташбилгенең дүрт ягына да тәгъликъ ысулындагы татар стилендә вак кына хәрефләр белән язылган. Аларның өч ягындагысын тулысынча укып чыга алдык, ә бер ягындагы язма өлешчә генә укылды.



*Алгы ягы*

Һуаллаһи әл-ләзи лә йәмәвети
сәнәи 1130 һиҗрийә тарихында
1697 дә мәдфүн[2]
мулла Госман бабамыз...
дә вәляди[3] Һади[4]
мулла Хәнәфийә бине әл-хаҗи
мулла Гыйззәтулла бине
мулла Һибәтулла бине мулла
Байтимер бине мулла Госман

---

[1] Усманов М. А.Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1972. С. 191–192.

[2] Мәдфүн – күмелде.

[3] Вәляди – балалары.

[4] Һади – туры юл күрсәтүче.

галәйһем әл-гофран[1] әрвахларина[2]

әл-фатиха

*Икенче ягындагы дәвамы*

Кәтәбүһә хаҗи вә хафиз Хәйрулла бине әл-хаҗи мулла Гыйззәтулла сәнә-и 1327//1909

*Арткы ягы*

Мәрхүмә вә мәгъфүрә вәляди Фәхретдин Хөсниҗамал бинте мулла Хәбибулла

Вөҗүдә Гөлгыйзәр

Шәмсекамәр вә Сәрвиҗамал

вә Гыймадетдин, мулла Габделгазиз вә Габделнәфигъ вә Шиһабетдин

Вәляди мулла Һибәтулла, Хөсниҗамал вә Бәдриҗамал

вә әхфаде[3] мулла Сәгыйдулла бине Галимулла вә Габделваһаб, вә Низаметдин

вә Габделгафур, вә Минһаҗетдин

йәнә ибне Госман әрвахларина әл-фатиха

Чынлы карйәсенә[4] мөәссәсдә[5] бабаларымыз Түмин вә Рәзан тарафындан килгән 18 мөселман хуҗа

*Өченче ягы*

Ташбилгенең кырларындагы язмалар:

Галәмәтдин морадым бер догадыр,

Бу көн бәңа йарин нәүбәт сиңадыр!

*Дүртенче ягы*

...

Чынлы буйында

Иске Йорт

Йәйләү урнына

ултырыб йир

Алмышлар, мәгәр Мөхәммәд Илмөхәммәд улы

...

...

---

[1] Әл-гофран – гаепләрен кичер.

[2] Әрвахларина – рухларына.

[3] Әхфаде – оныклары.

[4] Карйәсенә – авылына.

[5] Мөәссәсдә – нигездә.

Ындырҗай Алташ улы
... Агнай
... Алмакай...

Иске Задур ташбилгеләре

Эпиграфик язмалар Иске Задур авылы зиратында да беркадәр сакланган.

Ташбилгеләрнең берсендә аны эшләгән останың ташка уеп язылган имзасы кыйммәтле тарихи мәгълүмат булып тора. Язмада аның исеме Вәлиэддин әз-Задури дип бирелгән.



Ташбилгедәге Вәлиэддин әз-Задури имзасы

Вәлиэддин әз-Задури эшләгән ташбилгеләрнең саны бер дистәгә җитә. Алар известьташтан кисеп ясалганнар. Вәлиэддин әз-Задуриның тормышы турында әлегә берни дә мәгълүм түгел. Ясаган һәйкәлләренә карап кына останың 1885–1905 еллар арасында эшләгәнлеген чамалап була. Вәлиэддин әз-Задури эшләгән кабер ташларының үлчәмнәре 20 × 20 × 45/50 см, яки шуңа якын зурлыктагы һәйкәлләр булганнар.

Ул ташларны тигез, матур итеп, дүрт кырлы итеп кисеп, аның югары очын мәчет гөмбәзенә охшатып эшләгән. Язмаларны уеп та, кабартып та төшергән.

Буа төбәге авыл зиратларында да мондый стильдәге ташлар очрый. Алар 1908–1925 еллар арасында атаклы таш кисеп язучы оста Гарифҗан Буави тарафыннан эшләнгән. Бу һәйкәлләр Гарифҗан Буавиның Вәлиэддин әз-Задури стилен өйрәнеп, шул ысулда иҗат итүен күрсәтә.

Гарифҗан Буави чама белән 50–60 лап ташбилге эшләп калдырган.

Әлеге ике оста Татарстанның башка төбәкләрендә очрамый торган эпитафия стиле барлыкка китергәннәр.

Вәлиэддин әз-Задури эшләгән ташбилгеләрдән үрнәкләр

*Беренче ташбилге*

*Алгы ягы*

Көлли нәфсе даикатә мәвәти
Һазә мәркаде Хаҗел-



хәрамин Кәшифетдин
ибне Гыйззәтулла ибне
Рәхмәтулла Ниази
Рәхмәтү Аллаһу Тәгаләи

*Тәрҗемәсе*

Һәрбер җан иясе үлем ачысын татыр
Бу кабер Хаҗи
Кәшифетдин
бине Гыйззәтулла бине
Рәхмәтулла Ниазиныкы
Аңа Алланың рәхмәте төшсен.

*Икенче ягы*

Һуаллаһи әлләзи лә йәмүде[1]
Тарих вафаты миладийә
сәнә 1895, фиврал
19 ында, 56 йәшендә
Иске Задурда
...халыгы гофран өчен[2]

*Өченче ягы*

Тарих вафаты һиҗрийә 1311 сәнә, рәҗәб 3 ендә.
Милади 1894 сәнә, гыйнвар 15 ендә.

*Икенче ташбилге*

Лә иллаһе иллаллаһи, Мөхәммәд рәсүл Аллаһи
Сахибе һазә әл-мәркад
зәүҗәи Ә... рт
Задури ...
Тәрҗемәсе
Аллаһ бер, Мөхәммәд аның илчесе
Бу кабернең хуҗасы
...хатыны (хәлале)
Задури ...

[1] Һуаллаһи әлләзи лә йәмүде – ул үлемсез, мәңгелек (Аллага карата әйтелгән сүз).
[2] Гофран өчен – кичерү өчен.

# ГОРЯЧЕЕ ДЫХАНИЕ ХОЛОДНЫХ КАМНЕЙ

*Ильдар Муллин*

В ходе комплексной экспедиции Института языка, литературы и искусства Академии наук РТ 2012 года мы посетили следующие населенные пункты Дрожжановского района (перечисление в порядке хронологии посещения): Старое Дрожжаное (Иске Чүпрәле), Старое Какерли (Иске Кәкерле), Татарские Тюки (Татар Төкесе), Мочалей (Мунчәли/Мунчалы), Нижний Каракитан (Түбән Каракитә), Нижнее Чекурское (Түбән Чәке), Старые Чукалы (Иске Чокалы), Старая Задоровка (Иске Задур), Новое Дрожжаное (Яңа Чүпрәле), Шланга, Татарская Бездна (Татар Бизнәсе), Малая Цильна (Кече Чынлы), Большая Цильна (Зур Чынлы) и Старое Шаймурзино (Иске Шәйморза).

В ходе исследования кладбищ (число которых в некоторых поселениях иногда достигало четырех) вышеперечисленных деревень и сёл нам удалось обнаружить 17 эпитафийных памятников, выполненных арабской графикой (см. *Приложение 2*), а также 15 надгробий необычной формы (плоские круглые или овальные камни), которые предположительно представляют собой крупную речную гальку (см. *Приложение 3*). На одном из плоских камней имеется эпитафия, на другом – четко видимая тамга, а остальные надписей не имеют.

Самым древним эпиграфическим памятником в Дрожжановском районе по «Своду памятников археологии Республики Татарстан»[1] считается надгробие, находящееся в 7 км от села Старое Шаймурзино,

[1] Свод памятников археологии Республики Татарстан: в 3 т.: отв. ред. А. Г. Ситдиков, Ф. Ш. Хузин, 2007. Т. 3. 528 с.

у деревни Александровка на месте старого кладбища[1]. Размеры камня 90 × 50 × 20 см, надпись стертая. Свод относит этот памятник к XIV веку. В фундаментальной монографии Д. Г. Мухаметшина, посвященной татарской эпиграфике, также упоминается это надгробие[2].

«Свод памятников» сообщает, что в 0,8 км к западу от деревни Старые Ишли находится старое кладбище «Иски Зират», где имеются надгробные камни[3]. К сожалению, в ходе экспедиции нам не удалось исследовать эти объекты. И никакой иной информации о них, кроме приведенной справки, мы не имеем. И тем не менее общая картина требует учитывать все данные, поэтому мы включили в сводную таблицу по надгробным памятникам Дрожжановского района и сведения столь неполного характера (см. *Приложение 1*).

В указанном труде Д. Г. Мухаметшина упоминается и другое надгробие – «эпитафия, поставленная на могилу Мухаммед Ханафи Усманова в селе Большая Цильня Буинского района (так в тексте. – *И. М.*) Татарстана»[4]. Об этой же эпитафии пишет академик Миркасым Усманов в своей статье «Салкын ташларның кайнар сулышы»[5], посвященной эпиграфическим изысканиям. Мы находим у Д. Г. Мухаметшина упоминание и другого памятника в той же местности[6].

На кладбище, на котором находится надгробие Мухаммеда Ханафи Усманова, мы обнаружили еще три осколка, составлявшие, возможно, единую стелу.

Обнаруженные нами «эпиграфические камни»[7] условно можно разделить на три группы: «классические», «неклассические» и «круглоплоские» (терминология наша. – *И. М.*). Несмотря на

---

[1] Свод памятников археологии Республики Татарстан… С. 187.

[2] Мухаметшин Д. Г. Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. Серия «Археология евразийских степей». Вып. 6. С. 80. (Приложение 1). Однако в книге Старое Шаймурзино относится к Буинскому району – здесь, видимо, имеет место ошибка набора текста.

[3] Свод памятников археологии Республики Татарстан… С. 187.

[4] Мухаметшин Д. Г. Татарские эпиграфические памятники… С. 61.

[5] Госманов М. Салкын ташларның кайнар сулышы // Мирас. 1994. № 5–6 (30–31). С. 54–64.

[6] Мухаметшин Д. Г. Татарские эпиграфические памятники… С. 84.

[7] Крачковская В. А. Эпиграфика Средней Азии // Эпиграфика Востока. Выпуск VII. 1953. С. 45.

недостаточный для статистики материал, прослеживаются определенные сходные черты, которые в первую очередь находят отражение во внешнем оформлении памятников (текстологической стороны не касаемся). Подобная группировка основана на противопоставлении форм камней. Внутри групп мы также можем выделить отдельные таксоны.

Первую категорию составляют так называемые *классические* надгробия, которые в своем внешнем оформлении тяготеют к традиционно сложившейся архитектонике татарской эпиграфики, а точнее, определенному её типу. Последнюю можно обозначить как стелу с полукруглым завершением, при этом тимпан, однако, не всегда соблюдается. Внутри этой группы присутствует в качестве таксона подгруппа надгробий с почти идентичной организацией смысловых областей – это два камня с кладбищ Старого Дрожжаного (1903) и Малой Цильны (1905). Текстовая часть окружена рамкой, следующей за полукруглой формой камня, строки между собой разделены двойной линией. Различие заключается в том, что в первом случае на одном поле умещаются две строки, во втором же – по одной. А также у второго камня присутствует надпись на боковой поверхности. Стилистика, расположение деталей и близость во времени дают нам возможность с осторожностью предположить единого автора.



Малая Цильна



Старое Дрожжаное

Выделение столь малых подгрупп на первый взгляд может показаться излишним, но все же в таких таксонах мы видим маркер, который может быть полезен в дальнейших исследованиях данного региона.

Наряду с простыми надгробиями, которые мы можем отнести к народному искусству, или, сказать точнее, народному примитиву, встречаются и подлинные произведения камнерезного и каллиграфического искусства. Таковым является эпиграфический



Старое Шаймурзино



Большая Цильна

памятник с кладбища Старого Шаймурзино. В нише под полукруглым завершением разместился тимпан, украшенный рельефным письмом. Остальные части врезанного текста помещены в рамки. Легкое кружево арабской вязи в сочетании с тонкими выступающими буквами создают впечатление изысканности. Лаконичность подчеркивается отсутствием надписей на тыльной и боковых сторонах.

Примечательным памятником является надгробие Мухаммеда Ханафи Усманова в Большой Цильне. Две трети тимпана представляют собой нишу, в верхней части присутствует шестиконечная звезда или сильно стилизованная розетка. И с передней, и с тыльной стороны тимпан образует круг. Строки по одной или по две отделены друг от друга врезанными линиями, на обратной стороне весь текст взят в рамку. Боковые поверхности также заняты письменами.

Это надгробие интересно и как исторический источник: «В эпитафии перечисляется большое количество его родственников (21) и то, что его предки прибыли сюда в 1609/10 году со стороны Рязани из Темниково»[1]. И как пишет М. Усманов, заказавшим памятник является родной брат Мухаммеда Хайрулла хаджи – отец татарского писателя Шамиля Усманова.

Группа так называемых *неклассических* памятников представлена тремя стелами различной сохранности (Большая Цильна, Татарские Тюки и Старая Задоровка) с датами 1898, 1917 и 1927 соответственно. По своей архитектонике они практически

[1] Мухаметшин Д. Г. Татарские эпиграфические памятники… С. 61.

идентичны и представляют собой стелы с фигурным завершением, боковые края завершаются полукругом. В совокупности характеристик мы можем их идентифицировать как произведения профессиональных камнерезов, видимо, они имеют городское происхождение.



Татарские Тюки

Следующую группу памятников составляют плоские камни круглой и овальной формы, видимо, местного происхождения (см. *Приложение 3*). К сожалению, в литературе мы не нашли упоминание о них и условно назвали их *круглоплоскими*. На одном из них (Новое Дрожжаное) имеется эпитафия и дата – 1832 г. Текст занимает чуть меньше половины плоскости камня. На другом камне (Татарская Бездна) врезана тамга в форме «U» или «∩». Все остальные камни этой группы, обнаруженные нами, никаких письмен не содержат.



Татарская Бездна



Новое Дрожжаное

*Приложение 1*

## Сводная таблица информации по обнаруженным надгробным памятникам Дрожжановского района Республики Татарстан

| № п/п | Населенный пункт | Основание населенного пункта | Количество | Стиль | Грани с текстом (арабографика) | Измерения (длина/высота/ширина), см | Наличие эпитафии | Указанная или предполагаемая датировка | Источник информации | Время фиксации | Наличие фотоизображения |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1. | Большая Цильна// Бол. Чынлы / Зур Чынлы | с 1674 | 1 | классич. | 4 | 36 × 131 × 14 | + | 1909 | Материалы экспедиции | 2012 | + |
| | | | 1 | (классич.//неклассич.) осколок | 3 | 25 × 28 × 22 | + | ? | | | + |
| | | | 1 | (классич.//неклассич.) осколок | 4 | 24 × 18 × 8 | + | ? | | | + |
| | | | 1 | неклассич. осколок | 4 | 18 × 24 × 11 | + | 1927 | | | + |
| 2. | Малая Цильна / Кече Чынлы | Казанское ханство | 1 | классич. | 3 | 27 × 38 × 10 | + | 1905 | Материалы экспедиции | 2012 | + |

*Продолжение приложения 1*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Нижний Каракитан / Түбән Каракитэ | Казанское ханство | 1 | осколок | 1 | 35 × 43 × 29 | + | ? до 1908 | Материалы экспедиции | 2012 | + |
| | | | 1 | осколок жерновов (?) | – | 36 × 71 × 12 | – | ? до 1908 | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | – | d≈50 | – | ? | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | – | d≈24 | – | ? | | | + |
| 4. | Новое Дрожжаное / Яңа Чүпрәле | Казанское ханство | 1 | круглоплоск. | – | d≈50 | – | ? | Материалы экспедиции | 2012 | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | – | d≈40 | – | ? | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | 1 | d≈60 | + | 18?3(?)2 | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | – | d≈40 | – | ? | | | + |
| 5. | Татарская Бездна / Татар Бизнәсе | Казанское ханство | 1 | классич. осколок | 1 | 21 × 36 × 30 | + | 1878 | Материалы экспедиции | 2012 | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | – | d≈40 | – | ? | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | 1 | d≈30 | + | ? | | | + |
| 6. | Татарские Тюки / Татар Төкесе | Казанское ханство | 1 | неклассич. | 4 | 18 × 76 × 9 (выступ. часть) | + | 1917 | Материалы экспедиции | 2012 | + |

*Продолжение приложения 1*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Старая Задоровка / Иске Задур | Казанское ханство | 1 | неклассич. | 4 | 22 × 71 × 18 (выступ. часть) | + | 1898 | Материалы экспедиции | 2012 | + |
| | | | 1 | классич. | 4 | 32 × 77 × 15 | + | 1892 | | | + |
| 8. | Старое Дрожжаное / Иске Чүпрәле | Казанское ханство | 1 | классич. | 2 | 53 × 35 × 19 | + | 1903 | Материалы экспедиции | 2012 | + |
| 9. | Старое Какерли / Иске Кәкерле | Казанское ханство | 1 | неклассич. | 2 | 30 × 84 × 15 | + | ? | Материалы экспедиции | 2012 | + |
| 10. | Старое Шаймурзино / Иске Шәйморза | Казанское ханство | 1 | ~ классич. | ? | 50 × 90 × 20 | ? | ~ XIV | Свод памятников... Т. 3.; Мухаметшин Д. Г. Татарские эпиграфические памятники... | до 2007 | – |
| | | | 1 | классич. | 1 | 39 × 104 × 16 | + | 1864 | Материалы экспедиции | 2012 | + |
| 11. | Старые Ишли / Иске Ишле | Казанское ханство | ? | ? | ? | ? | ? | ? | Свод памятников... Т. 3. | до 2007 | – |

*Окончание приложения 1*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12. | Старые Чукалы / Иске Чокалы | Казанское ханство | 1 | классич. | 3 | 30 × 101 × 9(11) | + | 1910 | Материалы экспедиции | 2012 | + |
| | | | 1 | ~ классич. | 4 | 18x57x28 | + | 1924 | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | – | d≈28 | – | 1956 | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | – | d≈22 | – | 1989 | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | – | d≈30 | – | ? | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | – | d≈14 | – | ? | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | – | d≈26 | – | ? | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. | – | d≈23 | – | ? | | | + |
| | | | 1 | круглоплоск. осколок | – | d≈18 | – | ? | | | + |

*Приложение 2*

Эпиграфика Дрожжановского района РТ (по материалам экспедиции 2012 г.)*

| № п/п | Местонахождение | Указанная или предполагаемая датировка памятника | Измерения (длина/высота/ширина), см | Шрифт | Грани с текстом | Форма надгробия (стиль) | Изобразительные и семиотические элементы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Большая Цильна // Бол. Чынлы / Зур Чынлы | 1909 | 36 × 131 × 14 | Простой врез. | 4 | Классич. | Полукруглое завершение, круглый тимпан, в верхней части звезда с шестью лучами |
| 2. | Большая Цильна // Бол. Чынлы / Зур Чынлы | ? | 25 × 28 × 22 | Напоминает талик, врез. | 3 | Осколок | |
| 3. | Большая Цильна // Бол. Чынлы / Зур Чынлы | ? | 24 × 18 × 8 | Насх, врез. | 4 | Осколок | |
| 4. | Большая Цильна // Бол. Чынлы / Зур Чынлы | 1927 | 18 × 24 × 11 | Насх, врез. | 4 | Осколок, неклассич. | Фигурное завершение, как п. 10 и 11 |

* Надгробия, содержащие арабографические эпитафии.

*Продолжение приложения 2*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Малая Цильна / Кече Чынлы | 1905 | 27 × 38 × 10 | Талик, врез. | 3 | Классич. | Полукруглое завершение, рамка отделяет поле текста от краев, строки отделены друг от друга двойными рамками |
| 6. | Нижний Каракитан / Түбән Каракитә | ? до 1908 | 35 × 43 × 29 | Простой врез. | 1 | Осколок | Камень треугольной формы, врезные линии напоминают الله |
| 7. | Новое Дрожжаное / Яңа Чүпрәле | 18?3(?)2 | d≈60, h≈16 (выступ.) | Простой врез., | 1 | Кругло-плоская | Текст занимает половину площади выступающей части камня, начало – с даты |
| 8. | Татарская Бездна / Татар Бизнәсе | 1878 | 21 × 36 × 30 | Талик, врез. | 1 | Осколок | Прямоугольная рамка, дата дана вне рамки ниже |
| 9. | Татарская Бездна / Татар Бизнәсе | ? | d≈30, h≈16 (выступ.) | Врез. | 1 | Кругло-плоская | Тамга в форме «U» // «∩» |
| 10. | Татарские Тюки / Татар Төкесе | 1917 | 18 × 76 × 9 (выступ. часть) | Насх, врез. | 4 | Неклассич. | Фигурное завершение, боковые – полукругом, сверху прямоугольное углубление, на двойном постаменте (одна на другой), как в п. 4 и 11 |
| 11. | Старая Задоровка / Иске Задур | 1898 | 22 × 71 × 18 (выступ. часть) | Насх, врез. | 4 | Неклассич. | Как в п. 4 и 10, сферовидное завершение сохранилось |

*Окончание приложения 2*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12. | Старая Задоровка / Иске Задур | 1892 | 32 × 77 × 15 | Насх, рельеф. (с лицев. стороны), врез. с обратной стороны | 4 | Классич. | Полукруглое завершение, рельефное письмо, строки отделены друг от друга и от краев камня рельефной рамкой |
| 13. | Старое Дрожжаное / Иске Чүпрәле | 1903 | 53 × 35 × 19 | Талик, врез. | 2 | Классич. | Как в п. 5, присутствует надпись на боковой стороне |
| 14. | Старое Какерли / Иске Кәкерле | ? | 30 × 84 × 15 | Простой врез. | 2 | Неклассич. | Текст в прямоугольной нише, завершение стилизовано под крышу |
| 15. | Старое Шаймурзино / Иске Шәйморза | 1864 | 39 × 104 × 16 | Талик рельеф. – тимпан, талик врез. – остальная поверхность | 1 | Классич. | |
| 16. | Старые Чукалы / Иске Чокалы | 1910 | 30 × 101 × 9(11) | Простой врез. | 3 | Классич. | |
| 17. | Старые Чукалы / Иске Чокалы | 1924 | 18 × 57 × 28 | Простой врез. | 4 | Классич. | Необычная форма камня: сужается к завершению и обратной стороне, на тимпане – звезда и полумесяц, строки отделены друг от друга врезными линиями |

*Приложение 3*

## Круглоплоские надгробные камни Дрожжановского района РТ (по материалам экспедиции 2012 г.)

| № п/п | Местонахождение | Измерения, см d и h | Примечания |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Нижний Каракитан / Түбән Каракитә | d≈50 | П.1 и 2 относятся к одному погребению; предположительно поставлен над изголовьем усопшего, присутствует постоянно обновляемая кириллическая надпись краской |
| 2. | Нижний Каракитан / Түбән Каракитә | d≈24 | Поставлен предположительно в ногах усопшего |
| 3. | Новое Дрожжаное / Яңа Чүпрәле | d≈50 | |
| 4. | Новое Дрожжаное / Яңа Чүпрәле | d≈40 | |
| 5. | Новое Дрожжаное / Яңа Чүпрәле | d≈52, h≈15 | Присутствует эпитафия в пять строк (видимо, «Аятель-курси»), начинается с даты 18?3(?)2, (?) – напоминает тамгу, текст занимает чуть меньше половины поверхности камня, читается в направлении с центра к краю, шрифт простой, врезанный |
| 6. | Новое Дрожжаное / Яңа Чүпрәле | d≈50 | Видна лишь половина камня, на которой врезано «Яхиевич» (кириллицей) |
| 7. | Татарская Бездна / Татар Бизнәсе | d≈40, h≈20 | На одном кладбище с эпигр. памятником (см. прилож. 2, п. 8) |
| 8. | Татарская Бездна / Татар Бизнәсе | d≈30 | Тамга в форме «U» / «∩» |
| 9. | Старые Чукалы / Иске Чокалы | d≈28 | П. 9 и 10 лежат на одной могиле, дата: 1956 |
| 10. | Старые Чукалы / Иске Чокалы | d≈30 | |

*Окончание приложения 3*

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 11. | Старые Чукалы / Иске Чокалы | d≈30 | Прислонен к столбу, и на столбе, и на камне присутствует кириллическая надпись, на столбе дата: 1903–87/89, и столб, и камень выкрашены в голубой цвет |
| 12. | Старые Чукалы / Иске Чокалы | d≈14 | Половина верхней части камня отсутствует |
| 13. | Старые Чукалы / Иске Чокалы | d≈26 | Камень разломан |
| 14. | Старые Чукалы / Иске Чокалы | d≈23 | Камень разломан |
| 15. | Старые Чукалы / Иске Чокалы | d≈18 | Треть камня отломлена |

## ИЛҺАМЛЫ ЕЛЛАР, ТАБЫШЛЫ ЮЛЛАР

*Айдар Гайнетдинов*

Институтыбызның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Чүпрәле районына караган күп кенә фольклор, музыкаль, археографик материаллар саклана. Алар, нигездә, төрле елларда оештырылган фәнни экспедицияләр вакытында халыктан җыелган.

Чүпрәле якларына Институтның иң беренче фольклор экспедициясе 1945 елда оештырылган, дип санарга мөмкин. Ул турыдан-туры Чүпрәле районына булмый, ә Буа һәм Буденный (Чынлы) районнарына оештырыла. Билгеле булганча, ул вакытта Буденный районының кайбер авыллары хәзерге Чүпрәле районына кергән. 1957 елда Буденный районының биләмәләре Буа һәм Чүпрәле районнарына бүлеп бирелә.

Әлеге экспедициядә Хәмит Ярми, Халидә Гатина, Гомәр Разин (Гомәр Бәширов) катнаша. Аны күренекле галим Хәмит Ярми җитәкли. Фольклорчылар Кече Чынлы авылында барлыгы 2 әкият, 3 бәет, 1 дастан язып алалар. Аннан соң алар хәзер Буа районына кергән авылларда эшлиләр.

Чүпрәле авылларына 1955 елның июнь – июль айларында оештырылган экспедицияне дә күренекле галим Хәмит Ярми җитәкли. Экспедициядә катнашучылар берничә төркемгә бүленеп эшли. Алар Чүпрәле, Тәтеш, Кайбыч, Норлат районнары буенча таралалар. Чүпрәле төбәгенә Миншәех Зәбиров (төркем җитәкчесе) һәм Кәүсәрия Миңнекиева юнәлә. Алар, күп кенә авылларда йөреп, шактый бай фольклор материалларын туплыйлар.

М. Зәбиров һәм К. Миңнекиева сәфәрләрен Татар Саплыгы авылыннан башлыйлар. Биредә халыктан 1 әкият, 4 бәет, 239 кыска җыр, 4 сюжетлы җыр, 4 уен, 186 мәкаль һәм әйтем, 52 табышмак язып алына. Шунысы кызык, Институт хезмәткәрләренә өлкән

яшьтәге кешеләр генә түгел, 15–16 яшьлек егет һәм кызлар да үзләре белгән, олылардан ишеткән, хәтерләрендә йөрткән халык авыз иҗаты әсәрләрен бик теләп сөйлиләр һәм яздырталар.

Киләсе авыл итеп белгечләр олуг галим Шиһабетдин Мәрҗанинең әнисе туган авылы Иске Чокалыны сайлыйлар. Монда исә тагын да мулрак материал җыела: 1 әкият, 1 бәет, 464 кыска җыр, 19 сюжетлы җыр, 8 йола җыры, 26 уен, 31 мәкаль һәм әйтем, 42 табышмак.

Татар Бизнәсе авылында күбрәк йола җырлары, төгәлрәк әйткәндә туй җырлары очрый. Барлыгы 2 сөйләк, 524 кыска җыр, 6 сюжетлы җыр, 46 йола җыры, 6 уен язып алына.

М. Зәбиров һәм К. Миңнекиева, олуг әдип Габделҗаббар Кандалыйның нәсел тамырлары барып тоташкан Югары Каракитә һәм Түбән Каракитә авылларына барып, 8 сөйләк, 297 кыска җыр, 23 уен, 6 мәкаль һәм әйтем туплыйлар.

Аннан соң шулай ук зур шәхесләр биргән Мунчәли авылына барып, барлыгы 289 кыска җыр, 7 сюжетлы җыр, 6 йола җыры, 4 уен, 7 мәкаль һәм әйтем, 21 табышмак язып алалар.

Институт хезмәткәрләре Чүпрәле районында эшләгән иң ахыргы авыл Иске Кәкерле була. Аз гына вакыт эчендә 258 кыска җыр, 4 сюжетлы җыр, 3 уен язып алырга өлгерәләр.

Барлыгы 2 әкият, 10 сөйләк, 5 бәет, 2061 кыска җыр, 40 сюжетлы җыр, 39 йола җыры, 66 уен, 230 мәкаль һәм әйтем, 115 табышмак – ике кеше өчен бу бик югары нәтиҗә булып саналырга хаклы.

Институт хезмәткәрләренә фольклор әсәрләрен тупларга ярдәм иткән бер генә кеше дә онытылмаган – исем-фамилияләре теркәлеп куелган, һәрберсенең сөйләп, җырлап күрсәткән халык авыз иҗаты әсәрләре Институтыбызның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә кадерләп саклана.

1960 нчы елларда Институтта аспирантурада укучы Леонид Арсланов та Чүпрәле районындагы татар сөйләшләрен өйрәнү өчен экспедицияләргә чыга. 80–90 нчы елларда тел белгече Зидә Садыйкова шулай ук бу төбәктә булып, җирле сөйләшләрне өйрәнә. 2000 нче елларда исә тел галимнәре Дария Рамазанова, Флера Баязитова берничә тапкыр Чүпрәленең кайбер авылларына барып, диалектология буенча шактый күп материал җыеп кайталар.

Институт хезмәткәрләренең Чүпрәле районына археографик материаллар җыю өчен әлегәчә чыкканы булмаган иде. Эпиграфик мирасны өйрәнүгә килгәндә, танылган галим Марсель Әхмәтҗановның 1994 елда Кече Чынлы авылы зиратындагы борынгы ташъязмаларны тикшергәнен әйтеп үтәргә кирәк.

Ниһаять, 2012 елның июнь аенда Институт тарафыннан бу төбәккә комплекслы экспедиция оештырылды. Анда фольклор, археография, тел, халык музыкасы һәм сәнгатькә караган материаллар җыелды һәм җентекләп өйрәнелде.

Алда әйтелеп узган барлык материаллар да кыйммәтле мирасыбызның бер өлешен тәшкил итә. Теләгән кешегә бу байлыкны Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә иркенләп өйрәнү мөмкинлеге бар.




Экспедиция дәфтәре. 1955



## Сак белән сок бәете

Әнкәй каргагач, Сак-сок булдык без;
Бу дөньялардин гыйбрәт алдык без.

Бардым урманга Җиләкләр җыешкач;
Әнкәй егълыйдыр Исенә төшкәч;

Төшкәндер безгә Әнкәй каргышы;
Үзебез туганча Тәкъдир язмышы.

Су буйларында Дуңгыз комсышы;
Тын урманнарда Сак-сок тавышы.

Мендем ботакка: Карадым як-якка;
Ике баланы Каргады юкка.

Комач күлмәгем Һичтә кимәдем,
Очып киткәндә Сау-бул димәдем.

Кара бүркемне Алып кайтыгыз,
Әткәйне күргәч, Сәлам әйтегез.

Кара карлыгач, Сайрый сандугач;
Әнкәй, еглама, Үзең каргагач.

Бардым урманга, Җыйдым казлаган;
Без ятимнәрне Әнкәй каргаган.

Чыктым басуга Урак урырга;
Ходай язгандыр Шулай булырга.

Яугыр явдыра Әнкәй башына;
Егылап килдек без, Әнкәй каршына.

Каргыйдыр безне, Газиз әнкәбез;
Якты дөньяны күрми калабыз.

Экспедиция дәфтәреннән бер сәхифә

# ИСКЕ БУЛСА ДА, ИЗГЕ МИРАС

*Рәмил Исламов*
*Салават Галимов*

Чүпрәле районында археографик материаллар җыйнау-туплау максаты белән без дә булдык.

Дөрес, бер караганда, иске китаплар һәм кулъязмалар инде сакланмаганнардыр кебек. Әмма йөри-эзли торгач, сөенечкә күрә, эле хәлнең алай ук кискен түгеллеге ачыклана. Шунысын да әйтергә кирәк, моннан байтак еллар элек материаллар билгеле бер юнәлеш буенча гына җыйналса, инде мәсьәләгә башкача карау зарур. Чөнки хәзер мөмкин булганча бер материал да игътибардан читтә калмаска тиеш. Алга таба соң булуы ихтимал...

Район үзәгенә килгән көнне үк үзәк музейда хезмәт ветераны, язучы-шагыйрь, туган якны өйрәнүче Рафаил ага Субаев белән очрашу булды. Ул безне үзенең эшләре, ирешкән казанышлары белән таныштырды. Соңгы елларда гына аның «Чүпрәле: авыр сынау елларында» (2009), «Чүпрәле: узган еллар, үткән юллар: район тарихыннан очерклар. I т.» (2010), «Чүпрәлем – моң бишегем: антология. II т.» (2010) дигән фактик материалга бай саллы китаплары дөнья күргән. Рафаил ага шулай ук иске китаплар һәм кулъязмалар туплау белән дә шөгыльләнә икән. Аларның кайберләрен безгә дә тапшырды.

Эшебезне Иске Кәкерле авылыннан башладык. Туган якны өйрәнүче Р. С. Субаев мәгълүматына караганда, риваятьләр Кәкерле авылының ханнар заманында (Казан ханлыгы чорында) урыс князьлекләре белән икътисади бәйләнешләре юлында кәрваннар тукталышы һәм элемтә ноктасы буларак барлыкка килүен искәртәләр. Ул чакта бу авыл әлеге урында булмаган. Хәзер Яңа һәм Иске аергычы белән Кәкерле атамасын йөртүче ике авыл бар. Яңа

Кәкерленең әлеге урынына халык XVIII йөздә күчеп урнаша башлаган һәм аларның бабалары Иске Кәкерледә элек Исай елгасы буендарак яшәгәннәр. Чәчүлек җир мәйданнарын Яңа Кәкерледәге нәселдәшләре өчен киңәйтү максатында, иске урыннарыннан күчеп, төньяк-көнбатышкарак чигенгәннәр.

Исай елгасы буенда Казан ханлыгы чорында яшәүче җирле халык арасында төрле кабилә вәкилләре булуы ихтимал. Чөнки бу якларда халыклар күчешен, цивилизация үсешен өйрәнүче галимнәр XVII йөздә монда, татар-мишәрләрне күчерә башлаганчы, буртас, угро-фин кабиләләре яшәвенә игътибар иткәннәр. Татар-мишәрләр күченгәч, җирле кабиләләр йә бу тирәдән кысрыклап чыгарыла, йә ассимиляцияләнә, мәҗүси диннән мөселман диненә күчеп татарлаша.

Кәкерлене яңа урында нигезләүчеләр Пенза өлкәсе һәм Мордва Республикасы аша үтүче Сура елгасы буеннан күчеп килгәннәр, «иске» һәм «яңа» компонентлары, күргәнебезчә, агай-эне аерылышып утырудан килә.

Авылда безне җирле үзидарә рәисе Сәхаутдин Хөсәенов каршы алды. Ул безне урта мәктәп директоры Наил Исхаков белән таныштыргач, мәсьәләне уртага салып сөйләштек.

Авыл бик зур. Әйтүләренә караганда, элек анда унлап җил тегермәне генә булган. Биредәге халыкның ихласлыгы, һәрдаим ярдәм кулы сузарга әзер булуы эшне башкаруда уңай роль уйнады.

Нәфисә апа Кәримова яшәгән өйнең чормасында тактадан яхшы итеп эшләнгән әрҗәдә имам Абделкадыйр Кәримов китаплары сакланган икән. Хуҗабикә башта сагаебрак калса да, мәсьәләне аңлатып биргәч, шатланып, аларны безгә тапшырды.

Аннан соң Роза апа белән Хәбир ага Кәримовларга юнәлдек. Алардан гарәп һәм татар телендә төрле эчтәлектәге кульязма китаплар алдык.

Авылның Нурфасих мәчете имамы Латыйф мулланың өендә хәзерге вакытта яшәүче юк икән. Инде тәрәзә пыялалары да ватыла башлаган... Фиргать ага Камалтдинов ярдәме белән аннан агачтан эшләнгән ике чемодан китап алдык. Әйтергә кирәк, сакланышлары бик яхшы.

Гомумән, Иске Кәкерле авылыннан табылган материаллар арасында басма «Гайнел-гыйлем тәрҗемәсе», «Алты бармак», «Коръән» һәм төрле эчтәлектәге кульязма китаплар бар.

Мунчәли авылында да безне якты йөз белән каршыладылар. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, авыл Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. Авылның төзелә башлавына, атамасының этимологиясенә нисбәтле төрле риваятьләр сакланган. Мондагы картлар сөйләвенә игътибар итсәң, авылга 350–380 еллар дип фикерләп була. Айметов Зиатдин һәм Абулханов Усман бабайлар исән чакта сөйләп калдырганнар: «Алатыр ягыннан (элекке Курмыш өязеннән) Иске Мунчәли дигән авылдан өч кеше күчеп килгән. Шуларның берсе мукшы милләтеннән булган, диләр. Шуннан авылның бер очында мукшылар нәселе яшәгән. Мукшының исеме Сабай булган, имеш. Ул тора-бара татарлашкан. Субаев фамилиясе бу авылда шуннан килә». Хәзер бу авылда мондый фамилияле кешеләр калмаган инде. Килүчеләрнең берсе Бухари, икенчесе Шаһвәли исемле булган, имеш. Мунчәли башта хәзерге урынында булмаган. Ул Шлангага якынрак – төньяк-көнбатыштарак булган. Ул урынны хәзер «Паварь тирәсе» дип йөртәләр.

Мунчәлидә әүвәл имам Насих Садыйков белән күрешеп, мәчеткә бардык. Бу изге йорт аның беренче имамы Абдулла Измайлов исемен йөртә. Гадәт буенча, халык үзләрендә сакланган иске китапларны, кульязмаларны шунда тапшыра икән. Алар арасында Коръән тәфсире, «Мәҗмугыл-ләтаиф», «Мохтасар әл-Кодури», «Китаб мифтахет-тәварих» кебек кызыклы басмалар бар.

Түбән Каракитә авылы көньяктан Ульяновск өлкәсенең Сурск районындагы Чилим авылы белән, көнбатыштан Чувашстанның Шомыршы районындагы Бичурга-Баеш авылы белән чикләшә. Төньякта матур, тигез кыр-болыннар, көнчыгышта – Бизнә таулары. Көнбатыш якта Шамкино авылы һәм Югары Каракитә җирләре арасыннан сазлык эченнән Инеш суы ага. Мунчәли ягына таба сузылган урыннарда кеше үтә алмаслык сазлыклар булган. Ул тирәдә бер метр җир катламы астында әле дә торф ятмалары бар.

Каракитә атамасының килеп чыгышы бәхәсләр уята. Авыл аксакаллары аны сүз охшатуга әйләндереп, болай дип сөйлиләр: «Авылга беренче килүчеләр торак урыннарын, урман эчендә бәләкәй алан табып, шунда төзи башлыйлар. Еллар үтү белән тирә-яктагы урманнар киселеп, чәчүлек мәйданнарга әверелдерелә. Бу авылда чуашлар һәм татарлар яшәгән, ул озак вакыт исемсез булып торган. Менә авылга ике юлчы урыс килеп чыга. Алар шундагы крәстияннардан: «Бу нинди авыл?» – дип сораганнар, күрәсең,

ә аларның телен аңламаган кешеләр ни әйтергә белмичә, үзара сөйләшәләр: «Карап китүчеләрдер болар?». Шуннан бу урыслар, әлеге авылны исәпкә алганда, аны «Каракитә» дип яздырганнар, имеш.

Түбән Каракитә авылына килгәч, башта мәктәпнең тарих укытучысы Ринат Сирачев белән таныштык. Ул безне мәчеткә алып барып, имам Фәрдар ага Хөсәенов белән күрештерде. Фәрдар ага да авылдагы иске китапларны мәчеткә туплауны җайга салган. Ул, мәсьәләне яхшы белгән кеше буларак, безгә байтак материаллар бирде. Аерым алганда, алар «Китаб әнмүзәҗ», «Мөхәммәдия», «Шәрхел-фәраизес-сираҗия», «Әл-һәдия», шәкерт дәфтәре һәм кулъязма документлар.

Һәр авылның килеп чыгу тарихы, һәр авылга гына хас булган табигать үзенчәлекләре һәм гореф-гадәтләре бар. Чүпрәле районы Зур Чынлы авылы без йөргән башка авыллардан бу яктан бигрәк тә аерылып тора. Бер яктан куе урманнар белән капланган, икенче яктан Чынлы елгасына чиктәш булган бу җирләр, күрәсең, Ярамай Чынлысына (соңрак Зур Чынлы дип йөртелә башлый) нигез салучы бабаларны бу тирәнең табигате һәм уңайлы географик урыны җәлеп иткәндер. Без кульязма китаплар эзләп кергән авыл мәчете имамы Габделбарис ага Хәйрулла да сүзне тарихтан башлады. Мосафир буларак табынга чакырып, өстәл янында ул авылга бәйле кызыклы мәгълүмат белән таныштырды. Аннан соң ул Римма Фәхретдинованың Зур Чынлы тарихына багышланган китабын бүләк итте. Әйтергә кирәк, бу туган якны өйрәнү өчен кыйммәтле чыганакларның берсе булып тора: анда авылның килеп чыгышы, мәчетләр тарихы, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, авылда туып-үскән билгеле шәхесләр, шәҗәрәләр һ. б. киң чагылыш тапкан.

Мәчеткә килеп кергәч, анда гарәп телен өйрәнергә килгән балаларны күрү безне тагын да сөендерде. Габделбарис ага безгә ике төргәк китап тапшырды. Алар арасында яхшы сакланган басма «Алты бармак», «Китаб һәдия әс-сөгълек шәрхе төхфәтә әл-мөлек», Коръән һ. б. бар иде.

Вакыт чикле булуга карамастан, Татар Бизнәсе авылына да барып чыктык. Ул Бизнә елгасы буенда, Иске Чүпрәледән ун чакрым көнбатышта урнашкан; чыганаклардан күренгәнчә, аның Казан ханлыгы чорыннан ук булуы билгеле.

Анда без мәчетнең имамы Гомәр ага Сафин белән күрешеп сөйләштек, басма бер Коръән һәм тәфсир алдык.

Барлыгы алтмыш сигез берәмлек материал алып кайтылды. Алар барысы да чистартылып, исемлекләре төзелеп саклану урынына куелды.

Экспедициянең уңышлы башкарылуында зур ярдәм һәм теләктәшлек күрсәткәннәре өчен район хакимияте җитәкчелегенә, җирле үзидарә рәисләренә, мәктәп директорларына, укытучыларга, гомумән, без булган авыллардагы барлык халыкка да ихлас рәхмәтләребезне белдерәбез.



«Гакаид ән-Нәсәфи» (гарәп телендә), Каракитә авылыннан Р. Ф. Исламов алып кайтты



Төрле дини китапларның татар теленә тәрҗемәсе, Каракитә авылыннан
Р. Ф. Исламов алып кайтты



Гыйлем алу өстенлекләре турында язылган китап (гарәп телендә), Каракитә авылыннан
Р. Ф. Исламов алып кайтты

## МУНЧӘЛИЕМ, ГАЗИЗЕМ

*Нурмөхәммәт Хисамов*

Без үскәндә Мунчәли бик зур авыл иде. «Биш йөз йорт» дип сөйләгәннәре колакка керә иде. Җидееллык мәктәптә дә биш йөз бала укыдык. Авыл элек волость үзәге саналган. Чүпрәле районының 20–30 нчы еллардагы зыялылары Мунчәлидә укып чыккан кешеләр иде. Шундыйларның берсе Зариф Вәлиевич Вәлиев байтак еллар районның «Коммунар» гәзитендә мөхәррир булып эшләде, аннары атаклы Чүпрәле урта мәктәбенең директоры булды. Каракитәдән килеп укыган Шәрәф Мөдәррис, Төкедән килеп укыган Зәки Нури соңрак татар шигъриятенең күренекле шагыйрьләре булып киттеләр.

Мунчәли җидееллык мәктәбе үз заманында республиканың дүрт җидееллык мәктәбенең берсе булган. Мин Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре буларак, авылның килеп чыгышына кагылышлы мәгълүматлар җыеп йөргәндә, өлкән агайларга: «Мунчәли кайдан килеп чыккан?» – дигән сорау белән мөрәҗәгать иткән идем. Фатыйх абзый Таһиров: «Авылга, беренче булып, Нижгар ягыннан Мунчәли бабай килеп утырган», – диде. Соңрак Сергач төбәгендә, чыннан да, Мунчәли авылы барлыгын белдем. Шул исемдәге авыл Пенза өлкәсендә дә бар икән.

Узган гасыр башында (сүз XX гасыр турында бара) һәм Октябрь инкыйлабыннан соң авылда 700 дән артык йорт исәпләнгән. Мунчәлинең Шылаңка очыннан Бизнә очына кадәрге ара өч чакрымга сузыла иде. Авылның иң зур урамы Кычавыл дип атала иде. Ягъни аны Кече авыл дип санаганнар.

Табигый тирәлек бик үзенчәлекле һәм матур иде. Шылаңкага чыгып китә торган урамны Добрау дип атыйлар. Чөнки шуннан

уңга таба үргә күтәрелгән җирдә бик сусыл имәнлек шаулап утыра иде. Урамга русча «Дубрава»дан «Добрау» дип кушканнар. Авыл кешеләре, балалар әбиләренә барганда «Добрауга барам әле» дип сөйлиләр иде. Урам инде сирәгәеп калса да, әле дә шулай сөйлиләр.

Табигый тирәлек дигәннән, элекке имәнлек урынында яшь наратлык тирә-якка сагыз исе таратып утыра. Ә аның артында имән, чикләвек куакларыннан гыйбарәт катнаш агачлык китә. Авылдан 1–1,5 чакрымда Шыланҗка белән ике арада таллык бар иде. Калынрак талларны авыл халкы утынга кисте, ә яшьрәк пеше тал чыбыкларын кәрзингә кисәләр иде. Советлар Союзы герое Нурулла Фазлаевның әтисе Ариф бабай кәрзин, чуман үрү остасы буларак, бөтен тирә-як авылларны кәрзин белән тәэмин итеп торды. Яз башы җиттеме, чанасына тау чаклы каз чуманы өеп, бер чакрымдагы Матак базарына алып чыга. Авыл аша мул сулы инеш ага, бик күп кеше каз асрый иде. Көзге айларда булса, иптәшләр белән олыларга ияреп, мин дә кәрзин үрергә чыга идем. Бер-беребездән күреп, бу һөнәргә тиз өйрәнәбез. Яшь талчыбыкларны өйгә дә күтәреп кайтабыз. Кәрзин үргәндә бөтен өй талчыбык исе белән тула.

Таллык аланнарында мул булып сусыл үлән үсә, Добрау халкы печәнне шуннан чабып ташый иде. Авылдан 1–2 чакрымда зур урман башлана. Ылыслы, яфраклы урман. Ул Алатыр урманнарына барып җитә, аннан тайгага хәтле сузыла. Урман кырыеннан ерак түгел бик борынгы канау китә. Аны инде күптән чирәм баскан. Ул урыннарны «Кырым чиге» дип атыйлар. Казан ханлыгы белән Кырым ханлыгы арасындагы чик, димәк, шуннан үткән.

Мин инде Казан университеты студенты булгач, Шәрәф Мөдәррис «Татарстан яшьләре»ндә басылган шигырьләремә язган сүз башын «Атаклы Алатыр урманнары белән Ульяновск далалары килеп кушылган җирдә Мунчәли дигән авыл бар», – дип башлаган иде.

Авылда мәдәни тормыш гөрләп барды. Мәктәп зур, ятим балалар йорты бар. Укытучылар һәм детдом тәрбиячеләре авылның зур клубында спектакль куя. Халык, күңеле нечкәреп, елап утыра. Рәшит Ваһаповлар килеп концерт куйганы хәтеремдә. Республика сәхнәсенең атаклы солисты Венера Шәрипованың тамырлары Мунчәлидә. Камал театрының гүзәл актрисасы Алсу Гайнуллина да Мунчәлидә үскән кыз. Аның әтисе Әскәр ага Гайнуллин байтак еллар Мунчәлидә колхоз рәисе булып торды. Бүгенге сәхнәбезнең

зифа буйлы, гүзәл тавышлы җырчысы Алсу Әбелханова да Мунчәлидә үскән кыз.

Колхоз дигәннән, ул башта «Партизан» колхозы дип атала иде. Авыл кешесе Шакир абзый Салихов гражданнар сугышы чорында урманга китеп, партизанлык итеп йөргән. Мунчәлинең мәчет манараларын, райондагы чиркәү манараларын кисеп, «батырлыклар» күрсәткән кеше иде. Колхоз исеме аның хөрмәтенә шулай аталган.

Сугыштан соң колхозның даны дөнья шаулаткан еллар да булып алды. Авылга Иске Кәкерледән Шакир ага Кочетковны рәис итеп китерделәр. Ялкынлы кеше иде. Кырыс холыклы. Колхозны ныгытты, халыкны оештырды. Мул уңыш алынды, хезмәт көненә беркайчан булмаганча күп ашлык бирелде. Халык бодай коймагы ашый башлады. Алма бакчасы утыртылды. Мин әле кечкенә булган булсам да, яхшы хәтерлим: колхоз умартачысы әтием оештырды бакча утыртуны. «Партизан» колхозы барлык күрсәткечләр буенча Чүпрәле районында беренче урынга чыкты. Сабан туе ярышында Мунчәли аты беренче килде, аның алмачуар тае искиткеч матур иде, кушаматы «Кролик». Мин дә аңа атланып, Мунчәли болыннарын иңләп алдым. Ләкин Шакир абзабызны озакламый башка колхозны күтәрү өчен күчерделәр. Халык елап калды. Кочетков үзе дә Мунчәли халкыннан канәгать китте. «Бу халык белән эшләп була», – дип киткән.

Мунчәли халкын бик үзенчәлекле халык дияр идем мин. Авыл байтак еллар волость үзәге булгач, мәктәп-мәдрәсә системасы ныклы нигездә торган. Шактый заман авылда минем әбием Сабира абыстай мөгаллимәлек иткән. Ул үзенең алты почмаклы өендә көн саен кырыгар шәкерт укыткан. Чыра яктысында укыганлыктан, күзләре иртә сукырайган. Әтиемнең истәлек язуларында теркәлеп калган сүзләрне укыганда аркамнан суыклар йөгерде. Әбиебез: «Мин сукырайсам да үкенмим, чөнки күзләремне халкыма багышладым», – дигән. Шунысы акылга сыймас дәрәҗәдә гаҗәп: бу сүзләрне XIX йөз азагында татар авылының бер хатын-кызы әйткән!

Әбиебезнең шәкертләре бик укымышлы булып үскәннәр. Мәрхүм Фатих абзый Хәмзин Сабира абыстайдан белем алган этисе Нури абзыйның волость идарәсенә кереп, рус чиновниклары белән Библия темаларына бәхәсләр алып баруын сөйләгән иде. Нури абзый исә совет чорында Буада өяз комиссары булган.

Укымышлылык һәм мәктәп традициясенең ныклы булуы күп еллар дәвамында укыту дәрәҗәсенең югары саклануында чагылган. Мин моны үзем укыган еллар мисалында ышанып әйтә алам. Безнең буынның бәхетенә Мунчәли җидееллык мәктәбендә бөек педагоглар плеядасы эшләде. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фәтхи ага Әхмеров үзе генә дә ни тора! Ул мәктәпнең директоры иде. Рус теленнән Хәлил абый Хәмидуллин укытты, тарихтан һәм географиядән Шәмсеруй апа Якупова, соңрак – Нургали абый Нәзиров, математикадан Һадия апа Хәлилова, физикадан Солтан абый Сөләйманов укытты.

Мунчәлидә рәссамлык культы да сизелерлек көчле булды. Детдом укытучыларыннан Кыям абый Ишуков Ленин, Сталин портретларын, зур форматлы киндергә эшләп, клуб сәхнәсенә элеп куйган иде. Детдом балалары арасында да оста рәсемчеләр бар иде. Мин дә кечкенәдән рәсемгә тартылдым. Рәсем дәрте улларыма да күчте. Игезәк улларым Айдар белән Нияз рәсем училищесен, Ленинградта Сынлы сәнгать академиясен һәм Казанда Харис Якупов җитәкчелегендә аспирантура тәмамлады. Хәзер профессиональ рәссамнар. Нияз Германиядә яшәп иҗат итә. Алар иҗат иткән рәсемнәр Америкада, Япониядә, Скандинавия илләрендә бар. Франция һәм Германия каталогларына кертелгән. Мунчәлидә шагыйрьлек традициясе дә өзелми. Бүгенге шигъри барышта үзенә хас стиле булган үзенчәлекле шагыйрь Рәмис Аймәт иҗат итә, үсә. Ул – мәрхүм Кыям абый Аймәтов улы. Казандагы Тукай музее директоры булды, Хәзер Язучылар берлегендә рәис урынбасары.

Мунчәли халкы дигәннән, аның кешелек йөзен, гыйльми, рухани затын гәүдәләндергән кызыклы шәхесләрен атап күрсәтәсе килә. Минем күз алдында яшәп, дөньядан кичкән Атаулла бабайны телгә алмыйча мөмкин түгел. Ул тирән белемле, киң карашлы энциклопедист аксакал иде. Аның өе китаплар, гәзит-журналлар белән тулы булды. Олы кызы Хәдичә апа укытучы, бер улы Абдуллаҗан Химия-технология институтында доцент, декан урынбасары иде.

Атаулла бабай минем әти уздырган мәҗлесләрнең түрендә булды. Шушындый мөгътәбәр картларның халыкара сәясәт турындагы әңгәмәләрен тыңлау кызык иде. Әйтик, ике Германияне берләштерү өчен җыелган Берлин киңәшмәсе хакында әңгәмә бара. Әтием Шаһвәли, почтальон Насыр бабай, Атаулла бабай бер-берсен тулыландыра-тулыландыра сөйләшәләр, мәҗлес халкы игътибар

белән тыңлап утыра. Киңәшмәдә катнашучыларның позициясенә гаҗәпләнәләр. Бөек державаларда килешү кирәклеген аңлау бар, дип саныйлар. Ә ике Германиянең, алманнарның килешүдән ерак торуына сәерсенәләр. Шундый җанлы итеп, белеп фикер алышалар, әйтерсең, вакыйга авылдагы күршеләрендә бара!

Авылның рухани тормышында мөһим роль уйнаган Шакирҗан абзый Әхмәтов бар иде. Аны авылда мулла дип йөрттеләр. Аның белән сөйләшеп утырулары кызык иде. Әнинең җеназасында искиткеч матур тавыш белән Коръән укыды. Минем игътибарымны аның гарәп сүзләрен дөрес әйтеп укуы җәлеп итте. Ул «мөэминин»не гади халыкча түгел, ә саф гарәпчә «муэминин» дип укый. «Кайдан болай өйрәндең?» – дип сорадым. «Алимҗан мулладан», – диде. Алимҗан мулла чыннан да мәһабәт зат, тирән укымышлы хәзрәт иде. Аңардан соң Мунчәлидә озак еллар әтием Шаһвәли имамлык итте, аннары Шаһи абзый Мусин имам булды. Аны Шакирҗан абзыйдәвам итте. Без аңа «җизни» дия идек, чөнки ул әтиебезнең агасы Габдерахман абзыйның кияве. Ягъни Хәйрелбанат апабызның ире.

Шакирҗан җизнинең матур тавышы дигәннән, аларның бөтен гаиләсе матур җырчылар һәм гармунчылар иде. Хәбир абый, Габдери, Шаһиҗан абзый шундыйлардан булды. Аларның барысы да Төхфәт бабай уллары. Шакирҗан абзыйның улы, артист кыяфәтле Раил дә бик оста баянчы.

Авылның рухани тормышында бик зур рольне безнең әтиебез Шаһвәли уйнады. Ул төрле яклап гыйлемле һәм бөтен тирә-якта хөрмәтле шәхес иде. Аның киштәләре күн төпләмле китаплар белән тулы. Ислам тарихын, төркиләр һәм Европа тарихын тирән белә. Тукайны, төрек әдәбиятын, Пушкинны, Толстойны, Шекспирне, Мольерны яхшы белә иде. «Йосыф китабы»н әбиебез Сабира абыстайдан отып калган озын һәм моңлы көйгә тулысынча яттан укый. Бөтен тирә-якта мәшһүр умартачы. Укымышлы авыл карчыклары аның янына ерак урамнардан үзләренең Коръән укуын дөресләр өчен киләләр иде. Мин хәзер уйлыйм, уйлыйм да шуны төшенәм: алар тансыкка бал белән чәй эчәр өчен дә килгәннәр булырга тиеш.

Әтиемнең яшьлек гомере Тифлистә (Тбилиси) узган. Ул Кавказның генерал-губернаторында тәрҗемәче һәм дипкурьер булып эшләгән. Соңрак Лена вакыйгаларында катнаша (1912 ел). Әзәрбәйҗанча, грузинча, якутча, чуашча иркен сөйләшә иде. Гарәпне,

фарсыны, рус телен яхшы белә иде. Авыл халкы аны ихтирам итте. Күмгәндә зират тирәсе Сабан туе чаклы халык булды. Хәтта күрше авыллардан да килделәр. Аның кызыклары һаман халык телендә.

Тарихи авылның зурлыгын мәчетләр саны да күрсәтә. Мунчәлидә революциягә кадәр дүрт мәчет булган. Добрау мәчетен минем бабам Хисаметдин Кавказ мөселманнарыннан иганә җыеп салган булган. Үзе үк анда азанчы булган. 30 нчы елларда аның манарасын большевиклар кушуы буенча «партизан» Шакир кискән. Илдәге үзгәртеп кору һәм Республикабызда суверенитет шартларында Мунчәлидә мәчет салу хәрәкәте киң колач җәйде. Авыл халкының сәдака акчасына, Республика прокуроры Сәйфихан Нәфиев, Тәтештә урман хуҗалыгын җитәкләүче Ирфан Халитовның, Зәйнәп апамның Ульяндагы улы Расыйхның һәм Бөгелмәдәге улы Рифкать Мәхмүтовның, күпсанлы бүтән энтузиастларның матди ярдәме белән авыл уртасында мәһабәт мәчет калкып чыкты. Аның ачылу тантанасына, Татарстан мөфтиенең ул вакыттагы беренче урынбасары Госман хәзрәт Исхакый белән икәүләп, без дә кайттык. Манарадан изге азан яңгырады, хәзрәтләр өйлә намазын оештырдылар, авылда иман яңарды.

Күп еллар дәвамында район сабан туйларында Мунчәли данын атаклы көрәшче, мәһабәт сынлы Гыйльман абый Таҗиев тотып торды. Мунчәли элек-электән көрәшчеләр авылы булган, дип сөйлиләр. XIX гасырда әтиемнең бабасы Нәзир мулла өяз Сабан туенда батыр калгач, Буаның иң зур бае, аңа бүләк итеп, үзенең бик матур кызын кияүгә биреп җибәргән. Һәм, әйтергә кирәк, безнең нәселдән көчле көрәшчеләр бу заманда да үсә торды. Фәтанәт апамның улы прокурор Сәйфихан да, олы апам Хәлидә улы Фарук та бер сабантуйда дә җиңдермәделәр. Шунысы кызык: сәгатьләр буе көрәшсәләр дә, алар бер-берсен ега алмады.

Авылның мондый данын һәм күркәм традицияләрен югалтмаска иде.

Кыскасы, Мунчәлинең биш гасырдан артык тарихы кызыклы вакыйгаларга, колоритлы шәхесләргә бай булган. Мунчәли – ул минем йөрәк тибешем.

# ТАРИХЫ БУЛГАН АВЫЛНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ БАР

*Рафаил Субаев*

**Алешкин-Саплык** – Иске Чүпрәледән төньяк-көнчыгышка таба 6 чакрым ераклыкта урнашкан авыл.

Бу авылга беренче килүче кеше, имеш, Алеш исемле булган. Ул монда Чүпрәледән 1,5 чакрым тирәсендә төньяк-көнчыгышка урнашкан торак урыннан XVIII йөзнең икенче чирегендә күчеп килгән, дип исәплиләр.

Алешның өс киемнәре бик тә ямаулыклар белән сипләнгән булган, диләр. Чуаш телендә ямаулыкны «саплак» дип атаганга, бу кеше бүтән авылларга барып чыккач, аңа «Алеша-саплак» дип кушамат такканнар һәм ул яшәгән авыл да шул нигездә барлыкка килгән, диләр. Бу фаразлауны танылган галим Г. Ф. Саттаров та яклый. Кайбер риваятьләрдә «саплык» сүзенең бу тирәдәге вак куаклыкларга бәйләп, янәсе, көрәк, себерке саплыгына яраклык материалдан; икенчеләре, Татар Саплыгы авылын һәм кайчандыр анда нугайлар яшәвен исәпкә алып, «саплык» сүзенең алар телендә бодай икмәген аңлатуына бәйлиләр.

Алештан соң бу тирәгә аның туганнары күчеп килгән. 1795 елдагы ревизия кенәгәсенә караганда, авылда 38 йорт исәпләнгән. Анда 110 ир заты булган. Ул чорда хатын-кызлар ревизия исәбенә кертелмәгән, шуңа аларның күпме булуын фаразларга гына кала. Һәрхәлдә, хатын-кызсыз йорт булмагандыр.

1811 елда үткәрелгән ревизия (УДА, ф. 156, опись 2, ед. хр. 37) бу авылда 40 йорт булуын ачыклый. Ирләр 105 кә калган. Ә 1816 елда (ф. 156, оп. 2, ед. хр. 90) йортлар саны 44 кә җитеп, анда яшәүчеләр ике җенестән 216 кеше күрсәтелгән. 1834 елда – 42 гаиләдә 216 кеше булган (ед. хр. 151).

1858 елда йортлар 33 кә калган, ә халык саны 279 дип күрсәтелгән.

1911 елда Сембер губернасының Буа өязе Уби волостена кергән бу авылда 123 гаилә яшәгән. Анда 711 кеше булып, шуларның 360 ы – ирләр, 351 хатын-кыз исәпләнгән.

1903 елда авылда чиркәү-мәхәллә мәктәбе ачылган. Беренче укытучы булып Василий Степанович Дементьев эшләгән. Ул СССР авиация министры Петр Васильевич Дементьевның әтисе. Әлеге мәктәптә утызынчы еллар ахырында булачак Советлар Союзы Герое П. С. Юхвитов та укыткан. Анда укып, башлангыч белем алучыларның берсе – Мирза Хәбир улы Гафаров – юстиция полковнигы дәрәҗәсенә ирешә.

Алешкин-Саплык авылында туып, илебезнең төрле почмакларында яшәп һәм хезмәт итеп дан казанган кешеләр арасында Бөтенроссия информация институтының өлкән фәнни хезмәткәре П. Г. Филиппов (1923), СССРның Төзелеш министрлыгында хезмәт иткән И. Г. Сябуков (1937), Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты разведчигы И. Е. Кузнецов (1935–1999), Чувашиянең атказанган артисты П. А. Алексеев (1955), «Хыпар» газетасы журналисты И. Ф. Клементьев (1947), «Капкан» журналы хезмәткәре, журналист В. М. Палинов (1936) кебек күренекле кешеләр бар.

Алешкин-Саплык белән бер тирәдә Татар Саплыгы, Иске һәм Яңа Задур, Иске һәм Яңа Дуван авыллары да урнашкан.

*Дуван* атамасы белән безнең төбәктә өч авыл: Иске Дуван, Яңа Дуван, Рус Дуваны булуы билгеле. Рус Дуванында, 1859 елгы мәгълүматлардан чыгып караганда (Симбирская губерния. Список населенных мест по сведениям 1859 г. СПб., 1963. С. 39), 10 йорт булган, 1897 елгы исәптә (Список населенных мест Симбирской губернии. Симбирск, 1897. С. 41) – 20 йорт, 1930 елда (Список сельсоветов и населенных пунктов по районам ТАССР. Казань, 1930. С, 21) анда 188 кеше яшәве билгеле. Авыл сугыштан соң тәмам таркалды.

Иске Дуванда чуашлар яши, ул Казан ханлыгы чорында ук төзелә башлаган. Яңа Дуван – татар авылы. Бу авыл XVIII гасырда барлыкка килә. Шушы ике авыл арасында аерым чикләр юк. Патша хөкүмәтенең христианлаштыру сәясәте чорында – XVIII гасыр ахырында – бу авыллар христиан динен кабул иткән булган. Ләкин татар ягы XX йөз башында яңадан мөселман диненә күчкән һәм

аларны «яңа мөселманнар» дип атап йөртәләр. Татарларның чуашлар белән катнаш гаиләләр төзеп, үзара туганлык элемтәсендә яшәү очраклары шактый.

Бу авылда яшәүче мишәрләр бирегә XVII йөздә күчеп килгән булырга тиеш.

«Симбирская губерния, по сведениям 1859 года» исемле хезмәткә сүз башында А. Артемьев «Важнейшие из таких памятников древности (сүз казылган базлар, ныгытмалар турында бара – *Р. С.*) находятся в уезде Буинском – у селений Дуваново, Бездны, Чепкасово, считающиеся местными жителями за развалины особого татарского владения», – дип язган. Чынлы елгасы буена урнашкан бу авылның табигате – каенлык, күлләр, тигез кырлар – һичшиксез, кешеләрне җәлеп иткән булырга тиеш. Бу төбәктә авыллар бик еш урнашкан, аралары 1–2 чакрым гына исәпләнә һәм алар үзара бик тату яшиләр. Әлеге Дуван авылын чуашлар үзләре «Таван ял», ягъни «Туган авыл», дип атап йөртәләр. «Таван» атамасы белән Чувашиядә дә торак пункт бар. Җирле халык авыл атамасының нигезендә шушы туганлык, иркәләү сүзен күрә. Бу, әлбәттә, бик өстә яткан караш. Бары тик сүзләргә охшатып кына авыл атамалары турында фикер йөртү үзен аклап бетерми. Атамалар тикмәгә генә барелмәве турында уйласаң, тирәнрәк, ераграк катламнарга игътибар юнәлтү лязем.

Г. Ф. Саттаров бу атаманың кабилә исеме белән мөнәсәбәттә булуын күрсәтә. Әлеге исемдәге кыпчак кабиләләре һәм ыруглары башкортлар составына барып кушылганнар.

Мондый атамаларның Башкортстанда, Киров өлкәсендә, Чувашиядә дә булуы «дуван» (Кузеев Р. Г. Происхождения башкирского народа. М.: Наука, 1974. С. 118) кабиләләренең этногенезы белән мөнәсәбәтлелеккә дәлил булып тора.

«В Дрожжановском районе ТАССР есть чувашское село Старое Дуваново (Иске Дуван) и татарская деревня Новое Дуваново (Яңа Дуван). Безусловно, из них первичным является название чувашского села, которое, по всей вероятности, восходит к одному из башкирских родовых наименование *дуан* (дуван)», – дип яза Г. Саттаров (Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики. Казань, 1970. С. 43). Ул Казан ханлыгы чорында XV йөз урталарында башкорт кабиләләренең татарлар белән берлектә булуын һәм Казанны урыслардан саклау өчен бу якларга килеп

чыгуларын күрсәткән тарихи материалларга таянып, шушы нәтиҗәгә килгән.

Дуванлылар якташлары, гражданнар сугышы герое комиссар П. Е. Крепков, шагыйрь С. С. Сорокин (Таваньялсем Серкей) (1886–1957), чуаш язучысы Васса Анисса, халыкара танылган галим Р. Г. Ильязов белән дә горурланалар.

* * *

Задур исемле авыллар Иске һәм Яңа аергычлары белән билгеле. Көнбатыш диалектта «задур» сүзе – «чая», «кыю» мәгънәсен аңлата. Ул урыс теле аша кергән.

В. К. Магницкий «Список селений «мишарей» в Буинском уезде Симбирской губернии» исемле мәкаләсендә бу хакта болай дип күрсәтә: «Задурка, чув. сатурка (сатур /чув/ – проворный)» (Известия общества археологии, истории и этнографии. Т. XVII. Вып. 2, 3. Казань, 1901. С. 130).

Билгеле булганча, Болгар дәүләтен монголлар басып алгач, аның шактый халкы кысрыкланып, яшәү өчен ераккарак китеп, урын эзли башлый. Хәзерге Иске Задур урнашкан җир ул чорда күлләр, урманнарга шактый бай урын булып, качып килүчеләр күңеленә хуш килгәндер, дип исәпләнә. Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, монда элекке Болгар ханлыгы үзәгендәрәк яшәүче кабан, шөкран һәм нугай ыруыннан булган өч гаилә вәкилләре килеп нигез кора. Бу тирәдәге җирле халык – чуашлар: «Мен тусса килдени?» – дип сорагач, «Заи ри», – дип җавап биргәннәр имеш. Гарәпчә «заир» – «күрергә», «хәл белергә килү» мәгънәсен аңлата. Күрәсең, бу кешеләрнең исәбе «хәл белү, күрү» генә булгандыр. Әмма, урынны ошатканлыктан, шунда яшәп калганнар, имеш. Шулай итеп, бу авылның атамасын тирә-як авыллардагы чуашлар «заир» сүзенә охшаш яңгырашлы «задурга» әверелдергәннәрдер.

Якташыбыз галим Әхмәт Булатов бу авылда «Нугай очы» дип аталган урам барлыгын искә алып, аның мондагы мишәр авылларына караганда борынгырак булуын искәртә. Һәрхәлдә, ул Казан ханлыгы чорыннан соңгы түгелдер.

Авыл башта хәзерге урыннан көнбатыштарак булган. Анда иске каберлек урыны булуы билгеле. Әмма хәзер инде ул сукаланган. Шул тирәдә «Имән елгасы» дип аталган елганы кичеп, көнчыгыш

якка – авылга барганда кайберәүләр, башлары буталып, адашып калалар. Шуңа күрә бу тирәне «кирәмәтле», ягъни зәхмәтле (бедственный) урын дип тә атыйлар.

Башта күчеп килгән өч гаиләдән башланган торак пункт 12 йортка җиткәч, бу тирәдә эшкәртелгән җир мәйданнары кысан була башлый. Җир гаугасы килеп чыга. Шунда кабан ыруыннан булучылар нугай ыруының 5 гаиләсен авылдан читкә кысрыклап чыгаралар. Алар көнчыгышкарак китеп, шул Имән елгасы буенда урнашалар һәм яңа авылга нигез салалар. Бу авыл **Яңа Задур** дип атала, ә баштагысы Иске Задур дип йөртелә башлый.

Тагын күпмедер дәвердән соң Иске Задур авылындагы һәр ыруглан берничә гаилә 5 чакрым төньяккарак күчеп китәләр һәм Чынлы елгасы буенда **Татар Саплыгы** дигән авылга нигез салалар. «Саплык» атамасын алар күршеләрендәге Алешкин Саплыктан үзләштерәләр.

Казан ханлыгы басып алынгач, бу тирәдәге халыкларны да урыслаштыру сәясәте башлана. Мәскәү белән мәҗбүри элемтәләр урнаштырылгач һәм чукындыру гамәлгә кертелгәч, Казаннан Мәскәүгә юл тоткан бер төркем урыслар отряды Яңа Задур авылына «күз салалар». Монда татарлар яшәвен белеп, авыл халкын чукынырга димли башлыйлар. Алар теләмәгәч – көч кулланырга керешәләр. Әмма авыл халкы урысларга каршы сугыша башлый. Шулай да җиңелеп, берничә кеше чукындырыла. Моның дәлиле шулдыр ки: авыл читендә элек керәшеннәр каберлеге булган. Бу каберлек елга буенда булганга, яр ишелеп, аннан мәетләрнең сөякләре чыккан. Авыл эзтабарлары тикшерүе нәтиҗәсендә, 1966 елда бу каберләрдән урыс дәүләтенең металл акчалары табылган.

Иске Задурда 2 мәчет төзелгән. Мондагы мәчетнең бер мәхәлләсендә тирә-як авылларында атаклы ишан хәзрәт Сафа Биккулов имамлык иткән.

Яңа Задурда бер мәчет булган. Мәчетләрнең язмышы һәр авылдагыча – мәктәп һәм клуб итеп файдалануга дучар ителгән. Үзгәртеп кору елларында Иске Задурда мәчет төзеделәр, әмма аны саклый алмадылар, янгын нәтиҗәсендә юкка чыкты. 2000 елда мәчет кабат торгызылды.

Яңа Задур авылы татар мәдәниятендә күренекле урын тотучы мәгърифәтче Шиһап Шәрәфетдин улы Әхмәров (1882–1966) исеме белән горурлана.

Әхмәровлар – белемле, укымышлы нәсел. Олы уллары Гарифулла, мәсәлән, Кушкуак авылында мулла булган.

Шиһап Буа мәдрәсәсендә белем алып, 1901 елда Әлмәт авылына китә. Мәдрәсәдә алган белеме өстенә ул үзлегеннән дә дин гыйлемен, аның тарихын тирәнтен үзләштергән. Коръәнне яттан белгән, теләсә кайсы аятен гарәпчәдән татарчага тәрҗемә итеп, кирәк урында сөйли алган.

Әлмәттә аңа мәдрәсәдә татар телен укытырга кушалар. Иске карашлы, кадими бу мәдрәсәдә дөньяви белем бирелмәгәнлектән, Шиһап үзе дәреслекләр язуга алына, шулар буенча укыта. Аның «Мөнтәхиб әлифба» дигән ике кисәктән торган хезмәте 1908 һәм 1909 елларда аерым китап булып басылып чыга. Бу чорда ул Казанга күчеп килә һәм мәктәп-мәдрәсәләр өчен уку китаплары басу белән шөгыльләнә торган «Сабах» нәшриятына эшкә урнаша.

Казанда Ш. Әхмәров китап басу тарихы белән кызыксына Аның «Матбагачылык тарихы» дигән китабы бу өлкәдә беренче хезмәт булып, бүгенге укучы өчен дә әһәмиятен югалтмаган.

1913 елда «Мәктәп» журналы чыга башлый. Аның редакторы Ш. Әхмәров була. Күренекле мәгърифәтченең татар халык шагыйре Г. Тукай белән дуслык мөнәсәбәтләре турында матбугатта күп язылды. Шулай ук күренекле татар композиторы Салих Сәйдәшевның җизнәсе буларак, аны тәрбияләп үстерүе мәгълүм.

Ш. Әхмәров туган яклары белән гомере буе элемтәсен җуймый. Авылындагы ишан Сафа Биккулов белән дә, үзара аралашып, фикер уртаклыгына ирешеп торалар.

1929 елда ул Яңа Задурга кайтып, «Взаимный кредит» җәмгыятендә идарә рәисе урынбасары вазифаларын үтәүче була. Әмма, шәһәрдән качып торса да, ГПУ агентлары аның «эзенә» төшәләр. Ш. Әхмәров 1929 елның декабрендә кулга алына. Могҗиза белән аңа исән калу бәхете эләгә. 1959 елның 29 сентябрендә ул реабилитацияләнә.

**Городище** авылы Зур Якла (Сура елгасы бассейны) елгасы буенда урнашкан. Иске Чүпрәледән көньякка 22 чакрым ераклыкта. Хәзерге авыл XVI йөздә нигезләнгән. Анда татарлар һәм чуашлар яши.

Городище – чуаш авылы. Аны җирле халык Хуласырми – «Кала елгасы» дип тә йөртә. 1859 елгы мәгълүматлар буенча, бу авылда 147 йорт булган, 1060 кеше яшәгән (Симбирская губерния. Б. 43).

Бу авыл районда иң борынгылардан исәпләнә. Моны риваятьләр дә, шулай ук фәнни хезмәтләрдәге мәгълүматлар да раслый.

Татар галиме Равил Фәхретдинов болай дип күрсәтә: «Городищеның төньяк өлешендә Кала Елга дигән инешнең уңъягында, Зур Якла елгасының сулъяк тармагында Городище шәһәрлеге бар. Мәйданы 7850 кв. м.» (Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казань, 1975. Б. 175).

Бу авыл борынгы Болгар дәүләтенең көньяк-көнбатыш чик буен саклау максатыннан чыгып төзелгән, дип фикер йөртергә нигез бар.

Городищелылар ил күләмендә танылган якташлары белән горурланып яшиләр. Шундыйлар арасында сугышчан Дан орденнарының тулы кавалеры Г. Т. Семенов, Социалистик Хезмәт Герое А. Ф. Мокшин, математика фәннәре кандидатлары Ю. Г. Шмалаков (1937–1995) һәм Н. Н. Шихранов (1946–1998) та бар.

**Яңа Чәке** авылы XVIII йөздә төзелә башлаган. Бу урман-далалы, сөзәк таулы матур урыннарны татарлар һәм чуашлар бергәләшеп үзләштергәннәр, аралашып, дуслашып гомер кичергәннәр.

Яңа Чәке авылында бер мәчет эшләгән. Бу мәчет имамы Ситдыйк Сөбханкуловның биш улы да Казанда Мәрҗани хәзрәт мәдрәсәсендә гыйлем эстәгәннәр һәм төрле авылларда мулла вазифасын башкарганнар. Ситдыйк хәзрәтнең кызлары районның авылларында имамлык итүче муллаларга тормышка чыгып, гаиләләрендә тәрбияле һәм зыялы балалар үстергәннәр.

Авылда яшәүчеләрнең 57 процентын татарлар, 42 процентын чуашлар тәшкил итә.

**Зур Аксу** авылы Зур Аксу, Зур Якла елгалары буенда (Сура бассейны) Иске Чүпрәледән көньякка таба 18 чакрымда урнашкан.

Бу авылның Казан ханлыгы чорында ук булуы билгеле. Монда урта мәктәп, чиркәү, мәдәният йорты бар. Җирле үзидарә советы составына Зур Аксу һәм Чуваш Бизнәсе авыллары керә. Ике авылда да чуашлар яши.

Бу яктагы Аксу авыллары (Зур Аксу, Кече Аксу, Иске Аксу) атамасы Аксу елгасы исеменә (гидронимга) мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән. Аксу – «ак елга». Аны Акса дип тә йөртәләр. *Кса* топоформанты марича *елгачык* дигән мәгънәне белдерә. Окса, Окша, Укса, Укша угро-фин телендә дә ерынты, елга кушылдыгы мәгънәсендә йөри. Аксу атамасы Кавказда һәм Урта Азиядә дә очрый.

Ак төшенчәсендә игелекле, яхшы мәгънәсе дә бар: агапа – ак + апа, агәнәй – ак + әнәй (әби) кебек иркәләү, туганлык атамалары бу якларда киң таралган.

Аксу авылы XV йөздә төзелә башлаган булырга тиеш. Бу авылдагы Аксинский фамилияле кешеләрдә Казанны яулап алырга баручы урыс гаскәрләренә юл күрсәткән крәстияннарга Явыз Иван тарафыннан җир мәйданы бүләк ителү турындагы грамотаның XX гасыр башларына кадәр саклануы билгеле. Ул чиркәү янганда юкка чыккан. Димәк, Иван IV патшалык иткәндә Иске Аксу инде булган. Авылда татарлар, чуашлар, мордвалар яшәгән. Мордва нәселеннән булган, инде чуашлашкан кешеләр Кече Аксуда яшиләр, татарлар исә Иске Аксу өлешендә берничә йорт кына калган. Бу авылны **Эштәбән** дип тә атаганнар.

Эштәбән – антропонимга нигезләнгән атама. Ул мәҗүси чорда кеше исеме булган.

1859 елгы ревизия кенәгәсендә Эштәбәндә 38 йорт теркәлгән. Кече Аксуда – 34, Зур Аксуда 106 йорт исәпләнгән (Симбирская губерния. 1859. СПб., 1863).

1897 елда Эштәбәндә 94 йорт булып, анда чуаш һәм мордва милләтеннән 245 ир-егет, 225 хатын-кыз яшәгән. Зур Аксуда 192 йортта 558 ир-ат, 588 хатын-кыз, Кече Аксуда 110 йортта 344 ир-ат, 287 хатын-кыз көн иткән (Список населенных мест Симбирской губернии. Симбирск, 1897).

Эштәбән авылы исә, административ берәмлек буларак, Зур Аксу составына кертелде. Биредә яшәүче татарлар, һичшиксез, чуашлар белән нык аралашып көн итсәләр дә, ана телләренә тугрылыклы булып яшиләр.

**Зур Чынлы** авылы Чынлы елгасы (Зөя елгасының сул кушылдыгы) буена, Иске Чүпрәледән көньякта 24 чакрым ераклыкта урнашкан. Монда татар-мишәрләр яши. Мәчет, урта мәктәп, мәдәният йорты, элемтә бүлеге, кибет бар.

«Чынлы» атамасын «Чаллы» яки «Челны» атамалары белән тәңгәлләштерү дөрес булмас. «Чиль» дип төрки телдә «елга башы», «бәләкәй ерынты»ны атыйлар (Барашков В. Ф. Топонимия Ульяновской области. Ульяновск, 1974. С. 75). Ләкин бу як халкының *ц*-лаштырып сөйләвенә мөнәсәбәтле «Цынны» дип йөртелүен дә искә алсак, бүтән чыганак булуы турында фикер туа. Мондый атама Ульяновск өлкәсендә да бар: Русская Цильна, Цильнинский район.

Зур Чынлы төзелә башлаганда аның исеме Яңа Ишмай дип аталган, чөнки бу авылга нигез салучыларның башлап йөрүчесе Ишмайка Васильев дигән кеше булган. Ә соңрак бу авыл Сембер өязендә волость үзәге булып әверелгәч, волость старшинасы итеп Еремей дигән кешене билгеләгәннәр һәм халык, ике Чынлыны бутамас өчен, Зурысын Ярамай Чынлысы дип атый башлаган. Бу хәл XX йөз башларына кадәр дәвам иткән.

Әлеге авыл атамалары Чынлы дигән гидронимга нисбәтле төзелгән. Кече Чынлы елгасы шактый озын – 50 чакрымга сузыла һәм Зөя елгасына коя. Бу елга буена күп авыллар урнашкан. Татар-мишәрләрнең монда Ока, Цна елгалары буеннан күчеп килүләрен инде беләбез. Әлеге елганы да нигә *Цна – цына – цынны*, ягъни *Чынлы* (*Цильна*) дип атамаска?

Чынлы елгасының Татар Уби авылы янындагы бер кушылдыгы – «Укаби» дип атала. Бу – «Ока» исеме белән бәйледер, дип карала. Атамаларны өйрәнүче якташыбыз – журналист, галим Ә. Булатов шундый фикердә иде.

Зур Чынлы авылының төзелә башлавына караган ике ышанычлы чыганак бар. Аларның берсе – урыс миссионеры П. Мартыновның «Селения Симбирского уезда» (Симбирск, 1903), икенчесе – М. Госмановның «Татарские исторические источники» китабы (Казань, 1974. 178 б.).

Беренчесендә, Чокал авылының йомышлы татары Ишмайка Васильев үзенең 20 иптәше белән Сембер приказ йортына үтенеч биреп, Чильна елгасының Алгаш чиге буеннан җир бирүне сорый, дип күрсәтелә. Шунда алар Яңа Ишмоловка (Яңа Ишмай) авылын төзи башлыйлар.

М. Госманов язучы Шамил Усмановның әтисе Хәйрулла Усмани әс-Сембери тарафыннан кабер ташына теркәлгән мәгълүматка таяна. Анда мондый юллар бар: *«Чынлы къәрйәсенең мәэссис (нигезләүче) бабаларыбыз Төмин вә Рәзан тарафыннан 1600 тарихында (елда) килмешләр. 1018 сәнәи һиҗри вә Чылны суына, Иске йорт динелән (диелгән) урынга ултырып йир алмышлар, йегерме бер фамилия язылмыш. Әлмөхәммәт, Ишмөхәммәт, Индерчи, Агнай, Алташ, Алмакай кеби исемнәр асылда аларның мишәр кабиләсе улдыкларына шаһиддыр».*

Ш. Усмановның бабалары сала башлаган нигез Яңа Ишмайка авылыннан Алгаш ягындарак булган. Алгаш чигендә җир

алучылар – Урманче, Ындырче бабалар нигезләгән урын бүгенге авыл халкы телендә «Иске йорт» дип атала һәм изге санала.

1674 елда чуашлар белән тыныша алмаганга авылны тынычрак урынга – төньяк-көнчыгышкарак күчерәләр. Яңа урындагы авылны урталай бүлеп, Зур Чынлы елгасы ага. Әлбәттә, ул вакыт бу исемсез елга булган, Цна елгасы буеннан килүчеләр аңа шул исемне кушкан булырга тиеш.

Миркасыйм Госманов Хәйрулла хәзрәт язуында һиҗри белән милади елларында ялгышлык бар, һиҗри 1018 ел милади исәбе белән 1600 түгел, ә 1609 елга туры килә, дип күрсәтә.

Зур Чынлы авылы районда һәм республикада дан яулаган күренекле кешеләре белән мактана ала. Алар арасында Социалистик Хезмәт Герое Усман Алиев, Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары белән бүләкләнгән Венера Мөшәрова кебек гади хезмәт кешеләре, ветеринария фәннәре докторы, профессор Ирек Хәйруллин, СССР Дәүләт бүләге иясе, Халыкара инженерлык академиясе һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Ирек Фәхретдинов һ.б. бар.

**Шигали** авылы атамасы антропонимга (кеше исеменә) нисбәтле туган.

В. В. Вельяминов-Зернов «Исследование о Касимовских царях и царевичах» исемле хезмәтендә (СПб., 1863. Ч. 1. С. 248, 251) болай дип күрсәтә: «В 1516 г. на месте Шейх-Аулияра, в городах Мещерском сидел сын его Шах-Али. И весною 1519 года царевич Касимовский был торжественно объявлен ханом Казанским». Казан краенда очрый торган Шигали атамалары әлеге хан исеменә яки шул исемдәге биләргә нисбәтле дип карала.

**Чепкас-Илмәт** авылында татар-мишәрләр яши. Авыл җирләре районның төньяк чигендә, Чувашиядәге Чепкас-Никульское авылыннан Чатказ елгасы белән генә аерыла. Чуашлар бу авылны «Илмәт-Чатказ» дип атыйлар. Атамадан күренгәнчә, бу ике авыл өчен дә уртак Чепкас яки Чатказ компонентлары бар. Илмәт һәм Никуль, билгеле булганча, ялгызлык исемен тәшкил итәләр.

«Чатказ» атамасы белән В. К. Магницкий «Список селений «мишарей» в Буинском уезде Симбирской губернии» исемле китабында берничә пунктны күрсәтә: «Янтуган Чаткасы», «Чаткас башы» (130 бит), «Шарт Чаткас» (урысча «Каменный брод»), «Үтти Чаткас» (131 бит).

Чепкас нинди төшенчәләрдә йөргәнен төрлечә фаразлыйлар. Авыл халкы «чеби», «каз» үстерүгә бәйләп карый. Бәлки Илмәт дигән кешенең кушаматы «чебеш» булгандыр.

Чуаш телендә «чаркас» йомран төшенчәсендә йөри; *р – п* күчеше нәтиҗәсендә «Йомран Илмәт» – «Чапкас-Илмәт» булып китүе мөмкин.

Авыл аксакаллары монда нигез салучы кешенең Илмәт исемле булуы турында сөйләп калдырганнар. Ул монда дүрт гасыр элек килгән.

**Коршанга-Шигали** – Чувашия Республикасы чигенә урнашкан авыл, Иске Чүпрәледән төньякта 21 чакрым ераклыкта. Авыл XVI йөзнең икенче яртысында төзелә башлаган. Казан ханлыгы басып алынгач, урысларга теләктәшлек күрсәтүче мәҗүси диндәге чуашлар христиан диненә күчеп, дәүләткә салым түләүдә, бүтән буйсынуларда аерым срокка ташламалар алалар.

1649 елда патша Алексей Михайлович чыгарган закон буенча крәстияннар ясак түләргә мәҗбүр ителәләр. Ә чуашлар дәүләт крәстияннары дип исәпләнгән. Алар төрле авыр эшләр башкарырга мәҗбүр ителгән (урман кисү, хәрби ныгытмалар төзү, сал ясау, селитра заводында эшләү һ. б.). Шуның өстәвенә алар ясак җыючы чиновниклар изүенә дә дучар ителгән.

Христиан динен кабул иткәннәрне яңа керәшеннәр дип атаганнар һәм аларга үзләре теләгән урыннарга күчеп урнашырга мөмкинлек биргәннәр. Христиан динендә дип исәпләнсәләр дә, алар үзара рухи тормышларында мәҗүсилек йолаларын, гореф-гадәтләрен саклаганнар.

**Түбән Урманасты Шигали** һәм аннан бүленеп чыккан **Хорновар-Шигали** XVII гасыр урталарында барлыкка килгән. Бу яклардагы «Шигали» авыллары төрле чорларда бу якка күчеп килүчеләр артыннан ияреп килгән исем-атама астында барлыкка килгәннәр. Авыл картларының риваятьләренә караганда, хәзерге Чувашиядәге Подлесные Шигали авылыннан 3 кеше, югалган терлекләрен эзләп йөргәндә, шушы урыннарга килеп чыкканнар имеш. Тирә-якта матур, куе каен урманы, тау битләрендә чишмәләр агып тора. Җире дә уңдырышлыга охшаган: яшел үлән шаулап үсеп утыра. Әлеге 3 хуҗа монда күчеп йортлар салалар. Авылның исеме, элек яшәгән авылларыннан түбәндәрәк урнашканлыктан, Түбән Урманасты Шигалие дип аталган.

**Яңа Шигали** авылының барлыкка килүен 1720 ел белән билгеләүчеләр бар (Чебанов А. С. и др. Родимый Край. Караганда, 1993. С. 10).

Бу урынга беренче килүчеләр, шул тирәдә яшәүче җирле кешеләр белән киңәшеп, йортлар төзи башлыйлар. Бу якның табигате дә, шул тирәдә яшәүче мәҗүси динендәге ыругдашлары да аларның күңелләренә хуш килгән. Әмма илдә бара торган хәлләр зур юллардан читтә, табигатьнең тыныч почмагына урнашкан бу авылларны да читләтеп үтмәгән. Крәстияннар башыннан кичкән барлык вакыйгалар, чуалышлар, гаугалар монда да үз тамгаларын калдырган.

Тирә-як авыллар өчен дә зур әһәмияткә ия булган вакыйгаларның берсе – **Хорновар-Шигали** авылында 1897–1898 елларда мәктәп төзелү. Бу якларда мәктәп төзү идеясе чуашлар арасында православие динен ныгыту максатын күздә тотып барлыкка килә. Төзелешне яклап чыгучыларның берсе – Сембер халык училищелары инспекторы И. Н. Ульянов була. Әмма инспектор үзе мәктәп ачылганын күрергә өлгерми, 1886 елның гыйнварында вафат була. Бу мәктәпнең ачылуы һәм эшли башлавында чуаш мәгърифәтчесе И. Я. Яковлевның да роле зур.

Хорновар-Шигали урта мәктәбендә укып белем алучылар арасында СССР авиация промышленносте министры П. В. Дементьев, гражданнар сугышы геройлары П. Е. Крепков һәм И. С. Космовский, Социалистик Хезмәт Герое Е. Е. Немасев, Советлар Союзы Герое П. С. Юхвитов, чуаш язучысы, драматург А. С. Чебанов, язучы В. Н. Музыкантова, техник фәннәр докторы П. П. Марков һ. б. бар.

Яңа Шигали авылына нигез салучыларның бер тармагы – Батыр районындагы Подлесные Шигали авылыннан булган Алаберт нәселеннән килүче Чебановлар. Бу нәселнең шөһрәтен арттыруга аеруча зур өлеш кертүче Дмитрий Ефимович Чебанов була. Ул патша гаскәрендә 25 ел хезмәт итеп фельдфебель дәрәҗәсенә ирешә.

**Иске Кәкерле** – Чувашия белән чиктәш, Иске Чүпрәледән 16 чакрым төньякта урнашкан авыл. Аның барлыкка килүе Казан ханлыгы чорыннан билгеле.

Сөйләүләргә караганда, үткән гасырда Кәкерле авылының тарихы һәм нәсел шәҗәрәләре булган. Ләкин ул язмалар, кулдан-кулга күчеп, каядыр югалганнар.

Риваятьләр Кәкерле авылының ханнар заманында кәрваннар туктальшы һәм элемтә ноктасы буларак барлыкка килүен искәр-

тәләр. Хәзер Яңа Кәкерле һәм Иске Кәкерле авыллары бар. Яңа Кәкерле әлеге урынына XVIII йөздә күчеп урнаша башлаган; бу авыл халкының бабалары Иске Кәкерледә, Исай елгасы буендарак яшәгәннәр. Чәчүлек җир мәйданнарын Яңа Кәкерледәге нәселдәшләре өчен киңәйтү максатында, иске урыннарыннан күчеп, төньяк-көнбатышкарак чигенгәннәр.

Иске Кәкерле авыл җирлеге составында булган **Татар Төкесе** – район үзәгеннән 21 чакрым төньяк-көнбатышта Чувашия Республикасы белән чиктәш урнашкан татар авылы. Биредә дә тормыш Казан ханлыгы чорында башланган. Бу исемнең этник төркем атамасыннан, нәсел-ыру кушаматыннан чыккан булуы да бар.

Әлеге атаманың мәҗүси исемнәрдә сакланып калганлыгын искәртергә кирәк. В. К. Магницкийның «Чувашские языческие имена» исемле китабында, мәсәлән, Тикей, Тукин кебек исемнәр күрсәтелгән.

Төке атамасына аваздаш яки аның «тукюй» кабиләләренә бәйләнешле булу ихтималын раслаучы топонимнар шактый. Талды-Курган өлкәсендә Текели шәһәре, Казакъстанда Төке күле бар; Омск өлкәсендә Төкели – район үзәге. Воронеж өлкәсендә Тюковка, Рязан өлкәсендә – Тюково, Эстониядә – Тюки; Актаныш районында да Түке авылы бар.

Картлар сөйләве буенча, Төке авылы моннан 450 еллар элек барлыкка килгән. Бу турыда Е. А. Малов та: «Мишари Буинского уезда деревни Каракита и Тюки переселились в Симбирскую губернию из рязанской лет около 300 тому назад. Первый поселенец в Каракита был Абдулла, а в деревни Тюки Кадюкай Абыз (или Ходайбирди), в настоящее время мишари этих деревень считают себя 11-м колене от упомянутых переселенцев Абдуллы и Кадюкая», – дип язып калдырган (Сведения о мишарях. Казань, 1885. С. 28).

Бүгенге көндә дә авыл халкы Абыз Кадыкайның исемен изгеләштереп яши. Аның кабере авылның көньяк почмагында кадерләп саклана. Кабер өстенә куелган ак ташбилгегә изге дога сүзләре чокып язылган. Кабер тирәсе исә коймалап тотып алынган һәм, тирәяк авыллардан да бу изге зиратны хаҗ кылырга килүчеләр кереп намаз укыр һәм дога кылыр өчен, махсус ышык урын булдырылган.

Татар Төкесе – күренекле татар шагыйре Зәки Нуриның туган авылы. Бу авылда аның туганнары, Герой ана булган бертуган сеңелесе Һәдия Идрисова-Нуретдинова яши.

Бу авыл XIX йөз ахырында мәгърифәтчелек, җәдитчелек хәрәкәте үзәгендә кайнаган күренекле шәхесләр – Шәйхелислам һәм Шакирҗан Хәмидиләрнең дә туган ягы.

Шәйхелислам бине Әсәдулла Хәмиди әт-Төки (1869.20.IX–1911.9.VII) морзалар-муллалар нәселеннән булган. Авылда этисеннән белем алгач, Казандагы Шиһабетдин Мәрҗани мәдрәсәсендә укый. Аннары Уфага «Госмания» мәдрәсәсенә юл тота. Бу мәдрәсәдә белем туплагач, Әстерханга китеп, үзе мәдрәсәдә дәресләр бирә. Анда тәҗрибә туплагач, «Госмания»дә мөгаллимлек итә. 1904 елның 2 мартында Мәрҗани мәдрәсәсендә хатиб һәм мөдәррислеккә имтихан тота.

Шәйхелислам Хәмидинең гарәпчәдән «Кодури», «Борхарзадә», «Әмали», «Фякьһе Кидәни», «Гәрикаи Мөхәммәдия», «Төхфәтел Мөлек» әсәрләрен татарчага тәрҗемә итүе, Корьән тәфсире язуы да мәгълүм.

Шәйхелислам хәзрәтнең бертуган энесе Шакирҗан Хәмиди (1880–1933) шулай ук ата-бабалары юлын дәвам итүче татар зыялысы була. Казандагы мәдрәсәдә белем алгач, ул Кәримовлар типографиясендә корректор булып эшли. 1900–1910 елларда төрле догалыклар, тәгъбирнамә, йолдызнамә кебек китаплар төзеп бастыра. Ул шулай ук «Әхтәри кәбир» исемле («Бөек йолдызлык». – *Р. С.*) мең битле гарәпчә-төркичә сүзлекне төзүдә катнаша, дин турында «Һәдият, әл Хәмиди», «Җәннәт әһеле кемнәр?» дигән китаплар яза.

1907 елда чыккан «Һәфтияк сүрәләре» җыентыгында Шакирҗан Хәмидинең аңа кадәр басылган 26 китабы турында мәгълүмат бирелгән. Моннан тыш, бу зыялы шәхес әдәби иҗат белән дә мавыккан, фәнни эшчәнлек тә алып барган. Аның «Төштәге 5 сум», «Бәхет хикәясе», «Яшь ана вә үги кыз хакында», «Шәригать һәм заман» һ. б. әдәби әсәрләре, «Гарәп теле синтаксисына кереш», «Аваз ысулына бәйләнешле әлифба» кебек уку-укыту әсбаплары булуы мәгълүм.

Иске Кәкерле авылы халкы авылдашлары: фән докторы Иршат Инният улы Хәбибуллин, полковниклар Равил Вахит улы Салахов, Расих Халикъ улы Шакиров, Казан авыл хуҗалыгы академиясе доценты Рәшит Абделхаликъ улы Шакиров, Татарстанның атказанган артисты Рафикъ Зәкәрия улы Таҗетдинов һ. б. белән горурланалар.

**Иске Чүпрәле** – Кече Чынлы елгасы буенда Борындык тимер юл станциясеннән 45 чакрым көнбатышта (Ульяновск – Зөя линиясе) урнашкан авыл, район үзәге.

Картлар сөйләвенә караганда, Иске Чүпрәле авылы Казан ханлыгы чорында төзелә башлаган. Узган гасырның алтмышынчы елларында 88 яшьлек Кафия әби Алкаева бер риваять сөйләгән иде: «Бу урынга моннан 400–450 еллар элек Алкай, Алмакай, Салмакай атлы бабайлар килеп чыкканнар. Алар бер кизләү табып, шул кизләү янына ял итәргә утырганнар. Шунда берсе су эчкән дә, суыннан чүпрә тәме кебек әчкелтем тәм сизгән. Шуннан бу якта сазлыклы баткаклыкта чүпрәдәй чымырдап, әчеп яткан урыннар күреп, булачак авыл да, шундагы елга да Чүпрәле атамасы алган».

Мәрхүмә Хөсниҗамал әби Хәйруллова мондый риваять сөйләгән: «Мин Вәли хәзрәтнең (Вәли хәзрәт – Чүпрәле авылыннан чыккан, аз билгеле булган шагыйрь Вәлиулла Алкаев-Чүпрәле) авызыннан үз колагым белән ишеткәнем бар, безнең авылга килеп утырган Алкай, Алмакай, Салмакай бабайлар өчесе дә төректән килгәннәр. Алар сугыш вакытында пленга калган булганнар». Бу «төректән килгән» кешеләрнең мишәрләр булуына ачкыч бирә. Чөнки Е. А. Маловның «Сведения о мишарях» исемле хезмәтендә дә мишәрләрнең кайчандыр төректән килүләре турында легенда урнаштырылган (Казань, 1885. С. 38).

Вәлиулла хәзрәтнең туганнан туган энесе Абдрауф Алкаев хәтирәләрендә түбәндәге ачыклык кертелгән иде: «Алкай бабай безнең Чүпрәле урынында калган, Алмакай дигәне Каракитә урынына барып утырган, өченчесе – Салмакай бабай – Иске Чокалы урынына барып урнаша».

Әлеге өч риваятьне бергә җыеп, тарихи чыганаклар белән чагыштырырга керешсәң, түбәндәгеләр ачыклана.

Академик М. Г. Госмановның «Татарские исторические источники XVII–XVIII вв.» исемле хезмәтендә бу яклар тарихына кагылышлы нәсел шәҗәрәләре китерелгән. Аннан мәгълүм булганча, Саратов өлкәсендә яшәүче Габделкаһир Тимербулатовның, 1924 елда язып, Риза Фәхретдиновка тапшырган кульязма текстында Алтын Урда чорында мишәр феодалы Мамайның нәсел ыруы бу якларга күчеп утыруы әйтелгән: «Шәҗәрәнең бу өлешендәге кешеләр Сембер губернасының Чәке, Куш–Куак, Иске Чикали авылларында яшиләр», – диелгән. Шәҗәрәдә 1895 елдан кирегә

таба 9 буын күрсәтелгән: мулла Зәйнелгабидин – мулла Шәрәфетдин – мулла Әмирхан – Шәмсетдин – Курамша – Гомәр – Мәмдәл – Галимҗан – Мамай-хан.

Мамай-хан нәселе белән кызыксынуыбыз шушы бoҗрадагы бәйләнешне эзләү уңаеннан килеп чыкты. Бу нәселнең яшәү чоры 330 еллар чамасы дип исәпләсәк, Чүпрәлегә нигез салучы Алкай (Алиәкбәр) бабаларның нәселе дә шул чорга туры килә: Алкай – Бәшир – Абдулҗәмил – Әбдрәшит – Әхтәм – Хәбибулла – Сәнатулла – Абдрахман – Абдрауф (1909 елда туган). Алдарак Е. А. Маловның «Сведения о мишарях» исемле хезмәтеннән файдаланып, Каракитә авылына беренче килүче кешенең Абдулла исемле булуын искә алган идек. Әлбәттә, урыс миссионерының Алмакайны Абдулла дип кабул итүе ихтимал. Урысларның һәртөрле төрки исемнәрне үз телләренә җайлаштырып әйтү очраклары әле дә дәвам итә бит.

**Яңа Чүпрәле** авылы район үзәге белән янәшәдә Кече Чынлы елгасының сул ягына урнашкан. Исеменнән аңлашылганча, бу авыл XVIII гасырда Иске Чүпрәледән аерылып төзелә башлаган. Бу авылда 2 мәчет эшләгән: берсендә – алда телгә алынган Вәлиулла Алкаев, икенчесендә Фәхретдин Сөләйманов хәзрәт булган.

Иске Чүпрәле авылының илгә таклы, танылган һөнәр ияләре шактый: К. Станиславский исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Татарстанның һәм Россиянең халык артисткасы Алсу Әскәр кызы Гайнуллина, медицина фәннәре докторы, профессор Фарук Кәрим улы Манеров, Россия Герое, очучы Газинур Гарифҗан улы Хәйруллин һ. б.

**Иске Чокалы** Зур Якла елгасының башланган урынында (Сура елгасы бассейны) Иске Чүпрәледән 11 чакрым көньякта урнашкан. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты тарафыннан чыгарылган «Населенные пункты Республики Татарстан» дигән китапта әлеге авыл «1654 елдан билгеле» дип әйтелә. Әмма ТАССРның атказанган укытучысы Кадир Заһретдин улы Туктамышев, Иске Чокалы тарихын өйрәнеп, аның турында шактый материаллар туплый һәм бу авылның XIV йөз азакларында Казан ханлыгы чорында ук нигезләнгән булуын язма чыганаклар, җирле топонимик һәм этнографик фактлар белән дәлилләргә тырыша.

Авылның атамасына игътибар итсәк, бу мәсьәләдә И. К. Инживатов болай яза: «Название Чукалы было очень распространен-

ным в мордовских районах в XVII в. Только в одном Алатырском уезде с таким названием было шесть населенных пунктов. Старые Чукалы – на речке Морказее, Новые Чукалы – на речке Саре, Верхнее Чукалы – Нуе речке, Чукалы – на Вернуе, Новые Чукалы на Медянской вершине, Новые Чукалы на Сарских вершинах» (Инжеватов И. К. Мордовские топонимы Атяшевского района // Ономастика Поволжья. Уфа, 1973. № 3. С. 212). Мордва телендә «цикалей» – «цика+лей», ягъни «урыс елгасы» булуы ихтимал.

Бу атама чуаш сүзенә мөнәсәбәтле – «чик+ялы» – «чик буендагы авыл» формасында булырга да мөмкин. Бездәге Иске Чокалы һәм Яңа Чокалы атамаларын йөрткән авыллар да Болгар дәүләтенең көньяк-көнбатыш чиге буенда урнашуын искә алсак, бу фаразга ныграк ышанып була. Элекке чорларда үзаллы яшәүче Иске Татар Чокалы, Югары Татар Чокалы, Түбән Татар Чокалы авыллары булган. Алар хәзер барысы да Иске Чокалыга берләшкәннәр.

Риваятьләргә караганда, мишәр кабиләләре Алтын Урда таркала башлаган чорда, Касыйм ханлыгы булып берләшкәнче үк, бәйсезлеккә омтылганнар. Кадом, Төмән (Темников) һ. б. тирәләрдән күченеп, бу якларга килеп чыкканнар, чуаш-мордва авыллары үрнәгендә тагын бер Чокалы авылына нигез салганнар.

Казан ханлыгы чорында инде «авыл» дип әйтерлек торак пункт гамәлдә булган. Бу турыда Е. И. Чернышев «Селения Казанского ханства» исемле китабында күрсәтеп үтә. В. Магницкийның «Список татарских селений Буинского уезда» дигән хезмәтендә дә Чокалы борынгы авыллар исәбендә теркәлгән.

Авылның күпгасырлык тарихына дәлил итеп, монда каберлекләрнең күп булуын да искәртәләр. Иң борынгы зиратны «Ташлыкай бабай зираты» дип атаганнар. Икенче зират – «Караңгы оч зираты»; өченчесе – «Урталык зираты», дүртенчесе – «Югары», бишенчесе – «Чуашлар зираты» дип атала. Бу каберлекләр өстендә язулы ташлар да күп булган. Әмма 1930 нчы елларда мәктәп төзегәндә, бу ташларны җыеп, нигезгә салып калдырганнар.

1578 елда төзелә башлаган Алатыр – Арзамас – Төмән чик сызыгы буена күчерелгән татар-мишәрләрнең дә авыллар үсүгә йогынты ясавын сөйлиләр. XVII йөз урталарында Урта Идел буйларын нугайлардан саклау өчен Сембер-Корсун хәрби линиясен төзү дә бу якларга халык күчеп килүгә сәбәп була.

Ш. Мәрҗани үзенең «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле китабында үзенең әнисе ягыннан нәсел шәҗәрәсен Иске Чокалы авылына бәйли: «Габденнасыйр – (Мәрҗанинең әнисенең әтисе – *Р. С.*) тумышы белән Иске Чокалы карьясеннән. Анасы Бибирабига – Шатрашан исемле авылдан – Мөслим кызы. Ата-бабалары һәркайсы имам, Гали – Бизнә авылында имам һәм мөдәррис булып тора һәм шунда вафат була. Углы Мозаффар белән каберләре бер-берсенә якын... 1277 (1860) елда, Тау ягында сәяхәт иткәндә, каберләрен барып карадым.

Мелла Мозаффарның угылларыннан: менла Габделмәҗит – Борнак иле авылында, мелла Зәйнетдин – Нугай иле авылында (Сембер шәһәре тирәсендә), мелла Бәрзия Буклавыч авылында имам булганнар. Ә мелла Зөбәер яшьләй вафат булган. Мелла Гомәр бине Зәйнетдин атасы урынында имам булып калган. Мелла Габденнасыйрның атасы мелла Сәйфелмөлек Казан өлкәсенең Бай Оланнары авылы мәдрәсәсендә укый. «Гөлстан Сәгъди» китабын яза. Мелла Сәйфелмөлек озак гомер итә. Иске Чокалы авылында имам хатыйб һәм мөдәррис вазифаларын үтәп, йөз яшенә җитеп вафат була һәм Иске Чокалы авылы каберлегенә җирләнә.

Бабабыз мелла Габденнасыйр Ашыт авылында озак еллар зур мәдрәсә тотып, күптөрле фәннәрдән дәрес әйтеп, күпләр, көчләре бар кадәр, гыйлем һәм камиллеккә ирештеләр. Менә алар: мелла Сәйфетдин бине Бәшир әл-Чокалый, мелла Фәтхулла бине Вәлид әз-Задури, мелла Бәшир бине Җомга әл-Кара Китави, мелла Ибраһим бине Яһүдә эш-Шәйморзави, мелла Габделмәннан бине Сөбхан әл-Чокалый һ. б.» (Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан, 1989. Б. 181–183).

Ш. Мәрҗани безнең якларга ике мәртәбә кайта. Беренче мәртәбә 1848 елда Бохарадан кайткач була, икенче кайтуыннан соң алда күрсәтелгән китабында болай дип язган: «1860 елда бөтен гаиләм белән икенче тапкыр Тау ягына сәфәр кылып, Чокалы авылында бабабыз мелла Сәйфелмөлек бине Мозаффар һәм әбиебез Бибирабига Мөслим кызы, Бизнә авылында бабабыз мелла Мозаффар һәм аның атасы мелла Мортаза бине Гали һәм башка якыннарыбызның каберләренә зиярәт кылдык» (Б. 360).

Ш. Мәрҗани язган нәсел чылбырын түбәндәгечә күз алдына китереп була: Йосыф әл-Җәбәли (Җәбәли – Тау ягы мәгънәсендә) – Гали – Мортаза (Бизнәдә имам) – Мозаффар (Бизнәдә имам,

1795 елда вафат) – Габделмәҗит, Зәйнетдин, Бәрзия, Зөбәер; – Сәйфелмөлек (Иске Чокалыда имам) – Габденнасыйр – (Ашытта имам, 1833 елда вафат) – Габделмәннан – Хәмим (Иске Чокалыда имам, 1871 елда вафат) – Баһаветдин – Шиһабетдин – Мөхәммәдъяр.

Күреп үткәнебезчә, Мәрҗанинең әнисе ягыннан туганнары Иске Чокалыда озак еллар дәвамында мулла-мөгаллимлек итәләр.

Иске Чокалы авылында XIX йөз ахырында өч мәчет эшләп торган. Ә яңа гасыр башында мәчетләр саны 4 була. 1930 нчы елларга кадәр авыл 6 мәхәлләдән торган.

Гариф Айнулла улы Гайнуллин-Чокалый шулай ук бу авылның күренекле кешеләренең берсе. «Гариф Гайнуллин 1878 елда туа. Башта авыл мәктәбендә, аннары Сембер мәдрәсәсендә укый, үзлегеннән урысча укырга өйрәнә. Г. Гайнуллин-Чокалыйның әдәби мирасы – «Чын вәгъдә» (1910), «Биш мужик» (1910), «Надан ата» (1911), «Тәрәккый мәхәббәте» (1911), «Кызыклы шигырьләр» (1912, 1919) дигән китаплары. Ә «Гаффар агайның тормышы» (1912), «Яхъя суфи» (1914) исемле шигырьләре «Шура» журналында һәм «Идел» газетасында дөнья күргән. Рус әдәбиятыннан тәрҗемәләре бар (мәсәлән, М. Лермонтовның «Пәйгамбәр»е)» (Мирас. Б. 15–17).

Авыл ТАССР авыл хуҗалыгы министры булып эшләгән Җәвит Алиәкбәров, Ленин ордены кавалеры Нәҗибулла Кәлимуллин, галимнәрдән Ифрәт Әхмәтова, Әбдрәшит Нәҗмиев, академик Руханил Гафуров, һ. б. белән дан тота.

**Иске Шәйморза** авылы Кече Чынлы елгасы (Зөя бассейны) буенда Иске Чүпрәледән 30 чакрым көнчыгышка урнашкан.

Аның авыл буларак үсә башлавы XVII йөз урталарында – Сембер каласының сәүдә үзәгенә әверелү белән бәйле үсеш алган чорына – туры килә. Кайбер чыганакларда бу тирәдә тормышның аннан да иртәрәк барлыкка килүе турында мәгълүматлар бар. 1904/1905 елларда Сембер округ судының эш кәгазьләре сакланган архивта (Беренче чыгарылыш, 142–143 битләр), мәсәлән, түбәндәге мәгълүмат сакланган: «...упомянутая в грамоте 1615 года межевая граница д. Тинбаево участки тинбаевских чуваш граничили с наделами служилых татар д. Чепкас и землей Шаймурзинской...». Бу очракта безне Шәйморза атамасының рәсми кәгазьләрдә күренү вакыты кызыксындыра. Димәк, Сембер кала статусы алганчы Шәйморза авылы инде яшәгән булган.

Кече Чынлы елгасының сулъяк ярында Чуваш Шәйморзасы авылы бар. Бу авылга нигез салучылар Иске Алгаштан килгән чуашлар була. Алар бирегә Алатыр һәм Сембер арасындагы юлларны, күперләрне төзү һәм төзек тоту максатында урыс хөкүмәте кушуы буенча китереләләр. Мондагы халыктан христиан динен кабул иттергәннәр.

Шәйморза авылы башта хәзерге урыныннан 5 чакрым чамасы көнчыгыштарак Чынлы елгасының сул ягына урнашкан һәм исеме Уразбай дип аталган.

«Уразбай авылына килеп нигез салучылар үзләрен «төмәнлеләр» дип йөрткәннәр. Чөнки бирегә күчеп килгәнче алар Темниково җирендә яшәгәннәр һәм Корсун–Сембер саклану сызыгын төзү максатында бу якларга күчерелгәннәр» (Идел. 1993. № 9. Б. 65).

Сембер өязенең 1674 елгы биләмәләре турындагы язмада, Зур Чынлы татарларының әйтүе буенча, Уразбай авылына башта чуашлар, соңрак татарлар килгән, диелә.

Шәйморза авылына иң беренче килеп урнашкан кешенең исеме – Йәкилди. Авылга килүчеләр арасында Кәдичкә Дәүли, Алкайка Ороносов, Салҗыкайка Такаев, Маладышка Ишкаев, Памышка Байранов, Садубайка Мишаев һ. б. булган.

Авылны Шәйморза дип атаулары аңа нигез салучыларның берсе Шәһи морзадан килеп чыккан.

Авыл музеенда сакланган нәсел шәҗәрәләре дә аның XVII йөз урталарында үсеп китүен күрсәтә. Монда килүчеләрнең йомышлы татарлар булуы хак.

Иске Шәйморзага күчүчеләргә җир бирелү турында Сембер губернасы җир исәпләү язмаларында мондый юллар сакланган: *«...что татарам деревни Шаймурзино, 33 человекам земля пожалованы за службу и что по выписи 1700 года, дана им 3390 десятин пашни, 1360 десятин сенных покосов и 1220 десятин лесу. Во время же генерального межевания эта земля была замежована в одну окружную межу с деревней Елхово-Озерной и другими соседними селениями; хотя и оставалась все время в фактическом и единственном владении потомков перводатчика Умерхи Шаймурзино».*

Иске Шәйморзада 1929 елның декабрендә оешкан колхозга 29 хуҗалык гариза биргән. Тик, күмәкләшеп эшләп китә алмагач, 1930 елның мартында мәгълүм сәбәп нәтиҗәсендә берләшкән гаиләләр үз мөлкәтләрен кире алып таралышканнар. Ләкин озакка

түгел, шул ук елның чәчү сезоны башланыр алдыннан кырга чыгарга җыенган крәстияннарны яңадан колхозга туплый башлыйлар. 22 хуҗалык берләшеп, Буденый исемендәге күмәк хуҗалык оештыралар. Беренче рәис Шакир Алиев була.

1950 елда хуҗалыкларны кабат берләштерәләр һәм Сталин исемендәге бу хуҗалыкны 1950–1951 елларда Миргасим Азизов, 1951–1953 елларда Гәрәй Шәрәфетдинов, 1953–1955 елларда Сәетгәрәй Фәтхуллов җитәкли.

1955 елда әлеге Сталин исемендәге колхозга рәис итеп, утызмеңчеләр сыйфатында әлегә кадәр район партия комитетында эшләгән шушы авыл кешесе Әхмәтгәрәй Шакирҗан улы Әбдриевны сайлап куялар.

1959 елда Ә. Ш. Әбдриев ТАССР Верховный Советы депутаты итеп сайлана. Аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә.

Авыл халкы Иске Шәйморзада туып, шунда белем алып, хәзер төрле өлкәләрдә эшләп дан казанган якташлары – физика-математика фәннәре кандидаты М. В. Лотфуллин, физика-математика фәннәре докторы М. И. Фәтхуллин, юридик фәннәр докторы Ф. Н. Фәтхуллин, филология фәннәре докторы Ә. Ш. Йосыпова һ. б. белән горурлана.

**Кече Шәйморза** (Димин) турында сүз барганда, аның данын бөтен Татарстанга, хәтта аннан да читкә чыгарып үстерүче шәхесләрне искә алмый мөмкин түгел. Алар – Татарстанның халык артисты, күренекле җырчы Габдулла Рәхимкулов, Татарстан АССРның Министрлар Советы председателе дәрәҗәсенә ирешкән М. Җ. Азизов һ. б.

**Борындык** (тимер юл станциясе поселогы) Ульяновск – Зөя тимер юлы линиясендә Иске Чүпрәледән көньякта 52 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бу авылга 1943 елда нигез салына. Сталинградта авыр бәрелешләр барган чорда, бу каланы Үзәк белән тоташтыру зарурияtennән чыгып, Мәскәү – Казан тимер юлы линиясен төзү планлаштырыла. Ул Зөя (Свияжск) – Ульяновск арасында салына башлый.

Борындык атамасы Буа районындагы Борындык авылына нисбәтле бирелгән. Монда килеп урнашучы кешеләрнең шактые шул авылдан булуы билгеле.

**Кече Чынлы** авылы Чынлы елгасы буенча (Зөя бассейны) район үзәгеннән 28 чакрым ераклыкта көньякта урнашкан. Монда

татар-мишәрләр яши. XVII йөздә төзелә башлаган дип фараз ителә. Авыл тарихы белән кызыксынучы аксакаллар Шәкүр Сөләйманов һәм Заһидулла Шәйхаттаровлар фикерләвенчә, бу авыл Яңа Ишмайка (Зур Чынлы) авылыннан егерме еллап соңрак төзелә башлаган. Бу XVII йөзнең туксанынчы еллары ахырына туры килә.

Авыл төзелә башлаганда аның атамасы Кәрим Чынлысы дип йөртелгән. «Кәрим Чынлысы» дигән атамасы бу авылга килеп нигез салучы Кәрим исемле кешегә мөнәсәбәттә фараз ителә.

Кече Чынлының кайчанрак нигезләнүе хакында берничә версия бар. Берсендә ул Болгар дәүләте чорына, икенчесендә Казан ханлыгы заманында, өченчесендә XVII йөз ахыры белән XVIII йөз башы тирәсендә булырга мөмкин, дип гөман ителә. Тарихчы галим Евгений Чернышевның (1894–1979) «Селения Казанского ханства по писцовым книгам Д. И. Кикина, И. Болотина 1602–1603 гг. Дозорные книги 1616–1619 гг.» (Казан, 1971) дигән китабына күз салсак, авылның инде 500 еллап гомере булуы дәлилләнә. Бу чорда, ягъни XIV йөзнең ахыры яки XV йөзнең башында, ул Зөя өязенә кергән була.

Димәк, бу авыл күршеләрендәге Зур Чынлы авылына караганда ярты гасыр тирәсе алданрак барлыкка килгән.

Бу авылда яшәүче йомышлы татарлар Петр I Указы нигезендә Хәзәр (Каспий) диңгезенә төшереләчәк корабларны төзү өчен верфь оештыруда катнашкан. (Казан губернасында яшәгән 56 мең кеше корабль төзүгә файдаланыла торган агач хәзерләүгә – лашман хезмәтенә мәҗбүр ителгән).

Кече Чынлы – Республика һәм аннан читтә дә танылган күренекле галимнәр, сәнгатькәрләр, язучыларның туган авылы да. Кыяметдин Миңлебаев – гомерен милли мәдәниятне үстерүгә һәм ана телен саклауга багышлаган каләм иясе; Мансур Хөснетдинов – СССР мәгариф отличнигы, Россия Федерациясенең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре; Ринат Таҗетдинов – СССР Дәүләт, Республиканың Г. Тукай бүләге иясе, Татарстанның халык артисты; Харис Төхфәтуллов – К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты. Шулай ук медицина фәннәре докторы, профессор, Башкортстан Республикасының атказанган табибәсе Ф. З. Мирзаева-Җәмбиханова; медицина фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән эш-

леклесе И. Г. Салихов; Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Ә. Х. Алиева; филология фәннәре докторы Р. Р. Җамалетдинов; педагогика фәннәре докторы Җ. А. Хөсәенов; икътисади фәннәр докторы Җ. Г. Басыйров һ. б.

**Уби** – Кече Чынлы елгасы буенда, Иске Чүпрәледән 20 чакрым төньяк-көнчыгышта урнашкан чуаш һәм, аз санда булса да, урыслар яши торган авыл. Ул XVII йөздә төзелә башлаган, дип фараз ителә. Бу авылны җирле халык Село Уби, Чиркәүле Уби, Базарлы Уби дип тә атап йөртә. «Село Уби» атамасы – монда урыслар да яшәгәнлектән, «Чиркәүле Уби» – төрле яклап ерактан ук күренеп торучы зур чиркәүнең, бүтән авыллардагыга караганда иртәрәк салынуыннан, «Базарлы» атамасы исә монда XIX йөздән башлап ерак-ерак авыллардан, хәтта Сембердән, Буадан, Чуашстаннан да сәүдәгәрләрне җәлеп иткән зур базар эшләвеннән килә, күрәсең.

Уби авылларының берсе – **Кече Уби** (халык аны Турхан Уби дип тә йөртә) Чувашия Республикасындагы Батыр районы, Турхан авылыннан күчеп килүчеләр тарафыннан төзелә башлаган. Алар Усалук, Келней, Чупай һәм Мәмәт атлы булган имеш. Исемнәренә караганда, алар мәҗүси диндәге кешеләр. Беренче йортлар Кече Чынлы елгасы буена салынган һәм алар, төньякка таба күчеп, Йомышлы Уби авылын барлыкка китергәннәр.

Тарих белән кызыксынучы Николай Хмелев фикеренчә, Уби авылы 1658 елда төзелгән. Бирегә иң беренче булып төпләнүчеләр Чупай белән Искәндәр булган, диләр.

Бу авылларда төрле генеоалогик токымнар, этник төркемнәр яшәгән: Село Убида, әйткәнебезчә, чуаш һәм урыслар, Кече Убида – мукшылар, Татар Убиенда – татарлар, калганнарында – чуашлар.

Авылларның атамасы нинди мәгънәгә ия булуын да төрлечә фаразлыйлар.

*Уб–ув* – тамыры белән ясалган кырыклап торак пункт атамасы билгеле. Җирле халык «Уби» атамасын Упа (чуашча – *аю*) сүзенә мөнәсәбәтле дип саный.

Әлеге атаманың «Упей» – Олуг + би, ягъни зур түрә компонентларыннан кыскартылып ясалган булуы да ихтимал. Татар Убие авылында туган галим Ә. Булатов шундыйрак фикердә иде.

**Татар Убие** авылына нигез салучылар Иске Кәкерле авылыннан күченеп килгәннәр, дип фаразлана. Моның шулай булуын Иске Кәкерленең зыялы шәхесе Рифкат Иматдинов бабаларыннан сорашып калган дәлилләр белән сасларга тырыша. Аның язмаларыннан бер өзек китерик: «Татар Убие авылына беренче булып Иске Кәкерледән 12 гаилә күченеп килә. Алар арасында Ишнияз, Аббаз, Абдулла, Кадыйр исемле гаилә башлыклары булган имеш. Искекәкерлеләр тернәкләнеп яшәп киткәч, Яңа Кәкерле авылының да җирсезлектән интегүче 12 гаиләсе бу тирәгә күченү теләген белдергән. Шул рәвешчә яңа нигез тернәкләнеп үсеп киткән. Бу авыл кешеләре соңрак, Чиркәүле Убида була башлаган базарларда, көз көннәрендә оештырыла торган ярминкәләрдә төрле тауар белән сату иткәннәр, «барышниклар» (сатып алучыларны котыртып йөрүчеләр) булып та үзләренә шөгыль тапканнар».

Авылда 1859 елда 23 йорт булуы мәгълүм. Анда 107 ир заты, 90 хатын-кыз яшәгән, авылда мәчет эшләгән. Иске һәм Яңа Кәкерле авылларыннан күчеп килүчеләрнең 24 гаилә булганлыгы шушы рәсми мәгълүмат белән дә раслана (бер гаилә бәлки монда яшәп калмагандыр). Димәк, бу авылга әле алда искә алынган еллар тирәсендә нигез салынган, дияргә мөмкин.

**Шланга** авылы Чувашия Республикасы белән чиктәш, Чүпрәледән 15 чакрым көнбатышка урнашкан татар-мишәр авылы. Ул XVII йөздә төзелә башлаган (Населенные пункты Республики Татарстан. Казань, 1997).

XIX йөздә биредә 570 ләп йорт булган, 3 мәчет эшләгән. «Югары оч» мәчете каршында 1896 елда мәдрәсә ачылган. Анда малайлар дин белеме алганнар.

Шланга авылы атамасының этимологиясендә нинди мәгънә ята икән? Беренче карашка чуаш телендәге шал+ан+га компонентлары бар. Чуашлар «шалан» дип сазлыкта үсә торган наратбаш үләненә әйтәләр. Удмуртлар да саз наратбашын шулай атыйлар. Тилгән тибындагы ерткыч кошны чуашлар «шаланка» диләр. Шул ук кошны марилар «шаленге» дип атыйлар. Бу удмуртча да шулай.

В. К. Магницкий «Чувашские языческие имена» исемле китабында түбәндәгеләрне язып үтә: «Шаланга – птица, русского названия которой я не могу доискаться. Об этой птице у чуваш рассказывается легенда, из которой мне известно лишь то, что „шалан-

га” за что-то наказанный богом мучительным томлением жажды. Летает-де она над лесом и кричит жалобно; крик ее предвещает дождь. Прозвища „Шеланга” носят села» (10 б.).

Шланга атамалы торак пунктлар шактый күп. Мәсәлән, Шеланга – Татарстанның Югары Ослан районында, Шелангер – Мари Эл Республикасының Звенигов районында, Шламка – Самара өлкәсенең Челно-Вершинский районында. Шиланка – Балык Бистәсе районында да бар.

Шланга (җирле халык аны «Шланка» дип атый) авылының исеме шул төбәктәге үсемлек атамасыннан килеп чыккан булса кирәк. Бу авыл тирәсендәге урманнарда кытыршы сабаклы вак камыш үләнен җыеп, буялмаган такта идәннәрне кырып юар өчен файдаланалар иде. Әлеге үсемлекне Чүпрәле сөйләшендә «шлан» диләр.

Шлангалылар авылдашлары полковник Каюм Шәрәфетдин улы Айметдинов истәлеген горурлык белән саклыйлар.

**Яңа Ишле** – Карлы елгасы (Зөя елгасының сул кушылдыгы) бассейнында район үзәгеннән 11 чакрым төньякта урнашкан татар авылы. XVII йөзнең ахырында төзелә башлаган. Бу факт картлар сөйләве буенча да, нәсел шәҗәрәләренә нигезләнеп тә раслана.

Авылга нигезне, яшәгән җирләрендә чәчүлек мәйданнар җитешми башлагач, күченеп утыручылар салган. Бу урынны сайлап нигез коручыларның берсе – Каракитәдән, икенчесе – Чүпрәледән, өченчесе – Иске Ишле авылыннан, дип гөманлыйлар. Чүпрәледән килүчесен шик астына алучылар да бар. Ул Чокалы авылыннан күчкән булырга тиеш, диләр.

Яңа Ишле аксакаллары сөйләвенә караганда, биредә башлап яшәүче өч нәселнең берсе – Мамайныкылар (бу нәселнең Сарытау якларыннан килүе ихтимал). Икенчесе – Кыргызныкылар (Пугачев яуларында катнашучы татарларны кайбер очракта кыргызлар дип атау очрый. Бу кешеләр Касыйм ханлыгында яшәүчеләр булырга да охшый). Өченче нәсел исә мөселман динендә булмаган, имеш. Үткәннәрне сагынып сөйләүче кешегә: «Син Мамай заманнарын сөйләп утырма әле», – диләр иде. «Мамайныкылар», «кыргызныкылар» дип сөйләүне бу нәселләрнең монда күптән яшәүләренә ишарә дип кабул итәргә була.

**Иске Ишле** Бизнә елгасы (Сура елгасының уң кушылдыгы) бассейнында район үзәгеннән 13 чакрым төньяк-көнбатышта

урнашкан. Бу авыл Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. 1967 елда археология экспедициясе монда болгар чорына караган каберлек урынын тапкан иде. Каберлек авылдан көнбатышка таба, Безтөрле инешенең уңъяк ярында урнашкан. Аны «Иске зират» дип атап йөртәләр.

Болгар чорында монда угро-фин телле ыруглар – мари, мукшы, чуашлар яшәгән. Казан ханлыгы җимерелгәч, бирегә йомышлы татар-мишәрләр килә башлый. Алар җирле халыктан: «Монда нинди кешеләр яши?» – дип сорагач, аларга: «Без төрле халык», – дип җавап биргәннәр имеш. Шуннан чыгып, авылны да, инешне дә «Безтөрле» дип атаганнар, имеш.

Моның нигезендә «Ишле» атамасына да ачкыч шәйләнә: «төрле», «күптөрле», «ишле» сүзенең мәгънәләре якын бит. Шулай ук «күбәү», «күп» төшенчәсендә дә кулланыла (Ашмарин Н. И. Болгары и чуваши. Казань, 1902. С. 59).

Ишле авылыннан чуашлар 3–4 чакрым көньяк-көнбатышкарак күчеп, Чуваш Ишлесенә нигез салалар.

Чыгышлары белән урыс, мукшы, чуаш нәселләренең, мөселман динен кабул итеп, шул авылда калучылары да була. Руслар төбеннән – Ганиевлар, мукшылар төбеннән – Җәббаровлар, чуашлар төбеннән Фәезхановлар нәселе таралган.

Ил һәм Республика күләмендә танылган аерым шәхесләрнең нәсел башы Иске Ишле авылына барып тоташуы белән бөтен район горурлана. Мәсәлән, СССРның халык рәссамы Харис Якуповның әтисе Абдрахман – Иске Ишледән.

**Яңа Кәкерле** – Чувашия белән чиктәш, Иске Чүпрәледән төньякта 14 чакрым ераклыкта Карлы елгасының бер тармагы (Зөя елгасының сул кушылдыгы) буена урнашкан, татар-мишәрләр яши торган авыл.

1723 елда халык санын исәпкә алу документында (Вторая ревизская сказка) Яңа Кәкерле авылында 76 татар-мишәр һәм чуаш гаиләсе булуы теркәлгән.

Мөселман динен кабул итүче чуашлар Өчөйле авылында яшәгән. Яңа Кәкерле белән бу авыл арасы 2–3 кенә чакрым. Хәзер ул авыл Трехизб-Шемурша дип йөртелә. Урыс миссионерлары биредә чукындыру эшен «зур тырышлык куеп» башкарганнар. Бу авылдагы борынгырак фамилияләрнең татар исемнәре нигезендә булуы дә әлеге фикерне раслый.

Әлбәттә, Яңа Кәкерледәге чуашлар нәселенең Өчөйлегә китмәгәннәре инде әллә кайчан ассимиляцияләнгән, мөселман динен, гореф-гадәтләрен кабул иткән.

Авыл халкы якташлары Советлар Союзы Герое Зариф Алимов белән генә түгел, җырчы Илсур Сафин (Илсаф), филология фәннәре кандидатлары Әлфинур Зиннәтуллина, Эльвира Вәлиуллина-Сафина һ. б. белән дә горурланалар.

**Яңа Элмәле** авылында чуашлар яши. Чынлы елгасы буена район үзәгеннән 7 чакрым көньяк-көнбатышка урнашкан бу авыл Иске Элмәледән күчеп килүчеләр тарафыннан нигезләнгән, мондый исемдәге торак пунктның Чирмешән районында да булуы мәгълүм. 1750 елларда бирегә миссионерлар мәҗүси диндәге чуашларны чукындырырга килгәннәр. Димәк, аның төзелә башлавы XVIII йөз башларына туры килүе мөмкин.

**Яңа Чокалы** – татар-мишәр авылы. Шулай ук Чынлы елгасы бассейнында район үзәгеннән 9 чакрым көньяк-көнбатышка урнашкан. Бу авылның Иске Чокалыдан күчеп килүче кешеләр тарафыннан 1686 елда нигезләнүен күрсәтүче мәгълүматлар бар (Населенные пункты Республики Татарстан. Казань, 1997). Авылның зыялы затлары фикерләренә караганда, бирегә 16 гаилә күченеп килгән. А. Н. Зерцаловның 1896 елда Сембердә басылып чыккан «Материалы для истории Симбирска и его уезда» дигән китабында бу авылда 1667 елда ук татарларның 26 хуҗалыгы булуы турында хәбәр ителә.

Яңа Чокалы авылында башта чуашлар да, мордвалар да яшәп караган. Сембер ягыннан килүче урыслар да бәхетләрен сынаганнар. Ләкин алар монда төпләнеп калмаганнар. Бирегә башка төбәкләрдән дә йомышлы татарларның килгән булуы ихтимал.

Мәскәү дәүләт консерваториясе профессоры, җырчы, Татарстанның атказанган артисты Асия Измайлованың нәсел төбе шушы авылда. Күренекле татар язучысы Шамил Рәкыйпов, аның бертуган энесе – язучы, шагыйрь Роберт Рәкыйпов һ.б. авыл халкының мактанычы булып санала.

**Матак** – Бизнә елгасы (Сура елгасының уң кушылдыгы) бассейнында Иске Чүпрәленең төньяк-көнбатышында 10 чакрым ераклыкта урнашкан, XVII йөздә салынган чуаш авылы. Авылның атамасы Татарстан Республикасында бердәнбер түгел. Әлки районында Базарлы Матак, Иске Матак, Югары Матак авыллары бар.

Бу сүз борынгы мәҗүси чуаш антропонимы булган, дигән фикерне алга сөреп, Н. И. Ашмарин Матакның ирләр исеме булуын яза. Чуаш телендә «матак» сүзе «кыска» мәгънәсен белдерә. Элек чуашларда кыска буйлы кешегә шундый кушамат тагылган, һәм аның, соңрак, топонимга әверелгән булуы мөмкин. Тагын бер дәлил: 1625 елда Казан воеводасы каршында тырышып хезмәт итүче чуаш Мингазка Матакка Була елгасы буена irекле күчеп урнашуга рөхсәт бирелгән имеш. Ул монда урын сайлап, яшәп караган. Ләкин бу тирәдә нугайлар һәм башка ыруг кешеләре аны әледән-әле талап торганга, ул бу тирәдән качып, Бизнә елгасы буена килгән. Урнашыр өчен урын эзләп йөри торгач, ул хәзерге Матак авылы тирәсенә килеп чыккан. Монда да, әлбәттә, аңа кадәр үк килеп урнашкан, болгар чорында ук яшәү урынын шунда сайлаган ыруглар булган. Алар Матакны яннарына сыендырганнар.

1957 елда оештырылган археологик экспедиция вакытында Матак авылының үзәк өлешендә – Безтөрле елгасының уң як ярында – борынгы болгар чорына караган торак пункт булганлыгы ачыклана.

Матаклылар якташлары Советлар Союзы Герое С. А. Уганин, СССРның атказанган укытучысы Н. И. Кольцов, медицина фәннәре докторлары Т. П. Тайрова һәм В. Ф. Петровлар, КПСС Үзәк Комитетының политбюросы әгъзасы С. В. Кузнецов, философия фәннәре докторы Н. В. Муровцев, РФ Хәрби көчләре генералы В. П. Кузнецов, Мари Эл Республикасы Сәламәтлек саклау министры урынбасары Д. А. Юманов, Россия Федерациясенең атказанган укытучысы П. С. Тайров исемнәре белән горурланалар.

**Чуваш Ишлесе** Бизнә елгасының югары агымында (Сура елгасының уңъяк кушылдыгы) район үзәгеннән 9 чакрым ераклыкта көнбатышта урнашкан. Аның авыл буларак формалаша башлавы XVII йөзгә нисбәт ителә. Монда чуашлар Иске Ишле авылыннан килгәннәр һәм алар Матак авылының мәҗүси диндәге милләттәшләре белән туганлашып, дуслашып, соңрак христианлаштыру сәясәтен кичергәннәр. Әле дә бу авылның тормышы Матак белән тыгыз бәйләнгән.

**Мунчәли** (Мончәли, Мочалей) – Чувашия Республикасы белән чиктәш, район үзәгеннән 10 чакрым көнбатышка урнашкан.

Бу авыл Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. Аның төзелә башлавына, атамасының килеп чыгышына нисбәтле төрле риваятьләр

сакланган. Аймәтов Зыятдин һәм Әбелханов Усман бабайларның исән чакта сөйләгәннәре буенча, бирегә Алатыр ягыннан (төгәлрәге, элекке Курмыш өязеннәндер. – *Р. С.*) Иске Мунчәли дигән авылдан күчеп килгәннәр. Алар өчәү булганнар. Шуларның берсе мукшы милләтеннән булган, диләр. Шуннан авылның бер очында мукшылар нәселе яшәгән. Мукшының исеме Сабай булган имеш. Ул тора-бара татарлашкан. Субаев фамилиясе шуннан килә, дип санала. Хәзер исә бу авылда мондый фамилияле кешеләр яшәми инде. Килүчеләрнең берсе – Бухари, икенчесе Шаһвәли исемле булган имеш. Мунчәли башта хәзерге урында булмаган. Ул Шлангага якынрак – төньяк-көнбатыштарак булган. Ул урынны хәзер «Паварь тирәсе» дип йөртәләр.

Әбелханов Усман бабайның үзе әйтеп яздырган нәсел шәҗәрәсе 11 буыннан иде: Сәмак – Тәбускин – Арслан – Мостафа – Әхтәм – Әзмухан – Әбелхан – Миначетдин – Усман – Аделҗан – Альфред. Усман карт әйтүенчә, Сәмак картның әтисе һәм бабасы да монда яшәгән. 2008 елның июлендә бу авыл халкы, төрлечә исәпләүләр нәтиҗәсендә уртак карарга килеп, авыллары оеша башлауның 500 еллыгын зурлап бәйрәм иттеләр.

Авылның атамасына нисбәтле фаразлаулар шактый. Кайберәүләр аны гадиләштереп, сүзгә яраштыру юлы белән «мунчалы өй» мәгънәсенә бәйләргәдер, дип фикерлиләр. Янәсе, беренче килүчеләр, өй салгач, янына мунча да ясап куйганнар, башка авыл кешеләре шуны күреп: «Ай, мунчалы өй!» – дип гаҗәпләнгәннәр булып чыга. Шуннан бу сүз «Мунчәли»гә әверелгән имеш.

Илебездә «мочалка» (юкә сүсе) исеменә бәйләнешле түгелме икән, дип уйларга мөмкин атамалар да бар. Муса Акъегетзадә (мәгърифәтче татар язучысы) нәселе Пенза губернасының Чембар өязе, Мочали авылыннан булган. Татарстанда Мамадыш районында Иске һәм Яңа Мочалкино авыллары бар. Мочали – Волгоград өлкәсендә, Мочалеевка – Самара өлкәсендә, Мичалейка – Пенза өлкәсендә. Болар, билгеле, төрки нигездәге атамаларның урысча яңгырашы. Алар төрки телдә «мунчала» нигезен тәшкил итәләр кебек. Ләкин бу фараз гына.

Бу атама мишәр кабиләләренең бер тармагы булган «мочар» атамасына нисбәтән төзелгән булуы да ихтимал. «Финнәр кабиләсеннән килеп чыккан „мочар" кабиләләре Ока елгасы буенда яшәгәннәр, дип саныйлар. Бу кабиләләр мишәрләрнең формалашуында

шактый роль уйнаган» (Мухаммедова Р. Г. Татары-мишари. М., 1972. С. 30).

Мәҗүси исемнәр арасында Мочак, Мочей, Мочи кебек атамалар да булган (Магницкий В. К. Чувашские языческие имена. Казань, 1903). Димәк, бу этнонимга нисбәтле атама. Күчеп килүчеләр авылга элек яшәгән авыллары атамасын биргәннәр, әмма ул авыл мишәр – мочар этнонимына бәйле туган: мочар + лей (мордва телендә – елга), димәк, мишәрләр яшәгән елга буендагы авыл, яки шулай ук ике тамырдан: мочаг (юеш, кипми торган үзәнлек) + иле (ил, авыл). Чувашия белән Татарстанны аерып торучы чиктәге Әсән елгасы буенда сазлыклы урыннарны исәпкә алсаң, бу фикер дә куәтләнә кебек.

Мунчәли – Буа өязенә кергән волость авылы. 1859 елдагы статистик мәгълүматка игътибар итсәк, бу авылда 105 йорт булып, анда 474 ир заты һәм 529 хатын-кыз булуы билгеле. Бу чорда авылда ике мәчет эшли. XX гасыр башларында исә монда 600 дән артык хуҗалык булган, 4 мәчет һәм 4 мәдрәсә төзелгән, 2000 ләп кеше яшәгән, дип сөйлиләр.

Мунчәли ике каһарманның – Советлар Союзы Герое Нурулла Фазлаев һәм Социалистик Хезмәт Герое Абдулла Сабирҗановның туган авылы.

Мунчәли халкы галим Нурмөхәммәт Хисамов, Татарстан прокуроры булып эшләгән Сәйфихан Нәфиев, шагыйрь Рәмис Әймәт һ. б. белән горурланып яши.

**Чуваш Чүпрәлесе** – Кече Чынлы елгасының (Зөя бассейны) югары агымында район үзәгеннән 4 чакрым көньяк-көнбатышта урнашкан авыл. Аксакаллары фаразлавы буенча, бу торак пунктка 1620–1930 еллар тирәсендә нигез салына башлаган. Шулай да бу елларда, урыс патшасына намуслы хезмәт иткән өчен җир биләү хокукына ия булган өч кеше – Еливан, Ильмуха һәм Кранха (бу исемнәр авыл тарихына мәгълүматлар туплаучы Н. Матросовның мәкаләсеннән алынды) килеп урнашкач та, авыл тиз генә үсеп китми әле. Урман һәм сазлыклар белән уратып алынган бу тыныч якларда тормыш акрын җайга салынган. Алатыр ягыннан килгән әлеге мәҗүси диндәге өч чуаш гаиләсеннән үскән буыннар янына төньяктан – хәзерге Чувашиядәге Әсән, Кызыл Камыш якларыннан да – күчеп килүчеләр исәбенә авыл үсә башлый.

Чуваш Чүпрәлесе авылында туып үскән һәм полковник дәрәҗәсенә күтәрелгән П. Филиппов һәм В. Колпаков, очучылардан И. Яшин, В. Еливанов, Г. Алиев кебекләр бу якның горурлыгы булып тора.

**Каракитә** – Бизнә елгасы бассейнында район үзәгеннән көнбатышка таба 20 чакрым ераклыкта урнашкан. Авыл XVII гасырда төзелә башлаган. Нигез салыну Казан ханлыгы чорында булган, дип гөман ителә.

Каракитә атамасының килеп чыгышы турында аксакаллар болай сөйли: «Авылга беренче килүчеләр, урман эчендә бәләкәй алан табып, торак урыннарын шунда төзи башлыйлар. Бу авылда чуашлар һәм татарлар яшәгән. Менә авылга ике юлчы урыс килеп чыга. Алар шундагы крәстияннардан: „Бу нинди авыл?” – дип сораганнар күрәсең, ә алар телен аңламаган кешеләр, ни әйтергә белмичә, үзара: „Карап китүчеләрдер болар?” – дип сөйләшәләр икән. Шуннан бу урыслар, әлеге авылны исәпкә алганда, аны „Каракитә” дип яздырганнар янәсе».

Каракитә атамасы, В. К. Магницкийның «Список селений мишарей в Буинском уезде Симбирской губернии» исемле хезмәтеннән чыгып хөкем иткәндә, чуашча «Хура катта» (кара агачлык) сүзенә бәйләп аңлатыла.

Авыл халкы татар халкының күренекле шагыйре Габделҗаббар Кандалыйны үзләренең якташы дип саный. Чынлап та, галим Миркасыйм Госманов: «Кайбер мәгълүматларга караганда, Кандалыйлар нәселе элек Каракитә авылында яшәгән булган, Иске Кандалга шагыйрьнең ерак бабаларыннан берсе барып урнашкан», – дип яза. (Аңа кадәр бу фикерне Хатип Госман да әйткән иде.)

Габделҗаббарның нәсел шәҗәрәсе сакланып калган. Ул Каракитәдә яшәүче бабалары ягыннан түбәндәгечә бара: Йосыф – Ибраһим – Биктимер – Ибнейәмин – Габделмәҗит. Димәк, Йосыф бабайның бу авылга килү вакыты 1675 еллар тирәсе булуы мөмкин.

Каракитәлеләр шагыйрь Шәрәф Мөдәррис, биология фәннәре докторы Абдуллаҗан Җәләлов, классик көрәш буенча ике тапкыр дөнья чемпионы Шамил Хисаметдинов кебек күренекле авылдашларын хөрмәтләп яшиләр.

**Татар Бизнәсе** – Бизнә елгасы буенда Иске Чүпрәледән 10 чакрым көнбатышта урнашкан авыл. Ул Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле.

Авыл аксакалы Мәхмүтов Кадыйр бабай истәлекләренә караганда, «Бизнә» дигән сүз урысларның «төпсез» дигәнен аңлата икән. Монда кешеләр килеп утырганда бу тирәдә урманнар, күлләр булган. Монда татарлар белән урыслар да килгән. Килеп урнашучылар 7 кеше булган. Берсеме, икесеме – урыс милләтеннән, диләр иде. Берсенең аты Утес булган.

Күлләрнең бик тирән, төпсез кебек күренгәннәренә карап, монда килүче урыслар «без дна» (төпсез) дигәннәр һәм шуннан Бездна – Бизнә атамасы калган.

«Бизнәнең җир биләмәләре зур булган. Әле хәзер дә Утесовка дип йөртелә торган урын бар. Ул җирләр дә безнеке булган», – ди Кадыйр бабай. Аның истәлегеннән чыгып хөкем йөртсәк, авыл атамасы гидронимга мөнәсәбәтле туган.

Әмма, бу тирәдәге авылларга иң элек чуашлар һәм мордвалар нигез салганын искә алсак, әлеге атаманың мордва телендәге «пезнака» (баткаклык, сазлык) сүзеннән килүе дә ихтимал.

Әгәр авылны төрки телле халык вәкилләре, ягъни биләр төзи башлаган дип гөман итсәк, аның урманнар арасындагы *үзәнлектә* булуын да исәпкә алып, «биләр үзәнлеге» дигән атама бирелү ихтималы да юк түгел. Кыскарту нәтиҗәсендә ул «биләр үзәнлеге» – «биүзән» – «бизнә» рәвешенә кергәндер, бәлки.

Татар Бизнәсеннән авылдашлары гына түгел, бөтен район халкы да горурланырдай шәхесләр күтәрелеп чыккан: филология фәннәре кандидаты Шәйхелислам Садретдинов, техник фәннәр докторы Нияз Хисмәтов һ. б.

**Түбән Чәке** – Зур Якла елгасының (Сура елгасы бассейны) уң ярында Иске Чүпрәледән көньяк-көнбатышка таба 24 чакрым ераклыкта урнашкан. Бу татар авылына XVII йөздә нигез салынган.

«Чәке» атамасы борынгы болгар телендә кулланышта йөргән «чанка» – «текә» (бу сүз чуаш телендә хәзер дә бар) сүзенә нисбәтле булса кирәк. Борынгы болгар сүзе «чике», «чика» да чуаш телендә кулланыла һәм «чик», «кырый» төшенчәсен белдерә.

Аралары берәр чакрым тирәсе булган ераклыкта урнашкан **Югары Чәке** авылына да XVII йөздә нигез салынган, дип исәпләнә. Бу авыл Ульяновск өлкәсе белән чиктәш. Ә район үзәгеннән 22 чакрымда булган **Иске Чәкедә** чуашлар яши һәм ул Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле авыл.

Городище җирле үзидарәсе составына керә торган **Яңа Чәке** авылы район үзәгеннән 24 чакрым көньякта урнашкан. Бу авыл XVIII гасырда барлыкка килгән, дип исәпләнә.

Түбән Чәкедә заманында өч мәчет булган. XIX йөз урталарында бер мәчеттә Мифтахетдин Атласов муллалык иткән. Аның гаиләсендә 1886 елның 15 (29) августында булачак тарихчы галим Һади Атласи туган.

Чәке авыллары халкы татар мәдәни тормышында зур урын тоткан Афзал Хәйретдинов, Иршат Хәйретдинов, Рафаэль Ильясов, Клара Таҗиева, галим Илгиз Мөдәррисов, «ТАИФ» җәмгыяте җитәкчесе Альберт Шиһабетдинов, професор Феликс Шиһабетдинов белән горурланып яшиләр.

**Татар Шатрашаны** авылы – Ульяновск өлкәсе белән чиктәш, Иске Чүпрәледән 25 чакрым көньяк-көнбатышта урнашкан. Ул XVI йөз ахырында барлыкка килгән, дип исәплиләр.

Бу авылның тәүге нигезе Урыс Шатрашаны урынында була. Әмма ул чорда тирә-якта урманнар, аның эчендә күлләр, баткаклык-сазлыклар булу сәбәпле, мондагы халык вакытлыча төзелгән шатыр (чатыр) рәвешендәге урыннарда көн күргән. Авыл атамасын башкача аңлатырга тырышучылар да бар. Мишәр сөйләшендә «шадыр» сүзе «шат күңелле, кәефле» мәгънәсендә йөри. Авыл исеменең асылында чуаш компоненты (яки борынгы болгар сүзе) ятарга да мөмкин. Чуаш сүзе *шатра сан* – шадра йөз мәгънәсендә.

Җирле халык авыл атамасын Шатырхан исеме белән бәйләп күрсәтә. Икенчеләре исә, авылга нигез салучы кеше шадра чырайлы Әмирҗан исемле булган, диләр.

Урыс Шатрашанында алпавыт Травкинның биләмәләре булган. Шунда спирт заводы да төзелгән. Татар Шатрашанында Сембер фабрикантлары Акчуриннарның сукно фабрикасы филиалы урнашкан булган. Бу филиалның идарәчесе Әнәс исемле кеше авылның баена әверелгән.

Күренекле галим Шиһабетдин Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтендә бабасы (әнисенең әтисе) Габденнасыйрның әнисе – Бибирабига Мөслим кызының Шатрашан авылыннан булуын күрсәтә.

Сүземне Рафаил Сиражиның шундый сүзләре белән төгәллисем килә:

Чүпрәлеләр – якташ-парәләрем,
Ихлас белән сезне яратудан
Күңелемдә фикер тәлгәшләнә –
Уртак гамьдә яшәп, җан атудан...

И Туган як, сине сөюемне
Сүзләр белән генә раслыймын,
Олуг данны илгә таратучы
Фида җаннар белән бер сафта мин!

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН ТАНЫР

*Дария Рамазанова*
*Миңнира Булатова*

Билгеле булганча, җирле сөйләшләргә хас тел үзенчәлекләре сөйләш вәкилләренең этник формалашу тарихы белән үзара бәйләнгән була. Чүпрәле сөйләшенең формалашуын да тарих белән бәйләп карау әһәмиятле. Галимнәр, әлеге төбәктә төркиләрнең яши башлавы бик борынгы чорларга барып тоташа, дип саныйлар. Аларның фикеренчә, төркиләр бу тирәләрдә безнең эраның III–IV гасырларында ук билгеле булганнар (В. Ф. Генинг, А. Х. Халиков, М. З. Зәкиев һ. б.). Болгар дәүләте җимерелгәннән соң, XIII–XIV гасырларда бу тирәләргә татарларның актив рәвештә күчүләре төрле характердагы мәгълүматлар (язма чыганаклар, кабер ташлары, легендалар һ. б.) буенча билгеле. Бу турыда Һ. В. Йосыпов, Каюм Насыйри хезмәтләреннән карарга мөмкин.

Мишәр авылларының барлыкка килүе нигездә XVII гасырга карый. Рус дәүләте, үзенең көньяк чикләрен ныгыту өчен, чик саклау сызыклары һәм ныгытмалар төзетә. Шундыйларның берсе Карле сызыгы була һәм анда Түбән Новгород, Сембер (Курмыш һәм Алатыр өязләре), Тамбов (Темников өязе), Пенза губерналарыннан мишәрләр, морзалар күчерелеп утыртыла (Арсланов Л. Ш. Татарские говоры правобережных районов Татарской и Чувашской АССР: дис. ... канд. филол. наук. Казан, 1966. С. 8–27). Л. Ш. Арсланов тарихи чыганаклардан мондый фактлар китерә: «деревни Дрозжанова куста» – бу «куст»ка караган авыллар 1665–1667 елларда ук оброк кенәгәләрендә теркәлгән; шушы ук оброк кенәгәләрендә Шатрашан, Каракитә һ. б. авыллар да телгә алына; Зур Чынлы авылына 1674 елда Сембер өязе, Чокалы авылы йомышлы

татарлары нигез салган; Иске Шәйморза авылына 33 иптәше белән Умерка Шаймурзин нигез сала; Татар Бизнәсе 1685 елгы грамотада телгә алына; Мунчәли (Мочалей) авылына XVII гасыр урталарында Түбән Новгород губернасындагы Мунчәли авылы кешеләре нигез сала һ. б. Шушы ук фактлар халык арасында яшәп килә торган легендаларда да чагылган.

Чүпрәле сөйләше – көнбатыш диалектның *ц*-лаштыручы сөйләшләреннән берсе. Административ яктан бу сөйләш нигездә Татарстанның Чүпрәле районында таралган һәм сөйләшнең исеме дә шуннан алынган.

Географик яктан ул Тау ягындагы урта диалектның көнбатыш диалектка тоташа торган коридор сөйләш – тархан сөйләшенең көнбатышына тоташа. Төньякта сергач сөйләше белән чикләнә.

Чүпрәле сөйләше үзенчәлекле фонетик күренешләр һәм башка сөйләшләрдә табылмый торган диалекталь сүзләр белән дә мөстәкыйль сөйләш булып аерылып чыга.

Сөйләшне өйрәнү тарихы турында кыскача түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин.

Мөстәкыйль сөйләш буларак һәм шушы ук исем астында ул Л. Җәләй хезмәтләреннән үк билгеле.

Сөйләш беренче мәртәбә эзлекле рәвештә Л. Ш. Арсланов тарафыннан Татар халык сөйләшләре атласына материал җыю барышында өйрәнелә һәм аның кандидатлык диссертациясенең бер бүлеге буларак тасвирлана, татар диалектологиясендә беренче мәртәбә әлеге сөйләшнең үзенчәлекле яклары күрсәтелә, фәнгә кертелә.

Алга таба әлеге сөйләшкә, төрле максатларны күздә тотып, З. Р. Садыйкова, Ф. С. Баязитова, Т. Х. Хәйретдинова һәм Д. Б. Рамазановалар да экспедицияләр уздыралар һәм үзләренең хезмәтләрендә төрле мәгълүматлар китерәләр. Нәтиҗәдә татар теленең диалектологик сүзлекләрендә (1969; 1993; 2010) чүпрәле сөйләшеннән бай лексик материал чагылыш таба. 2008 елда чыккан «Татар халык сөйләшләре» (2 китапта) дигән тупланмада чүпрәле сөйләше З. Р. Садыйкова тарафыннан тасвирлана.

Чүпрәле сөйләше турында бай мәгълүмат, әһәмиятле факторлар И. Ә. Гаффаров хезмәтләрендә дә яктыртыла. Туган ягының чын мәгънәсендә патриоты, үз төбәгенең телен, гадәтләрен яхшы белүче кеше буларак, И. Ә. Гаффаров үзенең күзәтүләрен, күренекле

шәхесләргә бай булган туган ягын тарихта яктыртып калдырырга тели, шул максатта «Туган як мирасы» (2004), «Туган як мирасы» (икенче китап, 2005), «Мишәрләр. Тарих һәм тел» (2011) китапларын бастырып чыгара.

И. Ә. Гаффаровның әлеге хезмәтләрендә Чүпрәле төбәге татарлары гына түгел, бөтен татар халкы тарихына караган мәсьәләләр дә күтәрелә: Кемнәр алар мишәрләр? Чүпрәле төбәгенә ничек килеп чыкканнар? Чуашлар белән бәйләнешләре нинди? Аларның сөйләшендә нинди диалекталь үзенчәлекләр һәм сүзләр бар? Нинди йолалар, гореф-гадәтләр сакланып килә? Гомумән, бу китапларда Чүпрәле сөйләше турында бай материал бирелгән, автор һәм тарихчы, һәм филолог буларак әһәмиятле хезмәтләр язып бастырган. Алар татар фәнендә, тарихында һәм диалектологиясендә әһәмиятле өлеш булып тора. Хезмәтләрнең әһәмияте тагын шунда: автор үзе күтәреп чыккан мәсьәләләргә җавап бирә, үзенең карашын белдереп бара. Яшь буында туган ягына, туган теленә мәхәббәт тәрбияләү чарасы буларак та И. Ә. Гаффаровның хезмәтләре безгә бик кирәк.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Чүпрәле якларына оештырылган комплекслы махсус экспедиция төбәкнең телен, фольклорын гына түгел, тарихын, сәнгатен, музыкасын һ. б. аспектлардагы мәгълүматларын да туплап өйрәнү максатын күздә тотып уздырылды. Без исә Чүпрәле сөйләшенең диалекталь күренешләрен кыскача яктыртып үтәчәкбез.

### Сөйләшнең фонетик үзенчәлекләре

Чүпрәле сөйләше *а* авазын, көнбатыш диалектка хас булганча, ачык итеп, иренсезләштереп әйтү белән характерлана: *алма* – әд. әйтелеш а°лма°, язылышта *алма*, *бала* – әд. әйтелеш *ба°ла°*, язылышта *бала* һ. б. Авазның ачык әйтелүе барлык позицияләрдә дә саклана.

Көнбатыш диалекттагы кебек үк, чүпрәле сөйләшендә дә *ә* һәм *ү* авазлары алгырак позициядә һәм таррак ясалышлы итеп әйтелә: *үрдәк* – үрдәк, *күлмәк* – күлмәк һ. б.

Башка сузык авазларның әйтелеше әдәби телдәгечә.

Бер төркем үзенчәлекләр сузыклар тәңгәллегендә күзәтелә. *Ы ~ а*: *йаңы* – йаңа, язылышы – яңа; *кагыз* – кәгазь, *сындык* –

сандык һ. б. Фигыль формаларында: *баргынца* – барганчы, *цыгыр* – чыгар (выйдет).

*А ~ ә: хатле* – хәтле, *хатсез* – хәтсез, *хал'* – хәл;

*е(э) ~ ә: әрәкмән* – әрекмән;

*ә ~ и: әтәй* – эти, *әнәй* – әни, *әбзәй/әзәй* – абзый, *мәләш* – миләш, *зәрәт* < *зирәт* – зират, *шәкәр* – шикәр, *әләс-мәләс* – иләс-миләс, *әпәй* – ипи, *тәкле* – тикле;

*и ~ ә: мени* – менә, *пилмин* – пилмән, *кифен* – кәфен, *пике* – пәке, *тиспе* – тәсбих;

*э ~ и: энец* – инеч, *энде* – инде, *эшетә* – ишетә (бу күренеш Тау ягының аеруча норлат сөйләшендә актив);

*и ~ е: тирмән* – тегермән, *әрбир* – әйбер, *тигендә* – тегендә, *шиша* – шешә.

Әд. *ү* урынына *и* сузыгы тәңгәл килә: *тигел/тегел* – түгел, *биген* – бүген, *кеңел/киңел* – күңел.

Бу күренеш чүпрәле сөйләшенең характерлы үзенчәлекләреннән берсе, аның кайбер мисаллары касыйм, темников, мордва-каратай кебек архаик күренешләрне саклап килә торган сөйләшләрдә табыла: кас. *мулиш* – миләш, *күсәү* – кисәү, *кизләү/күзләү* – чишмә һ. б. Ул бу җирләрдәге борынгы татар сөйләшләре белән бәйле булса кирәк. Аның мисаллары XIV йөз татар әдәбияты җәүһәрләре арасында да, мәсәлән, Мөхәммәдьярның «Төхфәи Мәрдан» поэмасында теркәлгән. Шуңа күрә ул «Татар халык сөйләшләре атласы»нда да чагылыш тапкан (кара: карта № 16, 17, 18).

*О ~ у: орлау* – урлау;

*а/е (э) ~ ү: беген* – бүген, *көңел* – кеңел – күңел, *көп* – күп, *өwү* – өю һ. б.

Дифтонг *үө* авазы әйтелү очраклары бар: *күөп/көп* – күп, *дүөрт/дөрт* – дүрт.

*Ы ~ у: шыл* – шул, *шындый/шынди* – нундый, *сыкна* – сукно – тула;

*ү ~ ө: үмә* – өмә, *үләнү* – өйләнү, *үмер* – әйтелә: гөмер, языла гомер, *йүткерә* – йөткерә, *йүгән* – йөгән һ. б.;

*у ~ о: бутка* – ботка, *куңгыр/кунгыз* – коңгыз.

Сөйләшнең характерлы үзенчәлекләреннән берсе – иренләшмә *о, ө* сузыкларын иренсезләштереп әйтү, ягъни аларга *ы, е, ы°, е°* авазларының тәңгәл килүе. Мәсәлән: *йезек* – йөзек, *кебе* – гөбе, *эц* – өч, *һэнәр* – һөнәр, *кышлар* – кошлар, *кыры* – коры, *ыцыбызда* – очыбызда, *йымырка* – йомырка.

Бер төркем сүзләрдә әдәби телдәге *у* авазы урынына *ы* әйтелә: *шылай* – шулай, *шында* – шунда, *шынан* – шуннан, *шындый*/*шынди* – шундый, *шыл* – шул, *сыкна* < *сукно* – тула, *ырлау* – урлау һ. б.;

*ыб ~ у: цыбар* – чуар, *цыбан* – чуан, *цыбалу* – чуалу һ. б.

Шулай ук *ө ~ ү*: *көмгән* – күмгән.

Нечкә әйтелешле сүзләрне калын итеп һәм, киресенчә, калын әйтелешле сүзләрне нечкә итеп әйтү.

Мәсәлән, *дийәлмәсә* – дия алмаса, *кецеркән* – кычыткан, *зирәт* – зират, *кецтегән* – (борын) кычыткан, *әбзәй/әзәй* – абзый, *нәсеп* – насыйп (булса), *бәлцек* – балчык һ. б.; *чаука* – чәүкә, *тапай* < *тәпәй* – тәпи, *йанаша* – янәшә, *шиша* – шешә, *йогора / йегерә* – йөгерә, *корка* – күркә, *кукы* – кәккүк, *мацы* – мәче, *котчык* – көчек, *арцу* – әрчү, *бар'ам* – бәйрәм, *циклаwык* – чикләвек һ. б.

Сузыклар өстәлү: *йерегән* – йөргән, *өтөрү* – төрү, *макы* – мәк, *машы* – маш (манара), *тапы* – тап.

*Йаңылыш* (< ялгыш) сүзендә борынгы төрки әйтелеш сакланып килә.

Сузыклар төшү сүз башында күзәтелә: *сак* – усак, *лан* – олан, *ләшү* – өләшү, *ләк* < иләк < *йеләк* – җимеш, *руз'а* – ураза, *зән'* – идән, *йык* < *ойык* – оек, *лау* – олау, *йалу* – оялу һ. б.

Сузыклар төшү башка позицияләрдә дә күзәтелә: *кий* < *кийы* < *койо* – кое (*тәрәз* – тәрәзә), *сийр* < *сийыр* – сыер.

Сүз уртасында: *баллау* – балалау, *кыркмыш* – кырыкмыш, *урны* – урыны, *катны* – хатыны һ. б.

Ике сүз арасында: *курл'ак* – кура җиләге, *ацкамыр* – ачы камыр, *карыләк* – кара җиләк һ. б.

Рус алынмаларын үзләштерүдә дә үзенчәлекле күренешләр табыла: *рашутка* – рәшәткә, *аугыс* – август, *прәңкә* – пряник, *самар* – самовар.

**Дифтонглар.** Билгеле булганча, көнбатыш диалектта дифтонглар бер авазга әйләнәләр. Чүпрәле сөйләшендә дә, нигездә, шулай. Шуның белән бергә аерымлыклар да бар.

*-өй* дифтонгы ү авазына яки *-ий* дифтонгына күчә: сүләкли – сөйләштерә, *урә* – өйрә, *ү* – өй, *үлә* – өйлә, *түмә* – төймә, *йүләү* – җөйләү, *өw*/*ү* – өй, *күw* – көй һ. б.;

Сузык аваз алдында: *үwәбез* – өябез, *түwәбез* – түwәбез, *күwәнтә* < *көйәнтә* – көянтә, сү*wәк* – сөяк һ. б.

Шулай ук: *эрәнү* – өйрәнү.

*Өй < ий* очраклары бар: *ийдә* – өйдә, *кийәнтә* – көянтә, *тийә < төйә* – төя (грузи) һ. б. Мондый күренеш көнбатыш диалектта катнаш (стәрлетамак, чистай һ. б.) сөйләшләргә хас.

*-ай/-әй, -ой, -уй* дифтонглары, *я, н, р, т, ч, с* авазлары алдында килгәндә, *а, ә, о, ө, у, ү* сузыкларына монофтонглашалар, *й* өлеше алардан соң килгән тартыкларның йомшак авазларга әйләнүенә китерә: *кат'уwышлый* – кайтканда, *ад'а* – әйдә, ан'*у* – айну, *кан'ар* – кайнар, *ар'ан < айран* – әйрән, *ат'ә/әтә* – әйтә, *бәли* – бәйли, *Гелзәнәп* – Гөлзәйнәп һ. б. нечкә әйтелешле сүзләрдә *й* төшә: *кур'ик* – койрык, *бәләwец* – бәйләү эше (энәләр һәм бәйли торган әйбер бергә), *бәли* – бәйли, *әләнә* – әйләнә һ. б.

Шуның белән бергә сөйләштә әдәби телдәгечә *сайла, кайт, кайда, уйнап, байтак* дип сөйләү очраклары да теркәлде.

**Тартык авазлар** өлкәсендә түбәндәге үзенчәлекләр күзәтелә.

Сөйләш *ц*-лаштыручылардан булса да, *ч* урынына *ц* авазы әйтелү системалы характерда түгел, чөнки *ч* авазын үзен әйтү очраклары да бар, әлбәттә, ул шартлау элементы булган *тч/*$т_ч$ вариантында әйтелә. Мондый күренешнең берничә сәбәбе булырга мөмкин:

1) чүпрәле сөйләшенә хас *ц*-лаштыру әдәби тел йогынтысында системалылыгын югалта бара;

2) тикшерә торган төбәккә *ц*-лаштыручылар да, *тч/*$т_ч$-лаштыручылар да килеп урнашкан булырга мөмкин;

3) *ч*-лаштыруның мишәрләрне күчереп утыртканчы яшәгән халык теленнән сакланып килүе дә бар.

*Ц*-лаштыруның системалылыгы югалу *ч* авазының яңгырау пары *дҗ* аффрикатының дә сөйләштә шактый актив күзәтелүенә китерә булса кирәк.

Шулай итеп, чүпрәле сөйләшендә *ц ~ ч* тәңгәллегенең мондый күренешләре бар: әд. *ч* авазына *ц* әйтелү: *цәцә* – чәчә, *пецү < печү* – кисү (кроить), *пецән* – печән, *цәй* – чәй, *цалыр* – чалыр (корал исеме), *цәцәк* – чәчәк, *цабата* – чабата, *пыцак* – пычак, ц*алгы* – чалгы, *цаба* – чаба һ. б.

Сөйләштә түбәндәге очракларда *ч* авазы даими әйтелә: *кетчкенә* – кечкенә, *питч* – мич, *Тчынлы* – Чынлы (ав. ис.), *Тчәке* – Чәке (ав. ис.) һ. б., *котчык* – эт, *тчаука* – чәүкә, *тчаршау* – чаршау, *катчан* – кайчан һ. б. Алынмаларда: *култча* – божра, *тчашка* – чашка, *иркача* < рус. рукавица – бияләй һ. б.

Әд. *җ* урынына *дз/з* әйтелү: *дзәймә* – җәймә, *зийә* – җыя, *дзәяәү* – җәяү, *зиде* – җиде.

Әд. *җ* урынына *дҗ* әйтелү: *дҗымга* – җомга.

Әд. *җ* урынына *тч* әйтү: *Әнвәртчан* – Әнвәрҗан.

Болардан тыш, сөйләм агышында әлеге аффрикатларның шартлаулы өлеше генә әйтелергә мөмкин, ягъни: *дз > д/т, ц > т* күренешләре очрый. Мәсәлән, *зеңәти < зеңәци <* җиңгәчи, *кеткенә* – кечкенә, *мит цыгару* – мич чыгару, *тәймә < тчәймә < дҗәймә* – җәймә, *пит артына < питч артына* – әд.мич *артына, атышкан < ачышкан* – әчегән (сөт) һ. б.

Сөйләш өчен характерлы үзенчәлекләрнең берсе *дҗ* авазын куллану. Бу сүз башында, аеруча сүз уртасында күзәтелә: *мәрдҗән* – мәрҗән, *энджҗе* – энҗе, *кәдҗә* – кәҗә, *мердҗә* – морҗа, *бадҗа* – баҗа, *пәдҗи* – диал. пәҗи – сүс һ. б.

Чүпрәле сөйләшендә көнбатыш диалектка хас булганча, *й*-лаштыру күзәтелә: *йир* – җир, *йәй* – җәй, *йил* – җил, *йәйәү* – җәйәү, *йыр* – җыр һ. б.

Шул ук вакытта күрсәтелгән позицияләрдә *дз/з* авазы да әйтелергә мөмкин: *дзил/зил* – җил, *зәйәү/дзәйәү* – җәяү, *мәрдзән/мәрзән* – мәрҗән һ. б.

### ***Тартык аваз тәңгәллекләре***

Чүпрәле сөйләшендә дә, көнбатыш диалекттагыча, *к, г* авазлары тел арты авазлары булып әйтеләләр: *кайгы, кырк* – кырык, *агач* сүзләре әдәби телдә *қайғы, қырық, ағач* һ. б. әйтеләләр.

*Йахшы* (яхшы), *катын* (хатын) сүзләрендә этимологик *к* тартыгы саклана. *Сигез, тугыз* сүзләрендә ике сузык уртасындагы *г* авазы саңгыраулаша: *сикез, тукыз*. Тик бу күренешнең шактый сирәк күзәтелүен ассызыклап үтәргә кирәк.

Фәндә билгеле булганча, көнбатыш диалектта әдәби телдәге *w* авазы урынына *в* куллану хас. Бу бигрәк тә ике сузык арасында күзәтелә. Чүпрәле сөйләшендә мондый очракларда әдәби әйтелеш шактый системалылык саклый: *аwыл* – авыл, *каwын* – кавын, *циклаwык* – чикләвек, *баwырсак* – бавырсак, *баруwы* – баруы, *даwам итә* – дәвам итә, *сүwәк* (диал. севәк) – сөяк, *куwала* (диал. кывала) – каула һ. б.

Татар сөйләшләренә чит булган *һ* авазы чүпрәле сөйләшендә дә әйтелми:

*һ > о: энәр* – һөнәр, *Минаҗ* – Минһаҗ, *Адый* – Һади, *әркенне* – һәркөнне, *шәәр* – шәһәр, *йәт* – җәһәт;

*һ > г: Зеерә/Зегрә* – Зөһрә;

*һ > w: Зөwәр* – Җәүһәр;

*һ > й: Майнур* – Маһинур, *Шийаптин* –Шиһабетдин, *зийен* – зиһен;

*н ~ ң* тәңгәллеге 2 нче зат хикәя фигыль һәм иялек килеше кушымчаларында да күзәтелә: *киләсен* – киләсең, *ашнын* – ашның, *безнен* – безнең, *саласын* – саласың.

Ике сузык арасындагы *к* авазы саңгыраулаша: *тыгырык* – тыкрык, *йага* – яка, *тугу* – туку, *цугыну* – чукыну.

Иске Чокалы, Иске Задур, Яңа Чокалы авылларында саңгыраулаштыру очраклары күзәтелә: *Әнвәртчан* – Әнвәрҗан, *сират* – зират, *паҗа* – баҗа, *кенчәлә < гөнҗәлә* – каба.

Кайбер сүзләрдә *т* авазы яңгыраулаша: *ибдәш* – иптәш, *сәлдәү* – селтәү, *дустыган* (диал. *тустыган*) – чүмеч;

*м ~ н: үләм* – әд. үлән, *тетем* – төтен. Киресенчә, түбәндәге сүзләрдә *м* авазы урынына *н* әйтелә: *калын* < калым, *нүгез* – мөгез, *нүwек* < мох – мүк, *нүwеш* (диал. мөгеш) – почмак;

*м ~ б: малан* – балан, *мере* – бөре, *мәке* – бәке; алынмаларда: *минек* – яфрак себеркесе, *минаwат* – виноват;

*' ~ х: ра'мәт (х > к > ')* – рәхмәт;

*п ~ б: петү* – бөтү, *пыт сөwәге* – бот сөяге, *пытак* – ботак;

*р ~ й: әрбир* – әйбер;

*т ~ ч: тишмәгән* – чишмәгән;

*т ~ д:* тәwә – дөя, *тиспе* – дисбе;

*с ~ ч: тескери, тыскан* – тычкан, *гәдәс* – ядәч;

*н ~ л: шаунау* – шаулау, *кытнау* – кыртлау (тавык);

*р ~ л: арткы* – аркылы, *шурпа* – шулпа;

*б ~ м: цыбылдык* – чымылдык, *гарбун* – гармонь, *бун'* – муен һ. б.;

*й ~ д: йәште* – дәште;

*ф ~ п: фылант* < план – йорт урыны, *манфаси* – монпасье;

*ч ~ ц: ыркача* < рукавица – бияләй, *гуринча* < горница – ак өй;

*н ~ д: алны* – алды (*ишегалны*).

Сүз азагында: *күwәз* – күәс, *ләңгәз* – ләңгәс.

*З ~ с: зәрдә* – сәрдә;

*г ~ к: гаудан* – каудан (абага йоны);

Авазлар өстәлү: *кыстырымбый* – кыстыбый, *пинцак* – пычак.

Сүз башында *й* өстәлү очраклары күзәтелә: *йирне* – ирен, *йезә* – өзә, *йертә* – иртә. Мондый күренеш аеруча чистай, мәләкәс сөйләшләренә хас.

Сүз уртасында: *сугалцан* – суалчан.

Авазлар төшү:

*й* (сүз башында): *эләк/ләк* < *йиләк* – җиләк;

*л: кыннау* – колынлау, *йугату* – югалту;

*т: кецеркән* – кычыткан, *цигерткә* – чикерткә, *арткыры* – аркылы;

*р* авазы төшү, тамырлары *-р-* сонорына беткән фигыль (аеруча инфинитив) формаларында актив: *керегә* – керергә, *барысыз* – барырсыз, *тырыга* – торырга, *йерегә* – йөрергә, *утырыга* – утырырга, *күрегә* – күрергә һ. б.;

*г: джҗыма* – җомга, *дәа* – дога, *уз* – угыз, *сәт* – сәгать, *аза* – әгъза;

*г/г* авазлары төшү гарәп-фарсы алынмаларында сүз башындагы позициядә (аеруча кеше исемнәрендә) күзәтелә: *айып* – гаеп, *айыт* – гает, *үмер* – гомер, *Айша* – Гайшә, *Арифулла* – Гарифулла, *Арифзян* – Гарифҗан, *Алия* – Галия һ. б.

Башка очракларда: *йаңыз* < *йаңгыз* – ялгыз, *саат/сайат* – сәгать;

*ш: алма-тилмә* – алмаш-тилмәш.

Ике сүз арасындагы позициядә беренче сүз азагындагы *ш, ч, с* тартыклары яңгыраулаша:

*йәж бахыт* – яшь вакыт, *пиж баш* – мич башы, *кыж буйы* – кыш буе, *биж бармак* < бишбармак – перчатка, *пиз (ч > ц > з) баш* – мич башы.

Метатеза: б*ырны* – борын, *ирне* – ирен, *цорау* – очрау, *сиркыч* – сыерчык, *джымак* – оҗмах, *азбар* – абзар, *кецтегән* – кычыткан (борын кычыту турында), *күреш* – күрше, *кымырыска* – кырмыска, *үрмәкцә* – үрмәкүч, *бачкыз* – баскыч һ. б.

Түбәндәге сүзләрдә ике сузык арасындагы саңгырау *к* тартыгы яңгыраулаша: *тыгырык* – тыкрык, *тугу* – туку, *йага (йака)* – яка һ. б.

Интервокаль позициядәге *җ* авазы урынына *ж* әйтү: *менәжәт* – мөнәҗәт, *хужа* – хуҗа, *пәжи/пәҗи/пәзи* – сүс.

Тартык авазларның нечкәрүе: *Мус'а* – Муса, *н'ур* – нур, *руз'а* – ураза, *Хас'ан, камыл'* – камыл һ. б.

Нечкә әйтелешле сүзләрдә йомшак *ш'* авазы кулланыла: *кеш'е* – кеше, *Кәш'ифәттәй* – Кәшифә апа, *ш'әйкәләре* – аш-су чиләкләре, *кыры йәш'ен* – аҗаган.

**Морфологик үзенчәлекләр**

***Исемнәр.*** Кеше исемнәренә *-ч, -ш, -и, -әй* кушымчалары ялганып иркәләү-кечерәйтү формалары ясала: *Минач* – Минһаҗ, *Сәйфи* – Сәйфетдин, *Wәлеш* – Вәли, *Гайфук* – Гайфулла, *Ал'уш* – Гатулла, *Зәйдук* – Зәйдулла, *Сирач* – Сираҗетдин, *Апыл'* – Абдулла һ. б.

Иркәләп эндәшү өчен *тайым, колыным* сүзләрен куллану актив: *Тайым, авылнын тарихын без белмибез.*

Тартымлы исемнәрнең төшем килеше *ы–е* кушымчалары белән ясалу актив. Мәсәлән:

*Белгәнеңе (белгәнеңне) укып сийпийсын.*

*Әрбирләреме (әйберләремне) калдырып тордым.*

***Күрсәтү алмашлыклары:*** мыни/мыны/мени/муни – менә, тиге – теге, бу, мындый, шыл, шындый, улсы/усы – анысы, вата, вана, выт, шулсы/шылсы – шунысы һ. б.: *Улсы да кат'ты* – Анысы да кайтты. Мун*'и биредә йакын гына ызбалары* – Менә биредә якын гына өйләре. *Шылсын ыныткан инде мин* – Мин шунысын онытканмын инде. *Вана шыннан кара пыцакны* – Әнә шуннан кара пычакны һ. б.

Көнбатыш диалектка хас булганча, чүпрәле сөйләшендә дә күрсәтү алмашлыклары урын-ара килешләрдә икеләтелгән кушымчалар алалар: *Тегенәргә ут каба, кецкә сүндерәләр. Анарга кайм'ак кушалар. Мынарга нәстә дийәрсен, йылый вет.*

Иялек килеше *-нын/-нен* кушымчасы белән ясала: *циләкнен* очраклары күзәтелә: *безнен* (безнең) *вахытта, циләкнен* (чиләкнең) *төбе йук* һ. б.

***Сорау алмашлыклары:*** нә/нәрсә/нәмәрсә/нәстә – нәрсә, *нәшли* – нишли, нәрсә эшли, *кайан, катчан, кацан, нәцек/ницек* һ. б.: *Нәшли әнәң, туйга барамы? Нәмәрсә хәзерләдең саумга*? – Савымга (туй күчтәнәченә) нәрсә әзерләдең? *Касы ланы хасталанган?* – Кайсы баласы авырый? *Кем дә йереми бу жарда* – Беркем йөрми бу эсседә.

***Саннар.*** *-ау/-әү* кушымчалы вариантлар актив кулланыла: *Алар күбәү бит, тузгып, таралып киткәннәр. Элеке бер пылантта икәү-*

*икәү утырганнар. Зидәүләп үстеләр, цәцәк цыгардылар, андары эцәрләп үлделәр. Бер-бер артлы тугызаулап балалар булды.*

***Рәвешләрнең ясалышы.*** *-лата/-ләтә: Акцалата бирийем?* – Акчалата биримме? *Камаклата сата. Борцак берәр кыр цәцәләр иде, йәшелләтә кузагын ашыйлар иде* һ. б.

*Үзгәцәли(й): Ишетмештән беләм, үзгәцәлий белмим шул. Үзгәцәли йәрдәм джук шыл.*

*Теңнә: ындырны* (бәрәңге бакчасы) *теңнә* (төнлә) *баса* (казый) *идек.*

*Ката, сәтә* бәйлекләре белән: *Кыш ката* (буе) *тытам балны, биш үле зийдык зиде йылга. Тезләрем аwырта, кен сәтә* (көн буе) *сызлап цыгам.*

***Фигыльләр.*** Затланышлы формалар. Хәзерге заман хикәя фигыль. Хәбәр составындагы 3 нче зат хикәя фигыльгә *-дыр/-дер* кушымчасы ялгана: *Ул сүләргә йаратадыр* (ярата). *Ике ай артык үтте дәдер. Ул күрәдер дә әнәсенә әтәдер* – Ул күрә дә әнисенә әйтә.

Бу күренеш исем хәбәрләрдә дә күзәтелә: *Ул әтә, бу бүләк сиңадыр* (сиңа).

*Ди* фигыле еш кына *дир/дийр* рәвешендә әйтелә: *Кунакка килегез, дийр* (ди). *Безгә дә барыгыз, дир.*

*-ган/-гән* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман формасы билгеле үткән заман функциясендә дә кулланыла, бу вакытта ул зат кушымчалары алмый: *Син әле суга бармаганмы* (бармадыңмы)*? Мин быйыл капыста утыртмаган* (утыртмадым).

*Аналитик үткән заманнар.*

1. Чүпрәле сөйләшендә дәвамлы үткән заман *-а иде* формасы белән белдерелә: *Кимак пешерә идек. Нәстә кирәгеңне алып кат'а иде.*

Бу форманың юклыгы – *мийды-миде* кушымчасы белән ясалырга мөмкин*: Ун'га* (уенга) *йебәрмиде* (җибәрми иде).

2. Аерым очракларда урта диалектка хас *-адыр + иде* конструкциясе дә күзәтелә: *Кыз вакытта эч әттереш уйныйдырыйк.*

3. Тау ягы сөйләшләренә хас *-ды иде* формасын куллану очраклары бар, ул күптән үткән заман формасына туры килә: *Утырып бардым иде* – Утырып барган идем.

4. Көнбатыш диалектка хас үзенчәлекле *-а булган* формасы чүпрәле сөйләшендә дә күзәтелә: *Зур-зур цобаннар цыга булган әwәле* – Зур-зур чуаннар чыга торган булган элек. *Арцига эцәр-дүртәр пар бара булганнар* (бара торган булганнар). Мондый үзенчәлек,

нигездә, катнаш (мәсәлән, стәрлетамак) сөйләшләрдә очрый, әдәби (*-а торган иде*) һәм диалекталь (*-а иде*) формаларның контаминациясе нәтиҗәсе булырга мөмкин.

Эчке теләк *-кы/-ке + киләү* конструкциясе белән белдерелә: *Цыккым келәми* (чыгасым килми) *йаңгырда. Цәкцәкне эләкшә кебек кисеп пешерәбез, улсын да ашагыбыз келәми* (ашыйсыбыз килми).

Әдәби телдәге *теләсәң нишлә* конструкциясе чүпрәле сөйләшендә *теләдең нишлә* формасында әйтелә: *Син теләдең нишлә* (теләсәң нәрсә эшлә), *мин тизрәк барыйм.*

Тау ягы татар сөйләшләренә хас *-ма/-мә + келим* нията конструкциясе чүпрәле сөйләшендә дә күзәтелә: *Баргысы келәми, алып китмә келим* – Алып килергә уйлыйм, барасы килми. *Йакшы йәшәмә кели* – Яхшы яшәмәкче була.

*-ып/-еп* кушымчасы хәл фигыльнең юклыгы *-мыйца/-мицә, -минца/-минцә* кушымчалары белән ясала: *Кызларга сырамыйца* (кич) *цыгарга тигел* – Кызларга сорамыйча кич чыгарга ярамый. *Килминцә калмый ул.*

*-гач/-гәч* кушымчасының түбәндәге вариантлары күзәтелә: *Зидене бетергәц* (бетергәч) *пирмәгә бозау карарга кердем. Ускәцтән* (үскәчтен) *Казанга китте малайы.*

*-ганчы/-гәнче* формасының вариантлары: *Рашутка куйгыннца* (куйганчы) *таwыклар керә иде. Пецәнгә төшкәнцегә кадәр* (төшкәнче) *ял иткән. Пецән цапкинца* (чапканчы) *йаңгыр былмады.*

Чүпрәле сөйләшенә хәл фигыльнең *-уwынца/-үwенцә* кушымчалы формасы хас: *Баруwынца мәктәпкә кер, балалар зийылганмы?* – Барышлый мәктәпкә кер, балалар җыелганмы? *Икеләп сүләштем, баруwынца да, кат'умынца да* – Ике тапкыр сөйләштем, барганда да, кайтканда да.

Чүпрәле сөйләшендә борынгы *булдац* сыйфат фигыле сакланып килә: *Кийәү булдац күреш аwылныкы ғына* – Кияү буласы (кеше) күрше авылдан гына. *Кызы кийәүгә цыгарга тыра, кыда булдацлары да, кийәү булдац та кайтып килешеп киттеләр.*

Бу форма «Кыйссаи Йосыф» китабында да теркәлгән.

Эшнең үтәлеш дәрәҗәсен белдерү өчен, мишәр сөйләшләренә хас булганча, чүпрәле сөйләшендә дә *-акла/-әклә, -гакла/-гәклә* кушымчасы кулланыла: *Сүләкли бабай белгәнен* – Бабай белгәннәрен сөйләп-сөйләп ала. *Элгәре йегетләр йагада йерекләгәннәр акцышләргә* – Элек егетләр акча эшләү өчен читтә йөргәләгәннәр.

Аерылмышның килеш формасының инверсияләнгән аергычка ялгануы: *Джезек кашлыны кидерәләр* – Кашлы йөзек кидерәләр.

Кайбер башка очраклар: *Нәстә кирәгеңне алып кат'а.*

Чүпрәле сөйләшенә әдәби *күп түгел* конструкциясе *күб йук* рәвешендә әйтелә: *Акчасы күб йук* (күп түгел).

*Артык* бәйлек сүзе, әдәби телдән аермалы буларак, баш килешне башкара: *Ике йыл артык киткәненә* – Ике елдан артык киткәненә. *Безнен аwылда зиде йез артык йырт булган* (җиде йөздән артык).

Инверсия актив: *Су зур* (зур су) *бетте.*

*-мы/-ме* сорау кисәкчәсе җөмләдәге логик басым төшкән сүзгә ялгана: *Синең мәле ике игезәк ыланың?* – Ике игезәк бала синекеме әле?

### Лексик үзенчәлекләр

Фонетик һәм грамматик үзенчәлекләр белән беррәттән, чүпрәле сөйләше диалекталь сүзләргә дә бай. Аларның төп өлеше көнбатыш (мишәр) диалектына хас лексика белән уртак: *кан'игәц* – хатынының яки иренең апасы, *ызба* – өй, *сугым* – иткә суясы ат, *алаша* – ат, *питырац* – кечкенә икмәк, *бәбец* – читек-кәвеш, *лән* – җитен һ. б.

Сөйләштә тагын тау ягы сөйләшләре төркеме өчен уртак булган диалекталь сүзләрнең булуын да күрсәтергә кирәк: *малай* – бала, *ләнгәц* – агач тәпән, *ханжа* – самогон, *гензәлә* – каба.

Чуаш теленнән кергән сүзләр дә табыла: *дәнгәл* – тау шуу өчен скамейка рәвешле итеп ясалган җайланма (чув. тенкел – скамейка).

Чүпрәле сөйләшенә хас лексик-семантик системаның кайбер тематик төркемнәренә берникадәр тукталып үтү урынлы булыр.

***Туганлык атамалары.*** Билгеле булганча, кан туганлык атамалары телнең иң борынгы һәм тотрыклылык саклый торган төркемен тәшкил итәләр, алар нигезендә никахлашу нәтиҗәсендә барлыкка килә торган атамалар да (*кан'* + ата, *каен* + сеңел, *каенигәц* < *кан'* + *игәц* – кыз туган дигән сүз һ. б.), туганнарны якын итеп, яратып эндәшә торган сүзләр дә (*әбекәй* – әбигә эндәшү сүзе, *әпкәй* < абыс (гыйлемле, олы дигән сүз) + *тәй* < *тәй* (< түтәй) һ. б.) ясала.

Чүпрәле төбәге өчен түбәндәге кантуганлык атамалары хас: *әнәй* – әни, *әтәй, әттәй* – әти, *әбзәй/әзәй/әбзә/әзи* – абый, *түти/түтәй/тәтәй* – апа, *әби, бабай, сеңлем, эне(м), быратым* –

әд. энем, *ылан/лан* – бала, *йәш ылан* – яшь бала, *карцып әби* – кендек әби, *шәкерт әбзи* – абыйларның берсе, *әнтәй* – сөйләүчедән олы булган хатын-кыз туган яки чит хатын-кызга эндәшү сүзе (*абыз + түтәй* сүзләреннән), *эптәле-сеңелле* – апалы-сеңелле; *бабай; бабацы* – сөннәтче; *бәбәй, бәбәй буткасы* – бәбәй ашы, *бәбәй үстерү* – бәби туе; *дәдә* – этисенең абыйсы яки энесе, *игәц* – бертуган апа.

Гомуми туганлык *нәсел, туган, карендәш, нәсел-нәсәбә, теп* һ. б. сүзләр белән белдерелә.

***Никахлашу туганлыгы атамалары.*** Көнбатыш диалектның барлык сөйләшләрендәге кебек, Чүпрәле төбәгендә дә никахлашу нәтиҗәсендә барлыкка килгән туганлык атамалары *кан'* сүзе ярдәмендә ясала: *кан'ата* (эндәшү сүзе: *этәй/кан'этәй), кан'ана (әнәй, кан'әнәй), кан'ага (әбзәй, әбзи, әзәй, әзи), канигәц (эптә, эптәй/апа), кан'сеңел* (иренең сеңлесе), *каене, балдыз, җанагай, җәнагай* – каен эне, *пажҗа/бажҗа* – бажа; *бикәц* – яшь килен, *бикәцкә керү* – кияү белән кызның беренче кичәсе, зөфаф кичәсе; *дуwадак* – ялгыз ир һ. б.

Чүпрәле төбәге өчен характерлы моментларның берсе – *бийагай* сүзенең мәгънә үзенчәлеге. *Бийагай* сүзе тел яшерә торган киленне белдерә: *Әзәй белән, бигрәк тә ирнең иң зур әзәйе белән, бийагай булганнар. Элгәре бийагай булганнар, тел йәшергәннәр. Килен кайната белән сүләшмәгән, бу бит бийагай, сүләшми, диләр.* Мондый күренешнең таралу территориясе норлат, тархан сөйләшләреннән үк башлана.

Шулай итеп, татар телендәге *бийагай* сүзе никах туганлык атамасыннан йола атамасына әверелгән. Бу очракта *би-* компонентлы никах туганлыгы атамаларының чуаш теленә кереп җитә алмавы да роль уйнаган булырга мөмкин, чөнки туганлык атамалары, иң тотрыклы лексика буларак, чит йогынтыга тиз генә бирешмиләр.

Тагын бер үзенчәлекле күренеш игътибарга лаек. Чүпрәле сөйләшләрендә иренең абыйсын *бийагай,* энесен *йанагай* дип әйтү очраклары күзәтелә. Бу туганнар берничә булса, аларны аеру өчен төрле-төрле эпитетлар кулланыла: *ылы бийагай, кеwәз җәнагай, сылу җәнагай*. Шулай итеп, чүпрәле сөйләше әлеге атамаларны куллану ягыннан көнбатыш диалект сөйләшләреннән бераз аерыла. Мондый аерымлык Түбән Новгород өлкәсендә таралган сергач сөйләшендә дә билгеләп үтелгән иде.

Туганлык атамаларының тотрыклы булуын исәпкә алсак, әлеге күренешләр мишәрләр күчеп килгәнче яшәгән төркиләр һәм болгарлар телендәге үзенчәлекләр белән бәйле, дип фараз итәргә була.

Әдәби телдәге *ирем* атамасы урынына сөйләштә, сергач сөйләшендәге кебек, *татарым* сүзе әйтелә: *Минем татарым вайнада үлде. Зеңәци, зеңәти* – җиңгәчәй, *зизни* – җизни һ. б.

*Каниш* – килен кешегә ир ягыннан булган барлык туганнар.

*Йәш әби* – бабайның икенче хатыны.

*Йезек* – ахирәт дус, шуннан: *йезек кушылу* – ахирәтләр булу.

Хатын-кызлар арасында бер-берсенә яратып, якын итеп эндәшү сүзләре бар: *йезек* – ахирәтем, *сүгәнем* – сөйгәнем, *йандус* – җан дустым, *йөрәгем*, *малинам* һ. б.

***Туй йолаларын*** белдерә торган атамалар арасында чүпрәлеләрнең үзләренә генә хас лексемалар да күзәтелә. Мәсәлән, *арчы йөрү* – туйда катнашу, *эшәнчек* – бирнә, *йуллык* – иртәгә туй дигән көнне егетләр һәм кызлар туганнары катнашлыгында уза торган күңел ачу мәҗлесе; *саум/саwым* – туйга кода-кодагыйлар алып килә торган, билгеле комплекттагы күчтәнәчләр (пар каз, бавырсак/чәкчәк һ. б.). *Саум садакасы* – туй табынына *саум* чыккач өләшелә торган садака; *кабак сату* – капкада кияүне кертмичә тору, бүләк биргәч кенә кияүне уздырып җибәрү (борынгы төрки *кабак* – капка сүзеннән), *кийәү гусницы* – егет ягыннан кыз ягына китерелгән бүләкләр, *каруны түләү* – кыз ягыннан *кийәү гусницына* каршы бирелгән бүләк.

Туй керү – әле генә өйләнешкән яшьләрнең кыз ягы туганнарында кунак булып йөрүе, *ылау алу* – туйга килгән парлы кунакны кундыру, кунак итү.

***Аулак*** калган ***өйдә*** яшьләрнең җыелып күңел ачуы да чүпрәле якларында үзенчәлекле атала: *мәзәк*. Анда төрле уеннар булган: *йөзек салу*, *арка сугыш* һ. б. Җәзалар да төрле булган: «күгәрчен ашату», «тышка чыгып „йолдыз санап" керү», «егетләрне җырлату» һ. б. Түгәрәк уеннарында төрле шаян җырлар «яманлаш» (әд. төрттерешле) җырлар башкарыла. *Утырмага килгән кунак кызга* аеруча җылы, ихтирамлы мөнәсәбәт күрсәткәннәр.

Халыкның рухи дөньясын язгы кич чыгу вакытындагы, ташу өстендә башкарыла торган уеннардан башка күз алдына китерергә мөмкин түгел: *кыруг уйнау, түндәг алыш* (русча третий лишний),

*лапта, бармак уйыны, келтә зийу, тотынып уйнау* һ. б.; урамда кызлар *черки* (классики), малайлар *ашыг уйыны* уйнаганнар.

Төрле ***ышанулар*** киң таралган, алар татар халкының башка төбәкләрендәге төсле үк, тик исемнәрендә генә бераз аерымлыклар күзәтелә: *аран ийәсе* – йорт иясе*, өчайак* – атынгычның бер төре, *цицекай* – тәтиләр (фарфор кисәкләре һ. б. уенчыклар), *кабергә – йир пецү* – кабернең үлчәмен сызып чыгу, *туры ләхет* яки *шалгама* – янда түгел, аста, кабер төбендә ясалган ләхет һ. б., ягъни мәет кабернең төбенә куела, такталардан эшләнә. *Шалгама* шулай ук Чүпрәле якларының үзенчәлекле билгеләреннән берсе (Гафаров И. Туган як мирасы. 2004. Б. 50–51).

*Бармак тертеш:* 1) катнашучылар ике бармакны бергә куеп чыгалар; 2) берәү ике бармагын кушып өстәл кырыена куя, алып баручы әле бер читкә, әле уртага төртә-төртә бер җыр әйтә.

*Эцке бар'амы* – көзен уздырыла торган бәйрәм, эчемлекләр дә кулланыла.

*Әлемцәлек* – атынгыч.

*Киц утыру* – кицке уен.

*Күгәрцен ашату: Шырпы каптыралар берсенә берсе кыз белән йегет.*

*Дәңгәл* (< чув. дәңгәл ) бозда яки тау шуу өчен ясалган, скамейка рәвешле җайланма; *ләдән* (< рус. ледянка) – кечкенә, түгәрәк җайланма, астына боз катырылган була.

*Баткылдык* (балалар уены) – юлда кечкенә генә чокыр казып, өстен сизелмәслек итеп салам яки кар белән каплаштырып куела, берәрсенең аягы шунда төшсә, балалар өчен бик күңелле була.

Чүпрәле төбәгендә дә төрле ***мифик җан ияләре*** белән бәйле ышанулар яшәп килә: *су анасы* (сир.), *су иясе, су бүресе, аран ийәсе. (Су бүресе тытмасын, дир.)*

*Су анасы суган сакал,*
*Җир анасы җирән сакал,*
*Менә сиңә җим китердем.*
*Кабул итеп ал.*
*Саулыгымны кире кайтар, –*

дип, суны сибәсең.

Корылыкка китсә, авыл халкы, бала-чага *инеш келәве* (яңгыр боткасы) уздырган.

***Авыл төзелеше, ландшафт*** белән бәйле лексика составында да әлегә хәтле диалектологик сүзлекләргә кермәгән сүзләр очрый: *сыңар урам, бер канатлы (авыл)* – урамы бер генә якта булган (авыл), *кыр келәү йылгасы* – яңгыр теләү йоласы башкарыла торган елга буе, *чишмә* – таудан агып чыккан инеш, *күзләү* – чишмәнең чыгып, кайнап торган урыны, *атламыш* – куаклык, *каштау* – калкулык, *кыры йәшен* – аҗаган, *алгаш* – мәҗүси һ. б.

*Мокай тау* – авылның бер өлеше, *Имән йылгасы* – елга исеме (Иске Задур).

***Кешене тасвирлый торган сүзләр.*** Чүпрәле төбәгендә кешене тасвирлый торган лексикада да кайбер үзенчәлекләр табыла, алар арасында чагыштырулар да игътибарны җәлеп итә: *пиц тәке* – зур гәүдәле кешегә карата, *кеwәз/кевәс* – матур; *сылу* – нәфис; *аухатлы* – көчле, егәрле, *какух* – маңгай чәче, *адашу* – акылдан язу, *акыш-макыш* – аңгы-миңге, *тирес* – кире, *касталану* – авырып китү, *тез тупсасы* – тез буыны, *шеше* – тотлыгып сөйли торган, *нуми* (< рус. немой) – телсез, *батыр* – эре сөякле, зур гәүдәле кеше, *әтүле* – атаклы, *билтәк* – сакау һ. б. диалекталь сүзләр чүпрәле сөйләшенең үзенчәлекле сүз байлыгы турында сөйли.

***Йорт-җир*** белән бәйле лексика составында да чүпрәле сөйләше өчен үзенчәлекле сүзләр теркәлде: *ызба ышку, ызба кырыш* – өйне кырып-кырып юу, *ү йасау* – өй салу, *нигез боткасы* – өй күтәргән көнне пешерелгән ботка яки аш; *цитән* – горизонталь үргән читән, ятма үргән читән, *элеңге* – тәрәзә пәрдәсе, *цыпыш лампы* – сукыр лампы, *нүweш* – почмак, *зәмәт* – койма һ. б.

*Ләнгәц (фин-угыр сүзе)* – тәпән, зур булмаган кисмәк, *зимбел* – кәрзин, *пайыт асты* – лапас, *стул'а* (< стойло) – ат араны, *албут* – алпавыт.

***Хуҗалык эшләрен*** һәм төрле эш коралларын белдерә торган лексиканың составы ягыннан бу сөйләш көнбатыш диалектның башка сөйләшләре белән, нигездә, бертөсле. Мәсәлән: *тыратайга* – тарантас, *ызба* – өй, *цабу* – итәк, *запун* – алъяпкыч, *кәркеш* – киндерә, *пәзи/пәҗи/пәжи* – сүс, *чәчү/цәцү* – утырту (бәрәңге һ. б.), *басу* – казу һ. б.

***Кыр эшләре:*** *матыйклау* – (бәрәңгене) йомшарту, өю, *үwәбез* – өябез, ат белән: *сызалар; куласа сугу* – тәгәрмәч бөгү, *басу* – (җирне) казу, *богыл* – зуррак чүмәлә (печән), *салдат* – көлтә чүмәләсе. Һәм башка үзенчәлекләр дә бар: *ындыр* – бәрәңге бакчасы,

*пылант* – йорт урыны (өй урыны, бакчалар бөтенесе бергә: *Элеке бер пылантта икәү-икәү утырганнар), кыр* – җир үлчәү берәмлеге: *Элгәре бырцакны берәр кыр цәцәләр иде*; *йоморо* – гөнҗәлә, *цалыр* – кабер казый торган махсус корал, *пилит йармасы* – пила чүбе, *элән киндере* – җитеннән тукылган киндер һ. б.

***Кием-салым атамалары*** нигездә татар теленең башка сөйләшләрендәге кебек. Шуның белән бергә, үзгәлекләр дә күзәтелә.

Көнбатыш диалектка хас сүзләрнең күбесе сакланып килә: *запун* – алъяпкыч, *запун'ның циккәне* дә, *билдәне дә*, *л'амкалысы* да була. *Сап* – 1) куныч; 2) сабак (үсемлектә).

Түбәндәге сүзләр чүпрәле сөйләшенең үзенчәлеген тәшкил итәләр: *бала* – ала итәк, *балалы күлмәк* – балайтәкле күлмәк (*Балалы күлмәкләр кигәннәр, зиңнәрендә дә була, цабуwында да*), *сыкна* – тула, *бәбец* – читек, *wарига/бишинә wарига* (<рус. варежки) – бәйләгән бияләй, *ыркача*<рус. *рукавица* – тукымадан теккән бияләй, *кадау* – тагу *(Түмә тешсә, аны кадауцы йук), сыкныйыгы* – тула оек, *батыр шәл* – кышын, кунакка барганда, чанада ябынып утыра торган зур калын шәл, *әлце салу* – кыңгыр салу (баш киеме турында).

Кием-салым белән бәйле бер төркем сүзләр көнбатыш диалекттагыча әйтелү белән аерылалар: *йага* – яка, *энец* – инеч, *цабу* (чабу) – итәк, *бүрке* – бүрек, *алынны күлмәк* – изүле (бизәнү әйбере – изү) күлмәк.

Татар халкы матур бизәнү әйберләренең күплеге һәм төрлелеге белән аерылып торган. Чүпрәле төбәге татарлары да бизәнү әйберләренең составы ягыннан аерылмыйлар, ә атамаларында исә кайбер фонетик үзенчәлекләр яки диалекталь атамалар бар: *түмә* – муенса, *цулпы* – чулпы, *мәрдҗән* – муенсаның бөртекләре, *талир цулпы, талир тәңкә, кылагалка, шәрег* (< шәрыкъ – көнчыгыш) *алка* – айсыман алка, *алынча* – изүчә, *хастә* – хәситә, *тезем* – рәт һ. б. *(Эц тезем мени мынсы мәрдҗән), йерәк алкалары* – йөрәк рәвешле алка һ. б.

***Аш-су атамаларында*** да халыкның җирле сүзләр уйлап табу осталыгы шактый ачык чагыла. *Салма* – ракушка, *ләкшә* – токмач, *каплаwыц* – капкач (бәлешнеке), *кыстырымбый* – кыстыбый, *сумса* – бөккән, *зәймә* – юка, *җәймә, үрә, сетлүрә, киндераш кәкәце* – ватрушка, *кәлземә* – сумса, *курл'ак вәринҗы, пукыл'* – башлы шикәр (*Ике пукыл' шәкәр алды*), *бармак* – озынча итеп пешерелгән бавырсак, *тура* – йорт шартларында әзерләнгән сыр, *пилмин* – пилмән,

*эремцек пилмине* – вареник, *сугым ите* – ат ите, *йакмыш* – ватрушка, *келәт* – эчүле мәҗлес (*Әле бүген үземне келәткә йәштеләр*), *тызлык* – шулпа, *кырлый* – коры-сары (ашау).

Билгеле булганча, ***үсемлекләр дөньясы*** белән бәйле лексикага төрлелек хас, үсемлекләрне атауда һәр төбәк үзенчә эш итә, дип әйтергә мөмкин. Шуңа күрә дә бу тема буенча сүзләр китерү урынлы булыр.

Бу төбәктә дә әлеге тематик төркемнең бигрәк тә ашарга яисә дәвага яраклы үләннәрне белдерә торган төркемчәләрен генә яхшы беләләр.

*Какы, зәрдә* – сәрдә, *балтырган*, *кузгалак* – щавель, *ат кузгалагы* – конский щавель, *әрем, үгез борчагы* – песи борчагы, *сетлут* < сетле + ут (үлән) – сөтле билчән, *әрәкмән* – әрекмән, *кырмавык* – тигәнәк, чаукабаш: *ак чаукабаш* – ак башлы, *кызыл чаукабаш* – кызыл башлы клевер үләне һ. б.

Культуралы үсемлекләр: *киндераш* – киндер орлыгы, *киндер* (үсемлеге); *лән* < рус. лен, сөйләштә мишәр диалектына хас *элән* сүзенең варианты, *цүпләмә* – баса, *йир алмасы / алма* – бәрәңге, *буалмасы* < *баг* (бакча дигән сүз) *алмасы* – алма, *карыләк* – кара җиләк (черника), *курл'ак* – кура җиләге, *айбагар* – көнбагыш.

Үсемлекләр белән бәйле тагын бер төркем сүзләр: *таwык тәпәйе/тапайы* – акбаш үләне, *цыпцык тарысы* – сарут, *сылыца* – рус. овсюг, *сетлут* < *сөтле үлән* – билчән, *таwык күзе* – бөрлегән, *айу камыр* – гөлҗимеш, *рахман* – әрекмән, *сыргак* – сырлан.

Алынмалардан: *сирамин* – сирень, *газниц* (< рус. козелец) – кәҗә сакалы, *дәгел* < *рус. дягил* – шома күшә һ. б. санап үтәргә була.

***Хайваннар дөньясы*** белән бәйле кайбер мисаллар: *мурта, умарта* – бал корты, *гаудан* – ябага йоны, *ана башы сарык* – ана сарык, *теше* – саулык; (сарык) *баллау* – бәрәнләү, *батыр сарык* – зур сарык, *кәнәш* – колын, *кыннау* – колынлау, *тәwә* – дөя, *арулау* – печү, *кагау* – тилгән, *куцат* – этәч, *йүwеш таракан* – кыргаяк.

Көнбатыш диалектның бер элементы булганга күрә, чүпрәле сөйләшендәге алынма сүзләргә бераз аерым тукталырга кирәк, чөнки әлеге диалект рус алынмаларының күләме ягыннан үзенчәлекле урын тота.

Сөйләштәге алынмаларны фонетик үзләштерү белән бәйле күренешләрдән фонетик үзенчәлекләр бүлекчәсенә дә тукталып үтү мөһим.

Билгеле булганча, көнбатыш диалект рус алынмаларының күләме ягыннан урта диалект сөйләшләреннән аерыла. Чүпрәле сөйләше дә рус алынмаларының активлыгы ягыннан көнбатыш диалекттан аерылмый дияргә мөмкин. Алар тормыш-көнкүрешнең барлык тармакларында да табылалар.

Туганлык атамалары: *бырат* – эне, *пләмәнцә* – әти яки әнисенең туганының кызы, *пеләмәннек* – улы.

Кеше әгъзалары, аны бәяли торган сүзләр: *крута* – кызу, кискен, кырыс; *гадук* – яшьтәш, *н'умий* – телсез һ. б.

Хуҗалык эшләре, йорт-җир: *кырыл'ца* – болдыр, өй алды баскычы, *пираклат* – аркылы агач, *путалак* – түшәм, *герәплә* – тырма, *йәслә* – утлык, *пар'на* – пар басуы.

Матди мәдәният: *прәңкә* – прәннек, *ыркача* – бияләй.

Йорт җиһазы: *крамысла* – көянтә, *куфшина* – күәс, *кучарка* – кисәү агачы, *минек* – мунча себеркесе, *прабой* – келә тимере, *пузыйр* – лампа пыяласы, *сигелцә* – ыңгырчак һ. б.

Мал-туар һ. б.: *сыка* – ана эт, *кумка* – кантар һ. б.

Табигать: *зәрә* – таң, *зәрә йарылу* – таң ату, *жар* – эссе/кызу, *жажор* – рус. затор һ. б.

Кайбер алынмалар чүпрәле сөйләшендә икенче төрлерәк мәгънә төсмерләре алган: *гуринча* (көнб. диал. ак өй, өйнең ак ягы, түре) – 1) ак өй; 2) җәннәт, җәннәт почмагы (Гафаров И. Б. 90); *багылай* – шук, шаян, тиктормас; *калушка* – 1) калып; 2) чабата астына су үтмәсен өчен беркетелгән шакмак; *тамит булу* – аптырау, *тамит итү* – аптырату һ. б.

Сөйләштәге тагын чуаш (*деңгел* – тау шуу өчен скамейка рәвешле ясалган җайланма; *әбхам* – мактанчык һ. б.), мордва (*паңгы* – гөмбә, *кәркеш* – киндерә, пәзи – сүз һ. б.) телләреннән кергән сүзләр дә булу чүпрәлеләрнең төрле халыклар белән бәйләнышлары, тормыш тәҗрибәсе уртаклашып гомер итүләре турында сөйлиләр.

Шулай итеп, чүпрәле сөйләшенең үзенчәлекле күренешләр системасы формалашкан. Бер яктан, анда көнбатыш диалектка хас үзенчәлекләр табыла: ачык, иренләшү төсмере булмаган *а* авазы, алгырак позициядә ясала торган, нечкәрәк әйтелә торган *ә, ү* авазлары, *о, ө* авазларын иренсезләндерү, *өй, ай, әй, уй, ой* дифтонгларының бер аваз булып әйтелүе (*ү* – өй, *кан'на* – кайнана, *курик* – койрык, *бәли* – бәйли һ. б.), *к, г* авазларының тел арты авазлары итеп әйтелүе, *ц*-лаштыру, *й*-лаштыру, эчке теләкне белдерә

торган *-кы + кели* (*баргы кели* – барасы килә, *эҗки кели* – эчәсе килә), *укыкли* – укыштыра, *баргаклий* – баргалый формалары, *ката, сәтә* бәйлекләре һ. б.

Шул ук вакытта чүпрәле сөйләше бер төркем үзенчәлекләр белән көнбатыш диалекттан аерыла. Мәсәлән, сөйләштә *җ*-ләштерү күренеше дә күзәтелә: *дҗә кастадан* – йә авырудан (нәзер әйтә), *мәрҗән/мәрдҗән* – мәрҗән, *пәзи/пәҗи* – сүс һ. б., *өй* дифтонгы урынына *-ий/-ей* дифтонгларын әйтү (*тийәп/тейәп* – төяп, *ийгә кату* – өйгә кайту һ. б.). Кайбер авылларда традицион *ц* урынына *тч* авазының кулланылуы (мәсәлән, Мунчәли авылында), *тч*-лаштыру билгеле бер төркем сүзләргә хас (Гафаров И. Б. 88); көнбатыш сөйләшкә хас *в* авазының сирәк кулланылуы (*аwыл*) һ. б. Бу яктан чүпрәле сөйләше урта диалект белән уртаклык күрсәтә.

Сөйләштә Тау ягында таралган барлык сөйләшләр өчен уртак булган үзенчәлекләр дә күзәтелә. Мәсәлән, *-ды + иде* (*бардым иде* – барган идем), икеләнүне белдерә торган *-а булыр* (*бара булыр* – бара ахрысы), *-ма кели* (*барма кели* – бармакчы була) һ. б. Шундый характердагы уртаклык лексика өлкәсендә дә табыла: *малай* – бала; *ләнгәз* – тәпән; *ыртын* – урынтын, яшерен; *тишен* – чишен; *мечә* – гәүдә; *дҗүрмә* – чыбык һ. б. Кайбер үзенчәлекләр чүпрәле сөйләшендә генә күзәтелә. Мәсәлән, шундыйлардан билгеле бер төркем сүзләрдә әдәби *ү* авазына *и* авазы тәңгәллеге. Мәсәлән, *тигел* – түгел, *биген* – бүген, *бийыл* < бу ел – быел, *киңел* – күңел, *кизләү* – чишмәдән агып чыккан инеш, диал. *Күзләү, күзләwек* һ. б.

Күргәнебезчә, бу төркем күренешләр дә чүпрәле сөйләшенең көнбатыш диалектына караган башка сөйләшләрдән аерылыбрак торуына китерә. Чүпрәле сөйләшен урта диалект сөйләшләренә якынайта.

Мондый фактлар Тау ягы ареалы сөйләшләре вәкилләренең тарихы белән бәйләнгән. Фәндә билгеле булганча, Идел–Урал регионында безнең эрага кадәр IV меңьеллыкларда ук инде төркиләр яшәгән (бу турыда кара: Зәкиев М. З., 2008. Б. 158; Лайпанов К. Т., Мизиев И. М., 1993. Б. 16–48).

XVII гасырда, йомышлы татарларны (мещерякларны) әлеге төбәкләргә хәрби ныгытмаларга күчереп утырта башлаганда да, бу җирләрдә җирле төркиләр яшәгәннәр һәм, алар белән мишәрләр контактка кереп, үзара тәэсир итешү процессы башлана. Чүпрәле сөйләшенең үзенчәлекле күренешләрен бары чуаш теле

йогынтысы дип кенә аңлатырга тырышу, безнеңчә, чынбарлыкка туры килми.

Шулай итеп, чүпрәле сөйләше татар диалектлары системасында аеруча кызыклы, үзенчәлекле берәмлек булып тора һәм аның формалашуында борынгы төркиләрнең, соңга таба болгарларның, Алтын Урда, аннан соң Казан ханлыгы составындагы төрки-татарларның роле зур булган.

**Авыл тарихлары һ. б.**

Каракитәдән йырак тигел Кыр келәү йылгасы булган. Әwәле мында чуwашлар булган, чуwашлар Баешка (*ав. исеме*) киткән. Каракитә аwылы йер цәцеп, сукалап кен иткән, тырма булган йер себерегә (*тырмаларга*). Цабата тугыганнар, сыйаwы (*шөшле*) булган тугый тырган.

Келтәләрне зур атларга куйганнар, йаңгыр китмәстән аткыры куйа, цип (*чабагаш*) белә сугалар. Пецәнне кышкыга зур кылат куйалар. Богылы кецкенә, цүмәлә фурмысы, ике йә эц ылау, йәшәwекне (*курпыны*) бик цапмыйлар.

*Сөйләүче: Идрисов Арифулла*
*Сабир улы (1922 елгы).*
*Каракитә авылы*

Тукти кыйы (кое), Хәсейән кыйысы, Шәрәпи бабай тирмәне, Уртатау, Айгылди (?), Йогыры чирмә (чув.; уйлык, уйсулык), Аткыры күпер, Шапай (кушамат) Майрасы.

*Әйтеп яздыручы: Абелханов Азелҗан*
*Усман улы (1937 елгы).*
*Мунчәли авылы*

Аwылда йнде йез илле йырт булган, тузды инде. Шәйхелислам Садертдиновның туган аwылы бу. Зәнгәр цук кушаматыбыз. Бабай атына цыбык беләп «наа, зәңгәр цук» дигән, шуннан кушаматыбыз Зәңгәр цук былып калган. Цыбыгының зәңгәр цугы да булган. Әл инде цугын этмиләр, зәңгәр, зәңгәр булып калган. Безнең нәселебез эшчән. Түбән ы°цта туwыб үстем, сарыклар карадым.

Цәй суwына барабыз Нури кизләwе, дибез, тирәсен тытып, үткән ел аwылнын йез йыллыгын уздырдылар. Бакировның тепләре мыннан булган. Малай, кызлары булмаган. Чуаш Бизнәсенен

(*ав. исеме*) йылга буйында ташларын таптыралар. Татар Бизнәсе (*ав. исеме*) ин алдан килгән.

*Сөйләүче: Хәлиуллина Мөнирә.*
*Татар Бизнәсе авылы*

Ут баскан ындырыбызны. Алмагац ыцында үстем мин. Аннары мында килдем, бийем (*каенана*), әтәй, Хисматулла, Мөбәрәкша әзәйләрем бар иде, үләнделәр. Ахматша абзий. Үзем белән бертуганнар – тугызау. Үзләре wайнадан кат′ыб үлде. Муни (*менә*) wайна йылны без әле йәш. Башак калмастан йир тырный идек. Түбәбезгә түwәләр иде, башак калган, дип. Макы күп цәцә иделәр, йасмык, айбагар (*көнбагыш*). Айбагарны палка (*таяк*) белән кын′ий идек йителгәц. Аwыр йыллар, умац уwып суга, умац йасап ашыйлар иде.

Урман кисәргә йибәрделәр, Тархан (*ав. исеме*) урманында кистек, сыл әпәй, кибәк катыш, цем-цеце. Нужа күргәннәрне сүләп бетерерлек тигел. Алма-тилмә (*алмаш-тилмәш*) йал итеп алабыз. Кышкы кенне сәләзкә белән утын ташийбыз.

Аwылыбызны элгәреге диләр, Йарамай дигән кеше килгән ин беренце. Бик батыр (*зур*) калхуз иде безнен. Йирне керәк белә баса идек. Йилкәбезгә күтәреп (алып кайтырга) тызга йибәрделәр. Зәрә йарылганда (*таң атканда*) киттек, теңнә кат′ып кердек. Йыгылып йаwырнымы (*җилкә сөяген*) сындырдым. Ван′ы (*әнә*) иске йырт, шында кырбан цалалар иде.

*Сөйләүче: Мистякова Әлфия*
*Хәсәнзян кызы (1939 елгы).*
*Зур Чынлы авылы*

Асфал’тка йетәр wакытта ике киламитр кала, уң йакта безнен аwыл булган, Ярамай бабай күцеп килгән булган, Ярамай аwылы диләр. Чуаш аwылы бар анда (йакын булган), инеш аша. Аwылга каршы Ярамай аwылы булган. Безнең аwыллар күцеп килгәннәр мында. Ул инде өц йезме – дүрт йезме йыл таму назад. Анда зирәтләр дә булган. Әле дә зирәт бар, йаңгыр йаумаганда шунда баралар. Иске йорт, дибез инде, иске зират, дибез. Аннары бездән күцеп киткән унике киламитр Нариман аwылы бар, Нариман дигән кеше күцеп киткән унике киламитр мыннан. Хәзер дә бар. Сугышка кадәр мең йорт булган диләр монда – 1941 нце йылга хадәр бу аwылда. Безнен Зур Чынлы диләр бу аwылны.

Кырылык булса, укырга иске зирәткә баралар, иске йорт дигән иске зирәткә баралар. Каберләре йук, ташлары да беткән инде. Безнең зирәттә ташлар бар. Күпернең те йагында – йылганың те йагында – туже иске зирәт, анда 1600 ницәнце йылдагы каберләр бар – таштан йасалган, 1680 нце йылмы инде. Анда цыгып карасаң гына. Йан-йанында йазган 1680 нце йылмы дип. Безнең аwылга бер 400 йыллар бар инде, тегендә йәшәгәннәр, аннары монда күцкәннәр.

*Сөйләүче: Хөсәенова Оркия*
*Арифулла кызы (1926 елгы).*
*Зур Чынлы авылы*

**Туйлар, туйлар...**

Касы цыгарыб алалар. Мин үзем йакшылап (йола буенча, соратып, туйлар ясап дигән сүз) үләндем. Кийәү йуллыгы йасадык. Кийәү йуллыгы кыз йагында була, анда йәшләр (*егетләр*) генә була.

*Сөйләүче: Идрисов Арифулла*
*Сабир улы (1922 елгы).*
*Каракитә авылы*

Балга зийу диләр, никахтан сың була, туганы-тумацасы кыз-катыннар зийыла. Ни бар шуны алып килә шунда, цәй эцәсен, дәа (*дога*) кыласын.

Кияү йуллык кыз үwендә уза.

*Сөйләүче: Сәлахова Рауза*
*Зиннур кызы (1943 елгы).*
*Каракитә авылы*

Атасанасы (*атасы-анасы*) йегетнен килә, димце башта килә, аннары атанасы килә, никахны, туйны, катцан, дип сүләшәләр. Касының атасанасы килешми дә, бирмим, дир. Данийәне бирмәгәннәр, нәселенә карап китергә бит. Данийә цыгып китте (*ябышып чыкты*). Димцегә туйда берәр нәстә биреп кайтаралар, йакшы әрбирләр бирәләр димцегә, нәстә халеннән килә. Керәшен, дип бирмәгәннәр. Аларнын зиратлары да аерым, кайнеләре, кайнагалары йерде сырап. Бездә керәшеннәр дә булган, керәшен зираты да булган. Алар татарга чыгып бетте, икәү иде алар кауме. Фарзанийгә апа да Чәке (*ав. исеме*) малайына чыкты. Кызлар бижбармаклар бәләгән элгәре

кийәүләргә, батыр (*зур*) мирануслардан (*нәселле сарык атамасы: меринос*) дүрт кила цыга йын. Сондок тутырганнар кийәүнең үзенә күлмәкләр цигеп-цигеп. Килен тешкенцә, машина белән китереп кызнын әрбирләрен, ызбаны тезәтәләр. Эләңгеләр, селгеләр, мендәр тышлары, элгәре «тастымыл» дигәннәр энәйнең үзе тугыган тастымаллар, эскәтерләр тукыган тен ката (*төне буе*).

Туйга теп кыдагийлар каз алып бара. Никахтан сың эц кен келәт, кийәү эц кен кыз йанында кунак була. Кыз йагында кендез никах, эц кен келәт. Туйлар шәб иде. Туй керү, диләр, кыз йагында туганнарында кунак булып йерү кыз белән кийәү. Туй кертү шылай булган. Әле тагын ылау алу бар. Улысы туйга килгән бер парны үзенә кунарга кертү. Йегет йагында да шулай ук. Һәркемне киң келәт, иртә белә кийәү мынчасы, кийәү киймагы.

Кызны килешкәц, никахка куйарга сорыйлар мең дә бер сум мәһәр, шәкәр-бал, цәй. Икенце кенне саум, бирнә дигәне туганнарга бүләк. Утыз йыл кан′н′а белән тырдым.

*Сөйләүче: Хәлиуллова Гөлсүрә*
*Фатыйх кызы (1950 елгы).*
*Иске Чокалы авылы*

Элгәре батыр (*зур*) сындыкта биргән кызга әрбирне, күпчеген, йурганын, артлы цанага утыртып, батыр сандыкларын төwәп алып киткәннәр кызны. Кан′на бер сарык тытып киленне тайандыра, бал белә май каптыра. Суны цәцеп (*сибеп*) йибәрәсең. Әле анда питырац бешерәләр, шыл питырацны, ылауга утыргацтын, бәреп калдырасын. Wак акца тагын сибәсен, ыланнар йийа. Элгәр ун кашык, ти тырганнар иде, симйә ишле булган, аларга аш хутлап... Мин унынцы кашыкка килдем.

*Сөйләүче: Миңнебаева Заһира*
*Фәтхетдин кызы (1922 елгы).*
*Шланга авылы*

### Саум (*савым*)

Безнен вакытта саwым белән киләләр иде. Кыз йагы килә саум белән, и йегет тагы да саум белән киләләр. Каз, баwырсак, чәкчәк саум белән. Касы пирук алып килә, кыдагый пиругы буладыр. Саум алып килүцеләр садака өләшеп цыга, саум садакасы, диләр. Джаным, зегет йагы туганнарыннан зыйа, йарты миллион акца,

дип сүләкләделәр касын шунда. Кыз йагы каруны (*каршыга*) түли, бирнә диб ат′алар, теләдең кайан тап.

Кийәү белән киленне керткәндә кабакларны (*капканы*) саталар. Сагылмалыг (*искә алырлык*) ул туйлар. Безнең кызыбыз бәйәле.

Кан′анам, кан′атам, дип сүлисен. Минең ирем тепчек малай иде, әзәйләре бар иде: зур әзәй, кецкенә әзәй. Иң зур әзәйнен катны килендәш биагай булганнар (*тел яшергәннәр*). Ылы килен кайната белән сүләшмәгән, бу вет биагай, сүләшми, диләр бездә. Кан′агалар, кан′игәцләр күб иде, балдыз. Аларны хазер биг әтмиләр инде.

*Сөйләүчеләр: Сафина Солтания*
*Әхмәдулла кызы (1947 елгы);*
*Алиева Маһибәдәр Абдулхак*
*кызы (1941 елгы). Кәкерле авылы*

Каз итеннән, үрдәг итеннән туйга бәлеш йасыйлар. Пируклар, баwырсак, бетен каз – саум була туйга барганда. Кыдагыйлар да шылай алып килә. Патнусларга куйасын. Аш-судан сың саумны цыгаралар, казларны кисәләр, турыйлар. Берәр турам, берәр каwым (*кабым*) кисәләр, ләшеп цыгалар кеше сайын.

*Сөйләүче: Абелханов Азелҗан*
*Усман улы (1937 елгы).*
*Мунчәли авылы*

## Туганлык атамалары

Җәш әби бабайның икенце катны. Әби бик тансып иде, әби булмаган. Үзем йыгылып касталанам, кызым. Халсезәйәм, зийандаш тыта үземне әл дә. Нәсип мулла катны: «Син кеше бозыгына цораган», – дир. Тез тупсасы (*буыны*) тытмый. Йәш ыланы бар, нәселнәсәбә тигел, танышы гына. Зеңгәци, дибез, әнәй белән бертуган абыйның катны. Бырат кецкенәсе, энесе.

*Сөйләүче: Моратова Фирдәүсә*
*Арифулла кызы (1955 елгы).*
*Мунчәли авылы*

Зиде лан (*бала*) үстек. Әбзәйләр, әптиләр (*апалар*) бергә идек. Ике әбзәй, ике апа. Элек апаны әпти әйткәннәр. Мус′а бабай бар иды. Шакирәттәй харындаш кына ул. Мулла әбзәй ләңгәц (тәпән, кисмәк һ. б. ш.) йасаган, ылы апа күлмәкләр йүләгән, ылы апаны

Миннегел карады. Алып китмә келим, баргысы келәми. Кан′ан′ам әнәм (*каенанам*) йакшы кеш′е иде.

Кан′ата булдацысы (каената буласы кеше) йырак тегел, нүwештә генә тыра.

*Сөйләүчеләр: Хәкимова Майнур*
*Шакирҗан кызы (1929 елгы);*
*Айнетдинова Миңнегөл*
*Шакирҗан кызы (1941 елгы).*
*Каракитә авылы*

Алнартлы ике кыз биләдем, бийагай бар иде, кайнана, кан′ата. Әптәй, дип элгәре әткәннәр. Минем киленнен быраты бар, әптәй, дип джөри миңа. Малайыбыз да йаңы йыл йиткенцә кат′ырга. Туган быратым да, кат′ам, дир.

*Сөйләүче: Низамова Гөлинә*
*Һади кызы (1940 елгы).*
*Түбән Чәке авылы*

Каннам әнәй белән сука тартып цәцтек. Үземнен симйам көп тигел. Киленем бик асыл, бер йырттан икене алдык. Кан′ага, дибез катыннын әбзәйен, эптәсе булса кан′игәц, эптәй, әбзәй, диб этәбез, алар сүләми, мин дә бийагай (*тел яшерәм*).

*Сөйләүче: Миңнебаева Заһира*
*Фәтхетдин кызы (1922 елгы).*
*Шланга авылы*

Китмәгән кыз бар бездә. Ирем безгә берцәк нәсел дә тийә. Бу арттагы урам, сүләштек тә, килдем дә. Кайене, кан′нәнәй бар иде. Руз′ага кергенцә үләнештек. Йәмнеләп циккән күпцекләр куйып, артлы цана белән йеретәләр кийәүне дә, киленне дә. Әптәйләр йеридер йүгерә, кас′ы «май кап» дип, кас′ы бал каптыра.

Әптәй зур апа инде ул, үдәге апа. Тагы бер апам, анысы кунаг апа, ул йәтим үсте, безгә кат′ып тырды, нәсел дә тийә, туганыбыз, мында калгысы келәмәде. Мин барлыклы йырттан килдем. Үзебез нужаланганга күрә тырыш булдык. Бишекне күтәреп киттек цалуга (*болынга*). Үдә ыланнар бишектә, матцага таккан сикертмәсен (*сиртмә*).

Без, үз әбийем, үз бабайым, дип тә сүлибез. Мин килгәндә карт әби дә бар иде.

*Сөйләүче: Хәлиуллина Мөнирә.*
*Татар Бизнәсе авылы*

Сукыр игәце бар. Әwем-әwем (*әвен-әвен, ягъни олы гәүдәле*) бабайлар бар иде элгәре, шул хәтле батыр (*зур*) булганнар.

*Сөйләүче: Сибгатуллина Мөсфирә*
*Шиһабетдин кызы (1939 елгы).*
*Кече Чынлы авылы*

Минем кайнатам бар иде, мин бийагай (*тел яшерә*) идем, сүләшми идем. Хәзер йук андый кешеләр, хәзер тел йәшермиләр. Мин тешкәндә ка′нанам, кан′атам бар иде, ырыштылар, кан′атам «сүлә» дийә иде. Карчыгым үдә булмаса, сүләргә күршегә керим мени, дийә иде, әйбәтләр иде. Кан′атам әтә иде, айак таwышың та ишетмибез дийә иде. Каст′алансам кан′нам йылый иде. Усал булсан, йылап тырамы кан′наң. Минең әнәй әйбәт кеше иде. Шәкерт абзи, әзи бар иде. Әтәй wайнага киткәнне иц тә онытмыйм. Әнәйгә «нәнам» дир улым. Безең кырык ике йәштә ылан тапкан бер туганыбыз. Мине «үзапа» дир туганнарымның балалары, барчасы да «үзапа» диләр ийе. Камәрийә әптәй тәтәй инде ул. Элгәре «әптәй» дә дигән, «тәтәй» дә дигән. Игәцләр үлеп беттеләр, үзеңнән ылырак туган кыз-катын.

*Сөйләүчеләр: Мөнирә Зәкәрия кызы (1934 елгы)*
*һәм Сәгыйть Ибраһим улы (1932 елгы)*
*Ханбиковлар. Шәйморза авылы*

**Бала үстергәндә**

Карцыг әби (кендег әбие) кулына ала да баланы кийындырып цыга.

Әлли-бәлли Бәхтийар,
Ызбартында бүре бар.
Йылаганны кереб ал.
Аллаһу, Аллаһу,
Аллаһу, Аллаһу,
Кызым йыкыга китә.

Йә үзгәцәлий әтеп тырасын, өтөрәсен. Кы°йы°нганда цәт-цәт йеретәбез, зур үсәсен, дисен, мактыйсын:

Апаң кебек буласын,
Әтәң кебек буласын.
Тәтә йерисен, тәтә йерисен.

Джегет буласын.
Йабалактан йын сыра.
Карцыгадан май сыра.

Күзләр нацарланды, тайым, арпа цыкты. Карцыклар арпа белән санийлар иде.

Кыйарак (кайрак) цыга иде култыг астында, цыбан (чуан) цыга йә култыгастына, йә аркага.

Сигәндә мышкаж була, касык тебендә биз калка. Май белән сыдыралар (ышкыйлар).

Ай кайта, кен кайта
Мышкаж булсан, син дә кайт, – дир.

Шылай була, белгән кеше өшкерә тырган иде. Петен йасинны цыга идем.

Арпаны да шылай итәләр: Ай кат′а, кен кат′а. Арпа булсан, син дә кат′. Шындан арпа шилә (кими) бара, шилә бара. Бер, бердән кат′а, апкат′а, кен кат′а, арпа булсан, син кат′. Бер, ике, эц, эцтә ыцып кит, ай кат′а, кен кат′а. Арпа булсан, син дә кат′.

Бер, ике, эц, дүрт, биш, биштә бизеп кит.
Ай кат′а, кен кат′а, арпа булсан, син дә кат!
Бер, ике, эц, дүрт, биш, алты, зиде, зидедә зилгә ыц.
Ай кат′а, кен кат′а, арпа булсан, син дә кат!
Бер, ике, эц, дүрт, биш, алты, зиде, сигез, тугыз,
тугызда тузып кит.
Ай кат′а, кен кат′а, арпа булсан, син дә кат!
Унга тәке санийсын, андан кирегә таба тешәсен.

Шом тыту (бизгәк) көп булган. Өши, калтырый, зур пиз баш элке, менеп йата капланып. Бака бәргәннәр, куркытканнар.

Үле бар′амында (үлене искә алу мәҗлесе, коръән ашы) киймаг инде. Үлгәцтән эц кенгә хатле ашамыйлар. Үле бар′амында ин элек цәй, андары думашний ләкшә (*токмач*), бәрәңге белән ит, турт.

Бездә аран (*абзар*) ийәсе, мунца ийәсе, йырт ийәсе бар бездә. Балаларнын эрәхәтен серергә насип булсын.

Әйуп пигамбәребез аwырып йаткан. Кырт цыккан да, каршы тешеп муртага (*умарта кортына, бал кортына*) әләнгән. Әйүп пигамбәр рухына дип дәа кылабыз бал уңсын эцен.

Су анасы бар, дир, мин күрмәгән. Әткәннәрен беләмен:

Су анасы суган сакал,
Джир анасы джирән сакал,
Джир, кецемне бир, дир.

*Сөйләүче: Миңнебаева Заһира*
*Фәтхетдин кызы (1922 елгы).*
*Шланга авылы*

**Аулак өй**

Киц утыруда йезек салу ун′исын, арка сугыш, күгәрцен ашату, йарты шырпыны каптыралар да икенчесе авызы белән шыны ала. Мәзәг утырмадым, әнәй зибәрмәде.

Әйдә, иркәм, кил әле,
Икәү әйләниг әле, –

дип йырлап кыруг уйын ун′и иделәр. Йылдыз санарга цык, дип, цыгарып йибәрәләр, сүләшеп керәсен.

*Сөйләүче: Абелханова Саура*
*Әхәт кызы (1939 елгы).*
*Мунчәли авылы*

**Уеннар**

Черки унибыз йаз башында (*яз көне*), ашыг уйн′ы, диләр иде, малайлар ун′ий иде.

Лапта – тупны элгәре, агацтан керәге була, шыны белә суга. Кемгә тийә, ул суга. Анары кара-каршы ун′ап. Каз балаларын, бәрән, бозау саклыйбыз.

Кыз вакытта эч әттереш уйныйдырыйк мәзәктә (аулагыйда). Каз асырыйлар да эмә йасыйлар, кицен мәзәк. Әләндереп ун′ибыз. Терттереп ун′ау бар иде, такмаклар әтеб-әтеб.

*Сөйләүче: Хәлиуллина Мөнирә.*
*Татар Бизнәсе авылы*

Мәзәктә, аулакта инде, ун′и идек терле ун′нар элгәре. Утырмага кыз килә.

Бармаг уйыны әтәбез. Берәр бармак арасына тертеп-тертеп ун′ибыз. Цыккан кешегә йаза бирәләр.

Тытыныб ун′ау этә идек, йырлыйлар да уртадагы кеше берәрсен ала да әләнәләр.

Келтә зийабыз, диләр, йегетләр бии дә, келтә зийабыз, дип, рәттән бийеп цыга. Эцәрләб ун′исың.

Йаз башы йитсә, ташуга тешәбез. Ташу эсләре бик матур була иде. Кырукта ун′ибыз, эцәрләп, түндәг алыш.

Түндәг алышу ун′и идек, ике йакка йүгерәсең, кас′ын килеп зитә.

*Сөйләүче: Замниханова Гөлсинә.*
*Келе Чынлы авылы*

Йаз башында урамда ун’ий идек, анда кызлар, катыннар – бик кеңелле була иде. Аны «ташуга тешәбез» диләр иде. Ап-ак наскийен кийеп йибәрәсен, аннан башмакмы, калушмы – кемнең нәстәсе бар, сырмышын кигән инде. Тигендә, арйакка цыкканда мыни көпер бар, анда йугары оцлар. Бу йагыбыз – түбән оц, те йагыбыз – арйак, аларның да йугары оцы, түбән оцы бар. Тигеләр теге йактан тешәләр, аннары бу йактан. Дерес, анда кө(ү)пер йук иде, безнен ташыу wакытында бикләнә, теге йак та бу йакка цыгалмый, безнең йак та теге йакка цыгалмый. Шул хатле кецле ташу була. Ул wакытта мин фермада эшли идем. Шул ташу wакытларында вис ферма йаннары бетенләй, анда без цыгалмыйбыз, фермада шунда тыра идек. Элгәре әпәйләрне алып цыга идек мыннан. Әпәй цала идек пицләрдә. Анда әллә нәстәң йук, сыйыр саwасың да, сетеңне әпкереп ашыйсың. Шолай тыра идек. Аннары сон – ташу уза төшкәчтән сон инде – үгә катып киләр идек, көймә белән цыгаралар иде. Безнен йактан 9–10 кыз эшли идек. Завфермалар ызаталар иде дә, каршы алалар иде тагын, мыннан әберләребезне алып, кийенеп, әпәйләребезне алып. Шолай тыра идек пака күперләр суккынца.

Ташу өстендә круг ун’ий идек, түндәк алышу уйныйлар, эцәрләп тә ун’ий анда, йырлыйлар, гармун килә, гармун тешә, бар да йырлый. Чар-чар-чар сулар ага, бик матур, бик кызык була иде. Ницә кен, бер өц көн инде кызу, шулай йөри идек әле. Тегеннән бызлар киләләр иде. Быз эстенә йандырып-йандырып әрбирләр, теге сал фурмасы, цыбыклар белән йибәрәләр иде. Шолай, бик матур. Шолай кан’ап йериләр иде. Анда бит инде шул белгән кеше теләкләр теләгәннәрдер инде элгәре. Ул wакытта без йәшләр, безгә

өрәтмәгәннәр дә. Без теләнмәгән. Без хазер телибез дә бит. Ыланнарга да хазер өрәтәм.

*Сөйләүче: Сибгатуллина Мөсфирә*
*Шиһабетдин кызы (1939 елгы).*
*Кече Чынлы авылы*

### Кабер казу

Йугары Каракитә, Түбән Каракитә аwылларында каберләрне тирән казыйлар. Кеше сыйарлыкны казый туры итеп, туры ләхет бездә. Баганалары йитмешәр сантимитырга туры килә. Кабер казырга цалыр була, башында дугаланып тыра тырган тыткысы була, үзе ыцлы ул, эсте ике йәпле. Сыwыкларда каткан йерне казырга ыңайлы була ул цалыр. Бездә ләхет кабернен тебендә була, туры ләхет, диләр. Ләхетне астан алалар, йаннан тигел.

*Сөйләүче: Идрисов Арифулла*
*Сабир улы (1922 елгы).*
*Каракитә авылы*

### Йолалар

Йезек (*ахирәт дус*), йезек кушылу – ахирәт дус булу. Менәҗәтләр йезектә бар, дәптәр белән. Без йезек кушылган идек анын белән. Ике бармакны эстәлгә куйып берәр җыр башкаралар. Шыннан йезек булалар.

*Сөйләүче: Сәлахова Рауза*
*Зиннур кызы (1943 елгы).*
*Каракитә авылы*

### Биагай

Элгәре йаулыкны тишмәгән. Мин әттем, миңа бийагай кирәкми. Күрше кешесе бийагай имеш. Кыз цагында сүләгән дә, килен булып килгәц сүләшмәгән, бийагай имеш анын белән. Сездә, тел йәшерә, диләрме?

Син иреңә аты белән әтмә, дир. Нәсте эцен ат куштыгыз, дим. Элгәре кара, кара әле, син теге-бу, дип йергәннәр иренә.

Мим бийгай, анын белән мин сүләшмим. Берсе кийәүгә киткән. Таз йуг икән, күршедән алып цыккан. Кан'ата тирмән йаларга эрән-

гән. Тирмән йалагынца тырамы сун теге бийагай килен. «Тазың булмагац, апцыкмый нишлим сың», – дигән.

*Сөйләүче: Миначева Мәликә*
*Вәлиәхмәт кызы (1928 елгы).*
*Иске Задур авылы*

Избаны салып бетергәц, йасин укыталар, кырбан цалып. Йитмешләгән кеше була, ылы бар′ам вет. Башта «бисмилла» дип әнәй керде. Нигезен йасаганда азан әттердек, айателкөрсине матцанын асларына куйалар. Элгәре алтын куйганнар. Бер байнын өйен сүттеләр дә алтын акца цыкты. Хазер кемеш акца матца астына. Кем ницектер. Нигез боткасы өйне күтәреб бетергәцтән ботка китерәләр, анарга да кырбан цаласы. Малай хезмәтеннән кат′кац кы$^{о}$рбан цаласын.

Балаларым үлеп тыргац, тусыннар иде, салдатта хезмәт итсеннәр иде, дип теләдем.

Шом тыту бар иде. Мин йәш цакта нәнәйне шы$^{о}$м ты$^{о}$тты. Йә бака тыгалар кун′ына, йә «йанасыз» дип бер циләк су китереп бәрәләр, куркытып.

*Сөйләүче: Хәлиуллина Мөнирә.*
*Татар Бизнәсе авылы*

Йармунка была иды без бала цакта. Йәш киленнәр селгеләр цигеп бирәләр иде. Ат джилеше (*чабышы*) булайды, джилештерәләр атларны. Ацы (*тозлаган*) кыйарлар саталар иде. Гарбуннар ун′ап тыра, дудка бар.

*Сөйләүче: Сибгатуллина Мөсфирә*
*Шиһабетдин кызы (1939 елгы).*
*Кече Чынлы авылы*

Керәш буладыр сабантыйда, капцык сугышы, атлар цабышы.

Бийылгы күк кырыга китсә йаңгыр теләгенә цыгалар иде. Бу йылларда андый ниләр йук. Циләк белә су тутырып алып менә. Узып баруцынын эстенә йибәрә, сибә. Дүрт кетү аwылда.

Wайнада үзебезне үзебез айамыйца эшләдек. Ацлык та булды бит, кецеркән, балтырган, какы, зәрдә – терлесен ашадык. Бер карцыкның бакца башына бер кыз килгән кецеркән зийарга. Әби кыwа икән, үзебезгә дә йитми, ди икән. Аннары ул кыз бу әбигә килен булып тешкән, дир. Тату йәшәделәр, келешәләр иде сүләп.

Йаңгыр теләген, береңә береӊ су сибәдер ийеӊ. Ыланнар йымыркалар зийып йериләр. Кас′ы йымырка бирә, ка′сы йарма бирә пешерергә. Бер йыртта пешеррәләр аны, бер әбидән пешертәләр. Суны сибеп йериләр урамда, анда кызык була инде, бетен аwыл буйында сибешәләр. Сибешеп туктагац, кат′алар бытка пешкән йиргә. Ыланшакка (*бала-чагага*) кеңелле, идә ашарга бар, ә мындагысы тәмнерәк. Кас′ы айагы (*савыты*) белә, кас′ы ике кеше бергә аший.

Йаңгыр йау, йаңгыр йау,
Алла йаңгыр бир, –

дип кыцкыра-кыцкыра сибәләр. Бала-цага куркып тырмый ул.

Алла бир, йаңгыр йау,
Тәти кашык базарда,
Майлы бытка казанда.

Анда бала wакытта йери идек, хәзер йук. Бик кызу wакытта картлар кырга цыгадыр ыйык. Җир туйарлык бир, Хыдайым.

Син гаиб кунак. Менә синеӊ үз ыризыгыӊ була икән, ул минем аркылы килә. Менә мин йомырка пешергәндә артыгырак пешергәнмен. Менә синеӊ ыризыгыӊ алдан әзерләнеп торган. Кунак «үз ыризыгым» дип ашарга тийеш, анарга саwап кына ул.

Минеӊ әнәй әтә иде, исәпсез бирсен, дийә иде.

Минеӊ әтәй теш күрәм, дир иде. Кыйамәт кенен күрәм, дир иде. Кыйамәт купканын күргәнем бар, кыwаклар ыца, ницә мәртәбә күргәнем бар, йир убыла да убыла. Алланыӊ барлыгын, берлеген белеп, алдан әзерләнеп кетеп тыру бик йакшы, диләр.

Кыз чагым, арпа цыкты. Арпаны тытып саный, тирескә (кирегә) саный: ун, тугыз, сигез, зиде, алты, биш, дүрт, эц, ике, бер – берлексез булсын, ди дә эшкерә. Аннары тагы ун, тугыз, сигез, зиде, алты, биш, дүрт, эц – эцтә ыцып китсен ди дә тагын эшкерә. Тагы саный, ун, тугыз, сигез, зиде, алты, биш – биштә бизеп китсен, ун, тугыз, сигез, зиде – зидедә зилгә ыццын, ун, тугыз – тугызда тузып китсен ди дә тагын эшкерә:

Ай кат′а, кен кат′а,
Арпа булсаӊ, син дә кат′,

әтә, э$^{е}$рә шулай.

Тимерәү цыга иде түгәрәк кенә, тәңкә кебек. Аны да эшкерүце әби бар иде.

> Әм-әм, әмрәмун,
> Тим-тим, тимрәмун,
> Ай кат′а, кен кат′а,
> Тимерәү булсаң, син дә кайт.

Эᵉрә- эᵉрә эᵉшкерә, бетә Ходай рәхмәте.

*Сөйләүчеләр: Мөнирә Зәкәрия кызы (1934 елгы)*
*һәм Сәгыйть Ибраһим улы (1932 елгы)*
*Ханбиковлар. Шәйморза авылы*

Йаңгыр йаумаса, Саз күпер тебе, диләр, шында теләккә цыгалар иде. Балалар йүгерә йөри:

> Йаңгыр йау, йаңгыр йау.
> Сетле кәзә абзарда,
> Сырлы кашык базарда,
> Тәмле бытка казанда, –

дип кыцкырышалар. Циләге белә суны берәрсенә сибеп тә йебәрә.

> Майлы бутка пешмей,
> Йаңгыр йау-йау, –

дип тагын кабатлыйлар.

*Сөйләүчеләр: Идрисов Арифулла*
*Сабир улы (1922 елгы),*
*Сәлахова Рауза Зиннур кызы (1943 елгы).*
*Каракитә авылы*

Ү хуҗасына дәа кылам.

Нәзер кырбан, диләр, нәзер ат′асын бер-бер нәстәгә, кырбан цалып мәзлес йасыйсын.

Кырбан айытында эристән, йеземнәр бутап, тепкә кыᵒрт зәйеп, гөбәдийә бешерәсен.

Йуwаца цөцөли, уртасы тишек, берцәк уйырап (*чокырлы булып*) тыра. Бәбәйгә генә ул, табада гына пешә. Сеннәтле булган тешкә генә алып киләләр тарилка белән.

Бәбәй ашы үзенә башка. Бәбәй ашы буладыр пилмин, ботка, аш ташыйлар. Бәбәй мунцасына цакыралар. Искеләр китерәләр, цырнарга иске булмаган. Бишеккә салган ыланны, тен ката йыкы

йук. Марл′ыга әпәй цәнәп куйган, имезек (*имезлек*) йасап. Баш астына әптийәк куйалар, ыштубы зенме, шайтанмы килмәсен, күз тимәсен.

Матцаны тартып меңгерәләр, касы азан да әтә. Астына кемеш акца куйып калдыралар. Акца кебек йалтырап, кемеш кебек йалтырап тырырга булсын, тимер кебек тазага булсын, дир.

Меңгергәцтән утырып ашыйлар. Матцаны меңгергәцтән эшлиләр, ирләр цыгалар, катыннарны йәшәләр.

Йәш килен быткасы була. Йәш килен килгәцтән була ул, малай йагында. Туйдан икенце кенендә уздыралар.

Нардуган мәзәк (*аулагый*) утырганда була. Үмә белән утын кистерәләр дә, кицен мәзәк. Мәзәктә кара-каршы утыралар, кызлар эскәмйәдә, йегетләр каршы утыралар. Йезекләрне чашкага салып йеретәләр. Бер йезекне чашкадан алалар. Кемнең йезеге цыга, шыны йырлаталар. Кош коно мәзәк була, йегетләр гармун′ ун′ап керәләр, бийетәләр, йырлаталар, касын салкын мунцага цыгаралар, сүләшеп керәләр, касы урамга цыгып керә.

*Сөйләүче: Миңнебаева Заһира*
*Фәтхетдин кызы (1922 елгы).*
*Шланга авылы*

Кимсенә идем, кешеләрнең балалары бар, алты кыз булса да, кимсенмәс идем дип әтә идем.

Таң суwын иртә белән таң аткац аласын. Ыланнарга күз тисә, белгәнеңе укып сийписын касыкларын, битләрен.

Таң суwын кийыдан да, цүлекмәле кийы, аласың да ацык урынга куйып тырасын, таңның нуры тешсен. Цыктан мурталар (*бал кортлары*) бал дзийалар.

Аллаһу, Аллаһу,
Кәзәләрне талга ку.
Тал атасын китерсен,
Әминәгә мәмәй китерсен.
Әлли-бәлли итәргә
Кал′аскасы бар аның.
Йылаганда йуwатырга
Үз әбкәсе бар аның.

*Сөйләүче: Хәлиуллина Мөнирә.*
*Татар Бизнәсе авылы*

**Яңгыр боткасы**

Йаңгыр йаумаса, кырыга китсә, инеш keләwенә цыгабыз. Инеш keләwе, дир, су сибәләр йәше-карты. Пецән эсте йеткәцтән кабак баwына (*капка тоткасына*) герәплә (*кул тырмасы*) ышкыйлар. Күкәй зийып пешереб ашаталар балаларга. Кырга цыгып намаз укийлар, кыр башына цыгып.

*Сөйләүче: Миңнебаева Заһира*
*Фәтхетдин кызы (1922 елгы).*
*Шланга авылы*

Йаңгыр теләге була. Йаңгыр келәгендә су сибешәйек.

Йаңгыр йау, йаңгыр йау,
Арыштан, быдайдан,
Без сырыйбыз Хыдайдан.
Тәти кашык базарда,
Майлы бытка казанда, –

дип такмаклий-такмаклий йериде бала-цага.

*Сөйләүче: Сибгатуллина Мөсфирә*
*Шиһабетдин кызы (1939 елгы).*
*Кече Чынлы авылы*

Элке теләк теләп йири идек, бытка пешерәләр, быламык. Йымыркаларны пешерәләр. Кем нәстә бирә, шыны зийалар. Ашагац эцәр циләк бирәләр суны, йаңгыр йаусын, дип. Теләк теләү, диләр, йаңгыр теләү.

Алла бир, Алла бир,
Игеннәргә файда бир.
Арыштан, быдайдан,
Без сырыйбыз Хыдайдан.
Майлы бытка казанда,
Тәти кашык базарда.

*Сөйләүчеләр: Хөсәенова Оркия*
*Арифулла кызы (1926 елгы);*
*Мистякова Әлфия Хәсәнзян кызы (1939 елгы).*
*Зур Чынлы авылы*

### Кот кою

Йыгылып курыкса, «кайан килсәң – шунда кит, кайан киләсең – шунда кит», – дип эшкерәләр әбиләр.

Курку койдыру, дияләр бездә, курку койдыралар.

Сарыдан эшкерәләр этц мәртәбә, күпцег эстенә куйасың баланы.

Күзеккәннән була, улысын да эшкерәләр, таң суwы алалар, битенә, маңгайына сертәләр. Элке китап ачучы да бар иде.

*Сөйләүче: Хәкимова Майнур*
*Шакирҗан кызы (1929 елгы).*
*Каракитә авылы*

Ы$^{о}$ланнар курыксалар, әби кургашин кы$^{о}$йа. Бер әби матца астына утырта утыргыц белә. Анын түбәсенә минек (*яфрак себеркесе*) куйа. Эстенә салкын су белән саwып, анарга эреткән кургашин койалар. Мин дә аттан курыктым бит мин. Ат рәсеме те$^{е}$ште, арбасы, арба йанында нәзек-нәзек сузылып саламнар төште. Файдасы тийә инде, Алладан сы$^{о}$рарга, сабыр итәргә кирәк.

*Сөйләүче: Хәлиуллина Мөнирә.*
*Татар Бизнәсе авылы*

### Күз тию

Күз тийү булган элгәре, хазер дә бар вет. Күз ул – агац кырыта, дигәннәр. Ылан йылый, күсезләнә, йыкламый. Ишек баулары, тәрәзәне су белә сыдырабыз да ланны сертә идек. Касы шында имты$^{о}$м иткәннәр.

### Бүсер

Кас′ы баланын бүсере була. Бүсер сыны (*рәсеме*) йасыйлар да касыгындамы, шында сертәләр инде, дәасы булган, белгән әбиләр шыны укыган, эшкергәннәр дәдер. Лән (*җитен*), киндер майлары эцергәннәр.

*Сөйләүче: Миначева Мәликә*
*Вәлиәхмәт кызы (1928 елгы).*
*Иске Задур авылы*

## Аран иясе

Аран ийәсе атның йалын үргән.

Ү йасаганда дога айателкөрси дип ат'әләр, аны куйып калдырасын. Матца астына кемеш акца куйасын. Аркыны (матцаны) тымат куйарга кирәк. Ызбаны күтәреп бетергәц, нигез боткасы ашилар, аш уздыралар. Ашлар китерәләр, боткалар туган-тумачилар, тирә-күршеләр.

Ызбаны күтәргәц, путалак түшиләр.

Йаңгыр келәгәннәр. Балалар такмаклар әтә, ынытылган инде.

Майлы ботка бирермен,
Майлы бытка казанда,
Сырлы кашык базарда.

## Су анасы

Йылгага йебәрмиләр иде әнәйләр. Су бүресе тытмасын, су анасы тытмасын, дип куркыталар иде.

Су анасы суган сакал,
Җир анасы җирән сакал,
Мени сиңа джим китердем,
Кабул итеб ал,
Саулыгымны кире кайтар, –

дип, суны сибәсең.

*Сөйләүчеләр: Сафина Солтания
Әхмәдулла кызы (1947 елгы);
Алиева Маһибәдәр Абдулхак кызы (1941 елгы).
Кәкерле авылы*

## Аш-су

Кы°рт йасыйлар вет. Сет, йымырканы йакшы итеп былгыйлар, сың эретәсен, кене буйы каний, писүк, суды салып таы берцәк каний. Цәй эцәргә кисеб ала тырган аwыл эрбире. Биш литыр сеткә униге йымырка кирәгә.

Атышкан сетне сезәләр, каты гына була. Суды, ты°з, йымырка, ын салып басасын. Түгәрәкләр йасап цәпибез, табада жарит итәбез. Тәлинкәгә куйып-куйып бирәбез.

Кәлземә – эремчек пилмәне (вареники): сетне эретәләр, эремцек йасилар. Йымырка, йәшел суган, тыз, писүк, әз генә суды күпертеп

йибәрергә. Изәбез, камыр йасибыз, ләкшә камыры кебек, эценә тыгып шыны (эремчекне) пешерәбез. Шул кәлземә була.

*Сөйләүче: Идрисов Арифулла*
*Сабир улы (1922 елгы).*
*Каракитә авылы*

Йуwача бар бездә, ланны сеннәткә биргәц пешерәбез. Ланны сеннәткә утырткannар. Әцә килгән, сеннәткә бирәләр.

Кесәлне утырбыдан (*көрпә*) да йасилар, ац камыр белә ацып күтэрелэ.

Алма (*бәрәңге*) тәкәсен ацылый камырны табага зәйәсен, алма буткасы эстенә зәйәсен, эстенә йымырка сертеп пицкә тыгасын. Зур да була, кецкенә дә, табаң ницек.

Алма кәкәше әле ватрушкалар була бит, шындый ук.

*Сөйләүче: Сәлахова Рауза*
*Зиннур кызы (1943 елгы).*
*Каракитә авылы*

Туйга чәкчәкләр йасыйлар, пируклар салалар. Зәймә зәйеп кош теле йасыйлар. Хәзер бармак (*озынча формалы бавырсак*) йасыйлар, сумсалар пешерәләр майда да, корыда да. Былайга йакмыш (*бәрәңге пәрәмәче*), кыстырымбый (*кыстыбый*), катыклы салма тәмне була, йарма белән сетлүрә пешерәләр бездә. Бездә пилминне итен берцәк кенә пешереб алалар да балта белә тапыйлар. Эцпыцмакны эцәктән дә, иттән дә йасыйлар.

*Сөйләүче: Низамова Гөлинә*
*Һади кызы (1940 елгы).*
*Түбән Чәке авылы*

Киндерашны теwәләр, майы цыга, сийырцыгы (киндер орлыгын төйгәч, мае сугылгач кала торган төбе) кала, кас′ы курып табада ашый, айбагар (*көнбагыш*) майы, лән (*җитен*) майы, терлесен ашаганбыз энде.

Йәлпәк (*яссы*) кенә йасмык была. Бырцак киймагы, бырцак быламыгы, бырцак салмасы йакшы, катык катып-катып ашарга. Белен ацыга пешерәбез.

Эцпыцмаклар, ит бәлеше салабыз. Гөбәдийә кунакларга, джәймә, кош теле йасисын. Баwырсак була, усы (*анысы*) кисеп-кисеп.

Бармак пешерәләр йуwаца камырыннан, озынырак. Йуwацасы эрерәк, тужы. Тагын цәкцәк йасыйлар, бал белән катыралар.

Кыстырымбыйны (*кыстыбыйны*) хыт′ кен дә пешер, алма быламыгы белән, майын күбрәк салсаң бик тәмне була.

*Сөйләүче: Сибгатуллина Мөсфирә*
*Шиһабетдин кызы (1939 елгы).*
*Кече Чынлы авылы*

Сөздә дәме тура йасыйлар? Эремцек йасый башта, йомырка сыта, тозын сала, аг ын белән баса, сода саласын берцәк кенә, кирәксә тыз, пәсүк, майлап куйа. Әнәй йалан (*һаман*) йасый иде. Киндераш (*киндер орлыгы*) кәкәцләре (*ватрушка*) пешерә иде, киндераш кәлҗемәсе дә пешерәләр, тәмне була. Хазер кайа алар? Йасмык салмасы, бырцак салмасы да буладыр. Цумар эзеп-эзеп пешерәләр тызлык (*шулпа*) белә куйа да. Айбагарларнын майын сыктыралар, тебен алма (*бәрәңге*) быткасына бутаб ашыйлар.

*Сөйләүче: Моратова Фирдәүсә*
*Арифулла кызы (1955 елгы).*
*Мунчәли авылы*

Йылкы майлары тыта идек, баwырсаклар пешерәбез. Баwырсак, пирукләр, пирәшкиләр. Цумар пешерәбез эзмәләп (*өзеп-өзеп*) камырдан. Йыш иләктән иләп, салма (*ракушки*) йасийсын, кабартма, киймак пешерәбез. Зәймә йука гына, зәймә бар′ам азыгы. Келиндир аг ындан салабыз, уртасы тишек, йуwаца, дибез. Йакмыш булса, алма буткасы йагасын, кан′арлый ашийсын, тәмне буладыр.

Йуwаца камырдан гына. Ыланны сеннәткә биргәцтән, ыланнар сеннәтләгәцтән алып киләләр иде.

Кырт йасыйлар, тура йасыйлар. Икесе дә эремцектән. Кыртны туваруктан аклата йасилар. Тураны сетне кызаргынца каний, ак ситецка салалар, суwы агып петә, сеткә салып ашыйлар.

*Сөйләүче: Миңнебаева Заһира*
*Фәтхетдин кызы (1922 елгы).*
*Шланга авылы*

Тура – эремцеккә берцәк ын, май, йымырка кушалар ийе, аны мона шулай әwәлиләр, түгәрәк-түгәрәк йасыйлар. Аны шулай элекке пицтә пешерәләр иде әнәйләр. Аны әнәй безнен сары майны эретә иде дә, майга бастырып куйа иде. Тансык кунак килгәндә ала

да кисеп куйа майы белән. Тураны әнәйләр шулай пешерәләр иде, эремчек кып-кызыл кызарып, сеткә йымырка, май да кушасың, писук, берсәк кенә тәмләтерлек тыз. Аны әwәли иде дә түм-түгәрәк йасап шулай, табага тезә иде дә, пицтә пешерә иде кып-кызыл кызартып.

Кыртны сеттән йасыйлар, сауган сетне эретәсен дә катык салып, аны кан'атасын. Пицүк саласын, мөмкинлеген булганда, каймак саласын, йә май саласын кайнаганда. Бик тәмле була.

Сетнең есте калын гына тора, эстен алалар да әйбәт иттереп, тебе бар иде – түгәрәк агац сыман, аннары сон әләндереп май йасый торганым да бар иде. Эстен алу әнәйләр заманында, безнен заманда инде сипарат бар иде. әләндереп-әләндереп аласың, дүрт-биш кат кийы суы белән йуасын тебесе агацтан йасалган туры гына, монда сабы инде. Мында тепкә сугып куйылган плюс кебек алтыны. Ызак нитәсен, аннары майы тешә инде. Ар’ане (*әйрән*) була. Әләндерә торганны сындык кебек йасалганннар. Салалар иде, анда канатлар йасалган иде агацтан, әләндерәсен шулай ук. Анда да май төшә инде. Майын аласын, йуасын, ар’анен (*әйрән*) аласын, аннары ар’ане бик тәмле була. Аннары кебесен кайнар су белән йуып киптерәсен. Ул бит бәсәрә (*күгәрә*), начарлана – йумасан. Актыктан йуып куйалар, киптерәләр пасудасын. Бу айранны камырга да куцарга, эцәргә. Мин берүзем эцә идем, ыланнар (*балалар*) эцмәгәндә.

Сеттән катык йасыйлар, кем дә йасый аны. Аннары тваруг та барлыкка килә. Сезмәне дә сыркыта идек, каймагын салып ашыйсын.

*Сөйләүче: Хөсәенова Оркия*
*Арифулла кызы (1926 елгы).*
*Зур Чынлы авылы*

### Бизәнү әйберләре, кием-салым

Постау тун кызга, сәтин күлмәк, эшкә киндер күлмәк әзерләгәннәр. Мин тугымадым, ике балалы күлмәге әле дә торадыр кан'анамнын. Әни тугыган боларны. Мамык шәл, ак йефәк шәлләр. Сондокка тутырып куйа.

Әле алыннарында хастәсе бар кемеш тәңкәләрдән, ахыктан, бырушкасы, алтын йезеге, алтын алка элеп куйган. Мун'да мәрҗән, кәрәбә иде түмәләр. Ирләрнең сәгат цылбыры шикелле бунема

тагам цылбыр, бормасы бар эләктерә тырган. Цәцкә цулпы, эц тезем мәрзән, муни (менә) йаталар.

*Сөйләүче: Моратова Фирдәүсә*
*Арифулла кызы (1955 елгы).*
*Мунчәли авылы*

Кулга wарига (*бияләй*) бәли, бишинә wарига, дибез. Өркаца була улсы цүпрәктән. Тагын цикмән тун бар иде. Сыкна басуцылар үзенә башка булган. Ты$^{о}$лып тегәләр цырналыб утырыга.

*Сөйләүче: Абелханов Азелҗан*
*Усман улы (1937 елгы).*
*Мунчәли авылы*

Апа йүләгән күлмәкләре бар, алны бер ин, арты ике ин, әле куригы да была. Үзем пецтем, үзем йүләдем, улысы эстәнәсе (*кысасы*).

Элке пәзи тугып теккәннәр. Киндерашны цәцә иделәр, цүпләмәсен (*басасын*) алдан йийып ала иделәр. Пәзийтен түwә идек талкыда.

*Сөйләүче: Айнетдинова Миңнегөл*
*Шакирҗан кызы (1941 елгы).*
*Каракитә авылы*

Лән (*җитен*) киндерен пәзи (*сүс*) теwәләр иде. Пәзи кәркеше (*киндерәсе*) иткәннәр, мишүк бәләwеце дә шыннан, тымат (*нык*) инде ул, эзелә тырган тигел. Сыкны йыгы (*тула оек*) цабата белән кийәргә сукканнар өмә йасап. Чыкна басу эцен зен эрлиләр. Сыкны йыгы кизитек фурмасында айакка кийәләр. Кистек басуцы килә, кистек бастыралар.

Бишмәт кирәк булса, мамыг аласын. Кийем-тытым булмаган элгәре. Элгәре калын, батыр (*зур*) шәл, ты$^{о}$лы$^{о}$п, тун цикмән кеше келкесе батыр (*зур*) иде, батыр йагасы иде дуга кебек. Элгәре тиреләтә зийалар иде, ыздат′ итә идек тиреләрне.

Айакка байыраклар цитек тә кигән, кәwеш булган. Сай битле калуш. Цитек эстеннән калуш кийеп куйган.

Башта үзебез баскан кийез шл′апа, бүрке, шәл, мамык шәлләре, йон шәлләре, магазин шәлләре. Батыр (*зур*) сыкна шәл йабына кышны йулга цыкса.

Элгәре тугыз балалы (*балайтәкле*) күлмәк иде, йаулыкны зәйеп бәлиләр. Эцтән күкрәк кийеп куйа циккәнне. Күлмәктә түгәрәк йага гына, эц бармак инлесе (*иңлеге*).

*Сөйләүче: Миначева Мәликә*
*Вәлиәхмәт кызы (1928 елгы).*
*Иске Задур авылы*

Иртә тырам, кеше кетү сергенцә мин ыйыкның сабын (*кунычын*) бәләб бетерә идем.

Элгәре күкрәкцә эцтән булган, касы тәңкәләр белән. Иңсә йага астына петү, күкрәкцә акыклы, йан-йакка тәңкәләр.

*Сөйләүче: Миңнебаева Заһира*
*Фәтхетдин кызы (1922 елгы).*
*Шланга авылы*

Кийенгәннәр элке. Тәтәйне беләм әле. Пелүш камзул, цитек, зефәк шәл йабына иде, балалы (*балайтәкле*) күлмәкләр, җиңнәрендә дә бала, цабулаларында да. Запун (*алъяпкыч*) буган циккәнне, билдәне дә, л'амкалысы да була.

Күлмәкләргә энец салдырганнар, йанда кесә менә шындыйга. Йагасы шындый тар гына, түмә такканнар, ышчу ацык булмасын, муйн күренмәсен.

Шулысын дә этәм, мәрзәннәр такканнар, мәрзәннәре терлетерле, эре, сарысын тактым мин, йандар. Цулпы булган әwәле, беләзекләр кемеш, кемеш алкалар. Шәрег (*шәрыкъ*) алкасы бу, айсыман.

Сиксән сигезенче нумир
Кылаг алкаларында, –

дип йырлыйлар иде кич утырганда. Талир тәңкә, талир чулпы байларда гына иде, цәцүргец цулпысы, алынча (изү-бизәнү әйбере) бар иде, мәрзеннәр белән цигеп йасаган. Хастә булган, әнәйнен йуг иде, усын (анысын) да әйтә алмим.

*Сөйләүчеләр: Сафина Солтания*
*Әхмәдулла кызы (1947 елгы);*
*Алиева Маһибәдәр Абдулхак кызы (1941 елгы).*
*Кәкерле авылы*

Мөнәҗәтләр

Әтим әле мөнәҗәтләр,
Тыңласагыз кеңел салып.
Узган гемерләрне уйлап,
Утырамын хайран калып.

Эй, Ходайым, халем натчар,
Бу халлердин этчем пышар.
«Алла» дисәм, йерәгем бушар,
Сабырлык бир, бер Аллам.

Сабырларны Ходай сөйгән,
Сабырсызны ләт дигән.
Аларны җәннәттин сөргән,
Сабырлык бир үзең, Аллам.

Еламагыз, димәгез миңа,
Минем этчемдә ут йана.
Бу дәртләрдән (*кайгылардан*)
йана-йана,
Булмамын микән диwана.

Карасагыз ла йапанга (*яланга*),
Баладин айырылган казга.
Кунып булса иде сазга,
Битчара ай йапа йаңгызга.

Сандугачым сайрамыйсың,
Әллә йукмы тәхетең?
Син сайрасаң, мин йылыймын,
Минем дә йук бәхетем.

Упалардан кайткан атка,
Салкын су этчермәгез.
Ә йерәкләрем йанадыр,
Исемә тешермәгез.

*Солдатка ызатканда, үзләре йырлап китәләр ийе ызатканда:*

Салдат итеп алсалар да,
Будырмам билләремне.
Кара чәчем агарса да,
Ынытмам илләремне.

Казарма бийек булса,
Кышлар ыйа йасамый.
Ал булса да, гөл булса да,
Туган илгә ошамый.

*Әнәйнен борынгы йыры*

Укыйк әле Айател көрси,
Хибзыгыма дигән сүзне.
Сигез оҗмах тешләреннән,
Мәхрүм итмәсәнә безне.

Укыйк әле Айател көрси,
Хибзыгка дигән сүзне.
Чираттан да, миж(з)аннан да,
Җиңел чыгарсана безне.

*Аулакта аптыраталар иде мине йырлатып:*

Суда йезгән балыкларның
Бегелә микән билләре.
Һәркемнең дә үзенә йакын
Туып-үскән илләре.

Суда сусар йөзәдер,
Сусаган гелләр кебек.
Беребез – анда, беребез – монда,
Күтчергән гелләр кебек.

Санасаң, санамасаң да,
Гармун теле унике.
Уйласаң-уйламасаң да,
Гемерләр килми ике.

Үтте гемерем, үтте гемерем,
Үтте гемерем, әз калды.
Әз калган гемеремне дә
Кайгылар чырнап алды.

Сандугачым ник булдың,
Сайрамый гелгә кундың?
Акылымны алдың, дәрткә (кайгыга) салдың,
Ник былай йакын булдың?

* * *

Алма бакчасыннан үтәм,
Үргән чәчемне сүтәм.
Иртәдән кичләргә хадәр
Күрешү көннәрен кетәм.

Сандугачым сайрамәле,
Сайрама, дигән сайын.
Күз алларыма киләсен,
Уф, Алла, дигән сайын.

Агыйделләр аркылы
Ага сулар салкыны.
Су сипсәң дә, басылмыйдыр
Йанган йерәк йалкыны.

*Хөсәенова Оркия*
*Арифулла кызы (1926 елгы).*
*Зур Чынлы авылы*

* * *

Дустым, сүземне ишет –
Ул кабердә йук ишек.
Йылан-чайан урындыр,
Анда йатырбыз нитчек.

Илаһи сырыйм үзеңден,
Кабул кыл сыраwымны.
Үзеңнең рәхмәтең белән
Нәсеп илә зинһар инде.

Анда йатып тырырбыз,
Ни хәлләрне күрербез.
Безнең гөнаһыбыз көп,
Ницек йауап бирербез.

Ходайның бойырыгын тыткын,
Булырсың әүлийәләрдан.
Булырсың әүлийәләрдан
Изгелек күбрәк кылсаң.

Йерим дөнйаны куып,
Ул гүрнең эце суык.
Һичбер өйдә күңелем дә йук,
Тырдым дөнйага туйып.

Сахрада сайраган кышлар,
Алар күкләрне хушлый.
Һаwада зиһ(к)ерен йат итик,
Утырып мәйданнарда.

Бисмиллаһи эшнең башы,
Бисмиллаһи күңел хушы.
Бисмиллаһи иман нуры,
Айырылмагын иманымдин.

Ай, дусларым, беләсезме,
Күктә Гайсә пәйгамбәр бар.
Үзебез ме’мин, динебез ислам,
Шөкерана кылырлык бар.

Йөрәкләрем йана йукка,
Хәсрәтләр таптем йукка.
Әллә тешим микән утка,
Гемерем үтте лә бушка.

Сабырлыктыр гамәл башы,
Сабырлыктыр иман нуры.
Сабыр иткән бәндәләрнең
Ходай калепләрен хушлый.

Уңга барсам – балалар йук,
Сулга барсам – туганнар йук.
Миңа булмады һич йулдаш,
Бер Ходайым булсын йулдаш.

Шыбыр-шыбыр йамгыр йаwа,
Агачтагы җимешләргә.
Ницек айырылдык икән, дип,
Гаҗәпләнәм бу эшләргә.

Үзең салдың хазаларны
Башыгызга бәлаләрне.
Ходайым, үзеңә кайтыр
Әсир булган балаларны!

Укик әле намазларны,
Иртә намаз wакытында.
Уңнан очар, сулдан очар
Фәрештәләр йаныбызда.

Укик әле намазларны
Намаз бирер җаwапларны.
Укымасак намазларны –
Бирәлмәбез җаwапларны.

Кене-тене йереп туймыйм,
Башымны сәҗдәгә куймим.
Азыгымны алып анда
Ач булмасам йарый инде.

Китапларым, көр’әннәрем,
Дәwәл биргән остазларым.
Гайбирәннәр арасында
Булса иде мизаннарым.

Эй, Ходайым, Раббым Аллам!
Минем хәлне үзең белгел.
Дөнйада тарлыгым эчен
Фирдәwес җәннәте биргел.

Никадәрле малың булса,
Калдырасың барын монда.
Мәгәр үзең белән барыр
Гыйбәдәт кылсаң Аллага.

*Мистякова Әлфия Хәсәнзян*
*кызыннан (1939 елгы) 1982 елның*
*5 мартында язып алынган.*
*Зур Чынлы авылы*

*Мөнәҗәт*

Рәсүлулла йаратмады,
Салаwат әйтмәгәннәрне.
Ишетеп, тотмаганнарны
Сафат әйләмәт загу.

Мендем тауның башына,
Утырдым ап-ак ташына.
Гамәлем йук, гөнаһым көп,
Ницек барыйм хак Тәгалә каршына.

Иртән торып дога кылсам,
Кабул итәр микән Алла.
Баштин ашкан гөнаһымны
Кичерер микән Аллам.

Тәмүгыңнын тетене кара,
Күрсәм йөрәгем йана.
Үтә гомерләрем зайа,
Биш wакыт намазым кала.

Әзәл килер, җанымны алыр,
Кара туфракларга салыр.
Кара туфрак астында
Күзем ачсам, хайран калыр.

Шаулый куак, шаулый куак,
Дигерләр әтеп Аллага.
Туксан тукыз рәхмәтеңнән
Эметең бармы миңа да.

Бер Ходайым, бир сабырлык
Хасрәтле колларыңа.
Биргел бәхет, биргел тәүфыйк,
Күндер изге йулларыңа.

Үлгәндин соң терелмәк бар,
Эммәтләрне сырамак бар.
Йатар җирем, ләһетем тар,
Рәхим кыл, йә, Рәсүлулла.

Садакамны эләшегез,
Кәфенемне йүләгәндә.
Ризалыгым йуктыр минем,
Гайбәтемне сүләгәндә.

*Мистякова Әлфия*
*Хәсәнзян кызы (1939 елгы).*
*Зур Чынлы авылы*

*Ана васыйаты*

Сүлим әле, балам, сезләргә
Сүзләремнән түгелә моңнарым.
Мин үлгәцтен укы, балам, Көр’ән,
Тәрәзәдән килеп тыңлармын.

Зинһар, балам, укы Көр’ән,
Миннән васыйәтем шул булыр.
Син, бәбкәйем, Көр’әннәр укысаң,
Каберемдә минем нур булыр.

Миңа укыт Көр’ән,
Син бит минем бәбкәм.
Атна кицләрендә җаным кайтыр
Ак күбәләк булып әнкәйең.

Зинһар, балам, укыт Көр’ән,
Минем җаным кайтыр тыңларга.
Шушы сүзләремне йазып калдырамын,
Мине сагынганда укырга.

Каберемдә мин йатармын,
Балаларымнан дога көтәрмен.
Дога булса, рәхәт мин йатармын,
Укытмасагыз – ни хал’ итәрмен.

Садака бир, балам, минем эчен,
Мине йаткырмагыз газапта.
Мин бит сездән кайтып сырый алмыйм,
Мин – тыткында, сез бит – азатта.

Зинһар, балам, сездән сыраламын,
Уздырыгыз минем эчемне.
Белгәннәргә биреп дога кылдыр,
Буш үткәрмә атна кичеңне.

Зинһар, балам, уздырыгыз җидемне,
Минем рухым кайтыр сезләргә.
Шушы сүзләремне калдырамын,
Үлгәчтән дә сагынып сүләргә.

Тар ләһетләр эчендә йатканда
Кырыгымны уздырганны көтәрмен.
Догаларыгыз барса – шатланырмын,
Ынытсагыз – ни хал′ итәрмен.

Балам, илле бер кенемне үткәрегез,
Минем сезгә актык сүзләрем.
Карчыклар җийып укытыгыз,
Йакты нурлы булыр гүрләрем.

Балам, бәгеркәйем, сезгә сүлим,
Бу бит минем актык сүзләрем.
Син бәбкәйем, Көр’әннәр укысаң,
Йакты булыр минем йезләрем.

Йыламагыз, балам, йәш түкмәгез,
Миннән айырылып калганда.
Бер Ходайым үзе тел ачкычы бирсен,
Мәнкер, Нәнкир җаwап алганда.

Сахраларга чыгып йерегәндә
Хозур Илйас булсын йулдашым.
Тар кәбердә йалгыз башым –
Иман нуры булсын йулдашым.

Тар кәбергә кергәч,
Йауап алырга килерләр.
Чын иманым булса йаннарымда
Җәннәтләрдән урын бирерләр.

Барча балаларым, туганнарым,
Миннән бәхил булып калыгыз.
Алып барып тар кәбергә куйгач,
Тәхлил әйтеп туфрак салыгыз.

Цын күңелдән сезгә шуны этәм:
Догалар укып мине джыйыгыз.
Балаларым, дусларым, туганнарым,
Дога кылып ызатып калыгыз.

И, балалар, васыйатем шул сезгә
Искә алып хәйер-дога кылыгыз.
Без дә дога кылып йатырбыз кәберләрдә,
Иншаллаһ, Ходай кабул кылсын инде.

Әгәр миңа вакыт тәмам җитсә.
Газраил җанны алырга әзер тырса,
Хак Талә айырмасын иманымнан
Хак Талә каһәреңнән сакла инде.

Васыйатем миннән калганнарга,
Минем эчен йерәкләре йанганнарга.
Җомгаларда зирәт кылып барганнарга
Хак Талә җәннәт бирсен инде.

Балам, мине җомгаларда искә алыгыз,
Иртән гафил калсагыз да, кич калмагыз.
Каберләрдән үткән чакта
Күз салыгыз, газиз әнкәм анда бит, дип
дога кылыгыз.

*Мистякова Әлфия*
*Хәсәнзян кызы (1939 елгы).*
*Зур Чынлы авылы*

## Җырлар

### *Авыл көе*

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырламый тормыйк әле.
Бергә булган wакытларны
Бушка уздырмыйк әле.

*Такмаклар*

Сиксән сигезенче номер
Колак алкаларымда.
Нинди сүзләр ишетмәдем
Синең аркаларыңда.

Айырылу дигән кайгылар
Бигрәк аwыр кайгылар.
Айырылу дигән кайгылар
Йөрәгемдә кайныйлар.

Әй, аwызың зур, аwызың зур,
Аwызың зур нишләтергә?
Бер йагына мич чыгарып
Канушный эшләтергә.

*Сибгатуллина Мөсфирә*
*Шиһабетдин кызы (1939 елгы).*
*Кече Чынлы авылы*

## СҮЛӘМӘ КЕЛИМ, ТЫҢЛАУЦЫ БУЛСА...

*Флера Баязитова*

Татарстанның Чүпрәле һәм Буа, Чуашстанның Батыр һәм Канаш районнарында (элекке Сембер губернасы, Сембер һәм Буа өязләре) яшәүче татарларның сөйләше фәнни әдәбиятта көнбатыш диалектның, ягъни мишәр диалектының, чүпрәле сөйләше дип билгеле.

Бу төбәкләрдә яшәүче татар-мишәрләрнең сөйләш үзенчәлекләре турында мәгълүматлар XIX йөз галимнәре В. К. Магницкий (1896), Н. И. Золотницкий (1875), Г. Ә. Әхмәров (1903) хезмәтләрендә дә бар.

1962–1966 елларда диалектолог Л. Ш. Арсланов Иделнең уңъяк ярында урнашкан районнарның сөйләшен (шул исәптән чүпрәле сөйләшен дә) өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе язган. Чүпрәле сөйләшенең үзенчәлекләре Л. Т. Мәхмүтованың мишәр диалектына багышланган монографиясендә дә урын алган. 1982, 1987 елларда диалектолог З. Р. Садыйкова, 2002 елда мин үзем дә Чүпрәле районына экспедицияләр оештырган идек. З. Р. Садыйкова материаллары 2008 елда «Татар халык сөйләшләре» китабында, ә минем хезмәтләрем «Татар-мишәр рухи мирасы» (2003) китабында урын алдылар.

Архив материалларыннан мәгълүм булганча һәм риваятьләргә караганда, чүпрәле сөйләше вәкилләре элекке Түбән Новгород губернасыннан, Тамбов губернасының Темников өязеннән, Сембер губернасының Курмыш һәм Алатыр өязләреннән күчеп утырганнар. Аларның күчеп килүе Рус дәүләте тарихы белән бәйләнгән. XVI гасырның икенче яртысыннан башлап, рус дәүләте үзенең чикләрен көньяк-көнчыгышка таба киңәйтә, хәрби сызыклар төзи башлый. Мәсәлән, XVII гасыр башында «Карлы сызыгы» (Зөя

кушылдыгы Карлы елгасы буйлап) төзелә, 1648 елда Сембер сызыгы төзелә башлый. Бу хәрби сызыкларга Россиянең үзәк өлкәләреннән (шул исәптән, Зөя өязеннән дә) күчереп утыртулар башлана. Бирегә татар халкы белән беррәттән Россиянең башка халыклары (рус, мордва, чуаш һәм марилар) да күчереп утыртыла. Бигрәк тә Түбән Новгород, Сембер, Тамбов һәм Пенза губерналарыннан йомышлы татарлар (мишәрләр) күпләп күчерелә. Бу фактлар татар теленең чүпрәле сөйләше формалашуда әһәмиятле роль уйнаган. Яңа җирләргә күчеп утырганнан соң татар-мишәрләр шушы урыннардагы татарлар белән мәдәни-икътисади һәм сәяси мөнәсәбәтләргә керәләр. Шуның нәтиҗәсендә аларның сөйләше күп яктан урта диалект сөйләшләре йогынтысына бирелгән.

### Фонетик үзенчәлекләр

Чүпрәле сөйләше фонетик үзенчәлекләре ягыннан мишәр диалектларының чистай һәм сергач сөйләшләре белән уртак. Сөйләшнең фонетик үзенчәлекләре башлыча кайбер авазларның артикуляциясе үзгәрүдә, аваз тәңгәллекләрендә, аваз өстәлү һәм аваз төшүдә чагыла.

**Сузыклар.** *А* сузыгы – әдәби телдән һәм урта диалекттан аермалы буларак, иренләшү төсмере булмаган аваз.

*О–ө* ирен сузыклары, мишәр диалектындагы һәм урта диалектның аерым сөйләшләрендәге кебек иренсезләшеп, *ы–е* булып әйтеләләр: *былын* – болын, *телке* – төлке, *сет* – сөт һ.б.

Сузыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр аваз тәңгәллекләренә, төрле фонетик күренешләргә кайтып кала.

**Дифтонглар.** Чүпрәле сөйләшендә, мишәр диалектының башка сөйләшләре кебек үк, дифтонглар монофтонглаша.

*-өй* дифтонгы монофтонглашып, *ү* гә күчә: *ү* – өй, *сүлә* – сөйлә, *кү* – көй, *цү* – чөй, *түмә* – төймә.

*-өй* дифтонгы монофтонглашканда, күтәрелешләре төрле булган сузыклар арасында, ирен-ирен *w* тартыгы барлыкка килә: *сүwәк* – сөйәк (сөяк), *сүwәм* – сөйәм (сөям), *күwәндә* – көйәнтә (көянтә), *сүwәл* – сөйәл (сөял), *күwә* – көйә (көя).

*-ай, – әй, -уй, -ый* дифтонглары монофтонглаша, бу очракта ике сузык арасындагы тартыклар палатальләшә: *кат'а* – кайта, *ад'а* – әйдә, *а'ран* – әйрән, *бар'ам* – бәйрәм, *кас'ы* – кайсы, *кар'ак* – кайрак, *ал'әнә* – әйләнә, *кур'ик* – койрык, *бун'* – муен, *ун'и* – уйный.

*-ой, -ый* дифтонглары *-ий* дифтонгына күчә: *кийаш* – койаш (кояш), *кимак* – коймак, *тийак* – тойак (тояк), *кийар* – кыйар (кыяр), *сийыр* – сыйыр (сыер).

**Тартыклар.** Әдәби телдәгедән аермалы буларак, *к, г* авазлары сөйләштә тел арты тартыклары булып әйтеләләр: *кара, кабак, кар, йага* – йака (яка) һ.б.

*Х* авазы, әдәби телдәге белән чагыштырганда, алгырак артикуляциядә әйтелә: *хазер* – хәзер, *хал'* – хәл, *хабәр* – хәбәр.

Әдәби телдәге өрелмәле *ч* урынына *ц*, кайбер очракларда *тч* кушык авазлары да кулланыла: *цалгы* – чалгы, *пыцак* – пычак, *бырцак* – борчак, *цыгып* – чыгып; *катчан* – кайчан, *тчаука* – чәүкә, *тчармау* – чармау.

Сүз башындагы һәм сүз уртасындагы әдәби *җ* авазына *й, з, дз, дҗ* авазлары тәңгәл килә: *дзил/зил* – җил, *дзиде/зиде* – җиде, *дзыйылыш/зыйылыш* – җыелыш, *кәзә//кәдзә/кәдҗә* – кәҗә, *мәрдҗән* – мәрҗән, *зил* – җил һ. б.

Тартыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр авазлар тәңгәлләшүенә һәм башка үзгәрешләргә кайтып кала.

*Б ~ w.* Ике сузык арасында килгәндә, әдәби телдәге *w* авазына сөйләштә *б* тартыгы туры килә: цыбар – *чуwар* (чуар), *цыбан* – чуwан (чуан), *йыбату* – йуwату (юату), *цыбалу* – чуwалу (чуалу).

*М ~ б: малан* – балан, *мере* – бөре, *мәке/бәке* – бәке; *б ~ м: бун'ы* – муйыны (мены), *бучкы* – мичкә, *гарбун* – гармонь.

*Н ~ б.* Составында саңгырау *т* авазы булган бер төркем сүзләрдә сүз башындагы яңгырау *б* авазы саңгыраулаша: *пыт* – бот, *пытак* – ботак, *петерү* – бетерү, *петеннәй* – бөтенләй, *пыт'пылдык* – бытбылдык (көш).

*М ~ н* берничә сүздә: *үләм* – үлән, *чырмау* – чорнау; *н ~ м: нүwеш* – диал. мөгем – әд. почмак, *неwек* – мүк, *нүгез* – мөгез.

*Н ~ ң.* Хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыльләрдә, күрсәтү алмашлыкларында күзәтелә: *барасын* – барасың, *киләсен* – киләсең, *алырсын* – алырсың, *килерсен* – килерсең; *анарга* – аңарга, *монарга* – шуңа.

*Д ~ т.* Бер төркем сүзләрдә сүз башында һәм сүз уртасында *т* авазы яңгыраулаша: *дустыган* – диал. тустыган – әд. су чүмече, *күwәндә* – көйәнтә (көянтә), *абдырау* – аптырау, *ибдәш* – иптәш.

*Т ~ д: тәwә* – дөйә (дөя), *тиспе* – дисбе.

*З ~ р* фигыльләрнең йөкләү юнәлеше кушымчаларында күзәтелә: *менгез* – менгер, *кигез* – кидер, *үткәз* – үткәр, *йаткыз* – йаткыр (яткыр).

*Т ~ ч* аерым сүзләрдә: *тишмә* – чишмә, *тишен* – чишен.

*С ~ ч: тыскан* – тычкан, *йәдәс* – йәдәч (ядәч).

*Й ~ җ.* Чүпрәле сөйләше – нигездә *й*-ләштерүче сөйләш: *йир* – җир, *йибәр* – җибәр, *йыр* – җыр, *йәй* – җәй, *йил* – җил, *йыйылу* – җыелу, *йәйәү* – җәяү, *йан* – җан.

*Г ~ к.* Бер төркем сүзләрдә ике сузык арасында саңгырау *к* авазы яңгыраулаша: *цигеркә* – чикерткә, *тыгырак* – тыкрык, *цыгыр* – чокыр, *цугынган* – чукынган, *сигезән* – сиксән, *тугызан* – туксан.

*К ~ г: сикез* – сигез, *тукыз* – тугыз.

*К ~ х.* Бер төркем татар сүзләрендә һәм кайбер алынмаларда да *х* авазына сөйләштә *к* авазы тәңгәл килә: *катын* – хатын, *каста* – хаста, *йакшы* – йахшы (яхшы), *дҗымак* – оҗмах.

*Х ~ к* – берничә сүздә генә: *wахыт* – wакыт, *духтыр – доктор, тырахтыр* – трактор.

**Тартыклар төшү.** *Г* авазы төшә: *айып* – гаеп, *әҗәп* – гаҗәп, *аләмәт* – галәмәт, *Аптулла* – Габдулла, *тирмән* – тегермән.

*Т: кецеркән* – кычыткан, *цигерткә* – чикерткә.

*Һ* авазы төшә: *аман* – һаман, *үнәр* – һөнәр, *Әдийә* – Һәдия, *Адий* – Һади, *йәт* – җәһәт.

Ассимиляция (авазлар охшашлануы). Сүз ахырындагы *ч, ш* тартыклары тел уртасы *й* һәм яңгырау тартыклар алдында килгәндә яңгыраулашалар: *киҗ булды* – кич булды, *биж йыл* – биш ел.

### Морфологик үзенчәлекләр

**Исемнәр.** I һәм II зат берлек сандагы тартымлы исемнәрнең төшем килеше угыз телләренә хас кушымча (-ы/-е) ярдәмендә дә формалаша: *китабымы* – китабымны, *битеңе* – битеңне. *Битеңе йу. Күзлегеме күрмәдегезме?*

**Алмашлыклар.** *Күрсәтү алмашлыклары.* Әдәби телдәге (менә, әнә, бу, ул, шул) күрсәтү алмашлыклары белән беррәттән, сөйләштә *мына, мыни, мени, муни, ана, выт, вата, вана* (< рус) һәм зат кушымчалы *бусы, улсы, шулсы* алмашыклары актив кулланыла. Мисаллар: *Мыни* (менә) *кабак ацык, күрергә була. Шулсын* (шунысын) *нәстә белән ка'тарырбыз.*

*Шул* күрсәтү алмашлыгыннан ясалган *шолай, шылай, шондый, шындый, шонарга, шынарга* сүзләре чүпрәле сөйләшенә дә хас. *Шундый йырактанмы килдегез?*

***Сорау алмашлыклары.*** Әдәби телдәге *нәрсә* сорау алмашлыгы урынына *нәстә, нәмәрсә* алмашлыклары йөри: *Нәстә син керми торасын?*

*Нәстә* алмашлыгы *ничек, нинди* сорау алмашлыклары урынына да кулланыла: *Адий абыйың хале нәстә сың*?

***Билгеләү алмашлыгы*** *үзебез* гадәттә иялек килеше кушымчасыннан башка кулланыла: *Үзебез* (үзебезнең) *аwыл*.

**Сыйфатларның** грамматик формалары, кулланылышы буенча бу сөйләш әдәби телдән аерылмый.

**Рәвешләр.** Рәвешләрне куллану буенча сөйләш нигездә әдәби телгә якын тора. Шуның белән бергә диалекталь характердагы лексик рәвешләр дә шактый: *атына* – үзенә башка, аерым; *бер буйлы* – тоташтан; *насила* – көч-хәл белән; *маскар итеп* – кызык өчен, шаяртып; *үзгә/үңгә* – башка төрле.

***Ясалма рәвешләр*** нигездә әдәби телдәге чаралар белән ясалалар. Кайбер аерымлыклар да бар.

*-лата/-ләтә: Цәйне кан'арлата* (кайнар көе) *эцәм.*

*-лый/-лий: Башкыдалый барганда калац тотоп баралар.*

*Кен* (тен) *буйы*, *кыш* (җәй) *буйы*, *йаз* (кез) *буйы* тезмәләре белән беррәттән, *тен ката, кыш ката, йаз ката, кез ката, кен сәтә* кебек вакыт рәвешләре актив йөри: *Төн ката йыкламадык*.

**Фигыльләр.** Затланышлы фигыль формалары. ***Хикәя фигыль. Хәзерге заман*** хикәя фигыльнең I зат берлек санда кыска (*барам, киләм*) һәм тулы (*барамын, киләмен*) вариантлары параллель кулланыла: *Мунца пиценә ут кабызам. Киц утырганда кимак пешереп ашим, цәй эцәм.*

II зат берлек сан хәбәрлек кушымчасының борынгырак *-сын/-сен* варианты сакланган: *барасын* (барасың), *киләсен* (киләсең).

Хәзерге заман хикәя фигыльнең III зат берлек саны, әдәби телдән аермалы буларак, *-дыр/-дер* хәбәрлек кушымчасы ялганып ясала: *Ул цабадыр* (чаба) *минем арттан*, *калгысы киләми*. *Барадыр* (бара) *да быратына сүлидер* (сөйли).

Әдәби телдәге *ди* формасының сөйләштә *дир* варианты кулланыла: *Сиңа Казанга барырга дир*.

***Билгеле үткән заман,*** әдәби телдәге кебек, фигыль нигезенә *-ды/-де* кушымчасы ялганып ясала: *бар - ды - м, кил - де - м: Туйга саwым алып бардым.*

Шуның белән беррәттән сөйләштә категорик үткән заман мәгънәсендә нәтиҗәне үткән заман формасы да кулланыла: *Без бер каа да цыкмаган.*

Нәтиҗәле үткән заман, әдәби телдәгечә, *-ган/-гән* кушымчасы ялганып ясала (*күр - гән - мен, күр - гән - сең*), аны зат һәм сан кушымчаларыннан башка куллану очраклары бар: *Син хат йазган* (язгансың), *әле дә салмаган* (салмагансың).

II зат берлек санда, тау ягы сөйләшләрендәге кебек, шикләнүне белдерә торган *-дыр/-дер, -тыр/-тер* кушымчалары еш кына төшеп кала: *Аwылга кат'а тыргансыз* (кайта торгансыздыр)?

***Күптән үткән заман*** сөйләштә, әдәби телдәгечә, *-гән иде* формасы белән белдерелә (барган иде, килгән иде). Моннан тыш, сергач һәм өлешчә чистай сөйләшләрендәге кебек, *-ты/-те, -ды/-де* һәм иде формасы да кулланыла: *Тенә сүләшергә тытындык иде* (тотынган идем).

***Дәвамлы үткән заман*** сөйләштә әдәби (*-а иде*) форма белән белдерелә: *Атлар белән ташый идек келтәне.*

***Билгесез киләчәк заман*** (*-ыр - мын / -ер - мен*) формасында, сүзнең нигезе *р* авазына беткән очракта, I һәм II зат берлектә һәм күплектә кушымчадагы *р* авазының берсе төшеп калырга мөмкин: *барымын – барыбыз, барысың – барысыз. Кышын аларга барымын* (барырмын).

***Билгеле киләчәк заман*** (*-ачак/-әчәк*) сөйләш өчен характерлы түгел. Бу форма, күпчелек татар сөйләшләрендәге кебек үк, сирәк кенә *йук* һәм *төгөл* сүзләре белән кулланыла: *Ул анда баратчак төгөл* (бармаячак).

***Боерык фигыльнең*** II зат берлек саны, әдәби телдәгечә, фигыль нигезе белән тәңгәл килә: укы, эшлә.

***Теләк фигыль. -гы/-ге, -кы/-ке*** + *кели* формасы актив кулланыла: *Анда минем тыргым келәмәде* (торасым килмәде). *Урамга цыккым кели* (чыгасым килә).

Максатны, теләкне белдерү өчен инфинитивның кыскартылган *-ма/-мә* формасы һәм *кели* (< тели) ярдәмче фигыле белән ясалган конструкция кулланыла: *Эцкә цыкма килиләр* (чыгарга телиләр). *Цәй эцмә keләп утырам* (чәй эчәсем килеп утырам).

Әдәби телдәге *-асы/-әсе бар* (юк) формасы урынына сөйләштә *-ырга/-ергә + бар* (*йук*) формасы кулланыла: *Миңа тагы бер йыл укырга бар* (минем тагын бер ел укыйсым бар).

Фигыль дәрәҗәләре сөйләштә *-гакла/-гәклә, -акла/-әклә, -ыкла/-екләә* кушымчалары белән ясалалар: *Кунакка баргаклыйм* (баргалыйм).

***Затланышсыз фигыль формалары. Инфинитив.*** Чүпрәле сөйләшләрендә *-ырга/-ергә* формасы төп форма булып тора: *барырга, килергә.*

Тамыры *р* авазына тәмамланган фигыльләргә *-ырга* кушымчасы ялганганда, кушымчадагы *р* төшә: *барыга, күрегә.*

Сөйләштә ***исем фигыльнең*** әдәби телдәге *-у/-ү* кушымчалы формасы кулланыла: *Киц утыру кирәк ул кызларга, йырлап-йырлап утыру булган ул.*

***Сыйфат фигыль.*** Сөйләштә сыйфат фигыльнең түбәндәге формалары бар: *-ыр/-ер: тырыр урын, эцәр цәй; асы/әсе: бирәсе әйбер, барасы йир; -ачак/-әчәк: йугалачак әйбер, күрәчәк күрмен.*

*-уцы/-үце* формалы сыйфат фигыль кешегә карата актив кулланыла: *пецән цабуцы, ызба йууцы.*

***Хәл фигыль***. *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльнең юклык формасы әдәби телдә *-мыйча/-мийчә* формалары белән белдерелә. Сөйләштә тагын *минца/-минцә, -мица/-мицә* вариантлары да актив.

*-гац/-гәц, -гацтан/-гәцтән* кушымчалы хәл фигыльләр куллану күзәтелә: *булгацтан* (булгач)

*-ганчы/-гәнче* кушымчалы хәл фигыльнең *-гынцы/-генце, -ганца/-гәнцә, -гынчак/-генчәк* кушымчалы вариантлары да кулланыла: *таң атканцы* (атканчы), *кийаш күтәрелгәнцә* (кояш күтәрелгәнче).

Әдәби телдәге *барганда, барышлый* формалары белән беррәттән, сөйләштә хәл фигыльнең *баруwышлый, баруwынца* формалары да күзәтелә: *килүwешли* (килешли), *баруwынца* (барганда).

*-мастан/-мәстән* (*-мас өчен*) формалы хәл фигыльләр кулланылу актив күренеш: *бирмәстән* (бирмәс өчен), *батмас* (батмас өчен), *ашамастан* (ашамас өчен).

***Ярдәмлек сүз төркемнәре. Бәйлекләр***

Чүпрәле сөйләшләрендә нигездә әдәби телдәге бәйлекләр кулланыла. Шуның белән беррәттән аларның түбәндәге вариантлары да бар.

*Ката, сәтә* бәйлекләре, вакыт аралыкларын белдергән сүзләр белән килеп, дәвамлы вакытны белдерә: *кыш ката* (кыш буе), *тен ката* (төн буе), *кен сәтә* (көн буе).

*Хатлем, чикле, чәке, чәкле, тәке, тәкле, тике, тиңелте, тиңентен* (кадәр, хәтле), *тешкә тәкле* (төшкә хәтле), *урманга чәкле* (урманга кадәр).

**Кисәкчәләр.** Чүпрәле сөйләшендә әдәби телдәге кисәкчәләр (*бик, инде, гына, ук, -мы/-ме* һ. б.) актив кулланыла. Үзенчәлек итеп *бит* раслау кисәкчәсенең *вет* варианты актив булуын күрсәтергә мөмкин: *шулай вет* (шулай бит).

**Лексик үзенчәлекләр**

Лексиканың иң зур өлешен гомумтатар сүзләре һәм аларның тамырлары тәшкил итә. Алардан тыш, сөйләштә башка (рус, гарәп, фарсы, чуаш һәм мордва) телләрдән кергән сүзләр дә бар.

Сөйләштә әдәби телдә булмаган сүзләр дә шактый. Мишәр диалектына хас булган сүзләрнең күбесе чүпрәле сөйләшләрендә дә табыла.

Диалекталь лексиканың тематик төркемнәре түбәндәгеләр:

***Туганлык-кардәшлекне белдерә торган сүзләр:*** *әнәй* – әни; *атай/әтәй* – әти; *зур әнәй* – әби (әнисенең яки әтисенең әнисе); *зур әти* – бабай (әнисенең яки әтисенең әтисе); *алыс әби* – әнисенең әнисе, *игәц/игәч* – тута – бертуган апа; *абыти* – аптый – үзеннән олы кыз туганына эндәшү сүзе; *хәрендәш* – сеңел; *тудыкай* – туганнан-туган хатын-кызга эндәшү сүзе; *ылан/олан* – бала; *нук* – онык; *оланшак* – бала-чага; *бикәц* – кәләш; *бәбәй әбисе* – кенцек әби; *тайым* – иркәләп эндәшү сүзе.

***Хуҗалык, тормыш-көнкүреш белән бәйле сүзләр:*** *аран* – җылы абзар, *болдыр* – өйалды баскычы, *йорт* – ишегалды, *ишегалды* – өй алды, *кабак* – капка, *нешеш/нүшеш* – почмак, *кура* – киртә, *зәмәт* – койма, *туграп/пүгрәп* – кар базы, *лаука* – кибет, *эргә* – тышкы нигез, *пайыт* – лапас, *суллык* – киртәлек, *себерке* – ат тырмасы, *тәртешкә* – кисәү агачы, *герәплә* – кул тырмасы, *урдык* – сәке, *эскәми* – артлы урындык, *мәдәк* – кул арбасы, *матик* – китмән, *церге* – киез, *дустыган* – су чүмече, *кукцек* – мендәр, *балук* – бәләк, кер бәләге һ. б.

***Кием-салымнар:*** *барига* – бияләй, *ыркача* – зур күн бияләй, *пицәткә* – пирчәткә, *зыбын* – чикмән, *тәлпәк* – түбәтәй, *шалашар* – чалбар, *кәркеш* – чабата киндерәсе, *әлце салу* – (баш киемен) кырын салу һ. б.

***Аш-су:*** *йымшак* – бодай икмәге, ак ипи; *кыстырымби* – кыстыбый; *питырац* – кечкенә ипи (хәергә бирү өчен пешерелгән); *цәлпәк/чәлпәк* – кош теле; *цыгыт/чыгыт* – эремчекне йомырка бе-

лән туглап, табада мичтә пешерелгән ашамлык; *эре* – көрпә; *кукыл'* (<чув.) – пирог; *кагыт* – как, *ләкшә* – өйдә ясалган токмач; *кәкәш*/*кәкеш* – эремчек пәрәмәче; *казан кәлземәсе* / *эремцек кәлземәсе* – эремчек пилмәне һ. б.

***Үсемлекләр:*** *айбагар*/*гымбагар* – көнбагыш, *аwукамыр* – гөлҗимеш, *алма* – бәрәңге, *кырмаwык* – тигәнәк, *карагай* – нарат, *карагат* – карлыган, *ут* – үлән, *пәзи* – кишер, *элән* – җитен, *паңгы* – гөмбә, *нүwек* – мүк һ. б.

## ГАИЛӘ ЙОЛАЛАРЫ ЛЕКСИКАСЫ

### Кыз килешү, башкода килү

– Алма keләп йөри йегет, башкыда йөретә. Озак йөртәләр башкыданы кыз йаклары.

«Айакларына йыгыттылар инде», – дип сүләгәннәрен беләм.

Шолай башкыдалап килеп сорап алалар иде кызны. Башкыда килеп сүләшә. Килешсәләр, көнне билгелиләр.

– *Башкыда* булып бара йегетнең атасы, йә абзисы, йә йакын күршесе. Бал алып баралар кыз сори барганда.

– Иң беренце кызны килеп сорилар. Шикәр, бал, канфитлар алып киләләр. Туйның көнен билгелиләр.

– Менә мин *кыз бируце.* Тегеннән кан'ана, кан'ата килә кызны сорарға. Цәй эцәләр, килешәләр.

*Каракитә*

### Урлап алу

Ырлап алу – кызны урлап алу.

– Киц уйынга цыгалар. Егет кызны ала да китә, ырлый. Йәшләр белә инде, алар шул кызның йортына йиткәц йырлап китәләр:

Артлы чана йиккәннәр,
Кий йанына йиткәннәр.
Нуретдин бабай йыклап йатма,
Кызыңны алып киткәннәр.

– Праулка тебендә саклап торып, минем апаны ырлап кат'алар, пиц алнына пастыралар апаны. Әти әтә, алып кат'ик кызны, ди. Әни пиц белән ызба арасында бетерелеп йери, ырцык кебек:

«Карга аwызыннан калган цебеш» дип әтәләр инде, бирик кызны, – ди.

*Шланга*

## Чыгып килүче, качып килүче

Цыгып килүце, кацып килүце – әти-әниләре белән киңәшмичә, аларның ризалыгынан башка гына кияүгә китүче кыз; ябышып чыгучы.

– Цыгып килүцеләр бар ул хәзер дә. Цыгып килүце ул әти-әниләре белән килешмицә, сүләшмицә генә килә, йабышып цыга ул кыз. Йегет белән генә сүләшә дә, кызны йегет алып кайта.

«Мин үләнеп кат′ам, әнәй», – дир.

– Кацып киләсең дә монда никах укыталар. Бер кеше тә килә: «Кызыгыз бездә», – дип.

Монда кодалар килә, туйны сүләшәләр. Кыз йагында туй була.

*Түбән Чәке*

## Ясин бәйрәме, никах бәйрәме

Йасин бар′амы, никах бар′амы – өйләнешүне дини йола белән беркетү мәҗлесе, дини мәҗлес.

– Кыз башка аwылдан булса – никах бар′амы кыз ягында була.

– Хазер никах бар′амы зийабыз. Кыз үwенә киләләр туйга. «Ницә белән киләләр?» «Өц саwым белән киләләр».

– Йазылып кат′алар хазер. Йазылып кат′кан кенне зийалар мәзелес, икенце кенне йасин бар′амы була, ата-аналары киленнең, кийәүнең туганнары, картлар утыралар мәзелестә.

– Ницә белән килделәр? Дүрт-биш каз килә. Ул дүрт-биш казның барын да башлиләр әз-әз генә. Үрдәк тә, таwык та йөри йасин бар′амына. Ике йакның туганнары утыра.

– Йасин бар′амына туйга барабыз. Ике пиругың пешкән. Ашларны эстәлгә тезәләр, йасин укилар, теләк телиләр.

Балалар бахетле булсиннар,
Тигез үмер итсеннәр,
Үмерләре озын булсын,
Шәфкәтле, мәрхәмәтле балалар үстерсеннәр, –

дип теләк телиләр.

*Мунчәли*

## Өшәнчек

Эшәнцек – өшәнчек; кызның бирнә әйберләре. *Эшәнцек йасау* – өшәнчек әзерләү.

– Эшәнчек, дип әйткәннәр, сындык тутырып килгән. Туй алдыннан кызның эшәнцекләрен каралар. «Менә бу әйберсе йитми, йасарга кирәк кызлар йийып», – диләр. Йүли тырганын йүлиләр. Кызлар йиалар, йырлап-йырлап эшәнцекне йасилар.

*Иске Шәйморза*

**Өшәнчек әйберләре**

Эшәнцек әйберләре – кызның кияү йортына алып барган әйберләре: сөлге-тастымаллар, җәймә-юрганнар һ. б.

– Эшәнцек әйберләре менә этеп күрсәтим әле сезгә.

Намазлык: – Намазлыклары була киленнең. Кан′ана – кан′атага бирә.

Йәймә (әд. җәймә). Өстәлгә йәйә торган йәймәсе була, ул да циккән. Йә үзе бәләгән йәймә дә була.

Куwашна эскәтере (ипи күәсе өстенә ябу өчен әзерләнгән җәймә). Куwашна эскәтере, диләр ийе. Ул үзе айырым бар. Куwашна эскәтере, диләр ийе. Табынга да йәйәләр.

Цигүле күпцек (чигүле мендәр). Цигүле күпцекләр алып бара. Дүрт күпцек цигә идек. Күпцек тышларына дип акка цигеп куйа идек аллы-гөлле цәцәкләп.

*Иске Чокалы*

Цигүле элеңге (чигүле пәрдә). Цигүле элеңгеләр әзерләп бара, тәрәзәгә цигүле элеңге үзенекен элеп куйа, ызбаны йәмни.

Циккән корама (өйнең стенасының өске өлешенә эленә торган озынча тар җәймә). Циккән корама белән үне әләндергән кругум.

Циккән селге, кызыл селге: Циккән селгеләр, кызыл селгеләр. Нүwешләргә элеп куйган кызыл селгеләрен.

Сырган йурган: Куй йоны салып йурган сыра белгәннәр әwәле әбиләр.

Петүле йурган (корама тышлы юрган). Сырган йурганнары, петүле йурганнары сандык эстендә килә киленнәрнең.

– Петүле йурганнар йасадык. Ситсылардан калган петүләр инде ул. Хазер инде йасамилар инде. Шул петүләрне тоташтырып йурган сыра. Петүле йурган, диләр шуны.

Ызба матурлау (өй бизәү, өй матурлау). Ызба матурларга циккән элеңгеләрен элә, караwатка йәйеп куйа цигүле йәймә. Цигүле күпцекләрне күпертеп куйа.

Урдык – сәке.

Кецурдык – өйнең аш-су әзерли торган ягындагы (кухнядагы) кечкенә сәке.

– Ызбада урдык булган, урдык эстенә сындык куйган, сындык эстенә күпцекләрне, петүле йурганнарны үwеп куйган.

– Кецурдыкта саwытлар, самаwырлар торган. Киленнәр күбрәк кецурдык йакта булган.

*Шланга*

## ТУЙ ПЕРСОНАЖЛАРЫ

### Кияү һәм кияү егетләре

*Кияу* сүзенең әдәби тел һәм җирле сөйләшләрендәге мәгънәләре: 1. Кәләшнең булачак ире; 2. Яңа өйләнгән егет яки ир кеше; 3. Тормыш иптәше, ире (хатын-кызга карата); 4. Кызының яки үзеннән яшьрәк кыз кардәшенең ире («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән).

Кияү килү: Кийәү ат белән килә. Калакуллар элгән дугаларга, цигүле сөлгеләр кулйаулыклар элгән булган атларга. Хазер йәмле түгел, машина белән генә килә, күреп тә калмибыз.

Кияү егете – туй вакытларында кияүне саклап, озатып, аның хезмәтендә йөрүче егет.

– Кийәү йегете икәү килә. Кияүнең үзенең дуслары, кияү үзе әтеп куйа кийәү йегетләрен. Гармуннар белән, шаулап килеп керәләр кийәү йегетләре.

### Арчи

Арци, арчи – килен төшергән көннәрдә кызны кияү йортына озата баручы кызлар яки парлы кунаклар.

– Арци туйда кыз артыннан килә. Тугыз-ун ылау арци була. Арци булып күп туйга бардым мин үзем.

– Арцилар алар кызны озата баралар кийәү йагына. Кийәү йагы арцилар килә кызны күцергән йакка. Циккән запуннар кигәннәр арци кызлар.

*Шланга*

## Килен, яшь килен

*Килен* сүзенең әдәби телдә түбәндәге мәгънәләре бар. 1. Улының яки энесенең хатыны. 2. Яңа гына кияүгә чыккан яшь хатын. 3. Гомумән өлкән буынның яшь буын хатыннарына мәрәҗәгать итә торган сүзе.

*Килен* сүзенең җирле сөйләшләрдәге мәгънәсе әдәби телдән аерылмый.

Йәш килен – мишәр диалектында яңа төшкән килен.

Сырлиг әле талдан тайак,
Сырын үзем сырлармын
Кийәү белән йәш киленгә
Икесен тиңләп йырлармын.

Йәш килен абыз – яшь киленгә олылап эндәшү сүзе. Йәш килен абыз, бәхетле бул, озын гумерле, тигез йәшәп көн күрегез. Биргән бүләгеңә зур рәхмәтләр йаусын!

Йәш килен бүләге: Йәш киленне кунакка йөртәләр ызба сайын. Барган бер йиренә бүләк алып бара, селгеме, йаулыкмы, салфитмы.

Йәш килен белән кийәүгә йырлилар:

Самаwырны тиз кан′ата
Кайын агац күмере.
Кийәү белән йәш килennең
Озын булсын гүмере.

Карап торып сокланамын
Зифа буйыгызга да.
Онытмагыз чакырырга
Бәбәй туйыгызга да.

Киленне сыныйлар: Киленне суга йибәргәннәр. Сыныйлар. Суwы түгеләме. Суwы түгелсә – сүз йөртә торган була, бутый торган була.

Суwы түгелмәсә, «выт маладис», әйтәләр.

– Аннары сыйыр саудырып та караганнар. Саwа беләме, йукмы.

Килен әwәле тел йәшергән:

– Килен кан′ата белән сүләмәгән (*сөйләшмәгән*).

– Килен кан′ага белән дә сүләмәгән (*сөйләшмәгән*).

*Иске Чокалы*

## Кодалар, кодагыйлар

*Кода* сүзенең түбәндәге төп мәгънәләре билгеле:

1. Өйләнәсе егет ягыннан кыз яучыларга, кәләш сорарга барган ир кеше, ир яучы:

2. Өйләнешүчеләрнең берсенең атасы һәм ир туганнарына икенче якның ата-анасы һәм туганнары эндәшә торган туганлык атамасы.

Кодаларга йырлилар туйда:
Йугарычтан түбәночка
Очып китте йомырычка.
Бу йырларны мин йырлимын,
Кодаларга бурычка.

Кодалар үзләре дә йырлап бирәләр инде бер-ике йыру булса да:

Әтик берне, әтик берне,
Берне тегел, икене.
Әтмәсләр идем берне-икене,
Сез кодалар бик сикемле.

Кодагый – өйләнешүчеләрнең берсенең анасы һәм аннан өлкән хатын-кыз туганнарына икенче якның ата-анасы һәм туганнары эндәшә торган мөрәҗәгать сүзе. Кода-кодагый – мишәр диалекты сөйләшләрендә *кодаги/кыдаги* фонетик вариантлары кулланыла.

## Төп кодагый, кунак кодагый

Төп кодаги – кәләшнең яки кияүнең әнисе; туй уздырыла торган йорттагы кодагый.

Кунак кодаги – туй йортына мәҗлескә килгән кодаги; кәләшнең яки кияүнең әнисе.

– Башта төп кодагига сүзне бирәләр, ул башлый. Аннан соң инде килгән кунак кодаги әтә туйны башлаганда.

– Менә өц пар ат бара, өц пар кунак алып килә кунак кодаги. Дүртне, бишне алып килүцеләр дә була.

«Кодаги, син әле безнең сеңлебезне китермәдең, риза тегел», – ди.

«Сеңлем, кицке ашка булса да кил, кодаги риза тегел», – ди. «Мин әле йәш, ойалам», – дир сеңлем. «Йук, йук, килергә, танышырга», – дир.

*Түбән Чәке*

## Кода-кодагыйларны каршы алу, туйны каршылау

«Туй килә, туй килә, кода-кодагилар килә», – дип бөтен урамы белән каршы цыгып торалар. Матур атлар, цигүле күпцекләр белән туй төшә.

## Кода-кодагыйларны озату, туйны озату

– Кода-кодагиларны озату була, гармуннар белән озаталар. Туй озату көненә барлык туганнары зийылып киләләр.

«Туй кат′а, туй кат′а», – дип бала-цагалар да йүгерешеп килеп йитәләр туй озатканда. Атлар бизәлгән, дугаларда калакуллар.

*Каракитә*

## Кайнана, кайната

Мишәр диалекты сөйләшләрендә *кан′, кан′ата* – кайната, *кан′а-на* – кайнана, *кан′ага* – иренең абыйсы.

– Кан′атасына күлмәк, кан′анасына матур йаулык, баж йаулык, шәл баласы (*кечкенә шәл*) алып килә килен.

Йәж килен кан′анасының башына йаулык йаба, кан′атаның башына тәлпәк (*түбәтәй*) кигезә.

## Килен каршылау

Кан′ана киленне үзе каршы алып тора. Күпцеккә (мендәргә) бастыра: Кан′ана күпцек тотып чыга, килен күпцеккә басып керә.

Бал-май каптыра: Йәш киленне керткән wакытта киленгә дә, малайга да бал-май каптыра. Шәкәр самытында була бал-май.

Төкле айагың белән кил,
Бахытлы булыгыз,
Мәңгелеккә безгә бала бул,
Безнең кешебез бул.

*Шланга*

## Усал кайнана

Усал кан′а, усал кан′ана – усал кайнана.

– Әwәле булган ул, усал кан′алар да булган. Цәйне киленгә йасап биргән кан′ана. Икенце цынайакны китерсә:

«Әллә әwенеңә ут каптымы?» – дир. Ике цынайак цәй эцәргә күп булган, күпсенгән.

*Татар Бизнәсе*

## Ага-җиңгә, ага белән җиңгә

Ага-йиңгә – абыйсы һәм аның хатыны.

– Ага-йиңгә кулыннан кийәүгә китүцеләр дә булган. Аның йыры да бар:

Сат-бакцага кергән цакта
Кулым тиде цийәгә.
И, Ходайым, калдырмацы
Ага белән йиңгәгә.

*Кече Чынлы*

## Туй табыны, туй ашлары

Чүпрәле сөйләшендә табын ясап кунак чакыру мәҗлесләрен *бар'ам* (бәйрәм) диеп атыйлар.

Бар'ам уздыру – мәҗлес ясау.

– Элгәре идәндә иде бар'ам уздыру. Үдә тугыган кавир, шуны йәйә идек. Идәнгә тезелеп утырып аши идек.

Идәнгә утырып ашау: Идәнгә намазлыклар кизләрен йәйеп куйалар, ашйаулыкларын йәйәләр. Айак бөкләп утырып ашилар иде.

## Яшь килен бәйрәме

Йәш килен бар'амы – кияү йортына килен төшкәч уздырыла торган мәҗлес.

– Йәш килен бар'амы – кийәү йагында. Кан'н'а кеше катыннарны йийа. Ләкшә пешерәләр, йасин укыталар.

## Яшь килен боткасы

Йәш килен буткасы – туй узгач, кияү йортында уздырыла торган мәҗлес.

– Йәш килен буткасы да була. Менә туйлар узып беткәцтән, актыктан. Шунда, бүген бездә йәш килен буткасы, дип утыралар. Анда да саwым белән киләләр. Әлгәре бутка алып килә торган булганнар. Хәзер инде бутка алып килмиләр, саwым алып киләләр, нәстә бар. Камфитмы, туртмы. Кас'ы пирук пешереп килә.

Йәш килен буткасы ул бар'ам була. Бу инде туйның соңгы көне була, йәш килен буткасы. Ул туй беткәцтән була йәш килеп буткасы, кадерле генә бар'ам була.

*Мунчәли*

## Саwым

*Саwым* – туйга алып барыла торган күчтәнәч ашамлыклар. Бу сүз казан арты, тау ягы, мишәр диалекты сөйләшләрендә еш кулланыла. *Саwым, саwын* – себер диалектларында да бар.

– Туйга саwым белән баралар. Анда *цәй, пирук, әпәй* була. Үзенекеләр, йакыннары алып бара.

Саwым – патнуста. Кызыл эскәтергә бәләгән, ашка куйып килә саwымны.

«Туйга барсаң – туйып бар,
Кун′ыңа калац *куйып* бар», –

дип ат′кан сүз дә бар. Картлардан калган.

– Калач, диләр. Ике калач, парлы була. Оста саwымчы камырны уңарып, алып барырлык итеп йасаган инде. Колмак белән ацыткан. Әнием биг оста саwымчы булган.

– Саwымда каз, *баwырсак.* Безнең wакытта ике *йомошак* алып бара идек. *Йомошак* – бодай күмәце була.

– Йомошак, диләр иде бодай күмәцен. Саwымда ике йомошак булган. Шулай күпшәк йомошак пешергән ацкамырны изрәтеп. Кабартып пешергән. Пустуй баргысы келәми, алып бара әзерләп.

– Баwырсакны бармак кебек кисеп пешерәбез дә аны бал белән катырабыз. Патнуска куйабыз да эскәтер белән бәлибез. Шылай эскәтергә цорнап илтәбез.

– Йегет анасы әбизәтелни баwырсак алып килә. Баwырсакны үwендә пешергән, цәцәкләгән тәмле камфитлар белән. Ул йомыркалы баwырсак алып килә. Элекке әпәй алып киләләр иде. Матур, йәмне пиругын эскәтергә түнәгән. Үңгә кешеләр дә шылай алып киләләр.

– Кыз йагы *цәкцәк* алып бара. Цәкцәкне бийек итәләр, терсәк бийеклеге булсын. Шылай терсәкне куйып үлциләр. Цәкцәкне бизиләр кәмфитләр белән.

Цәкцәкне бәлиләр матур итеп тә, өскә куйалар тастымал, йә йаулык белән цәй, шәл баласы. Кем аца, шуңа була. Ацкан кеше йә сарык, йә акца әтә.

Тәрилкәгә йасатып алалар цәкцәкне. Балын, шәкәрен, цәйен китерәләр. Аларны кыз хакы итеп китерәләр. Аларны кире апкат′ырга тегел, ул шында кала. Бер генә дә буж килмиләр.

– Туйга саwым – кабыргалы кул, йә каз. Кабыргалы кул, дип әтәбез, ул сарыкның циреге – алгы йагы була инде. Йиде-сигез

кабырга санилар. Саwым пируклары, баwырсак, кабыргалы кул. Кабак, цөгөндер пируклары пешергән, хастәрләнеп барган саwым белән.

Йегет анасы бөтен каз алып бара, казы булмаса, кабыргалы кул алып килә. Ницә белән килделәр? Дүрт-биш каз килә. Ул дүрт-биш казның барын да башламилар.

– Элек йидешләр саwым белән килгәннәр: йиде каз, түгәрәк әпәй, зур-зур калачлар, паштитлар.

– Саwымга казны бизәп, матурлап алып баралар. Казны зур тәрилкәгә, йә патнуска куйалар.

Казның кырыйына кас′ы лимун, кас′ы апельсин тезә. Аны матур кагазлар белән йабып куйалар.

*Иске Чокалы*

## Саwым калачы

– Калач, диләр. Ике калач, парлы була. Саwым калачы өстенә камыр беләν алты, йә сигез санын куйа. Туйга килә кодаги менә шушы саwым беләν. Әһә, ул алты көн торачак, йә сигез көн торачак кунак булып.

Әгәр саwым калачына йазса, биж көн, дип, биж көн торырга тийеш булган. Шуны камыр беләν йазып куйа торган булганнар саwым калачы, саwым әпәйе өстенә.

## Саwым чыгару

*Саwым цыгару* – туй күчтәнәчләрен табынга кунаклар алдына чыгару. Яшьләр аны аягөсте торып (басып), хөрмәтләп каршы алалар.

– Саwымны алдан картларга цыгаралар. Саwым ашы цыкканда йәшләр айагүрә торып басалар.

– Саwым цыга. Башта төп кодагиның саwымы цыга, кодаги саwымы, дип каршы алалар. Аннан соң инде килгән кодагиның саwымнары цыга.

– Әрбер (*һәрбер*) килгән парлы кунак саwым алып бара. Аз-аз гына, берцәк кецкенә тәрилкәләргә салып цыгаралар. Барыбыз да аwыз итәбез.

Саwымны шылай берцәк-берцәк кенә турап, цашкы асты беләν цыгаралар.

*Шланга*

## Саwым күрсәтү, йасин уку

– Ул саwымны мәзелес халкына күрсәтәләр, мынсы – кодагиныкы, мынсы – шыныкы, дип.

– Саwымнарны өстәлгә куйып йасин укилар. Баwырсагын да, казын да куйасың өстәлгә, анда тора.

Ул саwымнарны бөтене белән цыгаралар, турап цыгаралар.

## Саwым турау, саwым тураучы

– Катыннар табынында саwымцы катын тури иде саwымны. Ирләр табынында ирләр генә турилар инде.

– Саwымны син тура, – диләр. Йегет йагыннан кем килә, шул турарга тийеш. Аны элек бабайлар тураган, укыган бабай тураган. Хазер инде кире алып кереп, турап цыгаралар. Тарилкәләргә салып бирәсең.

– Оста саwымцылар була. Казны аларга бирәләр турарга.

## Саwым тураучының сөлге, тастымалы

Саwым тураwцының йанында ак сөлге тыра кулын сертергә, артта кымганы тыра кулын йуарга.

## Саwым кискән кешегә бүләк бирәләр

– Саwымны кискән кешегә падаркы бирәләр. Йаулык, йә күлмәк. Бабай кешегә күлмәк, садака бирәләр.

## Саwым ашагач дога кылу, бүләк өләшү

– Саwымны берцәк барыбыз да аwыз итәбез. Дийа кылабыз, саwым алып килүцеләргә рәхмәт әтәбез дә туй бүләкләре өләшәләр.

Кыз анасы кыз йагындагы туганнарына бүләк бирә, йегет анасы йегет йагындагы туганнарына бүләк бирә.

*Иске Чокалы*

## Туй кунакларын хөрмәтләү

– Туй кунакларына көн сайын иртән *мунча,* көн сайын *кимак.* Һәр көнне кунакка йөртәләр.

Ике-өч йорт аша, күршегә генә туйга керсә дә, ул анда кунып тора. Аны шул саwымга ницә дип йазылган, шул көн кунак итәләр, алты, йә сигез көн.

Килгән кунак кодаги үзенең бөтен туганнарын китереп бетерә. Әтә: Менә, кодаги, менем әле шунди туганым бар, ул әле килмәде, китерә алмадыгыз әле аны. Аның сүзе закун булган. Ул үтәргә тийеш булган аның сүзен. Ул кодагиның китерәсе туганнарын китереп бетерергә тийеш булган.

– Менә өц пар ат бара, өц пар кунак алып килә кунак кодаги. Дүртне, бишне алып килүцеләр дә була.

«Кодаги, син әле безнең сеңелебезне китермәдең, риза тегел», – ди.

– Иртәнге ашны ашаганнар да, шуннан соң туганнары кодаларны кунакка алып киткәннәр. Көн сайын бишәр-алтышар йортка барганнар, аннан кат′каннар да, йаңадан, кичке мәҗелес ойоштырганнар. Шулай иттереп көне буйы кунакта.

## Коймак, тары коймагы

– Пич каршында бик тәмле пич кимагы пешергәннәр.

– Тары йармасыннан тары оны йасар идек, тары кимагы пешерә идек.

Тары йармасын килегә саласың да түwәсең кисап белән. Түwелеп бетмәгәнен илисең, калганын тагы түwәсең.

Бодай онын цүперә белән изеп куйасың да, аннары, тары оны кушып, тагын бер кат изеп куйабыз. Шулай тәмле була ул. Безнең әбиләр шулай тәмле иттереп ашарга үрәнгәннәр.

Тары кимаклары безгә дә эләкте әле ул. Хазер, нишләптер, пешермиләр тары кимакларын. Әле без бала wакытта түwә идек, пешерә идек тары кимагы.

*Иске Шәйморза*

## Юача

– Йугаца пешерәләр. Йомыркага басалар, беленер беленмәс кенә каймак салалар. Ару йомыркага гына басалар. Камырын басалар, кисәкләргә түгәрәклиләр. Кан′ап цыккан майга салалар. Сөзеп алалар. Шул йугаца була.

## Кыстыбый

Кыстырымби – әд. кыстыбый.

– Кыстырымби пешерәбез. Башта йәймәсен пешерәбез, аннары алманы (*бәрәңгене*) пешереп түwәбез, каймак салабыз. Йәймәне бөкләп, уртасына түгән алманы йагабыз. Соңыннан гына майлибыз.

Кыстырымби майларга, дип, май канатлары йасап куйалар. Менә күрсәтермен әле.

*Иске Шәйморза*

– Уразада аwыз ацкан кицкә кыстырымби пешереп, май канаты белән, сары май белән майлап куйабыз.

Кыстырымбины *йылы йырык* дип тә әтәләр каʹсы кешеләр.

*Түбән Чәке*

## Кәкәш

Кәкәш – бәрәңге яки эремчек пәрәмәче.

– Кәкәш тә пешерәбез. Камырны йәйеп, өстенә түгән алма (*бәрәңге*) йага, өстен йомырка белән майлый. Алма кәкәше кызарып пешә.

## Тура

Тура – эремцектән пешерәбез. Турага әзрәк писук, май саласың, йөзем саласың. Элеке йуг иде йөзем. Әзрәк он белән басасың да, wак-wак итеп пицтә пешерәбез.

## Казан кәлҗемәсе, эремчек кәлҗемәсе

Казан кәлземәсе – эремчек пилмәне.

– Сөтне каʹнатасың да, канʹап цыккац, катык саласың. Ул эремцек була. Эремцекне йомырка белән изеп, суган турап куясың. Пилмән камыры йасап йәйәсең, түгәрәкләп кисәсең. Wак кына итеп йасисың эремцек салып. Ул шулпада пешә, Казан кәлземәсе була.

## Боламык

Боламык та пешерәләр. Алманы пешереп түwә, анарга он азрак салып йибәрә, боламык була. Боламык ашарга арʹан, катык булса йахшы.

## Ботка

Бутканы пешерәләр, тары буткасы. Зур табак белән куйалар. Бутка уртасына казан йасилар, аңа май салалар. Бутканы кашык белән аласың, казанына тыгып аласың да ашисың бер казаннан майлап.

*Иске Шәйморза*

## ТОРМЫШ АВЫР ЕЛЛАРДА ПЕШЕРЕЛГӘН АШАМЛЫКЛАР

### Бәрәңге кырып ипи пешерү

– Бер циләк алманы (*бәрәңгене*) йуабыз да аны тирит′ итәбез (русча *тереть* сүзеннән алынган, ягъни *уабыз*). Ци алманы тирит′ итәбез дә он белән бутап куйабыз.

Ацкамыр белән изәсең, басып куйасың. Ул сеңәрә (*сыеклана*) инде. Аннары тагы он белән басасың аны, ул кабара.

Әпәйне түгәрәкләп-түгәрәкләп йастык өстенә салып куйа. Ул башта йәймә йәйә йастык өстенә, түгәрәк әпәй камырын сала. Ул анда матур итеп кабара.

Пумала белән пицне себерә. Әпәй керәге белән әпәйне пиц тебенә сала. Арыш әпәйе ике сагат пешә.

Әпәйне алырга wакыт йиткәц, пыцак тыгып карилар әпәйгә. Пыцакка йабышмаса, әпәй йахшы пешкән була иде, цыгарабыз пицтән. Бодай әпәйе тизерәк пешә.

*Каракитә*

### Крахмал күмәче пешерү

Кырахмал күмәце – өшегән бәрәңге күмәче.

– Кырга цыгабыз, ындырга цыгабыз. Туңган кырахмалларны җийабыз көрәк белән басып. Кырахмал күмәце пешерәбез. Ул өшегән алма (*бәрәңге*) инде, без инде аны кырахмал дип әйтәбез. Кабыгын арци, каты гына түwә, булса, аз гына он да куша.

Шулай үдәге пицне йагып, кырахмал күмәце пешерә идек. Ашагың келәсә, шулай тайым.

Ул кырахмал күмәцен ашагац инде без, тәкәләр кебек, сикереп йөрибез, тамак тук.

– Өшегән алма (*бәрәңге*) йийа идек йалан айак. Аны арци идек, әни кийашта киптереп тә куйа иде. Әнәй күмәц йасап ашата иде безгә. Ул тәмле иде. Элек алма тәмле булган ул, агу сипмәгәннәр хәзерге кебек.

Әнәй кабартма итеп тә пешерә иде өшегән кырахмалдан.

*Каракитә*

### Өйрә

Үрә – өйрә, ярма ашы.

– Кырдан бодай алып ка′табыз, күрсәләр – куwалар. Ул бодайны кул тирмәне белән әләндереп, үрә пешереп аши идек.

## Алабута күмәче

– Алабута орлыгын йийабыз, аны түwәбез. Ике алма (*бәрәңге*) кырып кушабыз. Алабута күмәце ашап кырга китәбез.

## Имән әкәләсе күмәце

– Имән әкәләсен (*чикләвеген*) пешерәсең дә киптерәсең, киледә түwәсең. Тирмәндә тарттырып, күмәц йасисың.

## Юкә яфрагы кабартмасы

– Кабартма пешерә әнәй. Йүкә йафырагын киптереп түгән, әз генә арыш оны кушып кабарткан. Кабартма пеште, бер бабай килеп керде.

«И-и, өстенә генә килеп кердем», – дир. Әнкәй әйтә: «Бир, кызым, бер кабартмаңны бабайга», – дир. Үземә ике кабартма, берсен бабайга бирдем, әнкәй дә бирде бер кабартмасын. Бабай ашады, цәй эцте, рәхмәт әтеп, дийа кылып цыгып китте. «Ул Хызыр бабай булгандыр», – дир әнәй.

## Кузгалак ашы

– Болында кузгалак бар. Әнәй иртән кузгалакка китә, без затып калабыз. Аннан бер мишук кузгалак алып кат′а, аны тапи, казанга сала, пешерә. Сөт саласың, тәмле инде ул. Сыйыр булгацтын сөт-катык булды безнеке.

– Кырдан үлән алып кат′а идек, кузгалак, цөгендер йафраклары. Шуларны салып аш пешерә. Катык катып аши идек.

Куйы булсын өцен кабак тури идек ашка.

– Безгә ата′ әни: «Кырга цыгыгыз, анда газниц (*кәҗә сакалы*) бар, какы. Шуларны ашарга йари». Без шуларны ашап үстек.

*Каракитә*

## Чәй ясау

– Цәй булмады сугыш йылларында. Әпәй булса, әпәй катысын йандыралар. Йә цөгендер, кишерне дә йандыралар, цәй йасилар. Аның кызылы цыга, тәме цыга, цәй була.

– Айу камырын (*гөлҗимешне*) зийабыз. Цәй итеп эцәбез. Йөрәккә файдалы, диләр.

## Күршедән ут алып кайту

– Пицне йагып йибәрергә шырпы булмады сугыш эстендә. Үле (сүндерелгән) цүлмәккә салып алып барабыз да күршедән ут алып кат′абыз пицкә йагарга.

*Шланга*

**ТЕКСТКА КЕРГӘН МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ БИРҮЧЕЛӘР:**

**Зур Чынлы**
Баһаветдинов Рәмис
Исламова Клара
Рамазанова Венера
Сәлахова Сания
Тукаева Рокыя
Фәтхулова Рауза
Хафизова Римма
Хәярова Гөлшат
Хөсәенова Рокыя

**Иске Задур**
Айнетдинова Гөлфарак
Миначева Гөлнур
Миначева Нурлыруй
Муслухова Сания

**Иске Чокалы**
Айнулова Сания
Йосыпова Рокыя
Усманова Фирүзә
Хәйретдинов Илһам
Шәйдуллова Рауза
Шәкүрова Наилә

**Каракитә**
Айлитова Нурҗиһан
Вәлиева Зәкия
Измайлова Нәүһәрия
Нуретдинов Гаян
Сәләхиева Зәйнәп
Шәйхаттарова Хамзия
Яфикова Яүһәрия

**Кече Чынлы**
Җамалетдинова Канифә
Җәмлиханова Зөбәрҗәт
Ибраһимова Әминә
Хәярова Кадрия
Шакирова Кәүсәрия

**Мунчәли**
Камалова Фәйрүзә
Моратова Фирдәүсә
Мөхәммәтшина Алия
Нәфиева Халидә
Туктиева Солтания
Хәлилова Сания

**Татар Бизнәсе**
Айнетдинова Луиза
Айсина Хәсәнә
Мөдәррисова Җәмилә
Сабитова Нәкыя
Сәлахова Мәфүрә
Халитова Рауза
Хәлилова Халидә

**Түбән Чәке**
Зәбирова Әсма
Сафина Әминә
Сафиуллина Әминә
Шагаева Әминә

**Иске Шәйморза**
Алиуллин Әнвәр
Алиуллова Мәсхүдә
Усманова Фәүзия
Фәхретдинова Гөләндәм
Ханбикова Равия
Шәмсетдинова Сәрия

**Шланга**
Алимова Дәелбәнат
Галимова Зәелбанат
Маниева Миңлегөл
Миначева Алия
Мөшәрәпова Сәрия
Садиева Нурзидә
Хафизова Сәрия
Хәярова Бибинур

**Яңа Чокалы**
Таканаева Мөнирә
Таканаева Нурания
Хисаметдинов Равил
Хисаметдинова Рәйнә
Юнысова Зөбәрҗәт

## ГЫЙБРӘТЛӘР АЛАСЫ БАР…

*Иршат Гафаров*

Сүзебезне кеше тормышына кагылышлы йолалардан башлыйк. Иң элек кеше үзенең дөньяга килүе турында аваз сала.

**Бала туу, исем кушу.** Яшь ананы һәм яңа туган баланы өйгә алып кайтканның икенче көнендә «*бәбәй*» мунчасы ягыла. Мунчада элек туган-тумача (гадәттә хатын-кызлар) юынып чыга, иң соңыннан, мунчаның кызуы беткәч, бала белән әнисен алып баралар. Элек хатын-кызга мунчага ялгыз барырга рөхсәт ителмәде, чөнки, имеш, шайтан «бәйләнергә» мөмкин.

Бу бәйрәм көнендә өстәлгә төрле тәмле ризыклар куела. Кунаклар үзләре дә бүләкләр, күчтәнәч ризыклар алып киләләр.

Гадәттә шул ук көнне балага исем-ат кушыла. Мулла яисә бүтән мәчет карты дога укый.

**Өйләнү, никах, туй.** Өйләнешү кеше гомерендә була торган иң истәлекле вакыйгаларның берсе. Ул ике төрле була иде: ике якның да әти-әниләре үзара килешеп яки, әти-әнигә белгертми, яшьләр үзара гына сөйләшеп кавышу.

Беренче очракта иң элек башкода җибәрелә. Ул авылның тәҗрибәле, утны-суны кичкән карчыгы, сирәк очракларда ир-ат та булуы мөмкин. Башкода ир-ат булса, ул кыз йортына кергәндә чалбарының бер балагын читек өстенә (аяк киеме өстенә) чыгарып керә. Оста телле башкодалар кияүне, аның әти-әнисен, туган-тумачасын мактыйлар, кызның әти-әниләрен ризалаштырырга тырышалар. Уртак килешүгә ирешелсә, булачак туй мәшәкатьләре, һәр яктан туйга нинди һәм күпме кунаклар килү, аларның кайсына нинди бүләк бирү, «картлар» һәм «яшьләр» туйларын кайчан һәм кайда үткәрү турында сөйләшүләр алып барыла.

Икенче очракта кызның әти-әниләренә егетнең берәр олы яшьтәге туганы, әти-әнисе яки әби-бабасы яшьләрнең үзара килешүе турында хәбәр итәргә килә һәм аларның хәер-фатихасын сорый.

Совет чорында ачыктан-ачык никах укыту яшьләрнең үзләренә дә, әти-әниләренә дә күңелсезлекләр китерергә мөмкин иде. Шуңа күрә дә никах күбесенчә яшьләрдән башка укыла, ә аларга дога укып өшкерелгән ашамлыклардан авыз итәргә генә кушалар иде. Никах укытылмаган туйлар ул вакытларда да бик сирәк булды.

Беренче кич яшьләр кунган йорттан олылар йокларга күршеләргә яки туганнарга китәләр. Яшьләр өйдә үзләре генә калалар. Икенче көн иртән кияү мунчасы ягыла. Беренче булып анда кияү белән кәләш юына. Аларның мунчадан кайтуларына коймак пешерелә. Котларга килүче туган-тумача, дуслар белән чәй эчелә. Гадәттә, берәр шаянрак дус кеше кияүдән: «Мунчаның парысы булдымы соң?» – дип сорап та куя.

Туй мәҗлесләре берничә көннән, атнадан, хәтта айдан соң да үткәрелергә мөмкин.

Иң элек олылар – картлар туе үткәрелә. Туйга, тулаем алганда, олы яшьтәге кешеләр генә чакырыла. Гадәттә бу мәҗлес көндез үткәрелә.

Туй элек кыз йортында үтә. Кодалар бүләкләр (*савым*) алып киләләр. Савым ул – камыр ризыклары, «кабыргалы кул» (сарык түшкәсенең чирек өлеше – алгы ягы, ул бөтен көе пешерелә), бал һ. б. Болардан башка кызның туганнарына, шул исәптән балачагага да, төрле бүләкләр алып барыла. Алар арасында күлмәк (ир-атка), күлмәклек тукыма (хатын-кызларга), яулык, сөлге, кульяулык, кызның үзе чиккән әйберләр дә булырга мөмкин. Кунаклар күбрәк булганда, мәҗлескә башта ир-ат, алар киткәч, хатын-кыз җыела.

Билгеле бер вакыттан соң туй егет өендә дә үткәрелә. Биредә дә бүләкләр таратыла, догалар укыла.

Әгәр килен башка авылдан булса, егетнең әти-әнисе һәм берничә якын туганы кыз авылына кунакка баралар, бу *туй төшерү* дип атала. Кодалар шул авылда берничә көн кунак булалар, чөнки кызның туганнары аларны бер йорттан икенче йортка ашка йөртә.

Шул ук күренеш егет авылында да кабатлана.

Туйның икенче өлеше гадәттә кияү йортында уза, ләкин, гаиләләрнең матди хәленә карап яки үзара килешү буенча, кыз йортында

да үтәргә мөмкин. Соңгы очракта егетнең әти-әнисе туй үткәрергә булдыра алган кадәр өлешен кертә.

Туй, туган-тумачаның санына карап, ике, өч көн уздырыла. Беренче көнне парлылар, ягъни ирле-хатынлы кунаклар җыела. Алар, башлыча, туган-тумачалар, якын күршеләр, дуслар һәм егет яки кызның әти-әниләре, алар эшли торган җирдән дәрәҗәле кешеләр булырга мөмкин. Гадәттә ирләр бер тирәдә – түр башында, ә хатын-кызлар икенче якта яки өстәлнең икенче башында утыралар.

Бәйрәм тәмамланыр алдыннан поднослар чыгарыла һәм кунаклар яшьләрне тәбрикләп алып килгән бүләкләрен (кемдер акча, кемдер әйбер) куялар. Акча һәркем күрерлек итеп куела. Зуррак сумма булса, бүләк бирүче бүтәннәрнең игътибарын үзенә җәлеп итәргә тырыша. Бүләкләрне яшьләр җырлап алырга тиешләр, үзләрендә мондый осталык булмаса, туганнарыннан кемдер булыша. Җыр бер яки берничә куплет итеп башкарыла. Мисал өчен түбәндәге җырны китереп үтик:

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме лә Вәлиәхмәт,
Безне болай зурлаганга
Сезгә бездән зур рәхмәт.

Шуны да искәртеп үтәргә кирәк, безнең заманнарда кияү белән кәләш хәзерге кебек өстәл башында түгел, ә бөтенләй өстәл янына да утырмыйлар иде. Бөтен мәҗлес дәвамында алар аяк өстендә булалар, кунакларга сый-хөрмәт күрсәтәләр, алар сөйләгәнне итәгать белән тыңлап торалар.

Туйның икенче яки өченче көнендә егетләр һәм кызлар, яшьләрнең дус-ишләре җыела. Бу көнне яшьләргә дә өстәл янына утыру мөмкинлеге туа. Туйда бары ялгыз биюләр генә башкарыла, хәзерге кебек күп кеше берьюлы бию булмый иде.

Ул заманнарда туй үткәрү бик мәшәкатьле эш иде. Иң элек тирә-күршеләрдән савыт-саба, өстәл, урындыклар алып торырга туры килә.

Ул вакытта өстәлләр дә хәзерге кебек мул ризыктан сыгылып тормадылар. Хәзинәдә ни бары куела иде: бавырсак, кош теле (*зәймә*), калач, казанда майда пешкән кабартма, клиндер, прәннек, печенье, пирог, балык консервлары, тозлаган балык, май, корт, каймаклы катык, бәрәңге, ит, токмачлы аш (*ләкшә*), сирәк очракларда

тозлаган кыяр яки кәбестә, винегрет (шулай ук сирәк йортта), кыш көне булса – холодец.

Иң элек табынга чәй бирелә, ул гадәттә күпләп эчелә, шуңа күрә тирә-күршеләрдән берничә самовар алып килеп куялар. Аштан соң, өстенә ит кисәкләре куелып, берничә тәлинкә белән бәрәңге чыгарыла. Шуннан кунакларның бер өлеше таралыша башлый, туган-тумача, якыннар тагын бераз вакытка калып, бәйрәм барышында бер тамчы ризык та капмаган хуҗалар белән чәй эчәләр.

**Җеназа йолалары.** Кеше төнлә яки иртәнге якта вафат булган очракта аны шул көнне үк күмәләр, ә инде көннең икенче яртысында булса, күмү икенче көнгә калдырыла. Бары тик читтән кайтасы туганнары булса гына, мәет берничә көн өйдә ятарга мөмкин.

Төнлә һәм көндез мәет янында кешеләр булырга тиеш, бу төнәтү дип атала. Гадәттә төн утыручы аерым әбиләр була. Алар дини китаплар укыйлар, пәйгамбәрләр тормышында булган гыйбрәтле хәлләр турында сөйлиләр, тәһлил әйтәләр.

Кабер казырга шактый кеше җыела, бу хәзерге заманда да шулай. Алар, чакырылып түгел, үз теләкләре белән киләләр. Кабер урынын зираттагы эшләрне алып баручы кеше күрсәтә. Гадәттә туган-тумачаны бер тирәгәрәк күмәләр.

Кабер казый башлаганда, мәчет карты, дога укып, җир йомшак булганда, дүрт почмаклап чирәмне дә кисеп ала, туң булса, балта белән чабып алалар. Бүтән төбәкләрдә мәетне ләхеткә салалар. Ләхет дип кабернең көньяк өлешендә уеп ясалган җире атала. Чүпрәледә «*шалгама*» белән күмәләр: кабер бер метр чамасы тирәнлектә казылгач (сары туфракка җиткәч), ике янда киртләч җир калдырып, ул «Мәнкир белән Нәнкир (фәрештәләр) сорау алырга килгәндә торып утырырлык» итеп казыла, шуны шалгама дип атыйлар. Киртләчләр мәетне гүргә иңдергәндә басып торыр өчен эшләнелә. Хатын-кыз мәетен күмгәндә киртләч бер якта гына (төньякта) калдырыла.

Шалгама эченә һәр ике якка өчәр имән багана утыртыла, аларга аркылы агачлар (*пираклат*) куела, шулар өстенә калын нарат такталары җәелә. Шулай эшләгәч кабер беркайчан да ишелми диярлек. Кабер казыганда, берничә балта тота белүче кеше шушы агачларны һәм такталарны эшкәртеп, әзерләп куялар. Кабер казылып беткәч, аны сакларга бер кеше калдырыла, калганнары җеназа алырга китәләр.

Шалгаманы казыр өчен «*цалыр*» дигән махсус җайланма кулланыла. Ул зур өтерге рәвешле итеп тимердән эшләнә, кул белән тотар өчен ярымдугага охшаган тоткы беркетелә. Аңа ике тармаклы агач сап куела. Дүрт-биш кеше цалырны күтәреп көч белән җиргә бәрәләр, ә аста берәү тезләнгән килеш тоткадан цалырның очын кирәк урынга юнәлтә барып, җирне каертып ала. Цалыр белән эш итәр өчен, аның остасы булырга кирәк, югыйсә тез капкачын имгәтү очраклары да булгалый.

Кабернең әзер икәнлеге турындагы хәбәрне берәү зираттан кайтып әйткәч, мәетне юалар. Суны махсус коедан дога укып тутыралар, чиләкләрнең өстен томалыйлар һәм коедан кайтканда беркем белән сөйләшмиләр. Чүпрәленең үзендә, мәсәлән, суны Миңналим исемле карт яшәгән йорттагы коедан алалар иде. Чөнки бу кое сиртмәле, аның өсте һәрвакыт ябык була, суны аннан бер чиләк белән генә алалар, шуңа да ул чиста саклана.

Әгәр мәет ир затыннан булса, аны өч кеше юа. Мәетне махсус «*кабык»* дигән җайланмага салып юалар, ул бераз авыш була, шуңа да су аяк очына таба агып төшә. Суны махсус «*сөннәтле»* комганнар белән салып торалар. Мондый комган кулдан эшләнгән була, борын очына алка кидерелә, шуңа да ул «сөннәтле комган» дип атала.

Хатын-кызлар алдан ук кәфен әзерләп (*печеп*) куялар. Мәеткә башта ләхет күлмәге кидерелә, кәфенгә төргәч, аны баш, бил, аяк турыларыннан бәйләп куялар. Элек, кәфенгә төргәч, мәетне күрсәтү тыела иде. Хәзер баш ягыннан кәфенне бәйләгәнче мәрхүм белән хушлашырга рөхсәт ителә. Бары тик аңа кагылырга, күз яше тамызырга ярамый. Шулай ук кычкырып елау да тыела. Мәетне юучыларга сәдака бирелә. Озатканда мәетне тагын одеялга яки паласка чорныйлар. Шуннан соң картлар тәһлилгә керәләр. Догалар укылгач, әйтелгән тәһлилләрне, шул исәптән төнлә белән карчыклар укыган (*тарткан*) тәһлилләрне дә, тутырылган Коръәне булса, аны да багышлыйлар. Тәһлилдән соң шунда булган кешеләргә мәетнең туганнары сөлге яки кулъяулык, сабын тараталар.

Мәетне аягы белән алга таба алып чыгалар һәм җеназага салалар. Җеназа укыла. Элек җеназа укырга картлар гына тезелеп баса иде, хәзер инде шунда катнашучы барлык ир-ат та баса. Җеназа укылганнан соң, мулла вазифасын башкаручы: «Җәмәгать, бу кеше яхшы идеме?» – дип сорый. Аңа: «Яхшы иде!» – дип җавап бирәләр. Шуннан соң җеназаны күтәреп зиратка юл алалар. Елның

вакытына һәм зиратка кадәр араның ераклыгына карамастан, җеназа кулда һәм кызу алып барыла.

Хатын-кыз мәетен алып барганда, җеназа өстенә агач яки тимер чыбыктан дуга ясала һәм ул чаршау белән ябыла.

Мәетне гүргә иңдерү өчен кабергә өч кеше, гадәттә икесе туганнарыннан, якыннарыннан, төшә. Аны йөзе белән кыйблага каратып салалар, баш, бил һәм аяк очын бәйләгән бауларны чишәләр. Мәет хатын-кыз булса, аны кабергә күчергәндә һәм шалгаманы такталар белән томалаганчы, кабер өстен чаршау белән каплап торалар. Мәчет картларыннан берәү, дога укып, җир кисәге бирә, аны мәетнең баш очына куеп калдыралар. Шуннан аркылы агачларны куеп такталарны җәяләр һәм туфракны кабергә төшерә башлыйлар. Берәү такталар урыннарыннан кузгалмасыннар өчен туфрак белән томаланганчы кабердә тора. Элек кызыл (*сары*) балчык төшерелә. Туфрак өелеп беткәч, булса, рәшәткә урнаштырыла.

Шуннан соң дога укыла. Дога укылып беткәч, зиратта булган барлык кешеләргә сәдака өләшенә. Мәрхүмнең туган-тумачасы күп булганда, сәдаканы ун һәм артыграк кеше өләшергә мөмкин. Сәдаканың күләме һәркемнең матди хәленә карый, бары бер генә шарт бар, ул да булса, дога укучыларга күбрәк бирү. Кешеләр таралышкач, кабернең дүрт почмагына дүрт кеше (карт) утырып дога укыйлар. Берничә дистә еллар элек хатын-кызга зиратка керү тыела иде, хәзер моңа бик игътибар итмиләр.

Мәетне алып киткәннән соң, өйне һәм мәет яткан әйберләрне юып, чистартып чыгаралар. Зираттан кайтучылардан берәү, өйгә кереп, дога укый.

Мәрхүмне искә алып, күмгәннең өченче, җиденче, кырыгынчы һәм бер ел (*ел ашы*) тулган көннәре билгеләп үтелә. Өчесе үтми торып, мәет чыккан өйдә ашарга һәм эчәргә ярамый. Бу көннәрдә йорт хуҗаларын туган-тумачалары, күрше-тирәләре ашка чакыра.

Өчесе көнне гадәттә ирләр һәм хатын-кызлар аерым җыелалар. Ирләр дога укыйлар. Ашта катнашучыларга мәрхүмнең якыннары сәдака өләшә. Мәетне юучыларга, кабер башлаучыга һәм саклаучыга, гүргә иңдерүчеләргә аерым бүләкләр (сәдака) бирелә. Җидесе, кырыгы, ел ашына гадәттә туганнар һәм мәчет картлары гына җыела. Бу көннәрдә ирләр белән хатыннар бергә җыелырга мөмкин. Элек мәрхүм рухына бер генә кеше Коръән (Ясин) укый иде, ә инде соңгы вакытларда берничәшәр кеше уку да күзәтелә.

**Каз өмәсе**. Әлеге йола милләттәшләребез яшәгән күп төбәкләрдә таралган, чөнки каз асрау татарда борынгыдан килә, кайсыбер йортларда аларның саны берничә дистәдән дә артып китә. Билгеле, аларны эшкәртү өчен зур көч куярга туры килә. Каз сую һәр җирдә дә бертөслерәк, әмма һәр төбәкнең, шул исәптән Чүпрәле якларының да, үзенчәлекләре дә бар.

Казлар сую, җир катыргач, кар яугач башкарыла. Бу эш таң атканчы ук башлана. Үз эшен яхшы белгән абзый дога укып казларны суя. Шуннан казларны өйгә алып керәләр дә, хатын-кызлар аларның мамыкларын йолкый башлыйлар. Билгеле, эш барышында уенкөлке, җыр осталары булса, бер-берсе белән шаярып алулар, кызыклы мизгелләрне искә төшерүләр һ. б. була, кайчакларда җыр да яңгырый.

Каз түшкәләре мамык-каурыйлардан чистартылгач, иң оста хатын-кыздан казның үпкә-бавырларын, бүтәкәләрен, эчәкләрен, маен алдырталар. Күп төбәкләрдән аемалы буларак, Чүпрәле якларында эчәкләрне орчык ярдәмендә ярып чистарталар да, тәпиләргә урыйлар. Тәпиләрнең үзләрен дә әйбәтләп юып чистарталар. Пешкәч ул, бүтәкә кебек үк, затлы ризыклардан санала.

Дөрес, бүтәкә ул чорларда балаларга бик сирәк эләгә иде. Чөнки олылар: «Бүтәкә ашаган бала үсмичә кала», – дип шаярталар иде. Каз тәпиенең сөяге дә малайлар өчен кадерле саналды, чөнки ул тимераякны киез итеккә бау белән бәйләгәч, бауны боргычлап, беркетеп куярга ярдәм итә (*тияк*).

Бала чакта без казның үңәчен (*йимшәүен*) тышкы ярысыннан аерып, нечкә өлешен өреп тутырып һәр ике башыннан да җеп белән бәйләп куя идек. Ул «*куык*» дип атала һәм озынча шарны хәтерләтә иде. «Куык» әле кибеп беткәч тә озак вакытлар кеше күзе төшә торган урында асылынып тора иде. Кайсы вакытларда куыкны сиздерми генә, шаяртып, аулак өй уеннарында катнашучылар астына да куялар, ул шартлап ярыла һәм аның өстенә утырган кешене куркып кычкырып җибәрергә, ә янәшәдәгеләрен көләргә дә мәҗбүр итә.

Элек каз өмәсе булган йортта кичен **аулак өй** (*мәзәк*) үткәрелә иде. Олылар яшьләргә комачауламас өчен тирә-күршеләргә яки туганнарга киткәч, бирегә кызлар, егетләр җыела. Сирәк кенә булса да күрше авыллардан да кунак кызлары, егетләре булуы мөмкин, гадәттә, алар хуҗаларга туган-тумача туры киләләр. Өйләрдә стена буена, табуреткалар өстенә озын такталар куелып, сәкеләр эшләнә,

шунда яшьләр тезелеп утыра. Бала-чаганың урыны мич башында, алар шуннан уеннарны күзәтәләр.

Мәзәкнең иң кадерле кешесе гармунчы була иде. Тальян яки хромка гармун тавышы яңгырагач, җыр-биюләр башлана, төрле уеннар оештырыла. Шундыйларның кайберләренә тукталып үтик. «Йөзек салыш» дигән уенда аны алып баручы кеше яшьләрнең учларына кулын тидереп уза һәм сиздермичә генә кемнеңдер учына йөзекне салып калдыра. Татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдәге кебек, бездә дә уенда катнашучыларның берсе йөзекнең кемдә икәнен әйтергә тиеш, әйтә алмаса, аңа җәза бирелә. Дөрес әйтсә, җәза, йөзек кемдә, шуңа эләгә. Җәзалар да төрлечә була: җырлау, бию, «күгәрчен ашату» һ. б. Мәсәлән, егет яки кыз авызына шырпы каба, ә шырпының икенче очын бүтән кыз яки егет кабарга тиеш. Бу очракта ул егет белән кыз арасында булган мөнәсәбәтне дә истә тотарга тырышалар. Әмма иреннәр иренгә тимәскә тиеш.

Икенче төр җәза – «йолдыз санау». Бу вакытта кыз белән егет бераз вакытка урамга чыгып керәләр.

Җәзаларның иң катысы – бил каешы белән кул учына суктыру. Җәза кызларга бирелгән очракта, аны егет кеше алырга мөмкин, бигрәк тә үзенең күңеленә хуш килгән кыз булса. Билгеле, җәза бирүчесе дә үз «осталыгын» күрсәтергә тиеш була, шуңа да ул җәзаны җиренә җиткереп үтәргә тырыша.

Уеннар, билгеләп үткәнебезчә, төрле булып, шул исәптән җыр, биюләр башкарыла. Мәсәлән, «Су агышы» исемле уен. Кулга-кул тотынышкан парлы яшьләр, кулларын күтәрә төшеп, «күперчек» ясыйлар. Хәзерге чордан аермалы буларак, сафларның алгы өлешендә парсыз егет яки кыз баса. Ул гармун тавышына кушылып, бии-бии яки биегән булып алдагы парның сыңарын кулыннан тотып, үзе белән әлеге күперчек астыннан алып, артка үтә. Алда так калган уенчы да сафтан берәү белән шулай ук артка таба уза. Кыюрак егетләр кызларның билләреннән дә кочып чыгарга мөмкиннәр, алар шуңа омтылалар да. Бу уен шактый озак дәвам итә, чөнки егетләр, үзләренең күңелләренә хуш килгән кызның биленнән тотып, әлеге «күперчек» астыннан үтүне үзләре өчен зур бәхет итеп саныйлар иде. Бер үк вакытта сафта тезелеп торучы уенчылар да биеп, җырлап алга таба хәрәкәт итәләр.

**Йорт күтәрү өмәсе.** Йорт күтәрү дә иртәнге якта башлана, чөнки бу вакытта гадәттә җил булмый диярлек, югыйсә бүрәнә

өстендәге мүкне җил очырып бетерер иде. Олы яшьтәге ир-атлар, кайчак бу эшкә хатын-кыз да кушыла, тигез катлам итеп бүрәнәләр өстенә мүк (*нүек*) яки сүс (*пәзи*) җәяләр. Мүкне Чувашстан урманнарыннан махсус җыеп, базарга китереп саталар иде яки йорт төзүчеләр (*салучылар*) үзләре үк шуннан барып алдылар. Җил исә башласа, мүкне суга манчып алалар. Яшьләрнең бер өлеше тамгалар буенча бүрәнәләрне әзерләп куя, ә бер өлеше аны өскә күтәрә. Бүрәнәләрне урыннарына урнаштырганда бик сак эш итәргә кирәк, чөнки куелган мүкне бәреп төшерергә ярамый, йә булмаса үзең дә очып төшүең бар. Шуңа да иң таза ир-егетләр бүрәнәне очыннан бау белән күтәреп куялар. Матча астына йорт хуҗаларына байлык, иминлек теләп көмеш акча куеп калдырыла. Халык күп булганда, бер үк вакытта мүкне бүрәнәләр арасына кечкенә көрәкчекләр, калаклар белән тыгызлап тыгу, кагу эше дә башкарылырга мөмкин. Бу эшне күбесенчә картлар башкара иде.

Соңыннан өмәдә катнашучыларга сый-хөрмәт куела. Өстәлне әзерләүдә туган-тумача, тирә-күршеләр дә катнаша. Хатын-кызлар кемдер коймак, кемдер ботка, кемдер бүтән төрле ризыклар алып килеп йорт хуҗаларына тапшыралар, ә алар, үз чиратында, бу ризыклар белән өмәдә катнашучыларны сыйлыйлар.

Өмә алдыннан йорт эшләүче балта осталары аның нигезен әзерләп куялар. Моның өчен почмакларга башлыча имән агачыннан ясалган калын түндәкләр утырталар һәм алар арасына нечкә түндәкләр тезәләр яки бура ясап куялар. Хәзерге вакытта йортның нигезе кирпечтән яки таштан эшләнә инде. Түндәкләр өстенә берничә бүрәнә (*виниц*) урнаштырыла, алар өстенә өрлекләр (*пираклат*) куелып, өрлекләргә идән такталары (*половойлар*) җәелә.

Идән астындагы бүрәнәләр янына туфрак өеп «*эргә»* ясыйлар. Бу җылылыкны саклау өчен кирәк. Билгеле, туфракны идән җәйгәнче өеп калдырсаң җайлырак була. Туфракны алгач шактый тирән баз хасил була, ул «идән асты» дип атала. Анда бәрәңге, кәбестә һәм башка яшелчәләр, кышка әзерләнгән тозлы әйберләр саклана. Элегрәк кыш чыгарга умарталарны да идән астына кертеп калдыра иделәр. Кыш җылы булганда, кайчак бал кортлары (умарталар, мурталар) идән ярыкларыннан өйгә дә очып чыктылар. Хәлле кешеләр базны бура белән, булмаса – такта белән әйләндереп алалар, бу базны туфрак коелудан һәм тычканнар керүдән саклый.

Өйнең түбәсен элек күбесенчә арыш саламы белән ябалар иде. Салам шуып төшмәсен өчен, нечкә агачларны тамыры белән алып кайтып яки агачның бер башына аркылы икенче кыска агач кисәген ныгытып, махсус җайланма ясыйлар. Саламны җил очырып китмәсен өчен, аны нечкә агачлар (*куралар*) белән бастырып бәйләп куялар.

Соңрак түбәне такта белән яба башладылар. Такталарны аралар калдырып кагалар, ә алар өстенә ярыкны томаларлык итеп тагын бер такта сугыла (бу ысулны «*разбежкы*» белән ябу, ә тактаны «*т'уз*» дип атыйлар). Өстә кала торган тактага яңгыр, кар суы агар өчен махсус ышкы белән ике кечкенә улак ясала. Күп очракта, өй белән беррәттән, бура яки такта чолан ясала, аның астында баз (*пугряб*) казыла, шунда бәрәңге, яшелчә саклыйлар. Җәй көнгә аңа боз тутырып калдырып күпмедер вакыт ул суыткыч булып та тора иде.

Тәрәзә яңакларына, шулай ук өйнең фронтонына да агачтан кечкенә пычкы, өтергә ярдәмендә төрле-төрле бизәкләр кисеп беркетәләр, бизәкләр күбесенчә геометрик фигуралар яки чәчәк рәвешле була. Рамнарны махсус остадан эшләтәләр, мәсәлән, Иске Чүпрәледә аларны Зиһанша исемле оста ясый иде.

Элекке заманнарда күп өйләрнең бүрәнә араларын тышкы яктан балчык белән сылап, акшар белән елга берничә тапкыр агарталар иде. Бу өйне җылы тотарга ярдәм итәр өчен эшләнә. Көз көне, җылы саклар өчен, урам яктан да тәрәзәнең аскы өлеше биеклегендә такта яки нечкә агачлар тезеп туфрак өелә, яз җиткәч ул яңадан таратыла иде.

Өйне җылытыр өчен, гадәттә, ике мич салына. Берсе зур мич, аны «урыс пице» дип тә атыйлар. Мондый зур мичләрне махсус осталар гына чыгара, чөнки аның ипи пешерә торган өлешендә гөмбәз булырга тиеш, андый осталар халыкта зур хөрмәткә ия булалар иде. Мичнең ипи пешерә торган бүлемендә ут каршында коймак, кабартма, бәрәңге пешереп була. Мич янып беткәч, кисәүләрне кисәү агачы белән тартып чыгарып, мич төбендәге көлне себереп алып, махсус эшләнгән агач көрәк белән ипиләрне тезеп чыгаралар да, мич авызын калай капкач белән каплыйлар. Шуның янына калган күмерләрне җыештырып өеп куялар, бу өстәмә җылылык бирә һәм ипи дә яхшы пешә. Ул заманнарда ипи пешерергә камыр әзерләү өчен бар йортта да күәс чиләге (*куашна*) булмый, шуңа да күршеләрдән алып торырга туры килә иде. Куашна белән бергә

әчетке дә (*ацкамыр*) да алып торалар, соңыннан, шул ук күләмдә итеп, әчеткене кире кайтаралар.

Мичнең гөмбәз өстендә шактый гына тигез урын – мич башы була, анда ашлык, юеш кием-салым, аяк киемнәре киптереп була. Мич башы бала-чаганың да яраткан урыны, анда йокларга да, уйнарга да була, зурлар да бик игътибар итмиләр. Сугыштан соңгы елларда чи ашлыкны киптерү өчен колхозчыларга тараталар иде, шуңа да, урамда җылы булса да, мичкә ягып өстендә ашлык киптерделәр.

Кайбер кешеләр кечкенә мич – «галанка» да ясыйлар. Ул бераз ара калдырылып зур мич белән рәттән урнаштырыла. Салкынча булганда, галанканы җәй көне дә ягып җибәрәләр. Аның учагы зур мичкә каршы ясала. Утын булмаганда аны салам яки тизәктән ясаган кирпеч белән дә ягалар. Мичләрне елга берничә тапкыр агарталар (*акшарлыйлар*).

Морҗаны ике мичкә бер итеп, «дуңгыз» ясап чыгаралар, моның өчен яндырылмаган (русча: сырец) кирпеч кулланыла. Гадәттә андый кирпечне махсус балчыктан аерым төбәкләрдә генә ясыйлар. Кайберәүләр морҗаның өске өлешен чирәмнән киселгән кәстән өеп меңгерәләр, кәсләр ныграк торсын өчен, аларны агач кадаклар белән берсенә берсен беркетәләр. Морҗаны да елга берничә тапкыр акшар белән агартырга туры килә, моны янгын сүндерүчеләр махсус тикшереп йөриләр.

Кайсыбер йортларда «галанка» миче белән стена арасына сәке эшләнергә мөмкин. Ул идәннән якынча ярты метр биеклегендә булып, аның өстендә ашыйлар, йоклыйлар, намаз укыйлар, кул эшләрен башкаралар. Сәке астында хуҗалык әйберләре, яшелчәләр сакланырга мөмкин, шунда ук казлар бәбкә чыгаралар, кечкенә бәбкәләрне дә салкын вакытта шунда ябып торалар. Моннан башка сәндерә дә булырга мөмкин, аны түшәмнән 50–60 см астарак ясыйлар. Ул да балаларның яраткан урыны, чөнки анда олы яшьтәгеләр менми, балалар үз ирекләрендә, шуңа да күп балалы гаиләләрдә бу урынны алыр өчен еш кына бәхәс була.

Зур мич белән стена арасында бушлык кала. Шунда, кыш көннәрендә, кайсыбер хуҗалар яңа туган бозаулар, бәрәннәрен кертәләр иде. Мич артында юыныр өчен дә урын ясала.

Үткән гасырның 50–60 нчы елларында авыл өйләрендә мебель юк дәрәҗәдә диярлек иде, гадәттә кулдан ясалган өстәл, савыт-саба

куя торган шкаф (буфет кебек), агач караваt, яшь балалар өчен яслә, урындык яки табуреткалар, шулай ук сандык була. Шуны да ассызыклап әйтергә кирәк, алар, кулдан ясалган булса да, бик зәвыклы итеп эшләнгән булалар, мәсәлән, өстәлләрнең аякларын махсус станокта кырдыралар, шкафларның ян-яклары да сырланып эшләнә иде.

Тәрәзәләргә кулдан чиккән пәрдәләр (*еленгеләр*) еленә, урынҗир, мендәрләр өстенә дә кулдан чигеп эшләнгән япмалар ябыла. Олылар йоклый торган урын гадәттә чаршау белән бүлеп алына. Идәнгә кулдан сугылган паласлар җәелә. Ул паласларны тар итеп ерткан чүпрәкләрдән сукканнар, шуңа күрә өйдәге бер иске чүпрәк тә чүплеккә китмәгән.

Һәр йортның тәрәзә төпләрендә гөлләр үстерелеп, татарлар яшәгән барлык төбәкләрдәге кебек, алар игътибар үзәгендә булдылар. Заманында Воробьев та: «…татарларның иң ярлы йортларында да тәрәзә төпләрендә тамчылы гөл яки яран гөле үсә. Русларда гөлләр бары тик байларда гына булып, калган халыкларда алар революциядән соң гына күренә башлады» – дип язды.

Мунчаларны усак яки юкә агачыннан эшләттеләр. Алтмышынчы елларга кадәр мунчалар «кара» була иде әле, икенче төрле әйтсәк, төтен морҗадан түгел, ә ачык ишектән чыга. Мунчаның эчендә, арасын 40–50 см калдырып, таштан фундамент кебек корылма ясыйлар, аның өстенә тимер кисәкләре сузып таш (*мунца ташы*) тезәләр. Моның өчен, елга буйларыннан махсус таш та казып чыгардылар. Ул сирәк очрый, аны картлар үзләре генә белгән билгеләр буенча эзләп табалар иде. Миңа, мәсәлән, бабайга ияреп берничә тапкыр таш чыгарган җиргә барырга туры килде. Шуны яхшы хәтерлим, бабай бервакытта да буш кул белән кайтмады. Таш өстенә казан, чиләк асып куела. Ялкын, ташлар аша үтеп, ташларны һәм казан, чиләкләрдәге суны җылыта.

Мунчаны белеп ягарга кирәк, чөнки ташның кайчан кызып җитүен, мунчаның әзер булуын чамалап кына белергә мөмкин. Утыны янып беткәндә, мунчаның ишеген ябалар, ул бераз вакыт кисәүләр белән торырга тиеш. Соңрак инде мунчаны «*уздырып*» кайталар. Башлап баручылар таш өстенә су сибеп исне чыгаралар, таш өстенә куеп себеркегә кайнар су салалар да аны әйләндерә-әйләндерә парлыйлар. Чәчне катыкка су кушылган «*башумак*» дигән сыекча белән юалар. Бер ягылган мунчадан тирә-күршеләргә дә өлеш чыга,

чөнки, беренчедән, ул заманнарда ягулыкка кытлыкны искә алсак, икенчедән, һәр гаиләдә дә мунча булмый иде.

Мунчаның тәрәзәсе кечкенә һәм астарак була. Шуңа күрә дә мунчада караңгылык хөкем сөрә, бигрәк тә кыш көне. Мунчаны шәм, ә кайсыбер гаиләләрдә «*шахтерка*» дип аталган фонарьлар белән яктырталар. Шахтерка – күмер кисүчеләрнең җир астына төшкәндәге иң кирәкле эш коралы. Ул, керосин белән яндырылып, яктылыкны аз бирсә дә, нинди генә көчле җил-давылда да ялкыны сүнмәве белән күпләрнең күңеленә хуш килә иде. Стеналар, түшәмнәр, корымга буялып, каралып бетә, мунчадан аңа гына хас хуш ис чыга башлый. Мунчаның ишек алды салкын була, идәнгә салам җәелә, соңыннанрак юынучыларга боз өстенә басып киенергә туры килә иде.

**Өй *(ызба)* юу.** Элекке заманнарда мичләрне күбесенчә салам, тирестән эшләнгән кирпечләр яки торф белән яктылар. Мич якканда өйгә шактый гына төтен, корым таралып, стеналар, түшәм карала башларга мөмкин. Шуңа күрә дә һәр елны, ягу чоры тәмамлангач, өй юу өмәсе үткәрелә.

Бу көнне өйдә булган әйберләр чоланга яки бүтән җиргә чыгарыла. Стеналарны, түшәмне махсус эшләнгән үткен тимер кыргыч белән кырып чистарталар, ә аннары берничә тапкыр чиста су белән юалар. Идәнне ком (моның өчен ике кызыл кирпечне бер-берсенә ышкып ком әзерлиләр; без андый кирпечләрне элек «приказ» дип аталган йортның нигез калдыгыннан казып ала идек) сибеп тимер челтәрне аяк белән йөртеп ышкыйлар. Бу паркет идәнне мастика белән эшкәртүне хәтерләтә. Идәнне югач, ул «сап-сары» (бу сүз чисталыкның артыклык дәрәҗәсен аңлата) булып кибә. Өйне юар өчен кар суларын да файдаланалар, чөнки ул йомшак була, селтене яки сабынны яхшы эретә.

Билгеле, бу эш тә күп көч куюны сорый, шуңа да гадәттә аны олы кешеләр генә, шул исәптән ир-атлар да башкара, ярдәмгә күршеләр һәм туган-тумачалар да килә.

**Сабан туе.** Чүпрәле якларында элек Сабан туе бары тик район үзәгендә генә үтә иде. Бәйрәмгә әзерлек алдан башлана. Авылларда йорт буенча бүләк җыеп йөриләр. Бүләкне һәркем көченнән килгәнчә бирә: чиккән кулъяулык, сөлге, тукыма кисәге, йомырка, акча һ. б.

Иртәгә Сабан туе дигән көнне бәйрәм мәйданына кибетләр өчен урыннар, кунаклар өчен трибуна ясала. Шул ук көнне сәүдә итү дә

башлана, район үзәгендә яшәүчеләр кирәк әйберләрне, ризыкларны шунда алып калалар, чөнки Сабан туе көнне кибетләр янына килеп булмый диярлек, чиратлар зур була.

Шул ук көнне кәмитләр (карусель) килә. 1960 нчы елларда алар Матак һәм Уби авылларыннан була иде. Кәмитләр балаларның үз көче белән хәрәкәткә китереләләр. Малайлар өске якка менеп өрлекне көч белән этеп берничә кабат әйләндерәләр, аннары үзләре бушлай агач атка атланып яки тарантаска утырып әйләнәләр. Алдан кәмит хуҗалары малайларның маңгайларыннан сыйпап карыйлар, тирләмәгән булмаса утыртмыйлар, ягъни эшләмәгән килеш утырырга тели. Һәр кәмитнең кечкенә генә оркестры була: гармун, барабан һәм җиз тәлинкәләр.

Сабан туенда, бүтән төбәкләрдәге кебек үк, төрле ярышлар, уеннар оештырыла: шома колгага менү, чүлмәк вату, капчык киеп, кашыкка йомырка салып йөгерү, ат чабышлары һ. б. Билгеле, һәр төбәктәге кебек, бәйрәмнең үзәге – милли көрәш. Ул шулай булмый мөмкин дә түгел, чөнки әле борынгы төркиләр дә билбау белән көрәшүне күзәткәннәр. Милли көрәшсез бәйрәмне алар бәйрәмгә санамаганнар. Җиңүчеләр шул вакытларда ук бүләккә тәкә ала торган булганнар.

Чүпрәледә дә көрәшне элек-электән яратканнар. Гадәттә көрәшне күзәтүчеләр мәйдан тирәсенә авылдашлары белән утыралар. Көрәш кыза барган саен мәйдан тарая, судьяларның карарына ризасызлык арта бара, ә инде көрәш тәмам булгач, халык, мәйданга йөгереп чыгып, җиңүчене күтәреп алып күккә чөя. Элек Чүпрәледә көрәшчеләрнең үлчәү авырлыгына игътибар ителми иде.

Мәшһүр якташыбыз Һади Атласиның Буа мәдрәсәсендә шәкерт чакларында шул төбәкнең сабан туйларында оттыру белмәс батыр булганлыгы билгеле.

Ирекле көрәш буенча СССРның дүрт тапкыр, Европа һәм дөньяның ике тапкыр, XX җәйге Олимпия уеннары чемпионы Шамил Хисаметдиновның әтиләре Каракитә авылыннан. Алар Тула өлкәсе шахталарына эшкә киткән булалар. Шамилнең кайбер туганнары әле дә Каракитә авылында яшиләр. Аларның бабалары бик көчле булган. З. Ю. Азизов сөйләве буенча, бервакыт ул урманнан утын төяп кайтканда, аты арбасын елгадан тартып чыгара алмагач, аны туарып үзе җигелгән һәм олауны тартып чыгарган. Шуннан: «Кара әле, хайванны, тарта алмагач, бер дә юкка

суккалаганмын икән, үзем дә авырлык белән генә чыгардым бит», – дип әйтеп куйган.

Каракитә авылында шулай ук Чуаштанның ирекле көрәш буенча чемпионы Шамил Локман улы Миңнебаев, Рәсәйнең спорт мастеры, ирекле көрәш буенча Якутия-Саха Республикасының чемпионы Фәрит Зәки улы Азизов туып үскәннәр.

Көрәш турында сүз йөрткәндә, Кече Чынлы авылы батырларына аерым тукталасы килә. Бу төбәк көрәшчеләре күп еллар буе Чүпрәледә генә түгел, күрше Буада, Чуаштанда, Ульяновск өлкәсе сабан туйларында да мәйдан тотып батыр калдылар. Алар арасында ике тапкыр Рәсәй, өч тапкыр Татарстан батыры, 1980 елда Татарстанның абсолют батыры, Рәсәйнең спорт мастеры Әсхәт Фәхретдинов, Татарстан чемпионы, спорт мастеры Мансур Айзатуллов, күп еллар төрле төбәкләрдәге сабан туе батыры Максуд Хөснетдиновны, аның бертуган энесе Рифкатьне һәм башкаларны атап китәргә мөмкин. Заманында Казан шәһәре 5 нче хастаханәсенең баш табибы булып эшләгән якташыбыз М. Г. Шәрәфетдинов та самбо көрәше буенча «Буревестник» спорт җәмгыяте чемпионы булган.

Ул вакытларда автобуслар түгел, йөк машиналары да колхозларда бармак белән генә санарлык иде. Шуңа да авыллардан бәйрәмгә өстенә такта сузылган озын арбаларга утырып киләләр, атларның дугаларында – кыңгыраулар, бизәкләр, тәртәләрдә чуклы сөлгеләр, яулыклар, төсле тукымалар. Һәр арбада гармунчы утыра, җыр яңгырый. Җыр дигәннән, Чүпрәле Сабан туеның ул чаклардагы бер үзенчәлеген ассызыклап үтәсе килә, ул – бәйрәм барышында төркем-төркем егет-кызларның култыклашып, гармунга кушылып, мәйдан буенча җырлашып йөрүләре. Җырлар ике телдә – татарча һәм чуашча – яңгырый. Шуңа да З. Нури «Чүпрәле сабан туенда» исемле шигырендә болай дип яза:

«Товарищ», «Юлташ» һәм «Иптәш»...
Монда бар да килешә:
Хәтта таныш түгелләр дә
Кул кысышып күрешә.

Сабан туе көнне терлекләр көтүгә куылмый, шуңа да балалар таңнан торып сыерларны елга буйларында ашатып кайтырга тиешләр, югыйсә аларның бәйрәмне күрми калулары бар. Ә сабан туе балалар өчен елга бер була торган шатлыклы бәйрәм, чөнки бу

көнне аларга яңа кием кидертәләр, әти-әниләре, туганнары, вак-төяк булса да, акча бирәләр. Шулай булгач, өч тиенгә тәмләткеч салган бер стакан су, ун тиенгә көнбагыш яки прәннек алып бәйрәм итәргә була.

**Уңыш бәйрәме.** Ул 1950 нче еллар ахырында, урып-җыюлар беткәч үткәрелә иде. Бу көнне колхоз идарәсе аерым йортларда, хуҗалар ризалыгы белән, сый әзерләтә. Шунда ирләр аерым, хатын-кызлар аерым җыелалар. Бәйрәмгә берәм-сәрәм килмиләр, ә алдынгыларны озын арбаларга тезеп утыртып алып киләләр. Шуның өстенә олаулар матур итеп, сөлге, яулыклар белән бизәлә. Хәтеремдә, әлеге бәйрәмнәрнең берсе – әти, ә икенчесе әни туган йортларда үтте. Миңа, йорт хуҗаларының баласы буларак, читтән генә булса да күзәтеп торырга насыйп булды, шуңа да ул вакыйгалар истә калган. Ике очракта да хатын-кызлар бәйрәме иде. Табында ит-аш, камыр ризыклары мул иде. Кунаклар аякларын бөкләп идәнгә утырдылар. Әле дә булса исемдә, әниләр йортындагы бәйрәм кар яугач үтте. Шул вакытта чак кына күңелсез хәл булмый калды. Мич артына, бәрәнен имезергә дип, сарык керткәннәр иде, ул нидәндер куркып булса кирәк, ике мич арасыннан атылып чыккан чакта кайнап утырган самоварны аударды. Бәхеткә каршы, беркемгә дә зур зыян килмәде. Бәйрәм барышында ашау-эчү генә булмый, ә уен-көлке, җырлар да яңгырый иде.

**Йомырка бәйрәме.** Чүпрәле төбәгендә гомер-гомердән татарлар чуашлар белән аралашып яшәделәр. Шуңа да кайбер бәйрәмнәр уртакка әйләнде. Сабан туе турында әйттек инде. Мәсәлән, пасханы (чуашча «мункун») чүпрәлеләр «*йомырка бәйрәме»* дип билгеләп үтәләр. Бу көнне тавык йомыркаларын төрле төсләргә буяп пешерәләр яки пешкәч буйыйлар.

Балалар йорт саен тәрәзә каршында такмак әйтәләр: «кытыйк-кытыйк, бер йомырканы тотыйк-тотыйк; аягым, кулым җиңел булсын, тавыкларыгыз күп булсын, йәренгә (*киләсе елга*) тагын булсын» һ. б. Такмаклау хуҗалар йомырка чыгарып биргәнче дәвам итә. Әгәр дә хуҗалар чыкмаса, аларга карата каргау сүзләре дә әйтелергә мөмкин: «…артыгызда күлегез, шунда төшеп үлегез...». Дөрес, мондый сүзләр сирәк ишетелә, чөнки балаларга нәрсә булса да бирелә иде.

Бу бәйрәмдә сынамыш та бар: иртән кем беренче булып өйгә керә? «Авыр» яки «җиңел» аяклымы? «Авыр» аяклы булса, имеш,

кош-корт начар үрчи, йомырка салмыйлар һ. б. Шуңа күрә кайчак иртән хуҗалар үзләре үк урамга чыгып, яңадан өйгә керәләр яки инде аягы «җиңел» саналган күрше-күләнне чакыралар.

Чүпрәле төбәгендә ел фасылы белән бәйләнгән бәйрәм дә бар, ул **«унбишенче май»** (иске календарь буенча санала) бәйрәме дип атала. Әлеге бәйрәм яңа календарь белән 28 майга туры килә. Бу вакытта табигать яшәреп чәчәккә күмелә. Халыкта җырлана торган җыр да шуны раслый:

Алмагачым чәчәк ата
Майның унбишләрендә,
Былбыл булып, гөлгә кунып
Керәсең төшләремә.

Чүпрәле төбәгендә алмагачлар тик май ахырларына таба гына ак чәчәккә күмелә. Бу көнне яшьләр, хәтта урта яшьтәгеләр дә урманга баралар. Мәсәлән, Иске Чүпрәле халкы «Чокалы» урманына бара. Шунда ук Иске һәм Яңа Чокалы, Чуваш Чүпрәлесе, Кыймалу (Хайбулдино), Кушкуак, Татар һәм Чуваш Бизнәсе авыллары кешеләре дә җыела. Җыр, бию, уен-көлке яңгырый, барысы да чәчәк җыя, күбесенчә ландыш һәм тумарбаш (купальница азиатская), дөрес, кайсыбер елларда әле чәчәкләр ачылмаган да булырга мөмкин.

Шланга авылы кешеләре бу көнне күршеләрендәге Чуаштан урманына, ә Иске Кәкерле авылы халкы Татар Төкесе авылы белән ике арада урнашкан Атламыш дип аталган куаклыкка баралар. Әбикарчыклар да елга буйларыннан, куаклык арасыннан үлән җыялар, аннары аларны, киптереп, дару урынына кулланалар.

* * *

Безнең халык борын-борыннан игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән. Төбәк халкы арыш, бодай, борай, борчак, ясмык, солы, тары иккән. Тарыны әле илленче елларда йорт тирәсендәге бакчаларга да чәчтеләр. Яшелчәләрдән кәбестә, суган, кишер, кабак, кыяр, хәтта карбыз белән кавын үстергән хуҗалыклар да булды. Помидорны Чүпрәле якларында 1950 нче елларда үстерә башладылар.

Бакчаларда алманың төрле сортларын, карлыган, кура җиләге, крыжовник үстерделәр. Үткән гасырның 40 нчы елларындагы суыкларда агачлар туңганнан соң, шуның өстенә җимеш агачлары

өчен салым да түләргә туры килгәнгә күрә, алмагач үстерүче хуҗалыклар саны азая. Мәсәлән, Иске Чүпрәледә алмагачны Сафиулла бабай, Закир бабай, Абделләтиф бабай, Абделкәбир бабай һәм тагын берничә йортта гына үстерделәр.

Чүпрәле якларының бер үзенчәлеге – авылларда һөнәр ияләренең күп һәм һәр авылда төрле булуы. Мәсәлән, Иске Чокалы авылы кешеләре эретеп ябыштыру һөнәрен яхшы белгәннәр. Алар үзләренең эш коралларын күтәреп, авылдан авылга йөреп, хәтта Самара өлкәсенә кадәр барып җитә торган булганнар, искергән, тишелгән җиз комганнар, самоварларны эретеп ябыштырып төзәткәннәр, шуның өчен бераз акча яки иген, бәрәңге юнәткәннәр.

Иске Кәкерле авылы үзенең такта яручылары белән дан тотты. Бу эшне ир-ат кына түгел, хатын-кыз да оста башкарды. Алар үзләренең махсус пычкылары белән Рәсәйнең бик ерак төбәкләренә кадәр барып җиткәннәр. Чуаш урманнарыннан нарат агачлары алып кайтып аны ярганнар һәм базарга сатарга чыгарганнар. Алар тактаны шундый нечкә итеп ярганнар, хәтта базарга алып чыкканда таралмасын дип башсыз кадаклар белән кадаклап та куйганнар. Шуңа да Иске Кәкерле халкында «потлап алабыз, кадаклап сатабыз» дигән әйтем сакланып калган. Туры мәгънәсендә куллансаң, бу әйтем 16 кило (бер пот) алып 400 граммлап (*кадак*) бүлеп сатуны аңлатырга тиеш, ләкин чынында ул тактаны кадак белән кадаклап сатуны аңлата. Соңрак әлеге авыл кешеләре, чит җирләргә китеп, балта эшләрен дә башкарып йөрделәр, чөнки бу авыл зур, халкы күп булып, колхозда ир-атка эш булмый иде. Дөрес, язгы кыр эшләре һәм урак вакытында алар, туган якларга кайтып, колхоз эшендә дә катнаштылар.

Яңа Кәкерле авылында мич һәм морҗа чыгарыр өчен яндырылмаган кирпеч ясадылар, моның өчен елга яры буендагы махсус балчыктан файдаландылар. Алар кирпечне хәтта базарга да алып чыкмадылар, чөнки кирәк кешеләр үзләре үк килеп ала иделәр.

Задур авылыннан базарларга мич, морҗа, йорт стеналарын агарта торган акшар алып килделәр. Сатучылар бу акшарны йомшак чагында кабартма зурлыгында ясап киптерәләр, ә инде сатып алган кешеләр аны ваклап, суда изерәтеп файдаландылар.

Шланга авылында әле 1960 нчы елларда да тәгәрмәч, чана, арба, күчәр, дуга, мичкә һәм агачтан башка хуҗалык кирәк-яраклары ясау комбинаты эшләп килде.

Болардан башка, кайбер авылларда юкәдән мунчала төшерү, чабата ясау (тугу), бау ишү эше киң таралган иде, ә Чуваш Чүпрәлесе кешеләре яндырылган балчыктан чүлмәк ясап сатты. Ул заманнарда һәр гаиләдә агачтан ясаган савыт-саба, йорт кирәк-яраклары күп була иде: табак, кашык, чүмеч, туку станы, киле, кисап, гөбе, май һәм бал савытлары (тәпән), күәс чиләге (куашна), тарак, йон эрләү җайланмалары (кензәлә) һ. б.

Чүпрәле төбәге шулай ук мич чыгаручылары белән дә атаклы иде. Район үзәгендә пекарнядагы мичләрне әнинең этисе Кәрим бабай чыгарды, төзәтте. Ул мичләр зур булып, гөмбәзле иделәр. Бервакыт, Кәрим бабай авырып киткәч, бер мичләрендә ипи пешерә алмый тордылар, чөнки якын-тирәдә аны төзәтә белүче кеше табылмады.

Чүпрәледә элек заманнарда авыллар зур, халык күп булганлыктан, һәммәсенә дә эш җитмәгән. Бу үз чиратында кешеләрнең чит җирләргә эш эзләп китүенә сәбәп була. 1910 елда әлеге төбәктән барлыгы 1152 кеше шахтер булып эшләгән. Моңардан башка 1620 кеше «кара эшче», 324 фабрика-завод, 159 – урман хуҗалыгы, 10 – алтын приискасы эшчеләре, 37 кеше диңгез матрослары булып хезмәт иткәннәр.

Район халкының тормышында элекке заманнарда базарлар зур роль уйнадылар. Төп базарлар булып Уби, Иске Чокалы, Иске Чүпрәле, Матак авылындагылар саналды, алар һәркайсы билгеле бер көндә генә уза иде. Мәсәлән, якшәмбе көнне Уби базары булып, аңа күрше Ульян өлкәсе һәм Чуашстаннан да байтак кеше җыела, алар куна киләләр иде. Базарларда хуҗалык кирәк-яраклары, төзү материаллары, шул исәптән такта, бүрәнә, мүк, кадак һәм тимерчелектә ясалган башка әйберләр, атланмай, яшелчә һ. б. сатыла иде. Базар кешеләрнең, дус-ишләрнең очрашып сөйләшү урыны да булган. Кайсыбер кешеләр базарны бер әйләнеп кайтуны гына да кирәкле эш итеп санаганнар. Сатучылар янына таныш-белешләре җыелып, сатулашырга ярдәм иткәннәр, үзләрен чит кеше итеп күрсәтә торган булганнар.

* * *

Балачак уеннары – туган як хатирәсенең иң җылы катламнары. Иң элек кечкенә балаларны уйнату мизгелләрен искә төшерик.

Баланың кулын үз кулыңа аласың да баш бармактан уенны башлыйсың. Баш бармакны тотып аңа сорау биргән буласың:

«Әйдә, бал ашыйбыз», икенче бармакка күчеп аңардан «акча юк» дип әйттерәбез. Шуннан урта бармак әйтеп куя: «табарбыз әле». Инде исемсез (атсыз) бармак шик белдерә: «Табалмасак, ни эшләрбез?» Кечкенә бармакның җавабы әзер: «Ашарбыз да качарбыз!» Шуннан соң, бармаклар белән йомшак кына итеп, баланың корсагыннан сыйпыйсың. Бала ләззәтләнеп көлә һәм «тагын уйныйк» дип сорый. Бу уенны ул дистәләрчә тапкыр кабатларга сораячак.

Шуңа ук охшашлы икенче уен бар. Баланың кулын учыңа алып баш бармак белән сөйләшә башлап, һәр бармакны тотып чыгып түбәндәге сүзләрне әйтәсең: «Баш бармак – балан үрдәк – серми сермәк – терми-термәк», ә инде кечкенә бармактан соң «кети-кети», – дип баланың тәненә йомшак кына массаж ясыйсың, ул бу вакытта да рәхәтләнеп көлеп уенны күп тапкырлар кабатлауны таләп итә.

Бала бераз үсә башлагач «Чүлмәк сату» уенын оештыралар. Баланы аркага асып гаиләдәге берәү янына киләсең дә: «Чүлмәк сатам, алмыйсыңмы?» – дип сорау бирәсең. Ул, үз чиратында, баланың арт ягыннан сыйпап карый да: «Юк, алмыйм, чөнки чүлмәгеңнең төбе тишек», – дип җавап бирә. Уен барышында өйдә булган барлык кешегә шул ук сорау белән берничәшәр кабат мөрәҗәгать итәргә туры килә, чөнки бу турыда бала үзе сорый.

Яз җитеп, җир кардан ачыла башлагач, балалар шунда уенга чыгалар. Иң яраткан уеннарның берсе «Актирәк». Балалар ике төркемгә аерылып, кулга-кул тотынышып бер-берсенә каршы басалар. Шуннан беренче рәттән сорау бирелә: «Актирәк!» Икенче рәт шулай ук сорау белән җавап кайтара: «Сезгә кем кирәк?» Беренче рәттәгеләр каршы яктагылардан берсенең исемен атыйлар. Исеме аталган малай яки кыз, каршы якка йөгереп барып, тоташкан ике кулны өзеп үтәргә тиеш, шул очракта ул ике уенчының берсен үз ягына алып кайта, ә инде өзә алмаса үзе шунда «тоткында» кала. Уен кайсы да булса бер рәттә уенчылар беткәнче дәвам итә. Рәтләрнең берсендә бер генә уенчы калгач, ул колачларын җәеп арты белән каршы рәткә бара һәм кулына туры килгән уенчыны алып кайта, ә инде тота алмаса, уен тәмам була.

Балаларның иң яраткан уеннарыннан берсе таганда (*әлемцәлек*) атыну. Бу уен өчен күп чыгым да кирәкми, бауны ботак яки аркылы агачка бәйлиләр, утырырга йомшак булсын өчен бау өстенә берәр төрле кием-салым җәяләр дә, сәгатьләр буе тибрәнәләр. Бер үк вакытта такмаклыйлар да: «Әлемчәлек такталык, әби бирде бер ба-

лык, аны ашадым, кикердем, зәмәт (*койма*) аша сикердем», соңгы сүзләрне әйткәндә, балалар көч куеп тагын да ныграк атына башлыйлар.

Кыш көннәрендә иске иләкнең аскы ягын бау белән челтәр кебек чорнап, аңа сыер тизәге сылап туңдыралар, соңыннан су сибәләр. Су тигез булып каткач «*ләдән»* (ледянка) килеп чыга. Аңа утырып таудан ерак араларга кадәр шуып китеп була. «*Дәңгәл»* дип аталган шугак тактадан ясала һәм аның аскы өлешенә шулай ук су туңдырыла. Өске ягында урындык кебек җайланмасы да була. Инде бер әйбере дә булмаган бала-чага, кемнәрнеңдер зур чанасын алып чыгып, шуңа төялеп шуа.

Кыш һәм җәй көннәрендә *«мәрә»* уены оештырыла иде. Бу уен хәзерге туплы хоккейны хәтерләтә, тик малайларның тимераяклары һәм капкалар булмый. Уйнар өчен урманнан яки бүтән җирдән очы бөгелгән агач таягы (чукмар) кисеп алып кайтыла һәм «мәрә» исемле агач шакмак алына (ул вакытларда резина туплар да юк иде әле). Уен барышында бер команда шушы «мәрәне» каршы якның чигенә җиткерергә тиеш, шуның буенча исәп алып барыла. Кыш көне бу уен гадәттә елга яки буадагы боз өстендә була.

Кызлар да, малайлар да уйный торган *«чиж»* дигән уенны да искә алмый булмый. Бу уен өчен дүрт кырлы, «чиж» дип аталган, шакмак алына. Аның ике башы очлы, ә ян-якларына саннар уеп куелган була, бер ягына «х» билгесе куела. Бу шакмак җиргә сызылган квадратка урнаштырыла һәм кечкенә агач көрәкчек ярдәмендә сугып чыгарыла. Икенче уенчы шушы шакмакны квадратка кертергә тиеш. Әгәр шакмак квадратка керми калса, квадратның өстә калган ягындагы сан исәбенчә тагын да ераккарак сугып җибәрелә. Уенның соңында квадрат янындагы уенчы, көрәкчеге белән болгап, «чиж»ны квадратка керттермәскә тырыша. Бу *«майлау»* дип атала. «Х» билгесе куелган ягы белән төшкән очракта уен туктатыла, уенны башлап җибәрүче җиңелгән дип санала һәм инде икенче уенчы аны дәвам итә.

*«Кл'ук»* дигән уенны да искә төшереп алыйк. Уен өчен 50–60 см озынлыктагы нечкә казык алына. Аны җиргә кагып кертәләр дә, өске ягына «г» хәрефенә охшаган шакмак кигезеп куялар. Уенчылар 10 метр чамасыераклыктагы сызык яныннан чиратлашып таяк атып, казык башындагы шакмакны бәреп төшерергә тиешләр. Казык янында торган уенчы шакмакны алып килеп яңадан беркетеп,

«кл'ук» дип кычкырганчы, шакмакны бәреп төшерүчесе йөгереп барып үзенең таягын алып, сызык янына кайтып өлгерергә тиеш. Өлгерә алмаса, тукталган җирдә басып кала. Шул ук рәвештә калган уенчылар да үзләрен сынап карыйлар. Ерактагылар шакмакны бәреп төшерә алмасалар, уенны якынрак сызыктагылар дәвам итә. Инде беркем дә казыкка тидерә алмаса, казык янындагы уенчы берничә сикереш ясап, якындарак яткан таякка шакмакны тидерергә тиеш. Шуннан соң казык янына әлеге таяк хуҗасы баса.

Көннәр җылыта башлагач, малайлар *«ашык»* уенына күчәләр. Бу уен өчен сарыкның кузна сөяге файдаланыла. Иске Чүпрәледә бу уен мәчет бинасы янында оеша иде. Уен барышында үз ашыгың белән стенага атып, икенче уенчылар ашыгы янына мөмкин кадәр якынрак төшерергә кирәк, шуннан карышлап (сөям белән) үлчәп ике ашыкны тоташтыра алсаң, көндәшләреңнең ашыгы синеке була. Ашык дөрес ятсын өчен кайберәүләр хәйлә юлына да басалар, моның өчен ашыкның аскы ягына тишек тишеп кургаш эретеп салалар, шуннан ул, ерак тәгәрәп китмичә, кирәк урынга төшә.

«Ашык» уенын өйдә дә уйнап була. Моның өчен аларны учка алып буташтырасың да идәнгә сибәсең һәм ашыкның ничек ятуына карап отыш билгеләнә. Ашыклар дүрт позициядә урнашалар, ас, өс һәм ике яны, аларның һәрберсенең үз исеме була: «бөк», «цек», «әлце», кызганыч, тагын бер атамасы исемдә калмаган. Болгар шәһәрендәге тарихи-археологик музей күргәзмәсендә булганда борынгы заманнардан калган ашыкларны күрергә туры килде. Алар мине яңадан бала чакларыма алып кайткандай булдылар.

## «МӘЗӘК ҖЫРЛАРЫ» ТУГАН ЯКТА

*Айсылу Садыйкова*

Җәйнең матур ун көнен без, Институтның берничә фольклорчысы, гадәттәгечә, комплексلы экспедициядә үткәрдек, Татарстанның Чүпрәле районында булдык. Соңгы елларда экспедицияләр бик җанланып китте. Алар чит төбәкләргә дә (татар авылларына), Татарстанга да оештырыла. 2010 елда без Түбән Новгород авылларында булган идек. Чүпрәле татарларының ул як халкы белән тел уртаклыклары булгач, бәлки фольклоры да охшаштыр, дигән уйлар да бар иде. Мәсәлән, Сергач татарларында (Камка авылында) «Зимчәчәк» дигән борынгы матур йола җырларын язып алган идек. Әмма Чүпрәле якларында андый җырларны очратып булмады. Борынгы озын җырлар да юк инде. Хәер, алар башка якларда да онытылып бара диярлек. Ярый әле фольклор җыентыкларында саклана. Чүпрәле авылларында мөнәҗәтләре күп булуы куандырды, барлыгы 78 мөнәҗәт язып алдык. Алар арасында оригиналь әсәрләр дә, таныш булган йә китаплардан алынганнары да бар иде.

Беренче көннәрдә, бәетләр биредә юкка чыккан икән, дигән фикер туган иде. Борынгыдан ук килгән, безнең татар халык иҗатының «Бәетләр» томына кергән «Чынлы бәете» музейларда хәзер дә саклана саклануын, әмма борынгыдан килгән бәет язу традициясенең сүнүе, бетүе аяныч күренеш, әлбәттә. Ә менә Чүпрәле музеенда язучы, туган якларын өйрәнүче Рафаил әфәнде Сираҗи (Субаев) белән очраштык, аннан күп мәгълүмат алдык. Ул безгә бәетләр язылган берничә дәфтәр дә тапшырды. Аларны Иске Чокалы авылында яшәгән Айметдинов Рафагат иҗат иткән булган. Ул, үз авылында һәм башка авылларда 1980–1990 нчы елларда вафат булган, йә һәлак булган якташларына багышлап, 20 дән артык бәет язган. Язмалары арасында шигырьләре дә күп. Бәетләрнең эчтәлеге

традицион – фаҗигале хәлләр, әмма аларның төзелеше, структурасы оригиналь. Мәсәлән, Иске Чокалыда туган, 1992 елда 50 яшендә үлгән Зелалова Венерага багышланган бәете бар. Ул бәетче сүзе белән башлана, аннан бер бүлек итеп мәрхүмәнең үз сүзләре бирелгән. Биредә Венераның дөньяда чактагы тормышы, авыруы, уйланулары һәм җиргә иңдерелүе, исәннәрдән дога соравы, исән калганнарны юатуы, үгетләү мотивлары үзе исеменнән бәян ителгән.

...Күпме генә яшәсәң дә,
Бу якты дөнья кала.
Балаларым, еламагыз,
Нинди авыр булса да...

Шактый озын бу бүлектән соң «балаларының сүзләре» дигән бүлекчә бар:

Әнкәй, ни эшләдең соң син?
Сиңа, әнкәй, ни булды?
Үле хәбәрең ишеткәч,
Күзләребезгә яшь тулды...

Ананың үлеме балаларын тетрәндерә, аның бу дөньядан китүенә ышана да алмыйлар. Бу аналарга багышланган, мөнәҗәт дигән әсәрләргә дә хас. Әйтергә кирәк, бәетләрне мондый структура белән язу беренче тапкыр очрый. Аның балалар үлеменә багышланган бәетләрендә «ата-ана сүзе» дигән бүлекчә дә бар. Һичшиксез, Рафагат Айметдинов талантлы иҗатчы булган, үзенең күп кенә якташларының исемен халык иҗаты тарихына кертеп калдырган. Барлык бәетләре дә шушындый 3–4 өлештән тора. Бу исә бәет эчтәлекләренә төзеклек кертә, аның жанрының яңа формасын тудыра. Мондый әсәрләр – исән калганнарның әрнүле күңелен юата торган, нәсыйхәтчел әсәрләр. Иске Чокалы авылында 1988 елда 14 яшьләрендә өч кыз батып үлә, шушы ук авылда 1985 елда Халюков Дамир машинасында янып үлә, 1992 елда Кавказда самолет шартлап, анда һәлак булган 34 солдат арасында Мунчәли егете Альфрит Камалов та була. Р. Айметдинов аларга да бәетләр багышлаган. Күренгәнчә, үлемнең сәбәпләре төрле, фаҗигаләр булып кына тора. Бәетләр милләтнең бер кешесенең үлүен, югалуын да хәбәр итүче жанр. Бәетче үзе дә андый хәлләрне авыр кабул итә һәм, күңеле тулып, бу хакта болай яза:

Барлык бәет куплетлары йөз җидедән артык булган.
Тагын бераз язар идем, күзләремә яшь тулган.

Минем соң сүзем сиңа – каберендә тыныч ят.
Бу бәетне чыгаручы Айметдинов Рафагат.

(1993 ел, 3 ноябрь)

Бу авторның бәетләрен аерым китап итеп бастырып чыгару мөмкинлеге туса, барлык вафат булганнар турында истәлек-ядкяр булыр иде. Безнең бу җыентыкка аларның барысын да урнаштыру мөмкин түгел.

Башка бәетчеләрдән дә әсәрләр язып алдык, алар искечә, традицион рәвештә язылган. Андыйларда мәрхүмнәр вафат булуы сәбәпләрен үз исеменәреннән сөйли, булган очракта – гаепле кешеләрне атыйлар, исән калганнарны юаталар. Бу мотивлар, борынгы бәетләрдән башлап, бүгенге көндә дә кабатлана. Шундый рухтагы әсәрләр Г. А. Низамовадан (3 бәет), Р. Н. Шиһабетдиновадан *(Иске Задур)* (2 бәет), З. Салиховадан *(Татар Бизнәсе)* («Айгөл бәете»), Җ. Яфизовадан *(Каракитә)* (Рафикъ, әтисе, әнисе бәетләре), Ф. Ә. Измайловадан *(Чынлы)* («Наилә бәете») һ. б. дан да язып алынды. Аларда да шулай ук хисләрне белдерү, исәннәрне юату тасвирлана.

Яңа Чокалы авылында «Ана бәете» дигән күләмле поэма (10 бит) сөйләделәр. Аны мөнәҗәт дияргә дә була. Чөнки ул гыйбрәтле әсәр. Ананы балалары, кадерсезләп, берәр ай асрап, берсеннән икенчесенә йөртәләр. Ниһаять, аны олы җанлы ят гаилә, кызганып, үзенә сыендыра. Балалар оятлы була. Бу әсәрне Н. В. Гафурова, Г. Ш. Идиятуллина, Ә. К. Хәлиуллова тапшырды. Ул бик нәсыйхәтле итеп, матур тел белән язылган.

Инде әйтеп үтелгәнчә, Чүпрәле районы авылларында күпсанлы мөнәҗәтләр язып алу насыйп булды. Бу яклар борынгыдан мәчет-мәдрәсәле, белемле, дини булган; китаби традицияләр яшәгән. Мөнәҗәтләр берничә төркемгә бүленә. Алар аналарга һәм еш кына балаларга, туган яктан аерылуга багышланган. Дини-фәлсәфи әсәрләр дә күпләп язылган. Бу темалар мәңгелек. Аналарны югалту, аларны юксыну – йөрәктән бер дә китми торган хәсрәт. Мунчәли авылында Ф. А. Мурашевадан 4 мөнәҗәт язып алдык. Берсе бик мөкәммәл дини әсәр, «Дөнья куам» дип башлана. Үлемнән соң теге дөньяда булачак хәлләрне тасвирлый, күп кенә юллары ислам тарихына кергән шәхесләрне яд итә, искә ала:

...Җиһанны итте мөнәвәр
Кичә көндез Шәмсекамәр.

Дингә куәт биргән Гомәр
Дусларындин кыйл, йә Рабби...

Әсәрдә сүз пәйгамбәр Мөхәммәд белән аның дин юлында йөргән яраннары (соңрак хәлифәләр) Гомәр, Госман, Бәкер, Гали турында бара. Пәйгамбәрнең хатыннары Хәдичә, Гайшә, кызы Фатыйма мөселманнарның аналары дип атала. Мунчәли авылында ук С. Т. Измайловадан «Яна бәгърем, көя бәгърем» дип башланган мөнәҗәт язып алдык, ул дини-фәлсәфи әсәр.

И, Ходаем, Син беләсең
Минем хәлнең авырлыгын.
Бер Ходаем, Үзең кылгыл
Пәйгамбәрләр сабырлыгын...

Биредә язмыштан зарлану мотивлары булса да, Аллаһ колы моны тәкъдир дип кабул итә һәм Коръән мактаган сыйфатны – сабырлыкны сорый. Татар Төкесе авылында Ф. К. Аббазовадан «Менә шундый заман җитәр» дигән әсәр яздык. Ул китапларда чыккан әсәрләргә бик охшаш булса да, үзгәрәк юллары да аз түгел. Биредә заман турындагы фәлсәфи уйланулар, борчылулар урын алган. Моның аерым вариантлары башка авылларда да бар.

...Бала-чага барыр алдан,
Хаклык бетәр, булыр ялган.
Гавам халкы бар да азган –
Менә шундый заман җитәр...

Аның икенче мөнәҗәте «Раббым кем? дип сораганда» дип башлана. Сүз дөньяның вакытлы булуы, әҗәл, мәхшәр турында бара. Сорау алганда дөрес җавап бирергә өндәү: динем – ислам, пәйгамбәрем – Рәсүлулла, дип әйтү тиешле. Болар ислам даирәсенә кергән халыкларга хас.

Каракитә авылында Җ. В. Яфисовадан (1963) берничә мөнәҗәт язып алдык. Алар арасындагы «Муса» мөнәҗәте традицион рухта иҗат ителгән, ул китапларга кергән, радио-телевизорда яңгырап торды. Без аны районның 5 авылында очраттык.

«Мәеткә укый торган мөнәҗәт» дигән әсәрнең дә шушы автор иҗаты икәне сизелә, кайбер юллары электән дә билгеле:

Алдым комган кулыма,
Киттем Аллаһ юлына.
Аллаһ юлы юл булсын,
Әти-әниемнең кабере нур булсын.

«Әниемне сагынам» дигән мөнәҗәтнең 4 строфасы халыкта, китапларда бар, әмма Җ. В. Яфисова аны үз иҗаты белән дә дәвам иткән:

...Атлар бара атлап-атлап,
Алма чәчәген таптап.
И, әтием, әнием! Яныгызга барыр идем.
Кара туфрак тора каплап.
Тәрәз ачып җимнәр сиптем,
Ашагыз, кошкайларым.
Мин моңаймый, кем моңайсын
Әнкәем юк киңәшкә.

Шулай ук Мунчәли авылында С. Т. Измайловадан аналарга багышланган ике мөнәҗәт («Ана күңеле», «Сөйлим әле, балам») язып алдык. Дөнья турында «Яна бәгърем» дигән фәлсәфи уйланулар тулы әсәр дә игътибарга лаек.

Яна бәгърем, көя бәгърем
Явыз дөнья учагында.
Үтте гомерем, сүнде гомерем
Кара бәхет кочагында...

Шул ук авылда яшәүче Г. Х. Измайлованың да ананың балага багышлаган мөнәҗәте бар. Ул васыять традицияләрен дәвам итә.

Иске Кәкерле авылында Х. Т. Габдрахмановадан «Лә иләһә иллә Аллаһ» дигән, тәһлилгә багышланган әсәр булуын белдек. Бу темага татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә иҗат ителгән әсәрләр керә. Аларга Аллаһны бөекләү, «Аллаһтан башка илаһ юк», дип кабатлау хас. Мөхәммәд өммәте булуга шөкер итү, аның юлында йөрү турында теләкләр әйтелә. Әҗәл, җан чыгу, ярдәм сорау кебек дини мотивлар да урын ала.

Мөнәҗәтләр күпләп язып алынды, димәк, традицияләр яши, дәвам итә. Бик күп кыска җырларга, такмакларга да юлыктык. Мәсәлән, кайбер авылларда аулак өйне «мәзәк утыру» дип тә атыйлар икән. Анда башкарылган җырлар «мәзәк җырлары» дип атала, алар бик күп санлы.

Чүпрәле районы – мәдәнияткә зур шәхесләр биргән як: Һади Атласи, Зәки Нури, Шәрәф Мөдәррис, Рафаил Ильясов, Сәйфихан Нәфиев, Нурмөхәммәт Хисамов һ.б. бик күпләр шушы җирләрдә туып үскән. Һәр авыл турында диярлек тарихлар язылып, китап булып чыккан. Халык арасында сөйләм культурасы саклана. Авыл

тарихлары, мифологик сөйләкләр, йолалар да шактый язып алынды. Димәк, иҗат җимешләре һаман мул, алар мәдәниятебезне, әдәбиятыбызны сугара, яңарта.

*Дөнья куам*

Һаман дөнья куа нәфсем,
Килеп җитте вакыт дәфен.
Менеп мәкам[1], киеп кәфен
Кигәннәрдән кыйл, йа Раббем.

Булыр ул көн йөрәк кәбап,
Кигәнең ак бүздин сарынып.
Җитмеш сөальгә ансат җавап
Кыйлганнардан кыйл, йа Раббем.

Мөнкир – Нәнкир кергәч,
Раббең кем дигәч, инсан
Раббем Аллаһе, динем ислам
Дигәннәрдән кыйл, йа Раббем.

Исрафилгә булыр фәрман,
Барча җаннар чыгар сурдин.
Гамәл дәфтәрләрен уңнан
Биргәннәрдин кыйл, йа Раббем.

Мөэминнәр сыйрат кичәр,
Изгеләр бер кош тик очар.
Кәүсәр шәрабеңне эчәр
Колларыңнан кыйл, йа Раббем.

Пәйгамбәрнең чаһарярлары
Алар исламның вәлиләре.
Сиддыйк, Гомәр, Осман, Али
Дусларыңдин кыйл, йа Раббем.

Әүвәл китерде иман тәхкыйк[2],
Мигъраҗны[3] әйләде тәсбих.
Исме Абүбәкер Сиддыйк
Дусларындин кыйл, йа Раббем.

Җиһанны итте Мөнәввәр,
Кичә, көндез Шәмсекамәр.
Дингә куәт биргән Гомәр
Дусларындин кыйл, йа Раббем.

Хөкем җитте Шәрәф Араб
Динне кыйлды нурга гарык.
Безне ул Гомәрем Фарук
Дусларындин кыйл, йа Раббем.

Әүвәл итте Җәмил Коръән,
Коръән юлында бирде җан.
Ике нур хуҗасы Осман
Дусларындин кыйл, йа Раббем.

Яман гамәлләрдән ерак Али
Аның өчен булды Вәли.
Хода арысланы Али
Дусларындин кыйл, йа Раббем.

Фатыйма ана угыллары,
Ике җиһан былбыллары.
Шәфәгатен бир, йа Раббем.

Хәдичә, Айшә, Фатыйма –
Бу өчесе безгә ана.
Кыямәт көн шәфәгатен
Насыйп әйлә син, йа Раббем.

Аклы ситса күлмәгеңне
Киясеңне белмәдеңме?
Караңгы гүр, җир астына
Керәсеңне белмәдеңме?

*Мунчәли авылында Моратова*
*Фирдәүсә Арифулла кызыннан (1955 елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

---

[1] Мәкам – урын.
[2] Тәхкыйк – үтәү, өйрәнү.
[3] Мигъраҗ – күккә ашу (пәйгамбәрнең ашуы).

*Яна бәгърем*

Яна бәгърем, көя бәгърем
Явыз дөнья учагында.
Үтте гомерем, сүнде гомерем
Кара бәхет кочагында.

Ходаемның колы идем,
Атамның былбылы идем.
Сайрар кошның теле идем,
Күрең, тәкъдир ниләр әйли.

Без бәндәләр генә түгел,
Пәйгамбәрләр дә хәсрәт күргән.
Үзе сөйгән бәндәләргә
Ходай хәсрәтләр биргән.

И Ходаем, син беләсең,
Минем хәлнең авырлыгын.
Бер Ходаем, үзең кылгыл
Пәйгамбәрләр сабырлыгын.

Хәсрәт күргән бәндәләрнең
Төн йокылары кала.
Үзе сөйгән бәндәләргә
Ходай хәсрәтен сала.

Ник мине шат итмәдең,
Кайгы юлдашы иттең,
Кайгы диңгезе чыгып торган
Кое янында мине яраттың?

Таңнар атса, көнем кайгы гына,
Кичләр җитсә, сагыш кына.
Нишләргә, дуслар, нишләргә
Хәсрәтләрнең ачы сагышына?

Тәкъдир яман, Ходай язган,
Ни сәбәптән китмидер?
Бәндә каршы торса да
Файда-чара итмидер.

Мәдрәсәләр почмагында,
Утлар яна учагында.
Көйде бәгърем, сүнде җаным
Кара бәхет кочагында.

Йа Ходаем, ни өчендер
Кешеләрне төрле-төрледән
кыйлдың?
Нилектән соң мине бәхет
түбәнлегеннән дә
Түбәнрәк кыйлдың?

*Мунчәли авылында Измайлова*
*Солтания Таһир кызыннан (1930 елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

*Раббең кем?*

Раббең кем? дип сораганда
Раббем – Аллаһ, дисәк иде.
Пәйгамбәрең кем? дигәндә,
Рәсүлулла, дисәк иде.

Динең кайу дин? – дигәндә,
Динем ислам, дисәк иде.
Әй Раббем, теләгем шул:
Тел ачкычы бирсәң иде.

Догалар телимен сезгә, догалар,
Килегез безгә.
Җәүмел мәхшәр көннәрендә
Булсак иде бергә-бергә.

Үтте гомер гел зарланып,
Фани дөньяга алданып.
Телим дидар[1], телим җәннәт,
Ходаем, Сиңа барып.

---

[1] Дидар – Аллаһ йөзен күрү.

Фани[1] булган бу йортлардан
Китәбез бакый йортларга.
Тәнебезне харам әйлә
Кабердә булган кортларга.

Туба дигән яшел агач,
Ярадыр ул җәелеп яфрак.
Җавап бирү җиңел булыр,
Ходай рәхмәтенә сыйсак.

Әҗәл хали[2] булыр, китәр җан тәндин,
Китәр хәл куәте, йотмагыл
Син хәсрәт утын, фанидыр
Бу дөнья йорты.

Ходаем, рәхмәтең белән,
Рәхмәтеңне кыйл Син безгә.
Газиз башлар, шәриф тәннәр
Керәсе бар ялгыз гүргә.

*Татар Төкесе авылында Аббазова*
*Факия Хәбир кызыннан (1928 елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

*Мәеткә укый торган мөнәҗәт*

Алдым комган кулыма,
Киттем Аллаһ юлына.
Аллаһ юлы юл булсын,
Әти-әниемнең кабере нур булсын.

Сузып салырлар караватка,
Кереп үлчәү алырлар ла,
И балаларым, туганнарым,
Мине елап озатып калырлар.

Самаварның краннарын
Авыр ла борулары.
Әти-әнисез яшәп лә
Авыр ла торулары.

Атлар бара атлап-атлап,
Алма чәчәген таптап.
И әтием, әнием, яныгызга барыр идем
Кара туфрак тора каплап.

15 ел булганчы ла,
Кайда гына булмадым.
Кайларда гына йөрсәм дә,
Мин әниемне таба алмадым.

Тәрәз ачып җимнәр сиптем,
Ашагыз, кошкайларым.
Мин моңаймый кем моңайсын
Әнкәем (әткәем) юк киңәшкә.

*Түбән Каракитә авылында Яфисова*
*Җәүһәрия Вагыйзулла кызыннан (1963 елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

*Әниемне сагынам*

И анам, назлы анам, моңлы анам!
Шул каберне күрсә күзем, өзелә үзәгем, яна.
Йөзең нурлы, күңелең моңлы, кулың йомшак, әнкәем,
Бер тавыш бир гүр эченнән «Бәбкәем», – дип әнкәем.

---

[1] Фани – үтеп, узып китә торган.
[2] Хали – ирекле, иркендә.

Һич тә онытмыйм сөйгәнеңне,
Үпкәнеңне шатланып.
«Балам бәгърем», – дия идең
Иркәләп, кулыңа алып.

И ачыл, кабер, ачыл,
Әнкәемне мин күрим.
Мин дә керим әнием янына.
Мин дә дөньяны сөймим.

«Бер җирем авыртмый», – дидең,
Белгертмәдең чирләреңне.
Яме сүнде бүлмәләрнең,
Бушлык басты күңелне.

Тыялмадым яшьләремне,
Тәгәрәшеп түгелде,
Һавалар да җитми кебек
Өйдә әнисез калгач.

Синсез минем җәйләрем дә,
Яфраксыз, нурсыз агач.
Нурсызланды якты дөньям
Юк кояшның җылысы.
Килә бары бертуктаусыз
Үксеп-үксеп елыйсы.

Синең белән яшәгән көн
Яшәмәгән дә кебек,
Каршы ала идең мине, әнием,
Карашың белән үбеп.

*Түбән Каракитә авылында Яфисова*
*Җәүһәрия Вагыйзулла кызыннан (1963 елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

*Ана күңеле*

Ана булу изгелек ул,
Дөньяда олы дәрәҗә ана кешегә.
Һәрбер баласының бәхетенә
Ана кеше ача тәрәзә.

Газиз аналарны ялгыз итеп,
Үзләренә юл эзлиләр.
Бала өчен ана утка керә,
Ә балалар шуны белмиләр.

Ни генә теләк теләми ул
Үз баласы – кызы, улына.
Бер йокламый төнне аша кичкән
Бишек бавын тотып кулына.

Авыр чорда бала үстергәндә,
Ни күрмәгән ана йөрәге?
Мәрхәмәтле булыгыз аналарга
Җирдә ятмас ана теләге.

Ялгызлыкны тоеп яшәмәсен,
Түрдә булсын газиз аналар.
Тешләр төшеп, чәчләр агарса да,
Ана өчен сез бит балалар.

Никадәрле авырлыклар
Күрсә дә ул ана кеше
Баласына каргыш каргамас.
Ата-анасын ялгыз калдырып китү
Алла каршысында ярамас.

Балаларым, бәгырьләрем,
Белдегез лә кадеремне.
Мин үлгәч тә онытмагыз
Зирәтләрдә каберемне.

Балаларым, сезгә теләгем шул:
Чәчәк атсын тормыш юлыгыз.
Айны бүләк итәр идем,
Сузылсак та, җитмәс кулыбыз.

*Мунчәли авылында Измайлова*
*Солтания Таһир кызыннан (1930 елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

### *Менә шундый заман җитәр*

Укулары нәүбәт белән,
Хезмәтләре сәгать белән,
Ризыклары үлчәү белән
Менә шундый заман җитәр.

Бала-чага барыр алдан,
Хаклык бетәр, булыр ялган,
Гавам халкы бар да азган,
Менә шундый заман җитәр.

Ата-анага гыйззәт бетәр,
Балалардан шәфкать китәр,
Туганнардан рәхим бетәр
Менә шундый заман җитәр.

Ирләрендә гайрәт бетәр,
Хатын-кыздан хәя китәр,
Балалардин шәфкать бетәр,
Менә шундый заман җитәр.

Хатын-кыздан өмет бетәр,
Хәмер эчәр, зина кылыр,
Өметләре зәгыйфь булыр,
Менә шундый заман җитәр.

Зур-зур биналар салырлар,
Шунда ашыгып барырлар,
Эчендә гауга корырлар
Менә шундый заман җитәр.

*Татар Төкесе авылында Аббазова*
*Факия Хәбир кызыннан (1928 елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

### *Лә иләһә иллә Аллаһ*

«Лә иләһә иллә Аллаһу»
Әйтми торма һәр заман.
Лә иләһә иллә Аллаһны
Телләрдин язсак, бик яман.

Лә иләһә иллә Аллаһу –
Гарше көрсинең баскычы.
Лә иләһә иллә Аллаһу –
Сигез җәннәтнең ачкычы.

Кыямәт көндә ике юлдыр,
Бастырма безне сулына.
Илаһым, бастырсаң иде
Рәсүлебезнең юлына.

Ишегалдымда алмагач
Чәчәк атадыр яз булгач.
Әлхәмделилләһи шөкер
Мөхәммәд өммәте булгач.
Шул дәүләт җитмиме безгә
Мөхәммәд өммәте булгач?

Ишегалдым яшел чирәм,
Күгәрчен төшә богдайга.
Кара гүргә илтеп куйгач,
Ни җавап бирим Ходайга?

Үлем, үлем дип әйтәбез,
Үлем тора яныбызда.
Әҗәл вакытлары җиткәч,
Алып калмый малыбыз да.

Юл өстендә печәнемне
Юлаучылар аты ашый.
Дөнья ачысы ачы түгел,
Җан чыгу газабы ачы.

Юл өстендә печәнемне
Һич беркем дә ала алмас.
Бу дөнья мәңгелек түгел,
Һәркем әҗәл татымый калмас.

*Иске Кәкерле авылында Габдрахманова*
*Хәдичә Таһир кызыннан (1938 елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

### *Истәлек дәфтәреннән*

Мәхәббәт ул булмый сагышсыз,
Шулай булган, шулай ул калыр.
Мәхәббәт – ул кысан күлмәктәй
Кию җиңел, салуы бик авыр.

Мәхәббәт – ул ике кеше бәхете,
Аның белән йөрәк шатлана.
Кеше үлә, кара гүргә керә,
Ә мәхәббәт һаман саклана.

Ялгыз каен җирдә үскән,
Мин бит ялгыз җирдә үсмәдем.
Матур, диеп карамагыз,
Матурлыкка дип төшмәдем.

Бу дөньяда беркемнең дә
Калмый икән гәүдәсе.
Калса калыр истәлеккә
Гәүдәсенең шәүләсе.

Өстәлләрдә пар машина
Көйләмичә җөйләми.
Карточкаларың килсә дә,
Телләре юк, сөйләми.

Сандугачлар басып сайрап,
Сындырган гөлләремне.
Сынган гөлләргә охшатам
Аерылган көннәремне.

Суга барам, су алам,
Су алам да кузгалам.
Әллә үзем аерылганга,
Аерылганны кызганам.

Аерылганда кулың birдең
Син миңа салкын гына.
Салкын кулың йөрәгемә
Тутырды ялкын гына.

Ай белән кояш бер генә,
Кояш сиксән мең генә.
Күрешербез, дип йөргән идек,
Күрешеп булмый тиз генә.

Ишек алдым салкын чишмә,
Суын эчеп туймадым.
Әйтер сүзем әйтә алмадым,
Күрешербез, дип уйладым.

Өзеп алма ашадым,
Кабыкларын ташладым.
Бергә чакны искә алып,
Үзең күреп сөйләшкәнче
Хатларым бара торсын.

Биек тауның башына
Чәчәк өзеп ташладым.
Өзелеп хатлар язмас идем
Сагындыра башладың.

Хатлар яздым мин сиңа,
Син дә язарсың миңа.
Шушы хатта ничә хәреф
Шул чаклы сәлам сиңа.

Биек тауларның башында
Бәйләнмәгән ат йөри.
Мин саргаеп үләр идем
Арабызда хат йөри.

Алсу алмалар төядем,
Тартыр микән атларым?
Үзем кебек ачык итеп
Сөйләр микән хатларым?

Сандугачлар очып китә
Таллары бөгелгәнгә.
Син дустыма хатлар язам
Үзәгем өзелгәнгә.

Бәгырькәем, хатлар язам,
Сандугач кагынганда.
Утка якма, суга салма
Укырсың сагынганда.

Түгәрәк күл уртасында
Битем юдым тирләгәч.
Бигрәк кыен була икән
Сагынганда килмәгәч.

Сандугачларны җибәрдем
Тыңларга сүзегезне.
Турыгызда сайрап кайткан,
Күрмәгән үзегезне.

Безнең тауда салкын чишмә
Гәрәбә эри торган.
Бер сандугач булса икән
Арада йөри торган.

И дускаем, хат язгансың,
Энҗе кебек тезгәнсең.
Энҗеләр кебек тезгәнсең,
Үзәгемне өзгәнсең.

Сандугачның мескенкәйнең
Сайрамаган көне юк.
Сәлам әйтеп җибәрергә
Сандугачның теле юк.

Бакчаларга кергәнем юк,
Гөлләр тигез үсәме?
Җил аркылы сәлам әйтәм,
Җилләр сезгә исәме?

Күгәрченнәр күктән төшә
Бергәләп гөрләшергә.
Яшь йөрәккәем талпына
Бер күреп сөйләшергә.

Ал тагалар, гөл тагалар
Алдан килгән атларга.
Күз керфекләрем талганчы
Карыйм сезнең якларга.

Күк күгәрчен гөрлидер
Гөлләр чәчәк атканда.
Сез дустымнан сәлам көтәм
Сызылып таңнар атканда.

Иркәм, иркәм, диеп,
Йөрисең янып-көеп.
Син иркәмнән хатлар көтәм
Көн дә саргаеп-көеп.

Гаҗәпләнеп карап тордым
Һавадагы болытка.
Мин сагынып хатлар яздым,
Син дә шулай онытма.

Ал тасмалар алдым әле
Чәчләремне үрергә.
Бу хат миннән бәхетле,
Бара сезне күрергә.

Сандугачлар сайрамаса
Ничек уяныр идем?
Сагынганда хатың килсә,
Укып юаныр идем.

Иртән торсам, кояш көтәм,
Кич булды исә, ай көтәм.
Кояш белән ай көткән күк,
Бәгърем, синнән хат көтәм.

Аклы ситса күлмәгемнең
Җиң очлары сәдәпле.
Син иркәмә хатлар язам
Якын күргән сәбәпле.

Алма бакчасына кереп
Хат язарга исәбем.
Хатка язып сүзләр бетмәс
Сау бул, алма кисәгем.

Зөя сулары бик тирән,
Карап күзләрем тала.
Хатка язып сүзләр бетми
Бик күп сүзләрем кала.

Гөлләрем шиңәр инде,
Сулар кем сибәр инде?
Сагынуымның хәлләрен
Хатларым сөйләр инде.

Карабодайның чәчәге
Кара булмый, ак була.
Ел тәүлеге унике ай,
Бик сагынган чак була.

Татлы йокым арасында
Уянамын калтырап.
Кай җирләрдә син йөрисең,
Тулган ай күк ялтырап.

Тау башына кояш төшкән
Җиләк булган җирләргә.
Алсу битем, миңа читен,
Син булмаган җирләрдә.

Казаннан Мәскәү ни чаклы
Әйләнәсе чәчәкле.
Күргәнемә күптән түгел,
Ник сагынам бу чаклы?

Бакчаларда йоклаганда
Җил алды юрганымны.
Коштан сорыйм, кош та белә
Ни хәлдә торганыңны.

Исле гөл исле була,
Яран гөл төсле була.
Сагынганда айга карыйм,
Гел синең төсле була.

Сандугачым, әйт үземә,
Кайсы талга кунасың?
Күзем йомсам, күз алдымда
Син торган күк буласың.

Аягыма сулар үтә
Сары сандал кисәм дә.
Кошлар сайрап сагындыра,
«Сагынмыймын» дисәм дә.

Килә-китә, килә-китә
Тәрәзәмә сандугач.
Син сабырмы? Син түзәрсең,
Мин нишләрмен сагынгач?

Тал бөдрәсе, тал бөдрәсе,
Тал бөдрәсе талларда.
Сандугачым, әйтеп сайра,
Сөйгән ярым кайларда?

Шәлем аклы, шәлем аклы,
Шәлем аклы шакмаклы.
Син дустыма бездән сәлам
Урам таулары чаклы.

Тәрәзә төбем гөл генә,
Исемлесе бер генә.
Сагынам сине, юксынам,
Исләремдә син генә.

Иртә торсам да исерәм,
Исле гөл исләренә.
Исле гөл исләре кебек
Төшәсең исләремә.

Хатлар язам өстәлдә,
Кара якты төшкәндә.
Бер минуты бер ел була
Син исемә төшкәндә.

Тау астында таллар бар,
Сандугачлар ияләшми.
Кулларымда карточкаң,
Телләре юк, сөйләшми.

Су буйлары бөдрә тал,
Башын кисеп суга сал.
Сагынганда бер җырларсың
Бу җырымны отып кал.

Ап-ак каен урман саен
Яфрак яра ел саен.
Сәгать саен, минут саен,
Күрәсем килә көн саен.

Агыйделне йөзеп чыктым,
Кулларыма гөл тотып.
Бер минут та тора алмыйм,
Син дустымны онытып.

Юл буенда кыяк үсә,
Аның берсе гөл кебек.
Бик сагынган чакларымда
Минутлары ел кебек.

Су буенда казлар уйный
Канатларын кагынып.
Ярты төннәрдә уянам
Син дустымны сагынып.

*Түбән Каракитә авылында Яфисова*
*Җәүһәрия Вагыйзулла кызыннан (1963 елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

## Бала туу йоласы

Бәбәй әбисе яшә идек, кендеген ул кисә. Аннары шылай мулла яшеп, исем куштыра идек инде. Баланың кендеген киптереп саклыйлар. Ул бернәрсәгә дә ярамый инде. Бәбине юындырганда суына берцәк кенә марганцовка салалар.

## Им-том. Ырымнар

**Күз тигәндә.** Тәрәз рамнарын, ишек бауларын җуып, җүеш куллар белән сөртеп кендекләренә, битләренә сөртә идек.

**Бүсер.** Бүсер сыны ясап, шуны язуга язып та, юып эчерәләр. Аның үз дәвасы бар. Андары соң буена да эләләр, дияләр иде.

Кемнең **аягы авырта,** аягын каймыктырса, төньякка таба су бәрәләр иде. Аягыннан 3 мәртәбәме, 7 мәртәбәме әләндерәләр, аннары бил турысыннан, аннары баш турысыннан су белән әләндерәләр. Аны төньякка бәрергә. Илаһи, үзеңнең шифаңны бир, дип әләндерәләр дә, шылай бәрәләр инде.

Аннары инде **күз тигәннән,** нидән таң алдыннан камил тәһарәт белән таң суын алалар. Аны инде юындырасыңмы, эцсә дә ярый. Коедан алалар. Анарга «Аятел-көрси» укырга. Аннары соң тәкбир әтергә алган цакта. Әкертен генә аласын да, тәкбир әтәсен, «Аятел-көрси»еңне первай укыйсың, чиләгеңне батыргынча. Аннары тәкбир әтеп-әтеп 3 мәртәбә саласын да, аннары «Аятел-көрси» укып чиләккә саласын.

## Топонимика

Голдыр кизләве. Аннан бөтен авыл су ала. Аны Голдыр бабай казыткан, бер бай. Аны инде ремонтлады шәһәрдән кайтып ике малай, андары Әнием чишмәсе дип атарга язып калдырдылар. Әнәләре үлгән иде икесенең дә яшьли.

Тинцәле елгасы – Тинцәгә таба киткән.

*Кече Чынлы авылында Миңлебаева*
*Нәзирә Миркасыйм кызыннан (1939елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

## Тарихи риваять

Иске Кәкерлегә бабайлар Темниководан килгәннәр (Төмән авылыннан). Районның күп авыллары шуннан килгәннәр. Куай юлы белән килеп, Атламыштан чыгып, Ишле, Яңа Ишле авыллары кырыннан Ефәк юлы буйлап киләләр. Шул юл белән руслар басып алгач, арестантларны йөртәләр.

Бабайлар килеп туктагач, бөтен тирә-юньне карап, Кәкерле башына туктыйлар. Куналар, таң ата. Яз башы була, бик матур. Бер якта – усак урманы, бер якта – карурман.

Безнең авылдан төрле җирләргә күп күчеп утырганнар. Беренче кеше – 2,5 метрлы Олуг бабай, энесе Мирза, ялчысы – Мукшы Семка. Олуг бабай бер кызын ялчысына биргән.

Кая утырырга – уйлашалар. Бабай бер үгезне кәкре каенга күл буена бәйли, берсен ireккә җибәрәләр. Бер сутка үтә. Бәйләгән үгез ятмаган, ятса, авыл нигезе шунда буласы була. Ирektәгесен эзләп китәләр. Ансы хәзерге авыл уртасына яткан була. Беренче казыкны бабайлар шунда сугалар. Авылда өйләр зур, ике катлы була. Шуңа күрә аны авыл-кала дип йөргәннәр. Заманнар үтә баргач, Мирза бабай нәселе аерыла.

Революциягә кадәр авылда унике җил тегермәне, өч ташлы су тегермәне икәү була.

## «Мәзәк утыру»

«Йөзек салышы» уены. Салкынга чыгарып җибәрү җәзасы бирелгән. Анда егет белән кыз сөйләшеп кергән.

## Әкият

Бай яңа капка ясаткан. Аңа смола эретеп сылаган. Аннан соң анда саескан килеп куна, ди. Саескан башын ала да, койрыгы ябыша, ди, койрыгын ала да, башы ябыша, ди.

Бабайларны әкият сөйләргә дип аптыраткач: «Кайчан шул саескан очып китә, шуннан соң сөйлим», – дия иде.

## Риваять

Кудюкай абыз Александр II (III) вакытында килгән монда. Яшь җегет килеп урнаша Текегә. Байга килеп, ялчыга керә ул. Урманга бара. Ике ат белән йөри. Бара да, ике олау төйи дә кайта, төйи дә кайта. Бервакыт хазрәтнең башына суга: бу нинди кеше соң? Ярдәм дә сорамый. Атын ерактарак калдырып, үзенең делянкасына ялчысын карарга китә. Атын туктата. Укый, дога кыла. Рычагларны куя да, агач үзе менә олауга. Аяклары дер-дер калтырый инде мулланың. Тиз генә кайта да, карчыгына:

– Бу кеше алдында гаеп эшләрең булса, гафу үтен, – ди.

Аңа өй салдыра и моны аерып чыгара. Аның гаиләсе булмый. Кешеләрне лечить итә и моның даны китә. Бервакыт Мәскәүдән делегация килә дә, патша дәште сине, кызлары авыру, ди.

«Мин Мәскәүгә бармыйм, кызын китерегез миңа», – ди. Кызны китерәләр Татар Текесенә. Кызны терелтеп алып китәләр. Патша аңарга 800 га урман бирә и 100 га җир бирә. Ну Кудюкай абзый аны үз исеменә яздырмый, Татар Текесе исеменә яздыра.

Чукындыру заманында руслар белән сугышканда Абыз бабай үлә. Искечә 15 нче майда була бу, Текегә күмәләр.

Хәзерге вакытта анда таш куелган. Ел саен анда кеше җыела, иллешәр корбан чалалар.

*Иске Кәкерле авылында яшәүче Иматдинов*
*Рифкать Абдрахман улы (1937 елгы)*
*язмалары*

## Аулак өй

Көз көне эшләр беткәннән соң җыелуны әйтәләр инде бездә Аулак өй дип. Кызлар бер өйдә җыелышып утыралар. Ул өйдә эшләр эшләргә булышканнан соң, кичкырын Аулак өйләр үткәргәннәр. Аннан соң анда егетләр килә торган булганнар инде.

Анда «Йолдызны күрәсеңме?», «Шешә әйләндереш» уеннары уйнаганнар.

«Йолдызны күрәсеңме?». Бер кешене яткызганнар да, телогрейка җиңе аша сораганнар:

– Син йолдызны күрәсеңме?

– Күрәм.

– Син нинди йолдызны күрәсең.

Ул бер кызның исемен атарга тиеш булган. Әгәр дә телогрейка җиңеннән ул кыз тотып торса, ул шул йолдызны тота була. Әгәр дә башка кыз тоткан булса, алдана була. Берничә тапкыр танымаса, җәза биргәннәр. Каршы уйнарга күбрәк үзенә ошаган кызны әйтә. Аларга икесенә генә сөйләшергә, аралашырга мөмкинлек биргәннәр инде, тышка чыгарып җибәргәннәр.

Аулак өйдә егетләр идәндә яталар.

Бииләр, җырлыйлар иде. Әгәр ошатмасалар, кызларга гармун туктаталар иде. Ул пазур санала инде.

## Кунак кызы китерү

Кыз теге урамда гына яшәсә дә, кунакка алырга әти-әнисе барып, рөхсәт сораган. Ул кыз баланы йортның әтисе-әнисе барып алган, бу йортта аны кунак иткәннәр, күршеләр дә аны кунак итеп йөрткәннәр. Кунак кызы хөрмәтенә Аулак өй җыйганнар. Кунак кызны йортның хуҗалары берничә көннән соң яңадан үз өенә илтеп куйганнар.

*Иске Кәкерле авылында Сәлахова*
*Рәмзия Вахит кызыннан (1948 елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

## 15 май бәйрәме

Сабантуй булмый иде. Майның уртасында Иске Кәкерле белән Теке авыллары бергә җыелышып уеннарга, җыр-биюгә җыела иде.

## «Бармак төртеш» уены

5–6 кеше тезелешеп утырасың. Бармакларны куябыз алты кеше. Бер кеше төртеп җырлап чыга. Җырның соңгысы кемнең бармагына эләгә, ул бармагын бөкли. Аннан соң яңадан китәсең бармак төртеш.

Сиңа җәза чыкса, сөйләшеп йөргән егетең белән янәшә утырасың, кулларны кулга тотышасың, кулъяулыкны урталай бөкләп, шуның артына ышыкланып егет белән кыз кара-каршы җырлый.

## «Мәзәк җырлары»

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Сиримин.
Шул сиримин чәчәгенә
Охшатамын сине мин.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Фәйрүзә.
Зәңгәр күктә сиңа охшаган
Тулган ай гына йөзә.

Уйна, дустым, гармуныңны,
Син матур уйнатасың.
Онтылып, югалып беткән
Уйларны уйлатасың.

Әйтим берне, әйтим берне,
Берне түгел, икене.
Әйтмәс идем берне, икене
Дус-ишләрем сөйкемле.

Зәңгәр ефәк шәлләремне
Күтәралмый беләгем.
Синең белән күрешүне
Күптән инде теләдем.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Миркасыйм.
Җәй дә яшел, кыш та яшел
Чыршы дигән бер агач шул.

Самавырны тиз кайната
Ак каенның күмере.
Кияү белән яшь киленнең
Тигез үтсен гомере.

Каен каты, каен каты,
Каен каералмадым.
Кая барсам да үземнән
Кайгым калдыралмадым.

*Татар Төкесе авылында Шәрәфетдинова*
*Гөлфария Вахит кызыннан (1949 елгы)*
*А. Х. Садыйкова, З. К. Шакирова язып алды*

# ПОЮЩЕЕ ДЕРЕВО

*Илюса Фаррахова*

В самой западной точке Республики Татарстан, в Дрожжановском районе, проживают татары-мишари. Каждому району присуща своя особенность, неповторимость. Образ жизни, который складывался годами, помог сохранить и передать национальные традиции от поколения к поколению.

Лирику мишарского народа можно увидеть, почувствовать там, где она зародилась, – в деревнях и в селах.

### Строительство домов и мечетей

Чем могут гордиться татары-мишари, так это своим ремеслом – строительством. Еще много поколений назад мужчины славились своим мастерством в строительстве, имея большой спрос, они работали и в других регионах, таких как Оренбургская и Тюменская области, города Уфа, Казань.

**Дома**. Деревни в Дрожжановском районе строились ровными и широкими улицами. Знатные дома стоят под стать высоким воротам, которые они сами называют «кабак». Строят дома как фронтоном, так и боковым фасадом к улице в зависимости от участка. Чаще всего они одноэтажные. Двухэтажные встречаются в раннем (купеческие дома) и позднем периоде (современные типологические постройки). Дома отличалась также крышами. Большинство были двухскатными, меньше встречаются четырехскатные или шатровые, набирают популярность мансардные и вальмовые крыши.

Характерным элементом в жилищной постройке является то, что дом соединяется с сараем, хозяйственной частью и примыкает

к воротам, образуя некий атриум в ансамбле. Но для функциональной организации жилого пространства двор частично покрывают крышей, чтобы избежать попадания дождя, и стелют доски для сохранения чистоты. Имея домашнюю живность, в хорошем порядке содержат двор. Опрятность – одна из основных черт характера мишарей. Такого рода организация говорит об определённом подходе к жизни, бытовые элементы отражают их мировоззрение. Анализируя убранство, можно подчеркнуть явное влияние шариата. Высокие ворота (приблизительно до трех метров) присущи мусульманским татарам издревле, так как женщины хозяйство вели во дворе, а ворота скрывали вид двора с улицы. Новое, но в то же время и хорошо забытое старое – это второй вход, парадное крыльцо в форме маленького портика с фронтоном, лежащим на столбах с перилами. Он позволяет пройти в дом, не заходя во двор, где мужчины и женщины могут ходить свободно, не сталкиваясь в дверях. В действительности это старинный прием в строительстве, так как по законам шариата и эстетическим соображениям женская и хозяйственная части дома всегда оставались в скрытой зоне, даже окна, выходящие на уличную сторону, были от гостевой комнаты.

Говоря о строительстве как о ремесле и искусстве, стоит подчеркнуть его декоративные функции. В нем выражаются самосознание и самоопределение людей, проживающих в этом районе. Во-первых, это подборка колорита, ярким цветом выкрашенные дома и ворота с оградой, может присутствовать еще и изображение в виде растений или животных, птиц. Ведется четкое комбинирование цветов, особенно сочетание белого с любым другим цветом; чередуют его, когда прокрашивают косые доски на фронтонах и пилястрах. Используют колорит вне зависимости даже от материала, например, если дом обшивают сайдингом, то обязательно в нескольких контрастных или дополняющих цветах. Во-вторых, это резьба. Используют контурную, пропильную, сквозную, накладную технику резьбы. Декорируют весьма помпезно и буквально все, начиная с ворот, где используют розетки и кронштейны, карниз в несколько ярусов из накладной резьбы. А также над дверью в воротах устанавливают козырек с маленькой двухскатной крышей. Если дом стоял фронтоном к улице, его особенно сильно украшали. Самый популярный элемент фронтона – это «барабаны» в нижних углах тимпана, на косые карнизы крепят симу из сквозной резь-

бы, нижний карниз из накладной резьбы, фриз декорируют триглифом и консолями, создающими ритм, а также окна с наличниками. Часто встречающийся элемент – накладная резьба с арочными проемами над карнизом между «барабанами». Если дом стоит боковым фасадом, пристраивают «собачатник». Это маленькое окно или два окна на крыше, также с кружевными наличниками. Оконные проёмы дома, выходящие на уличную сторону, обязательно обрамляются наличниками, декорированными резьбой. Часто можно встретить ставни на окнах – «тәрәзә капкасы», столь редкое явление в наши дни. При обшивке бревенчатого дома досками в местах углового соединения создается имитация пилястра, который также декорируется ажурной резьбой. В формировании всей композиции, будь это маленькая деталь резьбы или общий вид стены дома или ворот, всегда сохраняется ритм. В отношении татарского орнамента ритм – основа композиции. Узоры больше растительные, отсутствует стилизация животных и птиц, они изображены в реальных формах. Используются такие современные узоры, как «языки огня», геометрические формы орнамента зачастую испытывают влияние чувашского этноса. Присущи Дрожжановскому району пышно украшенные «кокошники» и «полотенчики» (элементы оконного наличника) с эклектичной резьбой. Кокошник наличника делится на верхнюю и нижнюю части. В верхней части чаще используют композицию орнаментов в виде цветка, веера, луны, звезды, солнца, травы, набегающей волны, голубей, уток, обрамляя луковичным сандриком либо многоярусным резным плинтусом в форме фронтона, нижняя часть заполнена ритмом резных узких консолей. Украшением дома служили также и палисадник с изгородью.

Общественным местом и местом для бесед в деревнях были ручьи («чишмә»), куда девушки, женщины спускались за водой. Ручьи порой были причиной возникновения деревень, именно поэтому их содержали в чистоте, ставили ограды, беседки. В зависимости от места нахождения ручьи могут быть нисходящими на подоле холма или восходящими на горе. При наличии возможностей люди ставят в палисаднике либо перед ним колодцы шахтного или скважного типа.

**Мечети.** Строительство мечетей пришло в Поволжье вместе с исламской верой. В результате перенимания с Востока с верой и других элементов образа жизни создалось новое направление в

мусульманском искусстве наряду с арабским – татарское. Ярким примером тому служит стилизация в строительстве и художественном оформлении мечетей на татарский лад, с сохранением всех канонов.

Мечети Дрожжановского района построены по типологическому проекту. Они простые как по строению, так и по эксплуатации (предназначены только для молитв). Одноэтажные или двухэтажные здания с одним простым призматическим минаретом по центру двухскатной либо шатровой крыши. В каждой деревне по одной мечети, в редких случаях, если имелись две махали, строили и две мечети. Исключение: деревня Старое Какерле, где стоят три мечети. Первая из них – построенная на общественных началах мечеть «Нурфасих», вторая – «Самат» и третья – имени Миннуллы Кашафовича построены на частные средства. Две последних из них постройки нового типа с большой площадью, что позволяет уместить учебные классы, и парадным фасадом, где использовался татарский орнамент в виде цветка «лилии», украшавший фронтон крыльца. Мечети построены на европейский манер с использованием классических элементов архитектуры, таких как аттик и расскрепованность рустованными лопатками бокового фасада третьей мечети. Очень примечательно спроектирован интерьер мечети «Самат». Первый этаж в форме гипостильного зала имеет два ряда по пять колон, второй этаж разделен на два зала одной аркой горизонтально вытянутой формы.

### Интерьер дома и его составляющие элементы

**Интерьер.** Внутренняя обстановка дома татар-мишарей складывается как у всех татар Поволжья. Начиная с крыльца, пол застилают самоткаными паласами, порой соединяя их в несколько рядов. Рабочей и кладовой зоной дома являются сени и чулан. Чаще сени были проходными, имелся выход в сторону двора, сарая. Жилая зона дома делилась в основном на кухонную и гостевую части. Особенностью является наличие цилиндрической печи, как они сами её называют «түгәрәк мич» .

Основные атрибуты дома – это мебель, а именно: кровать, буфет, стол, тумба, комод, сундук. Еще до конца второй половины XX века мебель мужчины делали вручную, таких было немало и по сей день. Дрожжановский район славится мастерами по дереву.

Татарский дом всегда отличался от других огромным количеством текстиля. Дома все накрывают тканью, верхнюю одежду, дверные проемы – длинными занавесками. По всему периметру дома от потолка протягивают короткие пологи – «кашага», окна зашторивают небольшими занавесками – «пәрдә», «чилтәр». В гостевой комнате мебель расставлена у стен, кровать заправляют подзорами, выкладывают подушку на подушку и накрывают накидкой. На стол накрыта скатерть – «ашъяулык», на стенах висят панно и шамаили. Характерным для этого района является изображение зданий мечетей на шамаилях, текст в основном аят «Аль-Курси», суры «Аль-Фатиха», «Ан-Нас». Все эти атрибуты в виде ткани были вышиты женщинами, привезены с приданым – «шәник». По сей день используют даже применительно к современной технике, как телевизоры и компьютеры, накрывают их вышитыми салфетками.

Рукодельниц Дрожжановского района отличает своя манера вышивания. Используют также тамбурный, крестовый, ковровый шов, технику канвы и глади, но выкладывают композицию в форме центрально-лучевого или радиального, розеточного раппорта, в виде цветочного букета. Присутствуют цветочно-растительный и зооморфный орнамент без стилизации, в более поздний период встречается изображение людей. Уникальным является использование перелива в цвете, подбора контраста цветового насыщения. Тем самым показывают тени, полутени и глубину, придавая цветку двухмерное изображение, собрав цветы в корзину или вазу.

Ткачество как род деятельности утеряло свою актуальность уже в прошлом веке в отличие от вышивания и вязания, чем охотнее занимаются женщины.

Мужской род занятий, как работа с деревом, востребован всегда. Умение обрабатывать дерево присуще почти каждому мужчине в деревне, но большими мастерами были единицы. К примеру, Мистеев Хабир Каюмович (1928 г. р.) из села Старое Какерле. Его дом виден издалека, весь покрытый ажурной резьбой; дом полон мебели собственной ручной работы. А также Каримов Абдулжан Абдуррахманович (1952 г. р.) – мастер встроенной мебели более современного типа.

Без сомнения, умелец, человек с большим талантом, в прошлом летчик-испытатель житель села Верхний Каракитан Раимов Ильдус Шамилович (1969 г. р.) . К своему пятому десятку лет он имеет

большую коллекцию собственных работ по дереву: мебель, настенное панно, игрушки, кухонную утварь и множество декоративных деталей (розетки, кронштейны, рамы). Ильдус Шамилович передает свое мастерство в рамках школьных занятий молодому поколению, а дома воспитывает юного мастера, сына Динара (1997 г. р.), последователя своего отца. Айзятова Марьямбану Хайрулловна (1928 г. р.), проживающая в селе Шланга, – вышивальщица с большим стажем и мастерством. Интерьер её дома полностью оформлен изделиями ручной работы.

История и культура Дрожжановского района богата и разнообразна, сохранила свою индивидуальность. С точки зрения искусства новые проявления народного творчества модернизируются, старые и устоявшиеся архивируются, консервируются. Большой вклад в сохранение артефактов субэтноса татар-мишарей внесли пришкольный и краеведческие музеи, один из которых находится в селе Старое Дрожжаное (руководитель Субаев Разиф Рафаилович, 1970 г. р.). В селе Старое Шаймурзино в 1982 г. был основан музей имени А. Ш. Абдреева (художественный постановщик Попов Владимир Александрович). Музей носит концептуальный характер, имеет девять выставочных залов и 10600 экспонатов.

## МАСТЕРА

***Село Старое Какерле:***

Мистеев Хабир Каюмович, 1928 г. р. (столяр, плотник)
Гарифуллин Ахтам Галиуллович, 1954 г. р. (строитель, плотник)
Каримов Абдулжан Абдуррахманович, 1952 г. р. (столяр, плотник)
Садретдинов Латфулла Садретдинович, 1932 г. р. (столяр, плотник)
Шиганов Забихулла Киямович, 1935 г. р. (столяр, плотник)
Алиев Зиятдин Хусаинович, 1937 г. р. (столяр, плотник)
Замалетдинов Жаудат Шагиевич, 1933 г. р. (строитель, плотник)
Сабирзянова Фархия Ахметзяновна, 1900–1985 гг. (ткачиха, вышивальщица)
Замалетдинова Гульшат Фатыховна, 1942 г. р. (вышивальщица)

***Деревня Тюки:***

Салихов Нурислам Садыкович, 1934 г. р. (столяр, плотник)
Хисматуллова Султания Гайнетдиновна, 1940 г. р. (ткачиха, вышивальщица)

***Село Мочалей:***

Абдулханов Азелжан Усманович, 1937 г. р. (мастер по плетению из прутьев)

Фахрутдинов Шахимардан Хайретдинович, 1930 г. р. (столяр, плотник)

Фахрутдинова Кадрия Кадировна, 1932 г. р. (вышивальщица)

Тухфитова Сакина Садыковна, 1949–1971 (ткачиха, вышивальщица)

Исметова Рушания Латыповна, 1935 г. р. (вышивальщица)

Фаизова Фания Арифулловна, 1940 г. р. (вышивальщица)

Фаизова Хакима Гайнетдиновна, 1903–1997 (вышивальщица)

Валеева Насиха Мусиновна, 1930–2011 (ткачиха, вышивальщица)

***Село Верхний Каракитан:***

Раимов Илдус Шамилович, 1969 г. р. (резчик по дереву, столяр, плотник)

Шарафутдинов Рифкат Касимович, 1958 г. р. (резчик по дереву, художник)

Камаев Рахимжан Касимович, 1940 г. р. (столяр, плотник)

***Село Нижнее Чекурское:***

Хисматуллина Нария Нургафовна, 1959 г. р. (вязальщица)

***Село Старые Чукалы:***

Асхарова Гульжихан Идиатулловна, 1946 г. р. (вышивальщица)

Хисамутдинова Хатира Арифуловна, 1938–2010 (вязальщица)

***Село Новые Чукалы:***

Низамутдинов Фаткелислам Низамутдинович, 1929 г. р. (столяр, плотник)

Низамутдинов Ильгиз Фаткелисламович, 1971 г. р. (столяр, плотник)

***Деревня Задоровка:***

Каримов Ильхам Анварович, 1973 г. р. (столяр, плотник)

Халиуллина Фидания Мухаметдиновна, 1975 г. р. (вышивальщица)

***Село Шланга:***

Низамов Канаф Кыямович, 1936 г. р. (столяр, плотник)

Низамов Раис Канафович, 1964 г. р. (столяр, плотник)

Махмутов Файзулжан Хасанжанович, 1949 г. р. (мастер по железной ковке)

Айзятова Марьямбану Хайрулловна, 1928 г. р. (вышивальщица, вязальщица)

***Село Татарская Бездна:***

Калимуллина Мунира (вышивальщица)

***Село Малая Цильна:***

Мусин Адижан Миначевич, 1928 г. р. (столяр, плотник)
Минлебаева Назира Миргасимовна, 1939 г. р. (вышивальщица)
Измайлова Факия Ахметзяновна, 1940 г. р. (вышивальщица)
Замдиханова Зубаржат Ибиатулловна, 1934 г. р. (вязальщица, вышивальщица)

***Село Большая Цильна:***

Миначев Равиль Рифкатович, 1958 г. р. (мастер по плетению из прутьев)

**ИНФОРМАТОРЫ:**

1. Гарифуллин Ахтам Галиуллович, 1954 г. р.
2. Абдреева Рамиля Ахметгалиевна, 1961 г. р.
3. Гибадуллин Радик Диргамутдинович, 1971 г. р.
4. Ракипов Фархат Хайдарович
5. Митеева Дина Хайдаровна, 1951 г. р.
6. Тухфитуллова Фарида Тауфиковна, 1969 г. р.
7. Сафина Наиля Митхатовна, 1965 г. р.
8. Гафурова Рамиля Ирфановна, 1978 г. р.
9. Юнусова Зубаржат Валиджановна, 1956 г. р.
10. Халиуллина Фидания Мухаметдиновна, 1975 г. р.
11. Мухарямов Альберт Альфретович, 1987 г. р.
12. Тимербулатов Ренат Амирлислямович, 1975 г. р.
13. Ибрагимова Таскира Рауфовна, 1961 г. р.

## «ИМЕ-ТОМЫ ШУЛ БУЛСЫН»

*Зөһрә Шакирова*

Ырымнар фольклор жанрлары арасында аерым урын алып торалар һәм аеруча халыкчан булулары белән игътибар җәлеп итәләр.

Халык арасында нинди генә ырымнар очрамый. Бу аларның турыдан-туры халыкның көндәлек тормыш-көнкүрешеннән, йола, традицияләреннән килеп чыгуы белән аңлатыла. Әле фән-техника барлыкка килгәнче үк, кешеләр үз тормышларын ничек тә булса җиңеләйтергә, төрле бәла-казалардан, чирләрдән котылырга тырышканнар, табигатькә яки үзләренә дә билгеле булмаган илаһи затларга мөрәҗәгать иткәннәр. Шул рәвешле төрле ырымнар барлыкка килгән, ырым текстлары формалашкан.

Фәндә яңа ачышлар ясалган саен, ырымнарның яшәештән төшеп калу ихтималы арта бара кебек. Әмма, башка йолалар кебек үк, кеше тормышының аерылгысыз бер өлешенә әйләнгән ырымнарны да кеше күңеленнән төшереп калдыру мөмкин түгел.

Ырымнарның килеп чыгышын хәтта дин, табыну белән дә бәйлиләр. Им-том текстларының аерым магик көченә ышану да шуның белән аңлатыла күрәсең. Ләкин ырымның мәгънәсе сүз көче белән генә чикләнми әлбәттә. Моннан тыш ул үз эченә йола компонентын да ала. Хәтта ырымнарга, билгеле бер дәрәҗәдә, борынгы йоланың кечерәйтелгән варианты дип тә карарга мөмкин.

Ырымнарны шактый тирәнтен өйрәнгән галим Марсель Бакиров аларга мондый билгеләмә бирә: «Ырымнар (өлешчә синонимнары – әфсеннәр, арбаулар, им-томнар) – халык иҗатының магия, ягъни сүз һәм хәрәкәт-йола кодрәтенә ышану белән бәйләнешле борынгы жанры, хыялый көчләргә һәм ияләргә тәэсир итеп нинди дер нәтиҗәгә ирешү өчен чыгарылган һәм шул максатта

кулланылган тылсымлы сүз формулалары яки калыплашкан магик гыйбарәләр».

Аллаһка түгел, ә нәкъ менә табигать, җир-су ияләренә мөрәҗәгать итеп төзелгән текстлар ырымнарның бик борынгы вакытларда ук барлыкка килүен тагын бер тапкыр дәлилли. Чөнки кешенең табигать алдында иң көчсез чоры, әйләнә-тирәне мифологик күзаллавы ыруглык дәверенә туры килә. Табигать кеше өчен серле дөнья булып тоела һәм төрле бәла-казалар, көчле яңгыр, җил-давылларны берничек тә җиңә алмавы аны табигый көчләргә ялварырга мәҗбүр итә.

Шулай булуга карамастан, ырымнарны бик борынгы бер фольклор жанры итеп кенә карау да дөрес булмас. Чөнки ырымнарга мөрәҗәгать итү дә кулланыла. Фольклор экспедицияләре вакытында халыктан җыелган материаллар шуны күрсәтә. Ләкин, кызганыч, ырымнар турында сораша башлагач, информантлар арасында аларны бөтен шартлары белән сөйләп-тасвирлап бирүчеләр бик аз.

Күп кенә ырымнар бала туу, балага күз тию белән бәйле. Чүпрәле районы авылларында аларны һәркем диярлек белә булып чыкты. Анда иң еш кулланганы – балага күз тигәндә аны ишек-тәрәзә рамнарын юган су белән имләү. Бу турыда Кече Чынлы авылында яшәүче Миңнебаева Нәзирә ападан (1939 елгы), Каракитә авылыннан Ильязова Наилә ападан (1940 елгы), Шланга авылыннан Хисамова Гөлшат һәм Хәлилова Гөлшат апалардан ишетергә туры килде. Әлеге ырым түбәндәгечә башкарыла икән:

«Чокырга су аласың, тәрәзәләрне, ишек露 тоткаларын ышкыйсың. Шул су белән баланы 3 мәртәбә сөртеп төшерәсең. Су башка, биткә, кендеккә тияргә тиеш. Аннан соң:

Ияңне тап,
Каян килдең, шунда кит, –

диеп, тупса аша ыргытасың».

Ә менә Татар Бизнәсеннән Гайсина Хәсәнә әби (1928 елгы) шушы ук ырымны савыт-саба юган су белән үтәргә кирәклеген әйтте.

Иске Шәйморза авылыннан Камалова Фәүзия апаның (1951 елгы) күз тиюгә каршы им-томы аеруча кызыклы:

«Имән гөмбәсе, 40 төрле чүпрәк, 40 штук чыраның берәрсен аласың да, ут төртеп бераз яндырасың. Шуннан чыккан төтен белән түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә баланы төтәштерәсең *(төтәслисең)*:

Име-томы шул булсын,
Кемнең күзе тисә, шул чыксын.
Зәңгәр күз, яшел күз, кара күз,
Барыгыз да чыгыгыз.
Өф-өф-өф, –

дип өреп җибәрәсең».

Шланга авылыннан Мәхмүтова Бибинур төтәсләүне күз тидергән кешедән алынган берәр чүпрәк белән эшләгәнлекләрен әйтте.

Күз тимәсен өчен «петү» (бөти), төймә тагу, маңгайга корым сөртү, таң суы белән юындыру да кулланыла.

Бала тууга бәйле им-томнардан тыш, халык арасында шактый киң таралган башка ырымнарны да күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән, күзгә арпа чыкканда, арпа йә баланны күз тирәли әйләндереп, ... *(затсыз сүз)* белән санап имлиләр; бүсер чыкса, кендеккә көмеш акча куеп, марля белән бәйләп куялар яки бүсер сыны ясап, язу язып, шуны юып эчерәләр икән.

Куркулык кою турында да күпләр белә, ләкин аны эшләү тәртибен Шланга авылыннан Хисамова Гөлшат һәм Хәлилова Гөлшат апалар гына әйтеп бирә алды:

«Баланы матча турысына утырталар. Кургашынны эретеп, табакка суга салалар; баш очына куеп:

– Кемгә курку коясың?
– Шуңарга курку коям.

Шуларны 3 тапкыр әйтәсе. Аннары:

Ай кайта, көн кайта,
Авыру булсаң, син дә кайт.
Имең-томың шул булсын,
Каян килдең, шунда кит, –

дип, төньякка суны бәрәсе.

Әгәр төзәлмәсә, 3 мәртәбә эшлисе. Нәрсәдән курыкса, кургашында шул рәсем чыга».

Гомумән, Хисамова Гөлшат һәм Хәлилова Гөлшат ырымнарны шактый күп белә булып чыктылар. Сөял имләүнең дә иң тулы тасвирламасын алардан алдык. Ул болай башкарыла икән:

«Җеп алып, сөял өстендә кырык тапкыр төен төйнәп, юешлеккә (дымлы урынга) бәрергә. Җеп черегәч, сөял бетә.

Имләгәндә биштән бергә хәтле кирегә саныйсың:

Биш, дүрт, өч, ике, бер
Дүрт, өч, ике, бер
Өч, ике, бер
Ике, бер
Бер, бер, бердән кайта,
сүәл булсаң, син дә кайт, –

дип әйтәсе».

Киң таралган ырымнардан башка, сирәк очраган ырымнарны да күрсәтеп үтәргә кирәк. Мисал өчен, Иске Шәйморза авылыннан Камалова Фәүзия апа (1951 елгы) тимрәүдән котылу им-томын сөйләп бирде:

«Күмер, акча, ашык (сарыкныкы) алып, өчесен өч көнне тимрәү тирәсендә түбәндәге сүзләре әйтеп, әйләндерәсең:

Әм-әм-әмрәмүнә,
Тим-тим-тимрәмүнә.
Ай кайта, көн кайта,
Тимрәү булсаң, син дә кайт».

Эч авыртканга, эчкә кату чыкканга Шланга авылыннан Мәхмүтова Бибинур әби (1931 елгы) тагын да кызыклырак ырым турында сөйләде. Янәсе, карлыгач оясын алып, җылытып чүпрәккә чорныйсың да, корсак өлешенә куеп торасың. Моның файдалы булуын ул, карлыгач оясының бик күп урыннардан җыелган төрле балчыклар белән ясалуында, дип аңлатты.

Кече Чынлы авылыннан Миңнебаева Нәзирә апа (1939 елгы) им-том ярдәмендә аяк авырту, каймыгудан да котылып булуын әйтте. Моның өчен савыт белән су алып, өч яки җиде мәртәбә аяк, бил, баш турысыннан әйләндерергә һәм суны төньякка таба ыргытырга кирәк. Ләкин ул ырымның текстын исенә төшерә алмады.

Им-том турында сөйләшкәндә күп информантлар ырымнарны башкарганда билгеле бер шартлар үтәлергә тиешлегенә басым ясый. Мисал өчен түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

– имләүче, ырымны башкарганда, кеше белән сөйләшергә тиеш түгел;

– им-томны эшләгәч, кулланган әйберне төньякка таба ташларга кирәк;

– бер тапкыр имләгәч, авырту кимемәсә, имләүне өч тапкыр кабатларга.

Шунысын да кабатлап әйтәсе килә: им-том, ырымнар турында сөйләшкәндә информантлар сагаеп калалар. Бу, беренче чиратта, ырымнарның ислам дине тарафыннан тыелган гамәл булуы белән аңлатыла. Чөнки информантларның күбесе һәрбер авыртуга каршы ул авыруның үз догасы булуын әйтте, күз тиюгә каршы да догалар укып сакланырга кушылуын искәртте.

Моннан тыш, таң суы алып коенуның файдасы күплеген дә искә төшерделәр. Мәсәлән, Шланга авылыннан Мәхмүтова Бибинур бу турыда болай сөйләде: «Таң суын таң атканчы, истинҗа алып, ару, пакь коедан алырга. Аннары укырга белгән догаларыңны укыйсың да шул суга өрә барасың. Аннары шул суны күзеккәннең (*күз тигән баланың*) башыннан сөртәсең, коена торган суына саласың, калганын авызына, битләренә, башларына сөртәсең инде».

Таң суын алуның тәртибе һәм әлеге суның шифасы турында Кече Чынлы авылыннан Миңнебаева Нәзирә апа да шактый тәфсилләп аңлатты: «...күз тигәннән-нидән таң алдыннан камил тәарәт белән таң суын алалар. Аны инде юындырасыңмы, эчцә дә ярый. Коедан алалар. Анарга Аятел-көрси укырга. Аннары соң тәкбир этергә алган цакта. Әкертен генә аласын да, тәкбир этәсен, Аятел-көрсиеңне первай укыйсын, чиләгеңне батыргынца. Аннары тәкбир этеп-этеп 3 мәртәбә саласын да, аннары Аятел-көрси укып циләккә саласың».

Йомгак ясап, шуны әйтик: элеккерәк заманнарда ырымнар халыкның көндәлек тормышында зур роль уйнаган. Кешеләр аларны дәвалау максатында да, хуҗалыкта да, үзара мөнәсәбәтләрне үзгәртү өчен дә кулланганнар. Фольклор галиме М. Х. Бакиров бу хакта болай дип яза: «Борынгылар фикеренчә, җисми характердагы халәт яки ияле чирләр кешегә төрле юллар белән күчә алган: җил яки су белән дә, зәхмәт яки җен кагылып та, күз тиеп яки

нәрсәгәдер орынып та һәм, әлбәттә, магик ритуал яки сүз-ырым ярдәмендә дә. Әгәр һәр нәрсә дә ияле-җисми икән, димәк, йоласын һәм телләрен белгәндә, аларны теләгән җиргә күчереп яки кире җибәреп була, дип уйлаган борынгы кеше».

Ләкин фән һәм техника үсә барган саен, алар үзләренең магик көчләрен югалта барганнар. Шуңа күрә дә күбесе кулланылыштан төшеп калган.

Шулай да, халык арасында бозым һәм сихергә әле дә ышанучылар бар, дип әйтергә мөмкин. Чүпрәле районында җыелган материаллар моны тагын бер мәртәбә раслый.

## КҮҢЕЛ ЧИШМӘЛӘРЕ САЕКМАС

Галимнәребез Чүпрәле якларында язып алган җырлар, балалар фольклоры, кыйссаларның иң матур үрнәкләре, түгелеп-чәчелеп югалмыйча, «Татар халык иҗаты» дигән күптомлы тупланмада урын алган һәм шул рәвешле киң җәмәгатьчелеккә танытылган. Без аларны бу җыентыкта да искә төшерү кирәкле һәм файдалы гамәл булыр дип уйладык. Һәр текстның кем тарафыннан кайсы авылда һәм кайчан язып алынганлыгы күрсәтелде.

Әлеге материалларны басмага Илмир Ямалетдинов әзерләде.

### ҖЫРЛАР

### Аллар, аллар

Ал беләзек, гөл беләзек
Минем сөеп кигәнем;
Кара кашлы, кара күзле
Комсомолка сөйгәнем.

*Кушымта:*

Аллар, аллар,
Аллар гөлләре белән;
Бәхетлеләр – өйләрендә,
Сөйгән ярлары белән.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр ал сабын;
Бер сагынмасаң, бер сагын,
Онытып бетермә тагын.

*Кушымта*

Урман буе коегызга
Алтын чылбыр куегыз;
Алтын чылбырларга охшап
Үскән зифа буегыз.

*Кушымта*

*Каракитә авылында*
*М. Зәбиров язып алган. 1955*

### Судагы балыкларны

Ач тәрәзәң, күтәр пәрдәң,
Нурлы йөзең күренсен;
Сөймәс булсаң, әйт дөресен,
Күңелләрем сүрелсен.

*Кушымта:*

Кармак салып алыйк әле
Судагы балыкларны;
Көнләштерергә яратам
Көнләгән халыкларны,
Таш бәйлик тә суга салыйк
Грубый халыкларны.

Оча, оча оч булдым,
Оча торган кош булдым;
Кадерен белмәгән ярларга
Кайдан килеп иш булдым.

*Кушымта*

*Чокалы авылында*
*М. Зәбиров язып алган. 1955*

### Икегез дә пар килгәнсез

Әй, икегез, икегез,
Икегез дә бертигез;
Икегез дә пар килгәнсез,
Тигез гомер итегез.

Самоварны тиз кайната
Кызыл миләш күмере;
Килен белән яшь кияүнең
Озын булсын гомере.

Сокланып карап туймассың
Зифа буегызга да;
Онытмагыз чакырырга
Бәби туегызга да.

Агыйделгә сал килгән,
Сал килгән җир тар килгән;
Сайлап алган алмалар күк
Икегез дә пар килгән.

Сандугачлар ояда,
Оялары кыяда;
Сандугач кебек сайрашып,
Шат яшәгез дөньяда.

*Мунчәли авылында*
*Рокыя Галимовадан (1921 елгы)*
*М. Зәбиров язып алган. 1955*

## БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫ

### Бишек җырлары

Кызым, кызым, сачәгем,
Алдадыр киләчәгең.
Йокла кайгың юк вакытта,
Самый рәхәтле чагың.

*Иске Ишле авылыннан*
*Гүзәлия Фәхретдинова (13 яшь)*
*язып җибәргән. 1975*

Әлли-бәлли, Бәхтияр,
Ызба артында бүре бар:
– Еламаганны кереп алма,
Елаганны кереп ал.

*Шланга авылыннан*
*Гыйльман Шәрәфетдинов (11 яшь)*
*язып җибәргән. 1975*

### Юаткычлар

Әт иткән, бәт иткән –
Кәҗәбез кая киткән?
Кәҗәбез суга киткән,
Минем бәби зур үскән.
Үс, үс, үс!

*Шланга авылыннан*
*Римма Мөшәрәпова (15 яшь)*
*язып җибәргән. 1975*

Әтисе дә ярата,
Әнисе дә ярата,
Апалары, абыйлары –
Барысы да ярата.

*Шланга авылыннан*
*Гыйльман Шәрәфетдинов (11 яшь)*
*язып җибәргән. 1975*

### Эндәшләр

Кояш, чык, кояш, чык,
Майлы ботка казанда,

Сырлы таяк базарда,
Көлле күмәч учакта,
Әниең кайтыр кичкә,
Җылы катык мичтә.

*Зур Чынлы авылыннан*
*Ф. Шагиева язып җибәргән. 1978*

### Такмаклар

Биек тауның башларында
Трактор гүләп тора.
Дурак уйный, тиле җырлый,
Дивана карап тора.

*Кече Чынлы авылыннан*
*Фирдәвес Йосыпова*
*язып җибәргән. 1982*

Бас, кызым, эзеңә,
Күз тимәсен үзеңә;
Асыл гөлләр үсеп тора
Синең баскан эзеңә.

*Иске Кәкерле авылыннан*
*Нәкыя Хәлимова (11 яшь)*
*язып җибәргән. 1982*

### Тел көрмәкләндергечләр

Кара карганың кара баласы туган көненнән бирле акыра да акыра, әнисен дә чакыра: «Карр, карр, кар!».

*Кече Чынлы авылында*
*Рәмзия Хәлиуллловадан*
*М. Хәлиуллова язып алган. 1983*

### «Аксак мәче» уены

Бу уенда катнашучыларның берсе «аксак мәче» була. Ул, башкалардан читкәрәк китеп, үзенә «өй ясый». Ә калганнардан «әни кеше» һәм «кызы» билгеләнеп, башка уйнаучылар – ризыклар: ипи, катык, сөт, каймак һ. б. булып, үзләренә баз кебек урын ясап, шунда утырып торалар. Аларның хуҗалары «әни» белән «кыз» була.

Кызның әнисе кызына йә «мин җиләк җыярга барам» дип, йә «су буена төшәм» дип чыгып китә. Моны аксак мәче тыңлап тора. Әни киткәч, аксак мәче килә дә ишек шакый. Кыз йөгереп чыга.

Шунда аксак мәче ялганларга тотына. «Җиләк җыярга киткән әниеңне урманда бүре ашаган» дип, ә башка җиргә киткән булса, башкача алдый. Кыз «ышана», елый-елый әнисен эзләргә йөгерә. Аксак мәчегә шул гына кирәк тә, ул, базга төшеп, йә сөтне, йә ипине, йә башкасын эләктереп, өенә элдертә. Кыз әнисен эзләп таба да, елый-елый мәченең сүзләрен сөйләп бирә. Әнисе кызны юата һәм өенә алып кайта. Кыз бик талчыккан була, аның ашыйсы килә һәм ул әнисеннән ипи сорый. Әнисе: «Баздан төшеп ал!» – ди. Кыз: «Куркам мин, анда тычканнар бар», – ди. Әнисе үзе төшә һәм ипинең булмавын күрә. Кызыннан сорый. Кызы: «Берсәген үзем ашадым, берсәген каргаларга ашаттым», – ди. Әнисе моның өчен кызын орыша.

Иртәгесен тагын «әни» берәр җиргә чыгып китә, аксак мәче шулай көн саен килеп, баздагы ризыкларны, ялганлап, өенә ташып бетерә. Әни кеше аптырагач, кызына: «Әйдә, кызым, аксак мәчеләргә барып кайтыйк әле, ул безнең ризыкларны ташып бетергәндер», – ди һәм кызны, кулыннан тотып, аксак мәче өенә алып китә. Барып җиткәч, аксак мәчедән ризыкларын сорыйлар, ул тагын ялганлый: «Миндә юк», – ди. Әни кешенең ачуы килә һәм ул аксак мәченең «койрыгыннан тотып» алып бәрә һәм ризыкларын кереп ала. Алар ризыклар белән елашалар да өйләренә кайтып китәләр. Уен бетә.

*Кече Чынлы авылыннан*
*Фирдәүсә Йосыпова (13 яшь)*
*язып җибәргән. 1981*

### Санамышлар

– Зәйни, Зәйни, Зәйнәбем,
Зәйни, кая барасың?
– Бакырчыга барамын.
– Анда синең ниең бар?
– Оча торган кошым бар.
Очты китте, ике балык сугышты,
– Аның канын кем юар?
– Ак сакаллы карт юар.
– Эремчек, төремчек,
– Син калып тор, төртеп чык.

*Зур Чынлы авылыннан Ф. Шагиева*
*язып җибәргән. 1978*

Ур баба, ур баба,
Урмания, коңгырт чия,
Ал чук, күк чук,
Сарманский яшел чук.
Ары кылчык, бире кылчык,
Син кал, бу чык.

*Яңа Кәкерле авылыннан Г. Алиуллина*
*язып җибәргән. 1978*

Одеял, идеал,
Зәкен, деккен;
Җәек кеннәм,
Кыңгыраулы беләккәнем.
Ары кылчык, бире кылчык,
Кодачага сикереп чык.

*Зур Чынлы авылыннан Ф. Шабаева*
*язып җибәргән. 1978*

Әттем, литтем,
Паппа, литтем,
Сәүен, гаузын,
Сәүен, гауын,
Гали, назыр,
Бәңки, казан,
Тимер чуңк!

*Мунчәли авылында туып үскән*
*Н. Хисамов тапшырган. 1978*

Берә, яра, има, тима,
Фәтә, сата, укы, чука,
Миграш таш.

*Мунчәли авылында туып үскән*
*Н. Хисамов тапшырган. 1976*

## Эттән курыккан

Әти мәрхүм сөйли торган иде. Безнең авылда Персиян Сатдин (Сәгъдетдин) – аны Әрмән Сатдин дип тә йөртәләр иде – исемле кеше булган. Шул, ике улы белән төнлә урманда кунганда, шүрәле күргәнен сөйләгән.

– Кискән агачларыбызны саклап, урманда кунабыз. Ай яктысында бер нәрсә, шатыр-шотыр ботак таптап, яныбызга килә. Озын, ябык, бөтен өстен йон баскан.

– «Һәм-һәм»еӊ бармы? – ди, бу миӊа әйтә.

– Юк, – мәйтәм.

– «Чух-чух»ыӊ бармы? – ди.

– Юк.

Малай артта этне яшереп тота. Эт сикерергә генә тора. Килә бу минем өскә.

– Кети-кети уйныйбызмы? – ди. Шунда этне ычкындырып җибәрәбез дә, – тегенеӊ аягы кая тия, кая юк, – элдертә генә!

Иртәгесен йокыдан торсак, артыннан бер буй агачлык тоташ түшәлеп калган. Бу шүрәле булган. Ул эт белән чыбыркыдан курка икән.

*Мунчәли авылында*
*Хисамов Шаһвәлидән*
*Н. Хисамов язып алган. 1973*

## «Моӊлы хатын Бибигайшә» бәете

Кайгы-хәсрәт күрмәдем яшь үсмерли чагымда,
Уйнап-көлеп үстем мин үз әнкәм кочагында.

Үсеп җиткәч мин буйга, әнкәй килгән бер уйга,
Шатлык алган бар дөньясын, хәзерләнәдер туйга.

Күп үтмәде – туй булды, өйгә кодалар тулды,
Озакламый мулла килде, никахы да укылды.

Шулай итеп, яшь килен булып китте кыз башым.
Шатлыкларым кайгы булды, кемгә төшәр күз яшем.

Яшь вакытта уйлый идем, гел рәхәт күрермен дип,
Балаларым, семья белән шатланып йөрермен дип.

Ирем яшь хатын алды минем өскә көндәшкә,
Көндәш утында яндырды, карамады күз-яшькә.

Зөләйхаӊ да артык түгел миннән артык карарга;
Бар көчемне сарыф иттем син җаныйга ярарга.

Гөнаһым синеӊ хакта, ир хакыӊны куймадым.
Син никадәр сөймәсәӊ дә, мин сөюдән туймадым.

Син шулай да күрсәтмәдең миңа якты йөзеңне,
Ишетмәдем синең бер дә йомшак, тәмле сүзеңне.

Хезмәтемне кызганмадым, караң ап-ак тоттым мин,
Син миңа җәфа кыйлсаң да, барысын да йоттым мин.

Матурлыгым, зифалыгым – бар да иде җирендә,
Эшли идем, ни кушсаң да, калдырмадым берен дә.

Алай да мин синнән риза, үләм синең юлыңда,
Кызганамын: балаларым кала көндәш кулында.

Көндәшемдин сакла яхшы – сукмасын да какмасын,
Әгәр сукса я орышса, ата булып якла син.

Көндәшемдин яхшы сакла күз нурларымны, зинһар,
Тәрбия кыл син аларны, синдә аларның хакы бар.

Өс-башларын яхшы кара, тишек-ертык булмасын,
Ятим булып моңаймасын, күңелләре тулмасын.

Вакыт җиткәч, бир мәктәпкә, укыр-язар, хат таныр,
Китап укыр, Коръән ятлар, минем рухым шатланыр.

Дөнья эшен эшли белсен, буш калмасын һич нидән,
Урак урсын, чалгы чапсын, куя белсен һәм кибән.

Балаларым, бәгырьләрем, укымыйча калмагыз,
Надан булып, үзегезне михнәт утына салмагыз.

Балаларым, бәгырьләрем, калдыгыз ла анасыз,
Үги ана учагында инде сезләр янарсыз.

Балаларым, бәгырьләрем, калдыгыз ла моңаеп,
Үги ана бик зәһәрле, табар бердин мең гаеп.

Васыятем әйтеп беттем, үлсәм дә үкенмимен,
Кабан күленә батамын, көтсәгез дә килмимен.

Мәрхәмәтсез явыз дөнья җәфа салды башыма,
Җиткермәде, алып китте егерме биш яшемдә.

*Татар Саплыгы авылында*
*Нажия Сабируллинадан (1914 елгы)*
*М. Зәбиров язып алган. 1955*

## «Йосыф китабы»

Борынгы вакытта Йосыф пәйгамбәр булган. Аның әтисе Якуб та пәйгамбәр икән. Якуб пәйгамбәрнең беренче хатыныннан сигез ир баласы була. Аларның һәр кайсының үзенә күрә башка кешедән аерымлыклары бар икән.

Яһүдә исемлесе, йөгереп килеп бер сугу белән, арысланның арка баганасын сындыра икән. Бер улы уктан бик яхшы ата торган булган. Берсе көрәштә бик оста, берсе ерткычлар белән сугышып җиңә икән. Бик зирәк, акыллы була берсе. Берсе сүзгә бик үткен, һәрберсе үзенә күрә бер аерымлыгы белән була.

Беренче хатыны үлгәч, Якуб икенче хатынга өйләнә. Икенче хатыннан Йосыф, Ибне-Әмин исемле уллары, Динә исемле кызы туа. Шулай аның ун улы, бер кызы – барысы унбер баласы була. Шул ун улы арасында иң сөеклесе Йосыф икән. Ул башка туганнары арасында ягымлы да, сөйкемле дә, әтисенә дә охшаган. Төскә дә бик матур була. Матур булганы өчен аңа һәр күргән кеше соклана икән. Әтисе аңа кечкенә чагыннан ук, күз тимәсен өчен, йөзенә пәрдә ябып йөрткән. Кешеләр аңа сокланып гашыйк була торган булганнар. Йосыфның чәчен озын йөртергә рөхсәт иткән, толымга үреп йөрткән. Зиннәтләп, үз куллары белән унике толымга үрә икән әтисе. Башка балалары шуннан көнләшкәннәр.

Бервакыт Йосыф көзгегә караган да пәрдәсен ачып, үзенең матурлыгына үзе исе китеп сокланган.

– Миңа тиң бер матур юктыр, – дигән. – Әгәр мин кол булсам, минем бәһамны тутыра алмаслар иде. Күп акча торыр идем мин, – дигән. Матурларның матуры икәненә ышана үзенең.

Бервакыт Йосыф төш күрә, төшен әтисенә сөйли.

– Әтием, мин бер төш күрдем, төштә миңа ун йолдыз сәҗдә кылды, – ди.

Әтисе Йосыфка мондый сүз әйтә:

– Йосыф, балакаем, бу төшеңне башка туганнарыңа сөйли күрмә. Мин сине иң яраткан улым итеп әйтәм, башка туганнарың белмәсеннәр бу төшеңне. Әгәр алар минем сине шулай яратуымны белсәләр, көнләшерләр. Көнләшүдән сиңа нинди дә булса зыян итәргә тырышырлар. Бу төшеңне мин болай юрыйм. Син һәр туганнарыңа караганда да бөек кеше булырсың. Менә синең ун туганың сиңа сәҗдә кылырлар, синең алдыңда тезләнеп торырлар. Арысланның арка баганасын сындырган көчле абыең да, телгә

оста булган чичән абыең да, чапса һәркемне уза торган йөгерек абыең да, ерткычларны тотып үтерә торган укчы абыең да, ат өстендә оста йөрүче абыең да, үзләре кай яклары беләндер синнән өстен булсалар да, көнләшерләр синнән. Син беркемгә дә бу төшеңне сөйләмә.

Бу сүзләрне ишектән бер туганы тыңлап торган. Ул моны башка туганнарына сөйләп биргән:

– Әти Йосыфны безгә караганда артык ярата, без һәммәбез аңа сәҗдә кылабыз икән, – дип аңлата.

Башка туганнары бу хәбәрне ишеткәч, дөрестән дә, көнләшеп калалар. Һәм алар үзара киңәш кылалар:

– Без Йосыфны ауга барган вакытта үзебез белән алып барыйк та, аны үтерик. Яшәмәсен дөньяда. Әти аны бездән артык ярата икән, без аңардан котылыйк, – дип сөйләшәләр.

Әтиләренә килеп әйтәләр:

– Әти, без кырга, болынга ауга чыгабыз. Йосыфны да үзебез белән алырга уйлыйбыз. Кырларны күрсәтеп кайтыр идек. Ул һаман синен янында өйдә генә утыра. Без аны алып барып, иркен ачар[1] идек.

– Юк, мин рөхсәт итмим, – дигән аталары. – Ул кечкенә әле, арыр. Сезнең белән йөрсә хәлдән таяр. Я арып авырыр, – дип рөхсәт итми.

Теге туганнары ничек булса да ялынып, әтиләрен күндерергә тырышалар. Шуннан әтиләре риза була.

– Ярар, алып барыгыз. Ләкин арыса, аны чиратлашып күтәреп йөрегез, аңар тәмлерәк ашлар ашата торыгыз, – дигән.

Йосыфның чәчен үргән, яхшы киемнәрен киендергән, тәмле азыклар хәзерләткән.

– Йосыфымның иркен ачыгыз, аңа күңелле булсын, – дип, юлга озатып калган.

Шуннан сигез бертуган, тугызынчы Йосыф, авылны чыгып, кырга киткәннәр. Сахрага җиткәннәр. Авылдан чykканда әтиләре күргәнче бик яхшы барганнар. Авылны чыккач инде сигез туган берләшеп Йосыфтан үч алырга теләгәннәр. Күтәреп тә йөртмәгәннәр, өстерәп йөрткәннәр, кайсылары типкәләгән, кайсылары суккалаган. Йосыф еларга тотынган.

---

[1] Ирек ачу – күңел ачу.

– Сез мине әтиемнән шулай җәберләргәме, кыйнаргамы алып киттегез, абыйларым? – дигән. – Әтием бит алай итәр өчен җибәрмәде.

Коега салырга булалар абыйлары Йосыфны.

– Үзеннән-үзе үләр, без әти каршында да, Тәңре каршында да гөнаһлы булмабыз, – дип, барысы бер фикергә килгәннәр.

Йосыфны бер тирән кое янына алып килгәннәр. Кое төбенә салганчыга кадәр, әтигә ничек җавап бирербез, дип төрле киңәшләр корганнар.

– Без әтигә болай дип җавап бирик. Әнә очып барган бер карганы үтерик тә аның канын Йосыфның күлмәгенә буйыйк. Кайткач әтигә, Йосыфны бүре ашады, без ау ауларга киткән идек, ераграк киткәнбез, ерткыч җанварлар килеп ашап киткәннәр, диярбез. Җәнлекме, бүреме ашап киткән. Менә аның канлы күлмәге, дип китереп бирербез, – дигәннәр.

Шул киңәш белән эш итеп, Йосыфның күлмәген салдырганнар, үзен кое төбенә салганнар. Карганың канын сөртеп, әтиләренә күлмәген алып киткәннәр. Әтиләре, сигез улы кайтып, алар арасында Йосыф кайтмавын күргәч, бик куркынган.

– Кая китте Йосыфым? Кая калды? Нигә алып кайтмадыгыз? – дип, болардан сораша башлаган.

Болар өйрәтелгәнчә сөйләп биргәннәр һәммәсе. Менә, имеш, ауга киткән идек, ераграк киткәнбез. Кайтуыбызга Йосыфны бүре ашап киткән. Менә ертык күлмәге генә калган, дигән хәбәр белдергәннәр.

Якуб бик җылаган:

– Юк, минем баламны ашаган бүрене тотып китерегез. Ул ни сәбәптән минем баламны ашаганын үз теле белән сөйләсен, – дигән.

Шуннан балалары кырга кире киткән. Юлда баручы гөнаһсыз бер бүрене тотып, менә шул бүре Йосыфны ашаган, дип, әтиләре каршына китергәннәр.

Якуб бүрегә караган да сорау ала башлаган.

Якуб әйдер: Йосыфымны нәтә җидең,
Күлмәгене ертмадың, бөтен куйдың?
Нәма нидән халикъдан[1] куркумадың?
Пәйгамбәрне мәхрүм, мәхзүн[2] куйдың имди.

---

[1] Халикъ – бар кылучы, Алла.

[2] Мәхзүн – кайгылы.

Бүре телгә килгән.

> Әйдер: валлаһ, Йосыфыңны мин күрмәдем,
> Һәм дәхи кайдалыгын мән белмәдем.

Шуннан соң әтисе:

– Бу бүре үзе дә кайгы-хәсрәтле, минем шикелле баласын югалткан. Илтегез аны каян алдыгыз шунда. Сахра буенча баласын эзләп йөрсен, – дигән.

Уллары бүрене илтеп куйганнар. Бүре үз юлы белән баласын эзләп киткән.

Якуб һәр көнне, һәр төнне Йосыфы турында елап үткәрә торган булган. Күзләре сукырайган баласының хәсрәтеннән, күрмәс булган. Үзе картайган.

Беркөнне туганнары:

– Әйдәгез, теге кое янына барып карыйк. Анда Йосыф әле үлмәде микән, – дип, җыйнаулашып әлеге кое янына киткәннәр.

Карасалар, кое янына кәрванчылар туктаган. Сирәк кенә очрый торган кәрванчылар узган-барганда бу коеның берәр кашыклап булса да суын җыеп ала торган булганнар. Хәзер инде бу кое кипкән. Карасалар, анда бер ир бала утыра.

– Мине алыгыз! Туганнарым мине коега ташлады, – дип кычкыра.

Шуннан болар сиксән метрлы бау төшереп, Йосыфны тартып чыгаралар. Менә шул вакыт Йосыфның туганнары килеп чыга. Бу кәрванчыларга сүз кушалар.

– Нишләп сез моны алдыгыз? Ул кое төбендә ятсын иде. Нигә кирәк ул сезгә? Ул алдакчы, карак. Ул безнең колыбыз. Без аны кое төбенә салып җәзаладык, – дигәннәр.

Йосыф, ни әйтергә дә белмичә, туганнарын тик тыңлап утырган. Шул вакыт аның кайчандыр көзге алдында үзенең матурлыгына сокланып, «мин кол булсам, бәһамә җитәрлек акча да булмас иде», дип уйлаганы исенә төшкән. Бу көферлек булгандыр инде, дигән дә эченнән генә үзен тиргәгән.

Туганнары, бу безнең кол, дигәнгә каршы кәрванчылар:

– Алай булса безгә сатыгыз ул колыгызны. Без аны үзебез белән алып китәбез, – дигәннәр.

Анын гүзәллегенә сокланып, бәһасе күпме торуын сораганнар. Туганнары:

– Карак, качак колның бәясе күпме булсын! Күпме бирсәгез дә ярый, – дигәннәр.

Кәрванчылар, бик әз акча биреп, Йосыфны кол итеп алып киткәннәр. Аны бер иң арттагы дөягә утыртып, юлга чыгып киткәннәр. Йосыфлар авылы аша үткәндә каберлек өстенә җиткәннәр.

Дөя Йосыф әнисенең кабере яныннан үтеп бара икән. Йосыф аяк-кулы бәйләнеп утыра. Әнисе кабере өстендә җылап, шунда төшеп калган. Кәрванчылар әйләнеп карамый байтак юл үткәннәр. Йосыф әнисе кабере янында күп җылаган, бәхетсезлеге турында сөйләгән.

Күпмедер үткәч, кәрванчылар әйләнеп карасалар, Йосыф юк, аның дөясе буш бара. Болар гаҗәпкә калганнар:

– Әйе, качак, дигәннәр иде бит аны. Менә күрсәтте дә инде үзен, – дип, иң усал бер кешене аңа җибәргәннәр.

Бу усал кол аяк-кулы бәйле Йосыфның әнисе кабере өстендә елап ятуын күргән. Аны-моны сорамый, үзенең тимер очлы камчысы белән Йосыфка кизәнеп суккан да ул:

– Синең ияләрең дөрес әйткән, син чыннан да качак икәнсең, менә бер хатаңны күрсәттең инде, – дигән.

Йосыф үзенең әнисе каберенә бәхетсезлеге турында гына сөйләргә төшеп калуын әйткән.

– Мин бит кол түгел, мине туганнарым үч алыр өчен генә сезгә саттылар, – дигән. – Әтиемнең иң сөекле улы булганга көнләшеп, алар мине кол итеп саттылар, – дип аңлаткан.

– Бусы тагын алдау. Синең икенче хатаң да беленде. Әле син ялганчы да икәнсең, – дип, тагы камчы белән суккан. – Әйдә, икенчеләп качсаң, сине бөтенләй кыйнап үтерербез, – дип алып киткән.

Яңадан сәфәр чыкканнар. Озак та бармый, боларның баш түбәсендә калфак кадәре генә болыт күтәрелгән. Бу болыттан боз яварга тотынган. Боз шундый көчле булган, кәрванчыларның йөзләрен, борыннарын канаткан, башларын тишкән, кулларын каерган. Бу кешеләр барысы җәзаланган боз яңгырыннан. Шулар арасында барган Йосыфка бер боз да төшмәгән. Болар, шуны күреп, монда ниндидер хикмәтле хәл бар, дип уйлаганнар. Бу колның бер җире яраланмагач, аның сүзләре чын булуына ышанганнар. Аны бүтән рәнҗетмәскә булганнар, кул-аягын чишеп, ireккә җибәргәннәр.

Барганнар, барганнар да болар, үзара киңәшкәннәр.

– Мондый гүзәл колны сатсак, безгә күпме акча керер! Без аны патшага илтеп тапшырыйк. Патша безгә аның өчен алтын белән акча түләр, – дип килешкәннәр.

Патша сараена килеп җиткәч, хәбәр биргәннәр. Патшаның ир баласы булмаган. Ул Йосыфны үзенә балалыкка алырга уйлаган. Хәзер шунда тукталабыз да Зөләйха турында сөйләргә күчәбез.

Зөләйха патша кызы була. Әтисенең тезе өстенә башын куеп, калгып киткәндә күз алдына бик матур бер егет килеп баса. Зөләйхага әйтә:

– Мин Мисыр патшасы Йосыф булам, – ди.

Шул вакыт Зөләйха уянып китә. Уянса, бу төш кенә булганын белә. Шуннан бу төшен беркемгә сөйләми, эчтән генә тына. Үзе, дөресме бу, юкмы соң, дип, һәрвакыт уйланып йөри башлый.

Шулай әтисенә дә, беркемгә дә белдермичә, бер ел вакыт үтә. Бер ел үткәннең соңында Зөләйха тагын төш күрә. Тагы шул ук егет, «Мин Мисыр патшасы Йосыф булам», дип тора имеш.

– Моннан бер ел элек бу төшне күргән идем, тагы шул ук матур гәүдәле, күркәм йөзле егет Йосыфны күрдем, – дип уйлап йөри.

Ашамый-эчми, йокламый. Әтисе, сарай кешеләре гаҗәпләнә, бу ни хәл булды икән Зөләйхага, диләр, кайгырыша башлыйлар.

Көннәрдән бер көнне патша Зөләйханы үзенең каршысына чакырып ала:

– Кызым, сиңа ни булды? Син көннән-көн кибәсең, суласың, нурлы йөзләрең саргайды. Күзләрең моңлы карый башлады, – дип сорый әтисе Зөләйхадан.

Зөләйханың әтисе аның һәр сүзен, һәр теләген үтәгән, аның турында кайгыртып торган. Зөләйха аңа үзенең бер еллык серен сөйләп бирергә булган.

– Синең итәгеңә башым куеп калгып киткән арада, моннан бер ел элек төшемдә бик матур егетне күргән идем. Ул, Мисыр патшасы Йосыф булам, диде. Янә бер ел үткәч, мин шул ук төшне күрдем, әтием. Һәрвакыт шул күз алдымда, мин бер эш тә эшли алмыйм. Мин синең бердәнбер кызың, җибәр мине Мисыр иленә, – дип, әтисеннән үтенә.

Әтисе әйтә:

– Кызым, кәрван белән барганда өч айлык юл бит ул. Анда ничек барып җитмәк кирәк? Бик зур азапларга очрарсың.

Шулай да, Зөләйха бик үтенеп сорагач, аны, кәнизәкләрен, ялчыларын, колларын, күп маллар төяп, кәрван белән Мисыр иленә озата.

Юлда азаплар күреп, суга интегеп, кызу көннәрдәге эсселеккә түзә алмыйча, дөяләре дә, кайбер картрак коллары да һәлак булалар. Өч айда болар Мисыр патшасына килеп җитәләр, патшага хәбәр бирәләр:

– Зөләйха исемле кыз Мисыр патшасына гашыйк булган. Бик бәяле, затлы бирнәләре белән сезгә кәләш булып килә, – дип хәбәр бирәләр.

Патша исә Йосыфка бөтенләй охшамаган, карт, ямьсез кеше булып чыга. Ризалыгын белдереп, Зөләйханы бирнәләре белән, коллары, кәнизәкләре, яучылары белән сарайга кертергә рөхсәт итә. Патшаны күрүгә Зөләйха:

– Бу түгел, мин ялгыштым, миңа ул кирәкми, – дип җылый башлый.

Кире кайтып китәргә уйлый. Ләкин ни азык, ни су, ни акча калмаган. Кайбер кешеләре дә һәлак булган. Дөяләре дә бик арган, кешеләре дә хәлсезләнгән. Шулай булгач, кире кайтып китәргә һич мөмкин түгел.

Кәнизәкләре Зөләйханы юаталар:

– Син бит төшеңдә Мисыр патшасын күрдең, Мисыр патшасы шул була инде. Ни хәл итмәк кирәк? Син бит үзең теләп килдең. Бәлки төшең дөрес булмагандыр, – диләр.

Зөләйха күнгән кебек була. Мисыр патшасына күренми, кәнизәкләрен генә йөртә аның янына. Патша кызы Зөләйха сүзенә бер кәнизәге дә каршы килә алмый. Ул кушкан сүзләрне үтиләр.

Көннәрдән бер көнне, шулай яшәп яткан вакытта, сиксән метр тирәнлектәге коедан тартып чыгарган коллары белән кәрванчылар килеп җитә. Бу кол – унике яшьлек Йосыф була. Аны Зөләйха белән Мисыр патшасы каршына китерәләр.

– Сезнең балагыз юк, падиша. Сезгә бер кол китердек. Бәлки бала итәрсез, бәлки колыгыз булыр, – дип, аның пәрдәсен күтәреп җибәрәләр. Йөзен ачуга кояш кебек балкып киткән гүзәллеген күрәләр.

Зөләйха:

– Менә мин төшемдә күргән шул бала бит! – дип, иң якын кәнизәкләренә белдерә. Ире патшага белдерми.

Патша:

– Күпме хакы бу баланың? Без аны балабыз урынына алырбыз. Безнең ир балабыз юк, – ди.

– Гүзәллегенә аның тиң юк. Бәһасе үзе күтәрерлек алтын, – дигәннәр.

Патша икеләнеп тора. Зөләйха патшага:

– Безнең ир балабыз юк. Бу бала безнең тормышыбызга ямь кертер иде, – ди.

Патшаны күндерә дә, сарайдагы бөтен алтыннарны китерергә куша. Үлчәүнең бер ягына Йосыфны, икенче ягына үз авырлыгы алтын куялар. Кәрванчылар күп алтын алып кайтып китәләр.

Патша да гүзәл Зөләйханың сүзеннән чыкмый. Шуннан Йосыф бу патша белән Зөләйхага бала булып кала.

Көннәр үтә. Йосыф үсә. Матур бер егет булып җитә. Аның гүзәллегенә, күркәмлегенә сокланмаган бер кеше калмый. Үзенең асрау баласы булуга карамастан, Зөләйха Йосыфка гашыйк була. Төшендә күргән егетне танып, көне-төне аны гына уйлап йөри.

Көннәрдән бер көнне патша ауга китә. Йосыф бик матур киенгән, үзенең бүлмәсендә утыра. Шул вакыт Зөләйха:

– Патша өйдә юк, Йосыф белән сөйләшергә дә булыр. Ничә еллар йөрәгемдә саклап йөргәнемне, мәхәббәт серләремне аңлатсам да ярый торган вакыт, – дип, Йосыфның янына керергә тели.

Йосыф бүлмәсенә керә, Йосыфның чәчләреннән сыйпый, аннан иркәләргә тели. Йосыф уңайсызланып, читкә китә. Зөләйха үзенең ни өчен кергәнен, дөньяда аның өчен генә яшәгәнен белдереп, мәхәббәт серләрен аңлата. Шуннан соң Йосыф ни әйтергә белми аптырап кала. Зөләйха Йосыфны кочакларга тели, аның янына ул җиде кат ишекне ябып кергән була.

Йосыф әйтә:

– Син минем әнием буласың. Үзе тудырган әнием булмасаң да, син минем әнием саналасың. Ничек мин үз әниемә гашыйк булыйм да мәхәббәт тотыйм? Ана буларак кына мин сине ярата алам.

– Ә, син каршылык күрсәтәсеңме? Мин синең өчен ничә еллар янып көям. Син минем йөрәгемне дә аңларга теләмисеңме? – дип, Зөләйха Йосыфка бәйләнә башлый.

Кочаклап алыйм дигәндә Йосыф йөгереп кача. Качмасын, дип, Зөләйха Йосыф артыннан йөгерә. Бер ишекне ачып чыга, икенчесен

ача, шулай җиде ишекне ачып чыга, Йосыфның җилән итәгенә тотына. Егет тартылуга – чабуы ертылып китә. Йосыф качып котыла. Шуннан Зөләйха бик үчләнә.

– Ярар, мин сине нишләтергә белермен! Мин сиңа аңлатырмын әле кем икәнемне, – ди.

Ире кайткач, бу хәбәрне иренә сөйли.

– Менә без асрарга бала алдык. Ул миңа мәхәббәт сүзләре сөйли башлады. Мин бүлмәдә торган вакытта бүлмәмә кереп, мине кочаклый башлады. Мин аның белән тарткалашканда аның җиләне ертылды, – ди.

Патша бик ачулана.

– Ничек ул алай, асрау бала булып, минем хатыныма әдәпсезлек күрсәтә? Мин аны хөкемгә бирермен, – ди.

Йосыфка хөкем каршында җавап бирергә туры килә. Судья, эшне тикшергәч, мондый нәтиҗәгә килә:

– Әгәр дә Йосыф сине кочаклаган икән, син аның белән тартышкансың икән, Йосыф җиләненең алгы өлеше ертылырга тиеш иде. Ләкин Йосыфның бит арткы итәге ертылган. Ничек соң алай булган?

Шуннан Йосыфның үзеннән сөйләтергә булганнар.

Йосыф:

– Ул мине үзе артымнан куды, куган чакта арткы чабуым өзелде, – дигән.

Судья:

– Менә бусы дөрес булыр. Нигә сиңа гаепсез кешене гаепләргә иде? – дигән.

Ләкин патша үзенең хатынын гаепле санамаган.

– Бу бала чаядыр. Аны болай калдырырга ярамас йортта. Ул асрау бала. Мин аны үзем хөкем итәм. Зөләйха нинди киңәш бирер, шул хөкем булыр аңа, – дигән.

Зөләйха унике ел зинданда тотарга боерык биргән. Йосыфны шунда ук унике елга зинданга салганнар. Зинданда иптәшләре төш күрсә, Йосыф аларны юрый торган булган.

Патшага каршы булган бер кеше төш күргән:

– Мин кызыл камыт кигәнмен, Йосыф, ни булыр икән? – дигән.

– И, гаебең булмаса да, патша синең муеныңа кылыч куярга тели, – дигән.

Таң белән бу кешене, зинданнан алып чыгып, палачлар башын чапканнар. Иптәшләре шуннан белгән кызыл камытның ни икәнен. Шуннан соң Йосыфка тагын бер иптәше төшен сөйли:

– Син дөрес әйтәсең, ахры. Бүген төшемдә җиде симез сыер, җиде ябык сыер күрдем. Бу ни булыр икән?

– Җиде симез сыерың халыкка җиде ел туклык елы булыр. Халык шул елларда ашлык запасын хәзерләп куярга тиеш булыр. Ә җиде ябык сыерың шуны күрсәтә, җиде ел ачлык булыр, – дигән.

Дөрестән дә бу шулай булган. Мисыр халкы җиде ел туклык күргән, аннан соң җиде ел ачлык күргән.

Шулай торганда патшалыкка яу килә, патша яуга китә. Зөләйха ире урынында кала. Йосыф инде җиде ел зинданда яткан була. Шул вакыт патшаның үлгән хәбәре килә. Зөләйха Йосыфны зинданнан чыгара да һаман аны үзенә каратырга тели. Зөләйха Йосыфны саф, чын мәхәббәт белән ярата. Үзе Йосыфтан олырак яшьле була. Йосыф аны үги анасы буларак хөрмәт итә. Ләкин мәхәббәт тотарга тиеш түгеллеген аңлый, аның мәхәббәтен дә кире кага.

Зинданнан чыгаргач, Зөләйха аны үзенең асрау улы дип йөртә. Үзе һаман җылый, күзләре сукырая. Күзләре сукырайгач, патшалыкны Йосыфка бирә. Менә шуннан инде Йосыф Мисыр патшасы була. Һәркем аның Мисыр патшасы булуын тели.

Зөләйханың мәхәббәте көннән-көн арта. Мисыр илендә гайбәт тарала. Имеш, Зөләйха үзенең колына гашыйк булган, аны ире дә белгән булган. Шул Йосыф өчен җанын фида кыла икән, дип, хатыннар гайбәт тарата башлаганнар.

Зөләйха, бу гайбәтне ничек юк итим икән, ничек бу хатыннарга мәхәббәтем саф булганы хакында сөйлим икән, дип уйлый.

Бер көнне дүрт йөз хатынны сараена кунак итеп чакыра. Барлык хатыннарга да берәр тәлинкә, берәр пычак китереп тоттыра. Йосыфның чәчләрен үзе тарап үреп, зиннәтле киемнәр киендереп, пәрдәсен йөзенә ябындырып, әлеге дүрт йөз хатын утырган зур залга кертә. Бу хатыннар алдына китереп, Йосыфның битеннән пәрдәсен ачып җибәрә. Бер минут та тотмый, алып чыгып китә. Бичара хатыннар моны күргәч һуштан язалар. Йосыфның матурлыгын күреп бары да гашыйк булалар.

Хәзер Зөләйха бу хатыннарга берәр җимеш китереп бирә. Бер кулларына җимеш, бер кулларына пычак тоттыра.

– Тәлинкәгә куегыз да турый башлагыз, – дип боера.

Үзе шул вакыт тагы Йосыфны дүрт йөз хатын утырган бүлмәгә кертә. Барлык хатыннар, күзләрен Йосыфка текәп, җимеш тураган бармакларын кисәләр. Үзләре бармаклары киселгәннең әрнүен дә тоймыйлар. Йосыфның чибәрлеге сихерли шикелле боларны. Шуннан Йосыфны алып чыгып китәләр. Зөләйха дүрт йөз хатынның алдына килеп баса:

– Менә күрдегезме? Үз кулларыгызны, үз бармакларыгызны җимеш итеп турадыгызмы? Белдегез инде хәзер, минем гайбәтемне ни өчен сатасыз икән. Бер генә минут күрдегез дә бармакларыгызны турадыгыз. Ә мин Йосыф кайгысыннан ничә ел янам. Аны күргәнемә генә җиде ел, аннан соң күпме яндым. Шулай да мин түзәм, бармакларымны да тураганым юк. Сабырым сездән көчлерәк икән, – дип, хатыннарга үзенең бәетен әйтә.

Хатыннарның исләре китә:

– Дөрес, Зөләйха, синең сабырлыгың безгә караганда көчле икән, – диләр.

Шуннан соң Мисыр хатыннары Зөләйха турындагы бу гайбәтне сөйләмиләр. Һәрберсе үзләре гайбәткә кала. Йосыфны бер күреп тә гашыйк булмау мөмкин түгел икән, диләр.

Бервакыт Йосыф патша ат өстендә сарай алдыннан үтеп барган була. Уң кулында камчысы. Зөләйха Йосыфның каршысына чыгып, килгән юлында көтеп тора. Җылап күзләре сукырая башлаган, яхшы күрми дә. Йончыган, йөзе нурсызланган, Йосыфка булган мәхәббәтеннән картайган Зөләйха. Юлда утырып тора икән.

Йосыф:

– Нигә бире утырып торасың? – дип сүз кушкан.

Зөләйха әйткән:

– Йосыф, сиңа бер генә сүзем бар. Бир әле камчыңны, – дигән.

Йосыф камчыны Зөләйхага сузган. Зөләйха камчы сабын авызына китереп өргән дә шунда ук Йосыфка тоттырган. Камчы сабы янып китәр дәрәҗәдә кызу булган. Йосыф кулы пешүдән камчыны ташлап җибәргән.

Шуннан соң Зөләйха:

– И Йосыф! Син камчыны тоттың да ыргыттың. Кулың пеште. Минем ничә еллар буе йөрәгемдә шул ялкын янып тора, мин түзәм. Ә синең кулың минем бер өргән сулышымдагы кайнарлыкка, утка да чыдамады. Күр минем мәхәббәтем ничек көчле икәнен! Шунда да исбат итмәсәм, ничек итеп аңлатыйм сиңа? Бу бит ничә йөздән

бер өлеше генә. Менә мин ничә еллардан бирле гыйшык утында янам, – дигән.

Йосыф бер уйга килгән.

– Зөләйха, мин сине аңлыйм. Шундый ялкын эчендә син тугрылыклы мәхәббәт белән генә түзә аласың, шулай сөя аласың икән. Мин синең барлык газапларыңны алам, мәхәббәтеңне үземә кабул итәм, – дигән.

Шуннан Зөләйхага өйләнергә риза булган. Зөләйха шатлана, аның эчендәге кайгылары бетә бара. Көннән-көн йөз сарылыгы кими. Ул бит әле яшь. Картаеп җыерчыкланмаган йөзләре, кайгыдан гына. Икәү бергә тора башлагач, Зөләйха бөтенләй башка кешегә әйләнә. Матурлыгы, гүзәллеге кире кайта. Йосыф аны күреп соклана, тиң итә. Йосыф – Зөләйханың мәхәббәте аларның бәхетле, тигез гомер итүләре белән бара.

Шуннан ачлык ел килеп җитә. Дөрестән дә җиде ел халык ачыга, интегә.

Көннәрдән бер көнне Якубның уллары әтиләренә бер хәбәр ишетеп кайталар.

– Әти, илдә ачлык. Мисыр иленең патшасы бик юмарт күңелле икән. Ачка үлә торган кешеләргә ярдәмләшә икән. Анда барып карасак ярамасмы икән, – дигәннәр.

Әтиләре риза булган. Уллары чыгып киткән. Мисыр патшасы алдына килеп басканнар.

– Мисыр патшасы бик миһербанлы, дип ишеттек. Безгә сукыр атабыз хакына, туганнарыбыз хакына, ачтан үлмәслек кенә булса да ярдәм итсәң иде, – дигәннәр.

Йосыф үзенең туганнарын танып алган да:

– Минем бүлмәмә керегез! – дигән. Шунда аңа сигез туганы сәҗдә кылганнар.

Йосыф:

– Мин сезгә ярдәм итәрмен. Менә бер олау иген төяп алып китәрсез. Әтиегез ни хәлдә? Ул нишли? Дөньядамы? – дигән.

Болар әйткәннәр:

– Әтиебез дөньяда. Тик аның күзләре күрмәс булды. Безнең бер туганыбыз бар иде, шул туганыбыз үлгәннән соң ул елап, сукырайды.

Йосыф пәрдәле булгач, белмиләр. Йосыф биргән малларны алып, кайтырга чыгалар. Йосыф озата чыга.

– Сезнең тагын туганнарыгыз бармы? Алар исәннәрме? – ди.

– Бар. Атабыз бер, анабыз башка туганыбыз Ибне-Әмин бар, сеңлебез Динә бар.

– Ә ул Ибне-Әминне нигә алып килмәдегез?

– Атабыз аны җибәрми. Сөекле улым Йосыфны адаштыргач, Ибне-Әминемне дә юк итәрсез, ди ул.

– Ярар, башка вакытта Ибне-Әминне дә алып килегез, әтиегезгә сәлам әйтегез, – ди Йосыф.

Моны кайтып әтиләренә сөйләгәч, әле улы һаман да исәндер, дип өметләнеп яшәгән ата, бу сүзләрне әйтүче кеше Йосыф үзе түгел микән, дип шикләнә башлаган.

Икенче елны Ибне-Әминне дә алып китәргә кушкан.

– Әгәр аны да адаштырсагыз, шул минутта үләрмен. Аталык хакына Ибне-Әминне саклап йөртегез, – дип әйтеп калган.

Уллары, ант итеп, Ибне-Әминне алып киткәннәр. Йосыф боларга тагы ашлык биреп җибәргән. Ләкин Ибне-Әминне бер бүлмәгә чакырып, үзенең кем икәнлеген әйткән, барысын сер итеп кенә сөйләшкәннәр.

– Мин сине янымда калдырыр идем, – дигән Йосыф.

– Ә юк, мин монда калсам, әтиебез бик кайгырыр, шунда ук үләр, – дигән Ибне-Әмин. Йосыф шундый фикергә килә. Ике олау иген бирә. Ибне-Әмин саклый торган олауга алтын тустаган яшерә. Капканы чыгып киткәндә, алтын тустаганны урладылар, дип тентү ясата. Алтын тустаган Ибне-Әмин олавыннан чыккач, аны хөкемгә тарткан кебек алып кала. Әтиләренә язып җибәрә: «Ибне-Әмин ышанычлы кулда. Мөмкин булса, үзегез дә килеп чыгыгыз».

Агаларына:

– Үзгә вакыт атагызны да алып килегез, – дип әйтеп җибәргән.

Болар хатны тапшыргач, әтисе ул кешене күрер өчен ашкына башлый. Икенче барганда әтиләрен дә, Динәне дә алып китәләр. Инде ун туганы моның алдында сәҗдә кылалар. Шул вакыт Йосыф үзенең пәрдәсен ача:

– Минә кайчан әтиемнең төш юраганы дөрескә килде. Ун туганым минем алдымда сәҗдә кылалар, – дигән.

Шуннан Якуб карт улын кочаклап, елап, яңадан күрә башлый.

– Сез, туганнарым, миңа яхшылык эшләмәдегез. Ә мин сезгә яманлык белән җавап бирмәдем, чөнки сез минем кан

кардәшләрем, – дип, Йосыф әтиләре алдында туганнары моны нишләткәннәрен сөйләп бирә.

– Мин сезне гафу итәм. Үземнең патша сараемда сезне рәхәттә яшәтер идем, – дип, бу туганнарын үзендә калдыра. Шулай бәхетле тормыш кичерәләр.

* * *

Халык телендә бу әсәр «Йосыф–Зөләйха» дип түгел, күбесенчә нәкъ шулай «Йосыф китабы» дип йөртелә. Бу аның Кол Гали «Кыйссаи Йосыф»ыннан таралуын күрсәтә. Аның төрле эпизодлары, мотивлары гына аерым сөйләнгән вариантлар бар. Кол Гали әсәренең татар халык иҗатындагы урыны турында Н. Хисамов хезмәтләре мәгълүм. Мәсәлән, «Йосыф китабы»ның көйләп укылуы турында ул болай дип яза: «Көйләп уку өчен язылган әсәрне көйләп башкару традициясен яңадан кайтарырга кирәк. Хәзер музыкаль белемле укучылар күбәя бара. Киләчәктә «Йосыф кыйссасы» кичәләре уздырырга мөмкин булыр. Шушы максатны күздә тотып, биредә әсәрнең бик борынгы һәм, әйтергә кирәк, уникаль бер көй үрнәген бирергә кирәк таптык. Аны мин әтиемнән отып калган идем, әтием Шаһвәли исә үзенең мөгаллимә әнисе Сабира абыстайдан откан булган. Көйнең салмаклыгы һәм моңы поэманың эмоциональ эчтәлегенә бик туры килә.

Шуның белән бергә көйнең халыкка киң таралган үрнәген дә китереп үтәбез. Йөгерек уку өчен кулай, башкару өчен дә ансатрак. Ул вариантны мин әнием Һаҗәрдән отып калдым. Азакны хөкемне исә хөрмәтле укучының үзенә калдырыйк» (Н. Хисамовтан).

Вариантларның берсе Чүпрәле районы Мунчәли авылында Һаҗәр Сөнгатулла кызы Зәйнетдиновадан (1895 елда туган) Н. Хисамов тарафыннан магнитофонга язып алынган. Һ. Зәйнетдинова бу әсәрне мәшһүр Кол Гали поэмасыннан гына түгел, борынгы китаплардан да яхшы отып калганын күрсәтә. Кайбер урыннарны көе белән әйтә.

Н. Хисамов язып алган көйләрдән ике үрнәк:




=96
1. Гъәзиз Йосыф тәмам унбер я–шәр и–де,
Йагъкуб сәүче тезлә–рен–дә йок–лар и – де,
йок–лаганда бер гаҗәп төш Йо–сыф күр–де,
ю–ра– лышын а– та–сыннан сорый ин – де.
2. "Туар ко–яш, тулган ай һәм ун–бер йолдыз
барсы миңа тө–шемдә баш и –де тәп-тез,
бу төшем–не шулай күрдем һичбер шиксез,
йа әт– кә–ем, шу–ны ми–ңа ю–ра ин– де."

## ҮТКӘННӘРГӘ КАЙТУ

Институтның татар фольклорчылары 1955 елның 22 июненнән 22 июленә кадәр Чүпрәле якларында фәнни экспедициядә булганнар (экспедиция җитәкчесе Х. Х. Ярмөхәммәтов). Биредә шул экспедициядә катнашкан Хәмит Ярми (Ярмөхәммәтов), Халидә Гатина, Миншәех Зәбиров тарафыннан язып алынган материаллар тәкъдим ителә. Алар Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана.

### Дастан

Кошлар әйтә, нәләр булды, Хода зикре илә булды,
Диңгез култыгында урным мән балага мохтаҗ булдым.

Эчем елый, телем сөйли, бөтен кайгыларны җыйгач,
Нә кадәрле җыласам да, кая инде миңа бала.

Бүләк итеп бала бирдең, аны мәннән ерак кыйлдың,
Әй, Раббем, әя мәүлам тәкъдиреңдин, диеп белдем.

Ана мохтаҗдыр балага, бала мохтаҗдыр анага,
Күрергә юк һич дөньяда, сабырлык бирсен Алла.

Йөрәгем парәсе идең, күземнең карасы идең,
Үземнең сердәшем идең, йөрәгем өзеләдер, балам.

Кичен ятып, бер төш күрдем, аккош булып очып йөрдем,
Дөньядагы хәсрәтләрнең барысын да үзем күрдем.

Бу хәлемне кемгә сөйлим, галимләргә, зирәкләргә,
Ни дарулар булыр икән, янган, көйгән йөрәкләргә.

*Кече Чынлы авылында*
*Абдрәхимовадан (80 яшь)*
*язып алынды*

## Бәхет күлмәге

Борын заманнарда бер патша авырып киткән, ди. Хәле начарланганнан-начарлана баруын күреп, патша: «Минем авыруыма дару тапкан кешегә бөтен байлыгымны, патшалыгымны бирәм», – дигән хәбәр тараткан, ди.

Шушы ук патшалыкта багучы бер карт бар икән. Патша бу картны яштерә дә:

– Минем авыруыма берәр дару таба алмассыңмы? – ди.

Карт:

– Әгәр дә син үз патшалыгыңдагы иң бәхетле кешене табып, шуның күлмәген кисәң, бу авыруыңнан терелерсең, – ди.

Патша шул ук сәгатьтә үзенең ике вәзирен чакырып ала да: «Барыгыз, – ди, – минем патшалыгымдагы иң бәхетле кешене табып, шуның күлмәген салдырып алып кайтыгыз», – ди.

Ике вәзир чыгып китеп, бик күп җирләр йөриләр, бик күп кешеләрне күрәләр. Кемне генә күрсәләр дә, кем белән генә сөйләшсәләр дә, һәркем үзенең тормышыннан зарлана икән, ди. Ни хәтле җир йөреп, таулар, елгалар, күп авыллар үтеп, «эшем юк, тамагым тук, кайгым юк» дигән бер кешене дә очратмаганнар, ди. Шулай йөри торгач, бу ике вәзир барып җиткәннәр, ди, авыл читендә генә торган бер кечкенә генә йортка. Бу йортның ишек алдына керсәләр, бер кеше коенып тора икән, ди. Вәзирләрне күрү белән теге кеше: «Әйдә, өйгә керегез», – ди икән. Ә үзе бер туктаусыз: «Ай, рәхәт тә инде, дөньяда миннән дә бәхетлерәк кеше бар микән?» – дип, бертуктаусыз сөйләнә икән, ди. Моны күреп, вәзирләр «бәхетле кешене таптык» дип бик шатланганнар, ди.

Теге кеше киемнәрен киеп өйгә керү белән үк: «Шулай, туганнар, бу дөнья дигәннең бер дә рәхәте булмады, алай карасаң да кайгы, болай карасаң да кайгы», – дип, үз тормышыннан зарланган, ди.

Шулай итеп, бу ике вәзир бөтен патшалыкны йөреп чыкканнар, ди, ләкин бер генә дә бәхетле кеше таба алмаганнар, ди. Патша да бәхет күлмәген кия алмыйча үлеп киткән, ди.

*Кече Чынлы авылында*
*Кәримә Маликовадан (26 яшь)*
*язып алынды*

## Аракы сатучы һәм җен малае

Борын-борын заманда була ярлы бер крестьян. Аның биш баласы була. Тормышы аның начар, икмәге дә булмый, өе дә бик начар була. Аның бер аты була. Шул атны җигеп, бер көнне байларга сукаларга китә. Эшкә баргач, бай анарга икмәк бирә ашарга. Ул көн буена эшләп бик ачыккан була. Шуннан соң ялга туктаган вакытта икмәкне ашарга тотына. Ашарга тотынгач, икмәкнең яртысын ашый да, өйдә калган балалары исенә төшә дә, икмәкне ашаудан туктала да балаларга алып кайту өчен яшереп куя. Тагын кичкә кадәр эшли, ачыга. Шуннан арбага килә дә калган икмәкне дә ашарга дип эзләнә башлый. Ләкин икмәкне таба алмый, бу вакытта икмәкне җен малае урлап киткән була. Җен малае икмәкне урлап китә дә җеннәр патшасына әйтә: «Мин бер крестьянның икмәген урладым», – дип. Җеннәр патшасы әйтә: «Ул сиңа икмәген урлаган өчен нәрсә әйтте?», – ди. Малай әйтә: «Миңа тагын Алла ярдәм бирер әле», – дип әйтте, ди. Чөнки ул Аллага ышана торган бер крестьян була. Җеннәр патшасы әйтә: «Син аның шулай әйтүенә канәгатьләнеп кайтмаска тиеш идең, сиңа ул җаның җәһәннәмгә китсен, дип әйткәнче торырга тиеш идең. Бар, кире кит», – дип, җен малаен куып җибәрә. Малай крестьян янына кире килә дә анардан үтенә башлый: «Син мине ничек булса да үз яныңа хезмәткә ал», – ди. Крестьян әйтә: «Мин сине хезмәткә алыр идем дә, үземнең дә ашарыма икмәк юк, сиңа түләргә акчам юк», – ди. Җен малае әйтә: «Син акча күпме хәлеңнән килгән кадәр түләрсең, мин кулымнан килгән кадәр хезмәт итәрмен», – ди. Крестьян монарга риза була: «Әйдә, кер, Алла ярдәм бирер, ризык табылыр, эшләрбез», – дип, малайны хезмәткә ала. Җен малае крестьян янында хезмәт итәргә риза булып керә. Хәзер алар икәү кырда эшли башлыйлар. Малай элек крестьян әйткәнчә эшли, аннары төрле зарарлар китерә башлый, крестьян монарга да риза була. Әйдә, эшләсен әле, безгә Алла ярдәм бирер, дип, аның барлык китергән зарарларына риза була.

Бер көнне крестьян, үзе өйдә калып, малайның үзен генә кырга эшкә җибәрә, атын җигеп. Малай кырга бара да, бөтен тауларны, урманнарны, кырларны сукалап кайта. Крестьян кырны барып карый да, монарга да риза була. Аннан соң крестьянның бөтен чәчелгән җирендә дә икмәге була. Шуннан соң крестьян байый,

икмәге җыеп бетергесез яхшы була. Хәзер җен малае әйтә: «Хәзер безнең икмәк күп, мин икмәктән аракы ясыйм, сиңа тагын да күбрәк файда килер», – ди. Крестьян аракының нәрсә икәнен белми, аңламый, күрмәгән була. Шуннан соң җен малае аракыны ясый да крестьянны яшә дә сорый: «Нәрсә, аракы яхшымы?», – ди. Крестьян әйтә: «Ул бигрәк тә яхшы нәрсә икән, мин хәзер, элеккеге яшемә караганда, 20 яшькә яшәреп киттем», – дип җавап бирә. Җен малае шуннан соң тагын да күбрәк итеп аракыны крестьянга эчерә. Крестьян исерә дә ятып йокыга китә. Җен малае крестьянны шулай алдавына шатлана. Аннан крестьян йокыга китә дә, җен малае моны йокысыннан уята башлый. Крестьян әйтә монарга: «Уятма, минем йокым туймаган әле, жаның җәһәннәмгә киткән нәрсә», – дип, җен малаен орыша башлый. Җен малае монарга шатлана да хәзер җәһәннәмгә китә. Анда барып, ул крестьянны шулай алдавын, шуның аркасында төрле бозыклыклар эшләвен сөйли.

Крестьян хәзер йокысыннан тора да аракы эчәргә күршеләрен яшеп керә һәм аларга аракыны сата башлый. Шулай итеп, хәзер крестьян бөтен бозыклыкларга бирелеп китә.

Җен малае хәзер җеннәр патшасына кайтып әйтә: «Крестьянны алдадым, хәзер ул бөтен бозыклыкларны эшли», – ди. Шуннан соң хәзер крестьянны ияртеп китә шәһәргә. Крестьян бер хатынга бәйләнә башлый. Ул хатынның ире өйдә булмый. Шушы вакытта теге хатынның ире кайтып керә. Крестьян теге ирне пычак белән чәнчеп үтерә. Хәзер бу инде кеше үтерүгә дә барып җитте. Шуннан соң крестьянны тотып алалар да асарга хөкем итәләр. Теге җен малае әйтә: «Мин сине асудан коткарам, син хәзер үз динеңнән чык, чукын», – ди. Крестьян чукынырга өлгерә алмый, өч бармагын күрсәтеп калдыра. Шуннан соң җен малае шатлана, шундый кешене дә, үз артыннан ияртеп, төрле бозыклыклар өйрәтә алуына.

Димәк, бу әкияттә, кеше аракы эчкәч, бөтен бозыклыкларны эшләргә дә мөмкин икән, дигән мәгънә салына.

*Кече Чынлы авылында*
*Кәримә Маликовадан (26 яшь)*
*язып алынды*

## Ямщик бәете

Ачы җил, буран тавышы ишетелә,
Киң сахраларда яшь ямщик үтә.

Җиктем чанага пар кара алаша,
Ачы җил, буран, ямщик адаша.

Кычкырам һаман илемә сәлам,
Өметне өздем җанымнан тәмам.

Юллар эзләймен, кулларым туңа,
Ерак та түгел, шунда ук ут була.

Атлар куганда уң беләк тала,
Янып сөйгәнем ятларга кала.

Әйт әнкәемә шушы сүземне,
Кулымнан алып, бир йөзегемне.

Әйт иптәшемә, мине көтмәсен,
Үзенә башка иптәш эзләсен.

Актык сүзләрен әйтеп җан бирә,
Вакытсыз, мескен, кабергә керә.

Ачы җил, буран, йомшак кар ява,
Ямщик атлары моңланып бара.

*Иске Чокалы авылында*
*Юнысов Таһир Юныс улыннан (1900 елгы)*
*язып алынды*

## Үги кыз турында бәет

Әй, иптәшләрем, мин сөйлим сезгә,
Бу эш туры килми һәркемгә;
Ата-анадан туулар яхшы,
Кайгы төште мин ятим кызга.

Көннәр берендә газиз әнкәем
Хәзерләнә инде үләргә;
Үлде әнкәем, мин калдым ятим
Хәсрәт эчендә гомергә.

«Әй, нәнәм, сине яратам бигрәк,
Бу кызыңнан тормыш калмады;
Үтер дә ташла, сугамы ыргыт,
Кайда булса да үтер син аны».

Көннәр берендә эти әйтәдер:
«Кил, Мөршидә кызым, яныма, – диер, –
Яратмыйм сине, торма дөньяда,
Яшь әниеңне тыңламадың да».

Һәм эти әйтә шунда ук миңа:
«Әйдә, кызым, чыгыйк дөньяга;
Карурманнарны, зыяратларны,
Әниеңнен каберен карарга».

Бармыйм, эткәем, барасым килми,
Ниләр бардыр синең фикереңдә.
Барсам да, эткәй, чыкмыйм йөрергә,
Барам әнкәй каберен күрергә.

«Озак тормабыз, тиздән кайтырбыз,
Әнкәеңә сүзләр әйтербез,
Үлгән әниеңнен изге каберен
Төрле чәчәк белән бизәрбез».

Чәчәкләр җыйган, эти әйтәдер:
«Кил, Мөршидә кызым, яныма, – диер, –
Яратмыйм сине, торма дөньяда,
Яшь әниеңне тыңламадың да».

Әти кулында ялтырый пычак,
Җыйган чәчәкләрем бер кочак;
Суйсаң да, эткәй, бәхиллим сине,
Нә эшлисең соң, бәхетем булмагач.

Кара чәчләрем җирдә ятадыр
Айга каршы сызылып, ялтырап;
Әти муеныма пычак  куйгачтын,
Китте бөтен тәнем калтырап.

Пычак суйса да, тиз чыкмады шул
Минем газиз җаннарым;
Әти суйганны белми әнкәем,
Кабереңә тама каннарым.

Үлән эченә сузып салдылар
Минем зифа, матур буемны;
Моңлы тавышта куаклар шаулап
Үткәрәләр актык туемны.

*Иске Чокалы авылында*
*Идрисова Камәрия Әбубәкер*
*кызыннан (1928 елгы) язып алынды*

## Яшьлеген югалткан яшь кыз турында бәет

Каядыр шунда, гөлбакчасында
Яшь кызлар белән йөри идем мин;
Дусларым белән җыйналып бергә,
Кайгы белми йөри идем мин.

Килде бер егет, тотты кулымнан:
«Әйдә, – диде, – бергә күңелле».
Иптәшләремнән, шул чагында ук,
Аерып алып китте үземне.

«Әйдә әле, матур, яратам сине,
Тыңла минем әйткән сүземне;
Кызганам сине, син бит ялгыз», – дип
Суырып үпте ике күземне.

«Күңелсез дөнья син матур кызга,
Бир кулыңны, шат бул инде гомергә;
Дөньяны бергә үткәрик әйдә,
Яшик бергә без мәңге, мәңгегә.

Бәгырем, курыкма, туйлап алырмын,
Бераз уздырыйк шушы вакытны;
Күңелле бергә гомер итәрбез,
Көлдертмәмен надан халыктан».

Егет бик матур, килде күңелгә,
Котыртты бит ул яшь кыз баланы;
Шулай сөйләнеп, шул егет белән
Уздырдык без ике араны.

Бер көн кич белән, бер сүздә булып
Йөрдек таңгача;
«Туйлап алам», дип көйләгән булды,
Шул көнне ул мине алдады.

Эшләр әйләнде бигрәк начарга,
Күңелле иде күңел ачканда;
Дөнья тормышы бик начарланды,
Яшь балакай белән калганга.

Көннәрдә бер көн күрдем егетне:
«Яшь бала белән ташладың мине;
Әйдә, – дим, – безгә, ир балам булды,
Бергә яшик, – дим, – сөярмен сине».

«Юк инде, кызый, юкны сөйләмә,
Мыскыл итмә мин яшь егетне;
Сине белмимен, күрмәдем дә, – ди, –
Хәзер эзлә үзең кебекне».

Инде мин шулай калдым, дусларым,
Егеткә ышанып, төнлә йөрегәч;
Йөремәс тә идем мин аның белән,
Болай буласын алдан ук белсәм.

*Гайнетдинова Латифа*
*Фәсхетдин кызыннан*
*язып алынды*

## Соңгы сүзләр

Беләм, әнкәй, авыр сиңа, саргайгансың, бетә торгансың,
Газиз балам хатлар яза, диеп, хатларымны көтә торгансың.

Көтмә инде, әнкәй, миннән хатлар, үлем килде миңа – балаңа,
Әнкәй, яшь йөрәгем чиксез әрни, түзә алмыйм авыр ярага.

Минем хәлне сез белмисез, үлгәнемә инде ничә көн,
Мин үлгәнлеккә, военкоматтан, булыр сезгә кара печатем.

Тимер пуля, аугач җиргә, кемнәр өчен анда син җәмне,
Әнкәй күрсә, өзелер инде, кан эчендә яткан бу хәлне.

Йөрәк әрни, ярам авыр, бертуктаусыз җиргә кан ага,
Озакламый тәнем суыныр, үлем килә япь-яшь балага.

Әнкәй, мин юк балаң, хатлар килмәс хәзер улыңнан,
Синең улың авыр яраланды немец-фашист аткан пулядан.

Актык минут, актык секунд, соңгы каным тама ярадан.
Хуш инде, әнкәй, хушыгыз, туганнарым, күрә алмыйм сезне яңадан.

Ике кашым бергә тартты, күрмешем өчен тарткан,
Немец кулларыннан үләр өчен, яшьлегем чәчәк аткан.

Бигрәк яшьли үлем килде, үләсем бит һич тә килмәде,
Башым җиргә куеп җан биргәндә су бирергә кешем булмады.

Әнкәй, җаным, рәнҗемә, булмадым эшегезгә,
Тилмереп җан биргән чакта кергәнмен төшегезгә.

Алсу каным җиргә тамган саен яшь йөрәгем әрни, сызлана;
Рәхәт күрми үләм инде, диеп, яшьлегемне җаным кызгана.

Яшь гомеркәй, иртә чәчәк койдың, немец җитте синең башыңа.
Их, кызганыч, япь-яшь егет башын куйды картлар йортына.

Газиз әнкәй, үле гәүдәмне санитарлар кая ташларлар,
Үле гәүдәм шунда черер инде, гәүдәм итен кортлар ашарлар.

Их, әнкәем, бәлки мине «кайтыр» диеп өмет иткәнсең,
Зәңгәр төндә йокламыйча, алсу таңда мине көткәнсең.

Беләсеңме, әнкәй, мин үзем дә тели идем илгә кайтырга,
Туган илгә кайтып, шат тормышта тагын матур чәчәк атарга.

Илгә кайту булмады ул миңа, юкка чыкты теләкләрем,
Балкып кайткан күзләр, сүнде инде тибеп янган йөрәгем.

Ярам авыр, чиксез әрнесә дә, мин бит ышанмадым үлемгә,
Җаннарымны биргән вакытта да тилмердем мин сезне күрергә.

Германия сугыш ачкан безнең башка җитәргә,
Үләсемне белмәдем бит, бәхилләшеп китәргә.

Кара күзем сүнде хәзер, күмелеп калды җиргә улыгыз,
Әнкәй, хәзер минем өчен дога гына кылыгыз.

Яшь егеткә кызганыч ул алсу канын түгәргә,
Мин бәхетсезлеккә булган җеназасыз күмелергә.

Ничек кеше исән калсын, утлар ява җирдән, күгеннән;
Кемнәр кызганмасын яшь егетне, күмелгәчтен җиргә бүгеннән.

Яшьлек вакыт – матур вакыт, туган илдә чәчәк атасы;
Яшь егетнең бүгеннән үк ничек килсен җирдә ятасы.

Шунда язган һәрбер сүзләремне «үзе сөйли» диегез,
Минем калган гармунымны Фидиямә бирегез.

Өйдә чакта гармунымны туйганчы уйнамадым,
Туган илгә кайтмамын, дип, киткәндә уйламадым.

Җан биргәндә салкын җилләр исте, шундый җилләр сездә исәме?
Минем гармун уйнап йөргәннәрем, әнкәй, исегезгә төшәме?

*Кече Чынлы авылында*
*Вәлиева Рәшидәдән язып алынды*

**Кече Чынлы бәете***

Тугыз йөз алтынчы елда килде патша казаклары,
Сөйләп бетерү мөмкин түгел алардан күргән газапларны.

Тарих мең дә тугыз йөздә алтынчы ел эчендә,
Дүрт кешене казаклар атты Матавилов кыры чигендә.

Камал бабай карт кеше, җитмеш ике яшендә,
Камали[1] ничек җавап бирер бер Ходайның каршында.

Икенчесе – Хәйретдин, агасы аның Фәхретдин,
Ат койрыгына бәйләп йөргәннәр, җәфаланып үлгән Хәйретдин.

Өченчесе – Сәгъдетдин, янында улы Хәлим,
Кылыч белән таптаганнар, казаклар бит бик залим.

Дүртенчесе – Камалетдин, кушаматыдыр Куян,
Казаклар белән сугышып, ул җанын корбан кылган.

Сәгъдетдинне казаклар кыйнаган кулын өзгәнче,
Арбасыннан егылып төшкән, сөйрәлеп барган үлгәнче.

Сәгъдетдин арбасында улы да булган янында,
Улының аягын өзгәннәр, ул да үлем хәлендә.

Безнең сулар тирән су, казлар төшәләр йөзәргә,
Мылтык белән атканнан соң үлми хәл юк түзәргә.

Алпут[2] кырына барганда, утырдык без олауга.
Аяз көнне томан басты, кырда халык елауга.

---

* *ТӘҺСИ Язма һәм музыкаль мирас үзәгендәге фольклор фондыннан* (колл. 23, п. 2, сак. бер. 41) *язып алучы – Айдар Гайнетдинов.*

[1] Камали – волостной старшина, Яңа Кәкерле волостенең старшинасы.

[2] Алпут – алпавыт.

Казакларның кылычы көнгә каршы ялтырый,
Казаклардан курку белән йөрәкләребез калтырый.

Ләгънәт төшкән казаклар, ахры, мәңге яшиләр,
Берәм-берәм барыбызның газиз башларын ашыйлар.

Дәҗҗал мәлгунь казаклар, Камали алар ишәге,
Кан эчүче түрәләр нишләтте авылыбызны.

Илне бутый Шаһидулла[1], берсен-берсеннән сүктерә,
Ләгънәт төшкән сельский илебездә кан түктерә.

Шаһидулла атлары йөри кырда тышаусыз,
Сельскийнең итенмеше булды илгә ошаусыз.

Шаһидулла ызбасын верховойлар ясады,
Безнең авыл сельские башыбызны ашады.

Су буендагы каенны Шаһидуллага бирегез,
Мунча ягып чабынсын, бүрәнәгә ут кабынсын.

Камали тирмән салдырды, канатын озын калдырды,
Безнең волость главасы дүрт кешенең җанын алдырды.

Камали белән Шаһидулла өстебездән торганнар,
Чынлы авылы бунтует, дип, телефонга барганнар.

Исправниклар, түрәләр торалар медальлар киеп,
Губернатор кычкырадыр: «Сез разбойниклар!» – диеп.

Бишенче елда Чынлыга губернатор килде үзе,
Разбойниклар, дип әйтү губернаторның сүзе.

Камали килде волостьтан кырдан кеше куарга,
Килмәгән кеше куарга, килгән башыбызны җуярга.

Казаклар безне аттылар, халыклар Чынлыга кайттылар,
Берәр сәгать узгачтын, ишекләребезне килеп ваттылар.

Йозакларыбызны ваттылар, ишекләребезне ачтылар,
Дон казакларыннан куркып, балаларыбыз бар да качтылар.

Ишек ачып, йозак ватып, документлар эзлиләр,
Тәрәзәдән чыгып качмасын, дип, мылтык белән төзиләр.

---

[1] Шаһидулла – Кече Чынлы авылының сельский старостасы.

Исправник белән пристав, казачий офицер да шунда,
Пристав әйтә: китерегез пулнамучларны[1] монда.

Казаклар килделәр кырга, мылтык белән аталар,
Кайсы аяксыз, кайсы кулсыз, тилмерешеп яталар.

Пристав Соболев сүгенеп йөридер кырда:
«Сез, бунтовщиклар, – диеп, – тагын килдегезме кырга?»

Кан эчүче түрәләр кылдан камчы үрәләр,
Николай вакытында халыклар ничек нужа күрәләр.

Шаһидулласы сельский, Камалие глава,
Камали килсә волостьтан илгә фетнә ява ла.

*1945 елда Кече Чынлы авылында*
*Шәкүр Сөләймановтан (1864 елгы)*
*Хәмит Ярми язып алган*

## Сак белән Сок бәете

Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбарәт алдык без.

Бардым урманга җиләкләр пешкәч,
Әнкәй еглыйдыр исенә төшкәч.

Төшкәндер безгә әнкәй каргышы,
Үзебез туганча тәкъдир язмышы.

Су буйларында диңгез камышы,
Тын урманнарда Сак-Сок тавышы.

Мендем ботакка, карадым як-якка;
Ике баланы каргады юкка.

Комач күлмәгем һич тә кимәдем,
Очып киткәндә, сау-бул, димәдем.

Кара бүркемне алып кайтыгыз,
Әткәйне күргәч, сәлам әйтегез.

---

[1] Пулнамучлар – уполномоченныйлар.

Кара карлыгач, сайрый сандугач;
Әнкәй, еглама, үзең каргагач.

Бардым урманга, җыйдым карлыган;
Без ятимнәрне әнкәй каргаган.

Чыктым басуга урак урырга;
Ходай язгандыр шулай булырга.

Яңгыр яудыра әнкәй башыма,
Еглап килдек без, әнкәй каршына.

Каргыйдыр безне, газиз әнкәбез,
Якты дөньяны күрми калабыз.

Бардым урманга, кистем пар каен;
Газиз әнкәбез сагына көн саен.

Кистем пар каен яңа ызбага,
Ике күземнән канлы яшь ага.

Йокыга киткәч, бер төш күрдем мин:
Кара урманда ялгыз йөрдем мин.

Имезгән сөтен әнкәй сусана,
Мәшкәр көнгәчә бәхил булсана.

Су буйларында бала үрдәкләр;
Искә төшкәндә яна йөрәкләр.

Кыйбла ягыннан җилләр исәдер,
Безнең нәфканы әнкәй кисәдер.

Мәдрәсәләрдә пыяла ишек,
Сак белә Сокның тавышын ишет.

Ишек алдында җигелгән пар ат,
Әнкәй каргагач, яралды канат.

Болай булдык без, каргыш тәкъбире;
Еглама, әнкәй, Ходай тәкъдире.

Бик күп егласаң, китапка кара,
Безне сагынсаң, Сак-Сокка кара.

Китап укырсың, гыйбрәт алырсың,
Кошлар үткәндә, карап калырсың.

Газиз әнкәем бер сүз әйтәем:
Бәхиллек бирсәң, илгә кайтаем.

Бер ел тулганча, «кайтам», дип йөрдем;
Бер ел тулгачтан, өметем өздем.

Әнкәй каргады, әткәй, белдеңме?
Турыңнан уздык, әткәй, күрдеңме?

Җыйган җиләкнең калды яртысы;
Ике баланың калмады берсе.

Кояш чыкканда, нур тула күзгә;
Кыямәт көнсез күрешү юк безгә.

Моңны моңнарсың, сайрый сайрарсың,
Балаң очырдың, кемгә егларсың.

Ишекне чыктым, башымны бөктем,
Кайтырлар, диеп, җитмеш ел көттем.

Мамык эшләпәм, чөйгә элмәдем,
Очып киткәндә, сау бул, димәдем.

Данлы тунымны ботак ерткандыр,
Нәфкым беткәндер, тәкъдир тарткандыр.

Базарга чыктым, самовар трубасы өчен,
Әнкәй каргады сөт кормы көйгән өчен.

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның тавышын ишетәсе.

Кояш иңгәндә, күзгә кан төшә,
Күрешә башлагач, арага тау үсә.

Ак шәл бәйләдем, киттем саякка;
Очып киткәчтен калдылар гаҗәпкә.

Сатучылардан алдым бер тарак;
Очып киткәчтен калдылар карап.

Сатучылардан алдым тегәр җеп;
Әнкәй каргады бигрәк рәнҗеп.

Кошлар үткәндә, артка калмагыз,
Ата-анадан каргыш алмагыз.

## Кисак белән Маһипҗамал бәете

Үзем идем мин кисак, малны җыйдым бикисап;
Ялчы кереп, мал өчен, муенга куйды пычак.

Маһипҗамал кич белән тәһарәт алган намазга,
Тирә-күрше уяу иде «Алла» дигән авазга.

Маһипҗамал үләр кичне чыгып йөри бакчага;
Шәһитлекне сорап алдым үзем җыйган акчага.

Маһипҗамал үләсе кич, чыгып айга караган,
Ялчы сталь пычак белән йөрәгенә кадаган.

Үләсемне эчем сизде, читтән малаем көттем,
Сәлахетдин йөрәгемне пычак белән әрнеттең.

Сәлахетдин, анаң кебек, өстең-башың карадым,
Ничек кулың барды икән йөрәгемә кададың.

Үләседин элекке кич сүнмәде лә учагым,
Иремне дә суя иде каты кергән пычагы.

Балакаем, син кайда, белмисеңме хәлемне?
Йөрәгемнән пычак чыкмый, авыр бирдем җанымны.

Яз көне кыска көн, таң атканчы суелдым;
Пүнәтәйләр карап торды, мин сүз белән куелдым.

Пычак белән суелдым, белмәдегез хәлемне,
Рәхмәт яусын, шәһид дин, юмадыгыз тәнемне.

Үләсе кичне белгән булсам, ята идем келәткә;
Күкрәк үтеп, пычак үтеп, кадалды ла йөрәккә.

Ирем яткан беләгемә, башын алмый кулымдан;
Син, йөрәккә кадаганчы, ник суймадың муенымнан.

Суеламын шуның өчен, мин малымдин күрәмен,
Ялчы мине суядыр, вакыт җитми үләмдер.

Әҗәлгә юк дарулар сатып алып калырга;
Бер кат үзем суелган, доктыр килә ярырга.

Ике арага яткан иде безнең белән кызым;
Йөрәгемнән пычагымны алмадылар дохторсыз.

Үзем китәм бу дөньядан минем малым кемгә кала;
Пычак – минем йөрәгемне, газраил җанымны ала.

Эчем пошты бер атна, кемгә сөйлим бу халем,
Пычак белән бәргәчтен, чыкты ла шәһит каным.

Ялан малны без җыйдык, дөнья өчен кирәккә;
Сәлахетдин суеп чыкты, каным сыймый чиләккә.

## Моңлы хатын

*(Гайшә көндәше Зөләйха)*

Менә сезгә бер кыйсса, колак салып тыңлагыз,
Бик күңелле булмаса да, көйгә салып моңлагыз.

Бу кыйссадин хат нидер, шуны чынлап аңлагыз,
Бу бер чүп-чар язган, дип, укымыйча калмагыз.

Аз булса да файда булыр, чын күңелдән укысаң,
Бер төрле бер һични алмас, колагына тукысаң.

Укый торган – укысаң, белерсең син, тәм кайда;
Була аның буш вакыт, укып алсаң, ни файда!

Мәдрәсәдә һәм мәктәптә укып булмый барын да,
Укып җибәр китап алып, азрак вакыт барында.

Бушка үтмәсен, бир мәктәпкә, аз булса да мәшһүл бул,
Якын күреп күрсәтәмен сиңа, туган, туры юл.

Эшсезлектән азып китә безнең татар яшьләре,
Яманлыктан әрәм була, алтын кебек башлары.

Китапханә бар түгелме, азрак барып укырга,
Сезгә кирәк юл күрсәтү, ничек кирәк сукырга.

*Гайшә хатынның иренә әйткән сүзләре*

Күзең төште бер яшькә, алдың аны көндәшкә,
Көндәш утында яндырдың, карамадың күз яшькә.

Сөя идем мин сине, чын күңелемнән яратып,
Син хезмәттә вакытыңда, көтә идем җан атып.

Син җанымны сөя идем, йоклата идем кулымда;
Сөйгәнемне шуннан бел син, корбан булдым юлыңда.

Хезмәтемне кызганмадым караңны (*өсте-башы*)
ап-ак тоттым мин,
Син никадәр җафа кылсаң, барысын да йоттым мин.

Матурлыгым, зифалыгым – бар да иде җирендә;
Ни кушсаң да эшли идем, калдырмадым берен дә.

Зөләйхаң да артык түгел, миндин матур карарга;
Бар күңелемне сабыр иттем, син җаныйга ярарга.

Гөнаһым юк синең хакта, ир хакымны куймадым,
Син никадәр сөймәсәң дә, мин сөюдән туймадым.

Син шулай да күрсәтмәдең миңа якты йөзеңне,
Ишетмәдем синең бер дә яхшы, тәмле сүзеңне.

Шулай да мин синнән разый, үләм синең юлыңда;
Кызганамын балаларым, калдыгыз үги кулында.

Көндәшемнән җәберләтмә күз нурларымны, зинһар,
Тәрбия кыл син аларны, синдә аларның хакы бар.

Өстен-башын яхшы кара, ертык-тишек булмасын,
Ятим булып моңаймасын, күңелләре тулмасын.

Көндәшемнән сакла аны, сукмасын да какмасын,
Әгәр сукса, йә орышса, ата булып якларсың.

Алар хәзер синең кулда, сиңа карый моңаеп;
Үги ана бик зәһәрле, таба меңнән мең гаеп.

Вакыт җиткәч, бир мәктәпкә, укыр, язар, хат таныр;
Өстемә килеп Коръән укы, минем рухым шатланыр.

Яшь чагында укысыннар, зинһар надан калмасын,
Артын-алдын яхшы белеп, уңны-суңны аңласын.

Дөнья өчен эшли белсен, буш калмасын һич надан,
Урак урсын, чалгы тотсын, куя белсен һәм кибән.

Сәясәттән җыр алсын, укып белсен һәм хөкүм;
Гыйлем-табышны яхшы белсә, доктор булса – кемнән ким.

Гыйлем-табышны укып белсен, хилла булсын бер илгә,
Яшь вакытлар бик кадерле, әрәм булмасын җилгә.

Яхшылыкны өйрәнсеннәр, яманлыкны чиксеннәр,
Гыйлем алулар өчен, чит җирләргә китсеннәр.

Васыятем әйтеп бетте, инде үлсәм дә үкенмим;
Кабан күленә сикереп төшәм, хушыгыз, инде мин килмим.

*Гайшә ханымның моңлы җырлары*

Кайгы-хәсрәт күрдем мин яшүсмер чагымда,
Уйнап-көлеп тордым мин үз әнкәем кочагында.

Үсеп җиткәч мин буйга, әнкәй килгән бер уйга,
Шатлык алган бар дөньясын, хәзерләнәдер туйга.

Күп үтмәде туй булды, өйгә кодалар тулды,
Озакламый муллалар килде, никах дәхи укылды.

Шулай итеп яшь килен булып китте кыз башлар;
Шатлыкларым кайгы булды, кемгә төшәр күз яшьләр.

Яшь чагымда уйлый идем, һаман рәхәт килер, дип,
Мәрхәмәтсез бу дөньяны, миңа гына килер, дип.

Мәрхәмәтсез канатын салды минем башыма,
Җафалады, карамады күзләремнең яшенә.

Бу дөньядан мин биздем, җафасына күп түздем,
Рәхәт булыр, димимен, өметемне мин өздем.

Әллә, дөнья, үчең бармы, шуны миннән аласың,
Җафалыйсың, хафалыйсың, газиз әдәм баласын.

Җәфаладың, хафаладың гомеремнең күгендә,
Ахырында чыкты җаным, Кабан күле төбендә.

Кызганмады дөнья мине җафа салды башыма,
Алып китте, җиткермәде егерме биш яшемә.

Алдамасын сезне, кызлар, яшь чагында шат йөрү,
Исегездән һич чыкмасын бер көн хәсрәт күрү.

Дөнья көлсә бер вакыт, егълатадыр күп вакыт,
Минем сүзне «дөрес» диярсез, килеп җитәр шул вакыт.

Хатын-кызлар, колак салың, сезгә әйтәм сүземне:
Мисал өчен, гыйбрәт өчен, китерәмен үземне.

Бу дөньяда бары хәйлә, чын нәрсәсе бер дә юк,
Туксан тугыз ач кешеләр, йөздән бары бере тук.

*Гайшә ханымның балаларга әйткән сүзләре*

Балаларым, бәгырьләрем, калдыгыз ла яшьли сез,
Әнкәгезне сагынганда, белмим инде нишлисез.

Бәлки сез дә үткәрерсез, моңаешып көннәрне,
Тәкъдир шулай, балаларым, ятим итми кемнәрне.

Бер сез генә түгел, калган атасыз да анасыз;
Бәлки сезләр, балаларым, хәсрәт утында янасыз.

Кызганамын, сызланамын сезнең өчен нурларым,
Күз алдымда сез идегез, миңа дөнья хурларым (*кызларым*).

Балаларым, чәчәкләрем, укымыйча калмагыз,
Надан булып, үзегезне михнәт эченә салмагыз.

Уку кирәк, балаларым, мужикка да муллага;
Надан өчен ничек кирәк якын булмак Аллага.

Сүзем тотып, укысагыз, якты булыр йөзегез;
Мин күрмәмен рәхәтен, рәхәт күрер үзегез.

Мәктәп юлы сезгә булсын, иртә торгач такыр юл,
Бик тырышып укысагыз, акча булыр сезгә шул.

Хуш, балалар, сау булыгыз, калдырамын сезләрне,
Кайчагында искә алыгыз, дога белән безләрне.

*Гайшәнең кардәшләренә әйткән сүзләре*

Кардәшләрем, минем өчен, кайгырмагыз сез бер дә,
Минем өчен монда рәхәт, ялгыз яту тар җирдә.

Үкенечем калды минем, күрәлмәдем үлгәндә;
Балаларымны юатыгыз искә төшереп килгәндә.

Дөнья мине мәҗбүр итте, теләп үлем алырга;
Кунак булып барып калдым сезне күреп калырга.

Сабыр итегез, тәкъдир шулай, кайгырмагыз юк өчен;
Җафалаган явыз дөнья, алды миннән тиз үчен.

Хуш, туганнар, сау булыгыз, тыныч булсын күңелегез,
Кайчагында искә алып, зиаратыма килегез.

*Гайшәнең ирләргә әйткән сүзләре*

И, чын ирләр, көзгеләр, сездә бармы изгеләр,
Үзегезчә әгәр әйтсәк, сез – акыллы, без – җүләр.

Бәгъзе ирләр әйтәдер: «Акылга ким хатын-кыз»,
Бу дөньяның яртысын түгелме соң тоткан без.

Ирләрдән бар шундыйлар, акылга ким, чын җүләр;
Хатын-кызлар булмаса, ертык-тишек кем җөйләр.

Ир булсагыз, урыныгызда игътибарлы булыгыз,
Хатын-кызны хур күрмәгез, алар түгел колыгыз.

Алар белән уйнамагыз, алар түгел бит курчак,
Хәзер инде сезгә вакыт, инсан, диеп белер чак.

Хатын-кызга сез карагыз, мәхәббәтле күз белән;
Хәтере калса, юатыгыз төрле тәмле сүз белән.

Хатын-кызның күңеле нечкә, тиз кырыла, өзелә;
Җитәр инде күп моңайдым, туктамакчы шул җирдә.

Каләмем дә тая инде, баралмыйдыр турыдан;
Каты сүзләр язган булсам, язылгандыр гóредан.

Гафу итегез, яшь егетләр, дәхи картлар, агайлар;
Гафу итү – берлек, диеп, әйтеп киткән бабайлар.

*Татар Саплыгы авылында Сабируллина*
*Нажия Сабирҗан кызыннан (1914 елгы)*
*язып алынды*

## Сугыш бәете

Ике лимон, бер афлисун,
Кайда чәчәк ата икән?
Ике күзем, нурлы йөзем,
Туганнарым кайда икән?

Ялгыз ята икән ике келәт арасында
Кырык ике үрдәк баласы;
Унике түгел, ике дә юк;
Бәнем туганнарым янда юк.

Без барасы юлларда,
Ике яны канаулы;
Без еламый кем еласын,
Безнең башлар санаулы.

Әни мине бәбәйләгән,
Ак юрганга биләгән;
Биләвен дә биләгән,
Бәхетле бул, димәгән.

Безне китергән машина
Туктап калды вокзалга;
Бән йөримен азганга,
Йөрим Ходай язганга.

Безне китергән машинаның
Трубасы җиз генә;
Үдән чыгып китәбез,
Кайталмыйбыз тиз генә.

Җитен чәчтем җирләрдә,
Үсеп җитәр җәйләргә;
Ходай язса, насыйп булса,
Шәт, кайтырбыз илләргә.

Торна килә такырдан,
Тырнаклары бакырдан;
Сез туганнарым өчен,
Сабам камил гакылдан.

Тырышып урак урган чакта,
Гәзит килгән конторга;
Гәзитәнең язуынча,
Сугыш булырга тора.

Әллә кайсы патшалыкта,
Серби атлы шул шәһәрдәге
Бер зур каһарман
Патшаның углын үтергән.

Аны гаепли торгачтан,
Зурга киткән эш, ди;
Немец патшасы әйткән, ди,
Серби безгә дошман, ди.

Ул малайны үтерергә,
Сиреб үзе кушкан, диеп,
Австрия патшасы
Гаскәрләрен җыйган, ди.
Малайга хөкүм итәм, диеп,
Вәзирләрен җыйган, ди.

Вәзирләре әйткәннәр, ди,
Сиреб патшасы дошман;
Шаһзаданы үтерергә,
Ул патша үзе кушкан.

Безнең белән шаярса,
Күзләрен ачык тотсын;
Җыелышып барабыз да,
Алабыз башкаласын.
Сиреб атлы патшалык,
Бу дөньяда калмасын!

Шулай итеп уйлаган да,
Немец ачкан, ди, сугыш;
Анда башкалар катышып,
Зурга киткән, ди, бу эш.

Сиребларны җәберләргә
Безнең патша күнмәгән;
Безнең патша аларны
Килешергә өндәгән.

Немец дигән дивана,
Белмәгән үз кадерен.
Үз кулы белән хәзерли
Үзе өчен каберне.

Безнең патша ачуланган,
Немецларның бу эшенә;
Хәзер инде чыдап торсын
Падишаның көченә.

Патша хәзер әмер иткән,
Гаскәрләрен җыярга;
Кире беткән немецларны,
Пуле белән сыйларга.

Урак урып яткан чакта,
Килеп төште бер хәбәр:
Урагыңны ат җиргә,
Әйдә, сугышка, егетләр!

Кайтып киттек без авылга,
Бөтен кырны тутырып;
Безне озатканнар
Кайта, тезелешеп, утырып.

Бөтен авыл шау килә,
Әйтерсең лә яз килә;
Гармонь белән хәбәрләшәбез
Һәртөрле моңлы көйгә.

Кояш кызу кыздыра,
Атлар тузан туздыра;
Кайсы уйный, кайсы җырлый,
Кайсы-берсе сызгыра.

Кайсылары хәзерләнә,
Юлга, диеп ашык-пошык;
Егетләр исәнләшә
Кызлар белән качып-посып

Кемнең кала сөйгәне,
Кемнең кала кибәне;
Мич артына кереп китә,
Балавыз сыга әни.

Безнең уен тавышына,
Урамнар селкенә;
Үтте бит, диеп, яшь вакыт,
Картлар карап җилкенә.

Бер заманда чыгып китәргә,
Бара-бара китеп утырып;
Сөйгән җаным карап кала,
Матур күзен тутырып.

Без китәбез сугышка,
Җаным сөйгән яр кала;
Җаным калганны уйлагач,
Зиһеннәрем таркала.

Тау башына менгәчтән,
Бер карадым каерылып,
Без сугышка киткәч инде
Җанкай кала ауышып.

Авыл күздән югалганча,
Күзне алып булмыйдыр;
Исән-йөреп, сау кайт, диеп,
Җанкай яулык болгыйдыр.

Безнең таулар биек түгел,
Чүрәгә булып сузылган;
Безне озаткан чакта,
Чызлап буйлый тезелгән.

Яулык болгап, җыр җырлап,
Җитәргә тауларны менеп;
Кайсы уйный, кайсы көйли,
Кайсы тик бара көлеп.

Без бара торган юллар,
Комлык белән таш кына;
Кайчан барып җитәрбез, дип,
Яшь йөрәкләр ашкына.

Көтү-көтү агылалар,
Төрле яктан конторга.
Ходай безгә язган булсын,
Сау-сәламәт кайтырга.

Проверкалар булганнан соң,
Киттек тимер юлына;
Исән булсак, без кайтырбыз,
Язгы сабан туена.

Без барабыз кайтырга,
Китмибез тик ятырга;
Немецларны ныклап җиңеп,
Исем калсын батырга.

Мин барамын дошманга,
Падишаһым кушканга,
Немец, залим, чыдап торсын,
Без барып сугышканда.

Без барабыз кичләрен,
Актарабыз эчләрен;
Ачуларны алган чакта,
Бушап китәр эчләрем.

Станцада без ятабыз,
Поезд килгәнне көтеп;
Уйныйм гармонь, әйтәм такмак,
Бөтен дөньяны селкетеп.

Эчләр пошып торган чакта,
Без уйныйбыз гармоньнар;
Гармонь уйнап, такмак әйткәч,
Таралып китә кайгылар.

Гармонь уйнап, җыр җырлап,
Бармакларны шартлатып,
Без барабыз сугышка,
Җан-күңелдән яратып.

Безнең солдат батырлыгы,
Дөньяларда бер булсын;
Немец, дигән бәдбәхетнең
Авызы-борыны кан булсын.

Немецларда булыр микән,
Безгә каршы түзәрлек;
Безнең халык бигрәк таза,
Типсә, тимер өзәрлек.

Безнең солдатның һәммәсе,
Әйтерсең лә тимердән;
Безнең белән сугышмакчы
Җүләр немец, тилергән.

Безгә каршы чыдый алмас,
Әдәм түгел тимер-таш;
Шуны да уйлап карый алмый,
Ахры, немец каткан баш.

Майлап, тазартып куямын,
Мылтыгымның көпшәсен;
Ахры, немец уйламаган,
Бу хурлыкка төшәсен.

Башта – бүрек, өстә – шинель,
Аякларда – күн итек;
Немец канын агызырбыз,
Уйсу җиргә күл итеп.

Барабыз дошман өстенә,
Узып матур күлләрне;
Төшеп күлгә эчерәбез
Немецларның күпләрен.

Авыл, урман, калалары –
Бар да әйләнер күмергә;
Бездән алган сабаклары,
Онытылмас гомергә.

Польшаны алмакчы булган,
Тиз генә ул куркытып;
Инде хәзер без кайтырбыз,
Аларны сабак укытып.

Моннан соң күп йөри алмас,
Сыра эчеп, күбенеп.
Тиздән инде сәҗдә кылар,
Безнең алга бөгелеп.

Бырып җиткәч сугышка,
Без белербез нишлисен:
Тар-мар итеп, агуларбыз
Юан сыра мичкәсен.

Аның күзен кызыктырган
Лондон белән Варшаулар;
Безнең патшаның гаскәре
Мичкәне нык кыршаулар.

Тагын бер сүз әйтим әле,
Әгәр хәтерең калмаса:
Төкермибез без сиңа,
Син бит сасы колбаса.

Немецларның туплары
Безне бер дә куркытмый;
Алтмыш төрле булмагае,
Ник булмый мең потлый.

Бер поезда – солдатлар,
Икенчесендә – атлар;
Бу солдатлар барып җиткәч,
Немец корсагы шартлар.

Без барып җиткәчтән,
Безнең күңел шатланыр;
Немецларның гәүдәләре,
Аяк астында тапталыр.

Барып-йөреп кайтыйк әле,
Күрмәгән җирләрне күреп;
Басып, кырып ташлыйк әле,
Дошман немецны аерып.

Кич яткачтан күрәбез,
Матур-матур төшләрне;
Немецларны җиңеп, медаль алгач,
Киерәбез түшләрне.

Көн барабыз, төн барабыз
Кояш баешларына;
Әҗәл якын килгән икән
Немецның башларына.

Алданрак булса да,
Куйыйм әле мактанып:
Немецларның эчләрен
Чыгарабыз актарып.

Без ачабыз утларны,
Атып мылтык-тупларны;
Кырып-себереп бетерәбез
Кап корсак немецларны.

Ятсам да йокы килми
Сугышларны исәпләп:
Кайчан турарбыз, диеп,
Немецларны кисәкләп.

Үтеп басу-кырларын,
Тауларын, чокырларын;
Көтү-көтү алырбыз,
Аерып алып зурларын.

Немец-дошман аңласын
Россиянең зурлыгын;
Күзләре белән күрсеннәр
Җиңелүнең хурлыгын.

Бу сугыштан кайтмабыз,
Җиңәлмичә немецны,
Аяк та атламабыз,
Алмаенча немецны.

Поезд тиз-тиз узып китә
Урман-кыр, басуларны;
Ашыгабыз без немецтан
Алырга ачуларны.

Поездагы солдатлар,
Барысы да бик шатлар:
Кайсы уйный, кайсы җырлый
Кайсы язалар хатлар.

Бер-бер артлы көн-кичә
Сизелми узып кичә;
Иптәшләрнең йөзләре
Шат һәм әвәлгечә.

Юл өстендә күренеп кала
Матур-матур калалар;
Юл буендагы халыклар
Безне озатып калалар.

Киткән саен безнең поезд
Чаба һаман, алга омтыла;
Йорт-җирләрнең кайгылары,
Барган саен онтыла.

Торган саен исем китә
Акылсыз бу немецка;
Ничек итеп чыдый ул,
Бездәге бу зур көчкә.

Үз хәлен үзе белми,
Ник сугыша котырып;
Без себереп ташлагачтын,
Бер еларсың утырып.

Үтерәбез үзләрен,
Чыгарырбыз күзләрен;
Ялынса да, ялварса да,
Тыңламабыз сүзләрен.

Без эшләрне тиз тотарбыз,
Йөри алмас бик күпкә;
Ватып-тетеп очырырбыз,
Немецларның көлен күккә.

Немец солдаты безгә
Каты торалмас һич тә;
Баш кечкенә, аяк нечкә,
Корсаклары зур мичкә.

Немец солдаты көчсез,
Күтәрә алмый башын;
Безнең Россия солдаты
Коеп куйган кургашын.

Төзәп мылтык-тупларны,
Без ачабыз утларны;
Бер-бер артлы алырбыз
Без крепость-портларны.

Моннан бара Руссия,
Тиздән килә инглиз;
Немец дөньяда багланыр,
Озак тормас инде, тиз.

Аргы яктан басып килә
Немецларны француз;
Нихәл, немец, хәлең ничек?
Бик исән-сау торамсыз?

Вильгелим бик яратыр,
Чын виноны сорамый;
Австрия ни хәлдә соң,
Онытып тора сорамый.

Русияне җиңә, дими,
Әллә юк, дими бер дә,
Әллә, җиңәм, дип уйлыймы,
Сез соң нинди фикердә?

Бик күп сөйләнә торгач,
Кереп киткәнмен читкә;
Поездның барып җиткәнен
Сизми калганмын чиккә.

Германиянең гаскәрләре,
Бар да җыен-җыентык;
Алар ничек каршы торсын,
Тота белмиләр мылтык.

Бездә бик күп солдатлар,
Бер төрлесе казаклар;
Немецларны күрерсез,
Күрә бездән газаплар.

Солдат бездә шул кадәр
Күп, әйтерсең лә арасат;
Мондый батыр гаскәрләрне
Җиңү булмас ансат.

Казакларның сөңгеләре,
Бер сажин бер буйлары;
Алар чапкач, искә төшә,
Язгы сабан туйлары.

Дон казаклары яхшы,
Әмма җитез уралый;
Башкалардан калышмыйлар,
Безнең халык татары.

Кылычка оста булмаса да,
Оста мылтык атарга;
Немецларның солдатлары
Килә алмый штикка.

Немецлар бер дә килә алмый
Безгә каршы «ура»га;
Немецларны мин охшатам,
Эче куыш курага.

Карлар бераз яуса да,
Каты түгел суыгы;
Аз гына суык булса да,
Кибә немец куыгы.

Немец солдаты юан,
Күтәрә алмый корсагын;
Без үтергән немецларның
Алла белсен хисабын.

Бетсен, корсын немец,
Йөремәсен дөнья бутап;
Андый файдасыз чүпләрне,
Шулай ташлыйлар утап.

Бетсен немец, калмасын,
Яшәмәсен дөньяда;
Ала күке, соры кортның,
Торуында ни файда.

Дөньяда немец бетүдән
Бер эш тә булмас харап;
Һичбер төрле зарар булмас,
Алар беткәнгә карап.

Алар беткәннән ни зарар,
Син үзең бер фараз ит;
Бер кемгә дә зарар килмәс,
Кимегәннән паразит.

Немецларны күргәчтән,
Ачудан каным ката;
Чын күңелемнән әйтәм,
Бу сүземдә юк хата.

Немецларны яндырырбыз
Әйләндереп күмергә;
Немецларның дошманлыгы
Онытылмас гомергә.

Аңла, немец, бәдбәхет,
Җирләреңне алырбыз;
Безнең белән күп маташма,
Каныгызны җиргә агызырбыз.

Бер тотынгач, без кайтмабыз
Алмаенча үчләрне;
Менә хәзер күреп кара
Инде безнең көчләрне.

Польшаны йотам, диеп,
Авызыңны зур ачтың;
Тамагың туйдымы әллә,
Нишләп алай тиз качтың.

Без сугыштан туктамабыз,
Сезне чыгармый торып;
Алачакларны алырбыз
Синнән, бугазың буып.

Гашыйк булдың Польшага,
Карап торып күз алмый;
Син – җылан, без – кырмыска,
Сикерсәң дә түзә алмый.

Карыйк әле синең дә,
Арт сабагың тыңлатып;
Аннан соң карарсың,
Күзләреңне томратып.

Куркытмакчы булган идең,
Безне бик зур туп белән;
Син безне куркыта алмассың,
Шаярма алай ут белән.

Утка пешсәң, нишләрсең,
Тартып алыр кешең юк;
Тирә-яклар бар да бикле,
Сиңа яраклы төшеме юк.

Үзеңне үзең күр,
Дусларыңа ышанма;
Италия дә таяр ахры,
Бер якка да ышанма.

Кара, әдәм картайгач,
Йөри алмый таяксыз;
Ничек итеп ул булышсын,
Булгач кулсыз, аяксыз.

Җитмәсә, аны борчып
Тора арт ягыннан Сербия;
Картайгач көче җитми шул,
Франция, Сербия.

Никадәрле кычкырсаң да,
Ишетмиләр сүзеңне;
Берсенең дә күрәсе килми
Синең сары йөзеңне.

Синең мактанганыңны,
Һәркайсы да беләләр;
Алдыңда дус булсалар да,
Артыңда шул көләләр.

Инде без дә танытырбыз,
Җыеп йөре итәгеңне;
Эләктегез инде нык кулга,
Китә алмассың котылып.

Күптән шулай бик кирәк,
Күп йөредең котырып;
Бик тиз барып кермәкче идең
Англиягә өч атлап.
Хәзер инде утырырсың
Киемнәреңне кочаклап.

Үз бәхетең булмагачтан,
Файда бирми дусларың;
Дусларың да усал икән
Тутырдыйлар күк көймә.

Җиңәрмен, дип уйладың,
Төштә күреп, саташып;
Малтыгыңны ташла инде,
Йөрмә юкка маташып.

Тартышудан юк файда,
Сиңа җиңүләр кайда;
Дөньяны ташлап китсәң,
Ул да сиңа зур файда.

Дусларыңны сатып алдың,
Вагон-вагон алтынга;
Бу дөньяда ышаныч юк,
Сатып алган хатынга.

Дустым бар, дип шатландың,
Акчасы күп, дип мактандың;
Хәзер инде берсе дә юк,
Агач атка атландың.

Италия дә серең алды,
Тик йөретте сөйләтеп;
Ахры, бер көн ташлап кисәтте,
Кәкре каенга терәтеп.

Уйлаган идең бугай син
Европаны алырга;
Инде үзеңә туры килә,
Кабыргаңны санарга.

Бөтендөньяны ашап,
Уйладың син туярга;
Инде хәзер вакыт җитте
Үз җилкәңне суярга.

Бу көнгә кадәр без яттык,
Ышыкланып ташларга;
Бүген безгә фарман килде
Һөҗүм итә башларга.

Без кайтырбыз Германиянең
Астын-өскә китереп;
Аннан соң күп йөри алмас,
Анда-монда сикереп.

Бетсен инде бәдбәхет,
Фетнәчеләр ким булыр;
Олугларга тел ачмаска,
Гомерлеккә им булыр.

Дөньяда безгә дошманнар,
Бик күп булса, ике-өч;
Ике-өчнең арасы
Иң дошманнары – немец.

Һәркайда да мәшһәр сүз:
Кешегә чокыр казыма;
Ничек хәлеңне аңладың,
Үзең төштең базыңа.

Елга итеп агызырбыз
Немецларның каннарын;
Бөтендөньяга җәярбез,
Россиянең даннарын.

Серби тубы сары алтын,
Ышанмыйбыз без һич тә;
Чигә-чигә ышанабыз,
Иртә булмаса, кичкә.

Сугышларны башладың,
Дөньяларны шаулатып;
Тиз көннәрдә таралырсың,
Мичкәң кыршавын ватып.

Зур уйны уйлый-уйлый,
Киттең акылдан шашып;
Чамасы юк күңелең,
Үттең чикләрдән ашып.

Бу җүләрлекләреңне
Дөньяларга фаш кылдың;
Күрәчәккә каршы икән,
Үз башыңа ашыктың.

Кул астыңдагы халыкның
Юкка җаннарын кыйма;
Егерме ел сугышсак да,
Бер карыш җир юк сиңа.

Ник маташкан буласың,
Төшәсең бит хурлыкка;
Бер бөртек ни дә бирмәбез,
Сорасаң да орлыкка.

Ник бу кадәр ашыгасың,
Халкыңны кырдырасың;
Бу кешеләрдән бик оят
Европада торырга.

Күптән кирәк инде сиңа
Падишага кол булырга;
Аны да уйларга кирәк,
Башта акыл булырга.

Ахмак немец кул күтәрә,
Оялмыйча зурларга;
Өйрәнгән икән дөньяда
Таларга да, урларга.

Соңгы көндә без яттык,
Сугышлардан читтәрәк;
Шушы йөргән җирләрдә,
Кереп киттек читләргә.

Инде килдек миранга,
Исемебез китсен дөньяга;
Елга сулары тулар
Дошманнан аккан канга.

Немецлар учлап йөриләр
Уч төбендә җаннарын;
Елга итеп агызырбыз
Дошманнарның каннарын.

Йөрмәсеннәр бәдбәхетләр,
Киң дөньяны тар итеп;
Киң дөньялар тар була бит
Кысса аякны итек.

Хатын-кызларны җәберләү,
Немецларның бар эше;
Башларына төшәр әле,
Бөтен дөнья каргышы.

Немецларның гаскәрләре
Бушый алмый качудан;
Балаларны үтерәләр,
Җиңә алмаган ачудан.

Картларны да үтерәләр,
Ай-һай, бигрәк көчлеләр;
Узып киткән җирләрдә
Хатын-кызны көчлиләр.

Немецлар, качып киткәндә,
Авылга ут салалар;
Хатын-кыз, бала-чагалар
Харап булып калалар.

Дошман утына без барабыз,
Гүя исә каты җил;
Дошман җаннарын алудан
Бушый алмый газраил.

Немец алдан хәзерләнгән
Күпләп-күпләп үләргә;
Чөнки машина ясаган
Үлекләрен күмәргә.

Яңа мылтыкның пулесен
Ясаганнар корычтан;
Бер атканда биш немецны
Кырып салам бер очтан.

Яңа пуле бик нечкә
Һич калмыйдыр эчтә;
Бер пуледан үлеп кала
Бер дә, ике дә, өч тә.

Үтерәбез немецларны,
Агызабыз кара кан;
Кырыла дошман гаскәрләре
Әйтерсең лә кара кан.

Немецларның башларына
Кубарабыз арасат (*кыямәт көне*);
Немецны атып төшерү
Куян атудан ансат.

Кайвакытта кирәк булмый
Йөрергә һич чокланып;
Тик берәмләп чүпләп ятам
Яткан җирдән ышыкланып.

Кыш салкыннар булса да,
Зарарлы түгел ышыкта;
Шуннан атып тик ятабыз,
Утларыбыз чок-чокта.

Атып-атып төшерәбез
Дошман һава көймәсен;
Безнең солдат аста ата,
Тик күз генә тимәсен.

Бу көн безгә әмер булды
Дошманга ут ачарга;
Немец урын таба алмый
Башын алып качарга.

Немец, болай җиңә алмагач,
Эзләп карый хәйләсен;
Дошманны җиңеп кайтырга
Ходай насыйп әйләсен.

Безнең солдат бик таза,
Һич чама юк көченә;
Бер солдатка – бер немец,
Немецларның өченә.

Ат өстендә сугышырга
Бик оста була казак;
Бер-бер артлы немецларны
Ала сөнгегә кадап.

Кылыч сугышларына
Немец каршы тора алмый;
Якын килә башлагач,
Ташлый тизрәк коралны.

Немецның кайсылары
Бөтенләй күпкән корсак;
Явызлыкларына күрә,
Ходай аларны орган.

Тамаклар тук, өс бөтен,
Без барабыз салмакка;
Барган саен эләктерәбез
Немецларны кармакка.

Безнең солдатлар бик юмарт,
Һич саранлык кылмыйлар;
Очраган бер немецны
Пуле белән сыйлыйлар.

Немец риза булмыйча
Өлешенә чыккан көмешенә;
Тамак кыйлып килгән иде
Варшавага, Польшага.

Тиз генә алмакчы иде,
Үтереп, талап, суеп;
Батыр Руссия гаскәре
Чыгардылар куып.

Немец халкы гашыйк икән
Зәңгәр күзле бүләккә;
Без куалап чыгаргачтан,
Инде калды көлкегә.

Әйдә немец кил инде,
Нәрсә торасың көтеп;
Баш астына хәзерләдек
Түшәк, кардан күп итеп.

Анда ятсаң китәрсең,
Мәңге татлы йокыга;
Монда килеп уйлама,
Сау кайтырга йортыңа.

Немец бер дә хафаланма,
Монда калсаң да үлеп;
Йорт-җиреңне өләшербез
Варисларыңа бүлеп.

Кайттым сугыш мәйданына,
Бик күп тордым сөйләшеп;
Сугышмасам чыдый алмыйм,
Сугышка киттем өйрәнеп.

Бер өйрәнгәч, чыдап булмый
Дошманнарны үтерми;
Бер немецны үтермәсәм,
Җаным һич тыныч күрми.

Мылтыкларны ата-ата
Беләкләрем талчыга;
Эләктереп аламын немецны
Әйтерсең лә карчыга.

Казаклары барып кайталар,
Немецларны китекләп;
Без дә атып төшерәбез,
Берләп түгел, дистәләп.

Без атабыз мылтыклардан,
Дөнья тора шау итеп;
Немец гәүдәсе җитәрлек
Өяргә дә тау итеп.

Без кайчагында куабыз
Дошманнарны ачыктан;
Немецлар кача алмый,
Хәле беткән ачлыктан.

Икмәк бездә бигрәк күп,
Кадаклап түгел, потлап;
Һаман азык килеп тора,
Бетереп булмый ашап.

Немец сугышка кереште,
Белмәенчә чамасын;
Ятим итеп калдыра бит,
Хатын, бала-чагасын.

Немецны куып чыгардык
Без Варшауның астыннан;
Күрәчәгенә каршы,
Үз башына ашкынган.

Руссиядән чигәчәген
Немец күргән төшендә;
Бу дөньяда тиң табалмас
Безгә сугыш эшендә.

Шайтан кушкандыр инде
Безгә сугыш ачарга;
Инде хәзер эзлә урын
Башыңны алып качарга.

Бу сугышта без кайтмабыз,
Кермәенчә җиреңә;
Калаларыңны алырбыз,
Карамабыз бер кемгә.

Германиядә туп ясарга
Җитми башлаган бакыр;
Немец солдаты ач йөри,
Ашау ягы бит такыр.

Ачның күзе икмәктә,
Безнең күзләр хикмәттә;
Безнең гаскәр бер-бер артлы
Һаман алга китмәктә.

Немецларның өсләренә,
Ява пуләләр яңгыры;
Безнең туплар аткан чакта
Тирә-яклар яңгырый.

Соңгы көндә сугышларда
Без чыгабыз өстенгә;
Немецлар калып баралар
Көннән-көн мескенгә.

Кояш чыгып күтәрелгәч,
Без башлыйбыз сугышны;
Аз арада немецларны
Тар-мар итеп ташлыйбыз.

Таң атар-атмастан торып,
Көтә башлыйбыз сугышны;
Йөрәк шул кадәр ярсыган,
Түзеп булмый сугышмый.

Бушаганда, чәй эчәбез
Чәйнекләрдә кайнатып,
Бергәләшеп, җырлашып,
Сандугач кебек сайрашып.

Бушап торган араларда
Язып алыйм әле хат;
Дошманнар чигенгәннәр,
Безнең күңелләр бик шат.

Кай көннәрдә бушап булмый
Көн буенча атудан;
Күңел дә туеп китәрлек
Окопларда ятудан.

Менә безгә әмер булды,
Безгә алга барырга;
Шуннан соң чынлап керештек
Немецны урып салырга.

Чыгып киттек алга таба,
Зур-зур атлап адымны;
Без газраил булып килдек,
Алабыз, немец, җаныңны.

Безгә каршы чыдый алмый
Немецларның муртлары;
Аяк астында изелә
Немец тәресе, кортлары.

Хәзер китте эшләр ходка,
Сугыш көннән-көн кыза;
Куәтле рус гаскәрләре
Немец сафларын боза.

Аннан безне җибәрделәр,
Бер-ике көннәр яткач,
Китәргә утырып поезга
Туган илләргә карап.

Тагын килербез әле, диеп,
Кул эшкә китсә, диеп;
Кайтып китәргә килгән
Юлдан туган илләргә таба.
Бәхетле булган кешеләр,
Морадын бик тиз таба.

Күп тырышып сугышкач,
Ахры, җиттем морадка:
Батырлыкка медаль алдым,
Мендем инде зур атка.

Сугышка киткән вакытта,
Озатып киткән калалар,
Батырларыбыз кайта, диеп,
Каршы чыгып алалар.

Кайтып җиттек исәнлектә
Туган үскән илләргә,
Якындагы шәһәрләргә,
Белеш-таныш җирләргә.

Китерделәр салдылар
Лазаретларга безне;
Җитәр инде күп сөйләдем,
Өзәргә кирәк сүзне.

*Татар Саплыгы авылында Гыйматдинов*
*Шәйхислам Гыйматдин улыннан*
*(1878 елгы) язып алынды*

## Күңелдәге җырлар

Әйтегез инде иркәмә,
Кара кепкасын кисен.
Хәзер инде миңа түгел,
Сокланыгыз, күз тисен.

Ташла, бәгърем, бер сүз әйтмим,
Иреш теләкләреңә.
Йөргән чакта сөйләшкәннәр
Торсын йөрәкләреңдә.

Ак одеал бирәм, дустым,
Өшесәң ябынырсың.
Якын дустың булмасам да,
Бәлки бер сагынырсың.

Өстәлләрдә ике китап,
Берсен алып мин укыйм.
Бергә булган минутларны
Ничек итеп онытыйм.

Алсу, зәңгәр чәчәкләрне,
Сахралардан алырсың.
Онытмам да, ташламам да,
Үлсәм генә калырсың.

Фанер янсын, фанер янсын,
Фанер янсын, ут алсын.
Уф, диярлек ярым түгел,
Пускай, ятларга калсын.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нурислам.
Сөеп-сөеп ят кулына
Бирмәс идем, мин булсам.

Сөям син, сөям сине,
Сөям сине багалмам.
Соңгы гомеремдә генә,
Дустым, сиңа булалмам.

Син дә ятка, мин дә ятка
Булсак нихәл итәрбез.
Очраганда бер-беребезгә,
Карап кына үтәрбез.

Урамыгыз киң булса да,
Бүлгәч, тараер әле.
Алма кебек алсу йөзең
Сагынып саргаер әле.

Алып бирим кызыл яулык,
Гармоныңны төрерсең.
Мин генә үкенмәм әле,
Үзең дә үкенерсең.

Искән җилләр өзәр инде
Алма яфракларын.
Тапсаң, эзләп кара инде,
Миннән яхшыракларын.

Шәл бәйлимен, шәл бәйлимен,
Алтын биш инә белән.
Алар эре, вакланмаслар
Безнең ишеләр белән.

Күз җиткәчтен кырау төшә
Урман чияләренә.
Сөймә, дустым, кеше ярын,
Булсын ияләренә.

Зәңгәр күлмәк, зәңгәр яулык
Килешә парлап кияргә.
Артык димим, ким дә димим,
Тиң дә түгел сөяргә.

Сандугачым, гүзәлем,
Өзелә минем үзәгем.
Вакыт җитми кавышып булмый,
Сабыр итик гүзәлем.

Иртә торам да тыңлыймын
Сандугач тавышларын.
Гомерлеккә булсын инде
Башлаган танышларың.

Аклы ситса күлмәгемнең
Итәге буй-буй яшел.
Алам, дигән ал телләргә
Ышанмый безнең нәсел.

Быел алган бурычыңны
Көзгә түләрсең инде.
Яр сөюеңне, мактанып,
Кемгә сөйләрсең инде.

Биек тауның башларында,
Шулмы инде стансагыз.
Ярларыгыз безнең кулда,
Бирербез офтансагыз.

Дустым, сиңа хатлар яздым,
Электр утларында.
Хатым сиңа барып җитсен,
Сагыну минутларында.

Военныйлар яшел кия,
Чирәмнән күренмәскә.
Салдың мәхәббәт утыңа
Гомергә сүрелмәскә.

Авылда телефон булса,
Звонит итәр идем.
Мөмкин булса, берәр елын
Служит итәр идем.

Пальто кигән, пальто кигән,
Ахры, туңармын, дигән.
Кеше ярына бәйләнгән,
Ахры, уңармын, дигән.

Сездә кар межасы булса,
Бездә кар межасы юк.
Сездә яр нужасы булса,
Бездә яр нужасы юк.

Узып бара машина,
Калай япкан башына.
Матур кызлар сайлый-сайлый,
Җиттең 30 яшеңә.

Алма алырсың әле,
Алмый калырсың әле.
Матур кызлар сайлап йөреп,
Ярсыз калырсың әле.

Аерылганда, исеңдәме,
Яшькә тулган күзләрең.
Йөрәгемнән мәңге китмәс,
Сау бул, дигән сүзләрең.

Мәскәүләрдән акбүз алдым,
Казан бүзе ак түгел.
Егет үзе ялынмаса,
Кызлар ялыначак түгел.

Утырганнарым – урындык,
Басып торганым – идән.
Яратып сөюем түгел,
Мәҗбүри генә сөям.

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява,
Кичкә таба сирәкли.
Сөям, дисәм яр бетмәгән,
Ләкин әле кирәкми.

Көн үткән саен борчылам,
Никтер, тынычсызланам,
Китәр көнем җиткәнгәме,
Уйлар эчендә янам.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Рәкыя.
Аерылганга үкенмимен,
Гөл дә чәчәген коя.

Тәрәзәмнең рамкасы
Виноград агачы.
Виноград – гөл агачы,
Син – сандугач баласы.

Гармонь кечкенә булса да,
Читен өйрәнүләре.
Сине күрми басылмый,
Йөрәгем әрнүләре.

Җелтер-җелтер утлар яна
Өй түрендәге ызбада.
Туган-үскән илләрендә
Күп яшәми кыз бала.

Су сипмиләр, яңгыр ява
Җирнең җиләкләренә.
Хат яз, дустым, дару булыр
Янган йөрәкләремә.

Кычкырта поезд, кычкырта
Станциягә җитәрәк.
Кайгы-хәсрәт килми булмый,
Безгә килде иртәрәк.

Үтеп китәр яшь гомерем,
Мин калырмын саргаеп.
Үткән яшьлегемне уйлап,
Мин җырлармын моңаеп.

Әй, шул үткән яшь гомерем, дип,
Йөрәгем ярсыр әле.
Йөрәгемнең ярсуларын,
Шул җырлар басар әле.

Яшьлек бит ул, шундый бит ул,
Белми ни күрәчәген.
Бел яшьлегеңнең кадерен,
Ашыгып өзмә чәчәген.

Сандугачым, кара кашым,
Тыңлыйм әйткән сүзеңне.
Тыңламас идем сүзеңне,
Бик яратам үзеңне.

Алмагачтан алма төшеп
Үләнгә күмеләдер.
Бәгърем, синең өчен генә
Күз яшем түгеләдер.

Кадерле дус, якын бәгърем,
Бик яратамын сине.
Шул якынлыкны уйлап,
Син дә онытма мине.

Алмалар аласыңмы,
Яулыкка саласыңмы?
Гомерлеккә яр булырга
Кул бирәм, аласыңмы?

Әнә килә автомобиль,
Эче тулы кишердер.
Чын мәхәббәт белән янам,
Сиңа мәгълүм түгелдер.

Сад-бакчадан алмаларны
Өзмиләр кызармыйча.
Гыйшык уты йөрәгемне
Ашый ла туктамыйча.

Әй бәгерем, син йөрисең
Миннән ачу алырга.
Язылышкан урын түгел,
Миңа ачуланырга.

Сад-бакчада ике алма,
Тик берсе дә мин булмам.
Син – бик матур, мин – уртача,
Хәтереңне табалмам.

Агыйделнең суы салкын,
Салкын булса да куе.
Башкаларга мин карамыйм,
Алтын булса да буе.

Кульяулыгым юар идем,
Ишек алдым күл булса.
Көн дә барып күрер идем,
Җир астында юл булса.

Яңа өйнең идәнен,
Яңача сипләтегез.
Ярларыгыз кирәк булса,
Сандыкка бикләтегез.

Кулымдагы беләзегем,
Секрет белән бикләнә.
Башка сөйгәнең бардыр, дип,
Яшь күңелем шикләнә.

Алмазлар белән кисәләр
Алманың түгәрәген.
Дошманга дучар булдың бит,
Мәхәббәт күбәләгем.

Солдат чәче үргә карый,
Көн саен майлап тарый.
Солдат мескен, бер төш күрсә,
Кайтыр юлларын карый.

Төшләремдә генә күрәм
Бодай таратканымны.
Ничек итеп сөйләп бирим
Сине яратканымны.

Зәңгәр күлмәк, ак яулык,
Шул минем кирәкләрем.
Гомерлеккә бергә булу,
Шул минем теләкләрем.

Кулыңдагы кул бавың,
Билеңдәге бил бавың.
Кичә көндез басма өстендә
Кемгә кулың болгадың?

Вак-вак көмеш тәңкәләрдән
Кемгә йөзек койдырдың.
Инде кемгә үпкәлисең,
Үзең тәмам туйдырдың.

Сандугачның балалары
Килми барып алмасаң.
Янган йөрәк басылмыйдыр,
Кычкырып җырламасаң.

Сары атымны җикмимен,
Җиксәм, керми елгага.
Яшь йөрәгемне яндырып
Кил, кулыңны болгама.

Кара урманга кермимен,
Керсәм, тартмыйдыр атым.
Сез дуслардан аерылгач,
Сынды сабыр канатым.

Дошман дошманлыгын итә,
Арада сүз йөретә.
Арада сүз йөретү белән,
Мәхәббәтне киметә.

Өстемдәге күлмәгемнең
Бизәк өстендә бизәк.
Сахраларга чыгып йөрим
Син дускаемны эзләп.

Аягыма юеш үтә,
Сары сандал кисәм дә.
Кошлар сайрап сагындыра,
Сагынмыймын, дисәм дә.

Иртә торып кошлар куам
Бакчада алмагачтан.
Сезнең хәлләрне сорыйбыз
Сайраган сандугачтан.

Биек тауның башларында
Алма төятә байлар.
Уйлата, ямансулата,
Саргайта торган айлар.

Базарларда әфлисун,
Кечкенәсе ике сум.
Синнән – миңа, миннән сиңа
Булсын иде телефон.

Сандугачлар кунып сайрый
Минем ак беләгемдә.
Үлгәндә дә син булырсың
Минем яшь йөрәгемдә.

Әнә килә автомобиль,
Әнә килә автобус.
Дошман сүзенә карама,
Дошман сүзен таптап уз.

Яшел чирәм өсләреннән
Эзләдем эзләреңне.
Табалмадым эзләреңне,
Онытмам сүзләреңне.

Сөям сине, бәгырькәем,
Башка ярың булмаса,
Башка ярың матур булып,
Җәл калырлык булмаса.

Кулъяулыгым төшеп калды
Кесәмнән көзге белән.
Кайда барсам да телимен
Яшәргә сезнең белән.

Көз җиткәнне тиз белерсең,
Куак кояр бөресен.
Мин сагынганны белерсең,
Төшләреңдә күрерсең.

Күктә – күбәләгем син,
Җирдәге тирәгем син.
Ялгыз чыгып сахраларда
Теләк теләгәнем син.

Уфтануларыңны beләм,
Ак ситса күлмәк киеп.
Йокыларымнан уянам,
Уф Алла, бәгърем, диеп.

Әнә килә якты яз,
Күлгә төшә үрдәк, каз.
Син бит минем якын дустым,
Сагынганда хатлар яз.

Карлар явып кына бетмәс
Синең йөргән эзләрең.
Йөрәгемнән китмәс инде
Синең әйткән сүзләрең.

Кулымдагы йөзегемнең,
Исемнәре Гөлсирень.
Син дә сөймә җиде ятлар,
Мин дә ятларны сөймим.

Аклы күлмәк матур була,
Ак епь белән юләсәң.
Үкенечем калмас иде
Бер күрешеп сөйләшсәм.

Өеп куйган мендәремне
Керле кул белән тотмыйм.
Мин, дустым, сине онытмыйм,
Син дә шулай, дип уйлыйм.

Әй дускаем, беләсеңме,
Сөям гүзәллегеңне.
Шушы гүзәллегең белән
Өзәсең үзәгемне.

Сары чәчәк эчләрендә
Сайрый тургай баласы.
Торган җирем гөл арасы,
Үзем авыл баласы.

Чит, чит, дидем, читкә киттем,
Чит иде теләкләрем.
Хәзер инде чит илләрдә
Өзелә үзәкләрем.

Агыйделдә йөзә микән
Сусарның балалары.
Кавышырсыз, дигән кебек
Кошларның сайраулары.

Алма бакчасына кереп,
Алмагачка үрелгән.
Матурлык өләшкән чакта
Әллә алдан йөгергән.

Косынкаңны артка бәйлә,
Чәчләрең күренмәсен.
Әй, дускаем, синең белән
Якынлык сүрелмәсен.

Бүз эленге бик килешә,
Буяулы тәрәзәгә,
Син дустымны сагынамын
Ифрат дәрәҗәдә.

Кибетләргә товар килгән,
Мин алам күгелҗемен.
Нинди генә җырлар языйм,
Сөекле күгәрченем.

Кибетләргә товар килгән,
Үкенәм алалмасам.
Хатка каршы хат салырсың,
Зурланып хурланмасаң.

Атлар иярләдеңме,
Тайлар иярләдеңме?
Әй, җаныем, җан кисәгем,
Ятларга иярмәдеңме?

Скрипка значогы
Нинди көйләр көйләми.
Карточкаңа карасам да,
Үзең кебек сөйләми.

Тәрәзәмне ачык куям,
Стенам тирләгәндә.
Син бәгыремне күрә алмыйм
Күңелем теләгәндә.

Тальянский гармоньнарны,
Уйныйлар, ди, садларда.
Нык тот, бәгърем, күңеленңне
Мин булмаган чакларда.

Сипаратым, сипаратым,
Сипарат казаннары.
Булса булсын грамотный,
Кирәкми наданнары.

Пич агартам, пич агартам,
Пич агартам кар кебек.
Йөрәгемнән китмәссең син
Гомер иткән яр кебек.

Агыйделнең аръягында,
Ниләр күзлисең икән.
Чынлап мине тиң күрмичә,
Ярлар эзлисең икән.

Әй, бәгырем, бир кулыңны,
Мин дә бирәм кулымны.
Синнән башка томан каплый
Йөри торган юлымны.

Тальянский гармоньнарны
Буйыйлар җилем белән.
Йөргән юлларымда телим
Яшәргә синең белән.

Казаннардан утыралмадым
Мәскәү поездларына.
Сине бик еш чыгып карыйм
Зөһрә йолдызларына.

Тәрәзәдән карар идем,
Күренер булсаң күземә.
Бер ел түгел, биш ел көтәм,
Әгәр булсаң үземә.

Сандугачлар кунып сайрый
Кибет ачкычларына.
Әйдә, бәгырем, икәү басыйк
Тормыш баскычларына.

Машинаның винтын бордым,
Хәзер ничек туктатыйм.
Уң беләгемә башың куеп,
Кил, бәгырем, йоклатыйм.

Кулымдагы бу алманы
Урталай бүләр идем.
Нечкә биленә кул салып,
Серемне сөйләр идем.

Их, җаныем, буйларың,
Кемдә синең уйларың.
Әгәр мине уйлар булсаң,
Мин дә сине уйлармын.

Колхоз басуына барып,
Трактор көйлисеңме?
Сөям, җаныем, ташлама, дип,
Син дөрес сөйлисеңме?

Алмагачтан алма алып,
Сабыйларга өләштем.
Төнлә төшләремдә күреп,
Синең белән сөйләштем.

Исле гөлләр чәчәк ата,
Бик күңелле җәй көнне.
Кая барсам да онытмыйм,
Алсу чәчәгем, сине.

Биек тауның башында,
Күренеп тора бер елга;
Озакка түгел, бәгырькәем,
Аерылышыйк бер елга.

Кара атым тарталмаса,
Күк атым тартыр әле;
Исән булса газиз башы,
Әйләнеп кайтыр әле.

Иртәнге җил, кичке салкын,
Бөркән, бәгърем, шәлеңне;
Күптән бирле күргәнем юк,
Белә алмыйм хәлеңне.

Алма бакчасына керәм,
Үзем алмалар өзәм;
Тормыш юлы чәчәк атып,
Бергә булуны көтәм.

Түгәрәк күл, төбе тирән,
Үрдәкләр йөзәр инде;
Минем ничек сагынганны
Хатларым сөйләр инде.

Биек тауның башына
Чәчәк өзеп ташладым;
Өзелеп хатлар язмас идем,
Сагындыра башладың.

Агыйделнең аръягында,
Ак пароходлар гына;
Үзем барып күрә алмыйм,
Җибәрәм хатлар гына.

Ишек алдым яшел чирәм,
Анда былбыллар уйный;
Төнлә күрәм төшләремдә,
Сөйләшеп кенә булмый.

Ал да яза, гөл дә яза,
Кулымдагы каләмем;
Хат башында барыр әле,
Сагынычлы сәламем.

Мәңге сүнмәс утлар яна
Шахта күмерләрендә;
Бер кемем юк синнән башка
Минем күңелләремдә.

Йокың килсә, ятып йокла
Мамык подушкаларга;
Исемеңне мин куямын
Алтын брошкаларга.

Тәрәзә төбем исле гөл,
Сал да балдагыңны эл;
Сагынмагач хат язмыйлар,
Сагынганны шуннан бел.

Алсу була, моңсу була,
Җәй көнендә таң ату;
Сагынуларым шул кадәрле,
Мөмкин түгел аңлату.

Иртә торып тышка чыксам,
Банкадагы гөлем юк;
Әй, бәгърем, ник оныттың,
Уйламаган көнем юк.

Күгәрченнәр җиргә төшә,
Бергәләп гөрләшергә;
Яшь күңелләрем моңая
Бер күреп сөйләшергә.

Ал тарелка, зәңгәр тирә,
Тәмләтә ашларымны;
Әй, бәгърем, мәхәббәтең
Бәйләде башларымны.

Сандугачның аягына
Ука чорнап җибәрәм;
Сагынганда бер укырсың,
Хатлар язып җибәрәм.

Тәрәзә төбем исле гөл,
Исерәм исләренә;
Сәгать минутлары саен
Төшерәм исләремә.

Минем чәчем уңга яткан,
Сулга таба тараган;
Булмый, бәгърем, синең кебек
Күңелемә яраган.

Безнең авыл уртасында
Чакырым саен бер нарат;
Сөйләр идем сүзләремне
Нурлы йөзеңә карап.

Безнең артта түгәрәк күл,
Кораблар йөри торган;
Бер сандугач булса иде,
Арада йөри торган.

Өстәлләрдә шәмнәр яна,
Тамчы-тамчы май тама;
Зәңгәр күзем, кара кашым,
Күрсәм, йөрәгем яна.

Аклы күлмәккәем кара,
Каралса да киямен;
Дошман ниләр сөйләсә дә,
Син бәгъремне сөямен.

Ак чәчәк белән гөл чәчәк
Күңелсез чәчәк түгел;
Сиңа төшкән мәхәббәтем
Мәңге сүреләчәк түгел.

Аклы ситса күлмәгеңне
Өстәлләрдә кистеңме?
Чәчәк аткан гөлләр кебек,
Банкаларда үстеңме?

Алты метр ал тасма,
Җиде метр гөл тасма;
Сөяр булсаң – бир вәгъдәңне,
Сөймәс булсаң – алдашма.

Киеп беләзегеңне
Уйдырма беләгеңне;
«Сөям», – диеп, бир вәгъдәңне,
Яндырма йөрәгемне.

Су буенда тал-тирәк,
Яфраклары бик сирәк;
Әй, бәгърем, ыңгырашканда
Кулга-кул бирү кирәк.

Безнең яктан искән җилләр
Синең чәчләреңне сөярләр;
Синең чәчләреңнән сөярләр дә,
Миннән сиңа сәлам, диярләр.

*Татар Саплыгы авылында Зарипов*
*Сабирулла Садыйк улыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

Сагынганда айга кара
Дустың төсләре итеп;
Яшьлек сердәшем бул минем,
Дошманнарга үч итеп.

Мәхәббәтнең күле булса иде,
Мин коенсам иде шул күлдә;
Юк кирәкми, тамчы кадәре дә
Диңгез булып ярсый күңелдә.

Яшел чирәм су эчендә,
Уртасында камышлык;
Сагынып саргаерга гына,
Нигә соң без таныштык.

Авыр икән, бигрәк авыр икән,
Өзелеп сөйгән ярдан калуы;
Күңелем сүрән, башым түбән иям,
Һич басылмый йөрәк януы.

Язмыш уйный кеше белән,
Ул һәрвакыт үзгәрә;
Йә күтәрә бик югары,
Йә тибәрә түбәнгә.

Аклы ситса күлмәгемнең
Итәген киң итәрмен;
Суга төшсәм дә, йөзәрмен,
Сине күрми нишләрмен.

Аклы ситса күлмәгемнең,
Итәге ике иңсез;
Мин дә синсез, син дә минсез,
Мин түзә алмыйм синсез.

Аклы ситса матур да бит,
Кия алмадым айлысын;
Эзләмәдем, сайламадым,
Таптым ярның җайлысын.

Кулларына гармонь тоткан
Җитез бөркет шикелле;
Мәхәббәтең минем йөрәгемдә
Чыңлап үтте гармонь шикелле.

Аргы якның кыр казларын
Бирге яктан карыйбыз;
Егетләрнең ничеклеген
Бер күрүдә таныйбыз.

Мин дә уйлап торам әле
Синең белән китәргә;
Бир кулыңны, вәгъдә бирәм
Кайтуыңны көтәргә.

Кулымдагы йөзегемнең,
Исеме Гаян икән;
Алмагачларың булса да,
Талларга таян икән.

Биек тауның башларында
Аерым-аерым түтәлләр;
Без аерылдык, авыр булды,
Аерылмасын бүтәннәр.

Синең кашың кара диеп,
Кызыкмыйм кашларыңа;
Янып-көеп сине сөеп,
Кайгы алдым башларыма.

Киям әле, киям әле,
Киям әле ал фартук;
Кеше ярлары кирәкми,
Үз ярларым да артык.

Алъяпкычым алсу, алсу,
Алсуга манмасам да.
Дөньяны шулай уздырам,
Ярымнан калмасам да.

Агыйделнең буйларын,
Сандал киеп буйлама.
Үзең ничек, мин дә шулай,
Ялыныр, дип уйлама.

Алмагачның алмасын,
Ал булмый ашамыйлар;
Яратмагач башламыйлар,
Башлагач ташламыйлар.

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява,
Соңга таба сирәкли;
Сөям, дисәң, яр бетмәгән,
Ләкин әле кирәкми.

Өстемдәге күлмәгемнең,
Итәкләре киң генә;
Җирдә – җиләк, күктә – кояш,
Күңелемдә син генә.

Гармонь уйный бер малай,
Гармонь телләре калай;
Ялындырмак телисең дә,
Без ялынмыйбыз алай.

Сөйлиләр бит, сөйлиләр бит,
Сөйлиләр бит һаман да;
Сөйләсәләр дә һаман да,
Селкенмидер салам да.

Безнең күлгә казлар килгән,
Ике мең дә ике йөз;
Дошманнар безне аерсалар,
Аерылмабыз икебез.

Сөям сине, сөям сине,
Сөям сине, асылъяр;
Ләкин сөям вакытлыча,
Гомерлеккә – ярым бар.

Алма сатучылар килгән
Алма ашаучыларга;
Бик исебез китми әле
Сөеп ташлаучыларга.

Ботинкасы эчләрендә
Балтыр бәйләвечләре;
Ул сөйгәндә мин сөймәдем,
Шуннан ала үчләрен.

Талдан тартма ясар идем,
Тал кабыгы суелса;
Башкаларны сөяр идем,
Синнән җаным суынса.

Ал киюче без түгел,
Гөл киюче без түгел;
Үзләре ялынмаганга
Ялынучы без түгел.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Хәдичә;
Өч көнлек ярым бар иде,
Сдавать иттем кичә.

Алтын бирәм алганга,
Көмеш бирәм калганга;
Ярымны подарить итәм
Яр таба алмаганнарга.

Безнең колхозның атлары
Бары да печән ашамый;
Якын күреп сөйгән ярны
Һичберәү дә ташламый.

Безнең бакча артында
Яшел чыршы урманы;
Вакыт үтсен өчен генә
Сөйгән идем мин аны.

Минем шундый гадәтем бар,
Җырны шигырь итәмен;
Трантайга утыргач,
Мәскәүгә дә җитәмен.

*Иске Чокалы авылында Йосыпова Мөнирә*
*Аниятулла кызыннан (1934 елгы)*
*язып алынды*

Ага сулар, ага сулар,
Ага сулар көньякка;
Укып чыккач аерылабыз
Төрлебез төрле якка.

Зәңгәр чиләк матур була,
Су белән тулгач кына.
Әй, бәгърем, бергә булыйк
Сүзеңдә торсаң гына.

Уфаларга бармыйсыңмы
Уфа юлын карарга.
Җибәр, бәгърем, карточкаңны,
Сагынганда карарга.

Агыйделгә сикереп төштем
Аккош булып кагынып;
Каләм алып хатлар язам
Син бәгъремне сагынып.

Аклы ситса күлмәгемне
Машинада бетерәм;
Җырларымны тәмам итәм,
Каршы җырлар үтенәм.

Яз җиткәнне шуннан беләм,
Су тула болыннарга;
Канат куеп очар идем
Сез торган урыннарга.

Яшел тарантас җигәр идем,
Әгәр пар атым булса;
Сагынганда барыр идем,
Ике канатым булса.

Сез Казан каласында,
Без Мәскәү каласында;
Безнең кебек аермасын
Дөнья кош баласын да.

Сандугачлар кайда сайрый?
Агыйделнең ярында;
Синең белән яшәр идем,
Гомеремнең барын да.

Алмагачтан алма төшеп
Җирләрне уяр микән;
Нурлы йөзләреңне күреп,
Күзләрем туяр микән.

Су агымында барганда,
Кызу бара кораблар;
Иртән искән җилләр белән
Синнән көтәм җаваплар.

Бер туйганчы ашар идем
Бохараның карбызын;
Эч серемне сөйләр идем,
Әгәр күрсәм ялгызың.

Аклы күлмәк кияр идем,
Билләремне кысмаса;
Карточкаңны карар идем,
Ул да юк бит ичмасам.

Өстемдәге күлмәгемнең
Тирәләре яшел чук;
Ышан, бәгърем, шул сүземә:
Синнән башка ярым юк.

Казаннардан Мәскәүләргә
Бар да тимер юл икән;
Авыруларга бар дарулар,
Сагынуларга юк икән.

Изба салдырсаң, бәгырем,
Астын биек калдырма;
Киләм, дисәң, кил, бәгърем,
Үкенечкә калдырма.

Тау башына менәр идем
Беләгемә таш куеп;
Эч серемне сөйләр идем
Күкрәгеңә баш куеп.

Ак келәтнең тәрәзәсе
Сиксән сигез өлгеле;
Начар егеткә бәйләнсәң,
Хур буласың билгеле.

Безнең урам аркылы,
Ага суның салкыны;
Акмыйдыр суның салкыны,
Яна йөрәк ялкыны.

Алдыр сукно, тектер пальто,
Өшесәң ябынырсың;
Яшьли сөйгән ярым, диеп,
Бәгырем, сагынырсың.

Матур булып язлар килер,
Чәчәк атар алмагач;
Ял итүдә ни файда бар,
Сез янымда булмагач.

Самоварың җиз генә,
Кайнап чыга тиз генә;
Матур да күп, чибәр дә күп,
Җан сөйгәнем син генә.

Чикләвек ваттым теш белән,
Күкрәктәге көч белән;
Көндез үткәрәм эш белән,
Сагынам иртә-кич белән.

Күзләрең матур синең,
Карасам күзем тала;
Матур күзең карашлары
Йөрәкне чеметеп ала.

Нур булып төшәр идем,
Чәчеңне тарар идем;
Күз керфекләреңә кунып
Күзеңә кара идем.

*Мунчәли авылында Алиакберов*
*Марсель Фатих улыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

Сандугачым әйт үземә,
Кайсы талга кунасың?
Күзем йомсам – күз алдымда,
Күз ачсам – югаласың.

Көз китмәгән сандугачлар,
Баку ягына китә;
Иртә торсам, яшь күңелем,
Өзелеп сезне көтә.

Алтын йөзек, көмеш каш,
Киясең килсә, сандык ач;
Синең кебек булса булыр
Бакчадагы сандугач.

Агыйдел сулары булып
Урамга агар идем;
Яңгыр тамчылары булып
Куйныңа тамар идем.

Ак тапочкаларың бармы,
Бакчада кия торган?
Син бит минем роза гөлем,
Мәңгегә сөя торган.

Аклы ситса күлмәгемнең
Бизәге йөзек-йөзек;
Синең кебек кошлар сайрый
Тавышын өзеп-өзеп.

Биек тауның башыннан
Мәк чәчәген карадым;
Мәк чәчәген, сиңа охшатып,
Күкрәгемә кададым.

Чәчләрем озын булса да,
Чуалтып үргәнем юк;
Сахраларда сезгә охшаулы
Кошларны күргәнем юк.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Бибинур;
Авызың уймак, тешең энҗе,
Иреннәрең помидор.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Миләүшә;
Кашың кара, буең зифа,
Сөйгәнең белән яшә.

Ак атың булыр идем,
Күк атың булыр идем;
Өстеңдәге күлмәгеңнең
Якасы булыр идем.

Иртә торып тышка чыксам,
Күрәм колхоз атларын;
Күңел кошым сиңа төште,
Сындырма канатларын.

Алма бакчасына кереп
Тал бөресен өзәсең;
Күз карашың бик матур,
Үзәгемне өзәсең.

Аклы ситса чиста була
Ефәк белән юләсәң;
Үкенечкә калмас идем
Бер туйганчы сөйләшсәм.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәрзәнә;
Былбыл булып кунар идем,
Гөл куйсаң тәрәзәңә.

Колак алкалар тагамын,
Колагым чиләнсә дә;
Дошман сөйли, сөйләп кала,
Нишли соң сөйләсә дә?

Муеныңдагы мәрҗәнең
Өзмәле дә, тезмәле;
Сөйгән ярың ерак түгел,
Өметеңне өзмә әле.

Уфа телеграмының
Баганалары каен;
Яр өстенә яр сөясең,
Азасың бит, җанкаем.

Дошман сөйләр, ниләр сөйләр,
Без аларга бирешмик;
Сүз бер булсын, гүзәл ярым,
Җиде ятлар сөешмик.

Яңа ызба син салдырсаң,
Куй урамга каратып;
Дошман әллә ни сөйләсен,
Мин сөямен яратып.

Турыгыздан узган чакта,
Конфет сүтеп ашадым;
Зифа буеңны күрсәтеп,
Хәсерәтле ясадың.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нургали;
Шул яшемдә бер яр сөйдем,
Ул да ятларга карый.

Аклы ситса күлмәгемнең
Якалары тар икән;
Агымсуны туктатырлык
Мәхәббәтең бар икән.

Безнең авыл әйләнәсе
Сигез ярым чакырым;
Синнән башка сөйгәнем юк,
Ышанамсың, матурым.

Аклыларны ник тектердең,
Атна саен кимәгәч;
Күңелемне ник аздырдың,
Ихлас белән сөймәгәч.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нурылмый;
Синең кебек матур ярлар
СССРда да булмый.

Капка төпләренә чыгып,
Кулъяулыгы киптерәм;
Серле күз карауларыңны
Күз алдыма китерәм.

Ишегемнең бусагасы
Бик киң микән, тар микән;
Синең кебек матур ярлар
Бу дөньяда бар микән.

Дустым, күлмәкләр тектерик
Икебез дә карадан;
Дошман түгел, җил дә үтмәс
Икебезнең арадан.

Исле гөл исле була,
Кына гөл кызыл була;
Сине өзелеп сагынганда
Көннәр дә озын була.

Гөл чәчәгенә бәйләнеп
Чия пешә алланып;
Нигәдер, кырын карыйсың,
Бардыр сөйгән ярларың.

Гөл чәчәгенә бәйләнеп
Чия пешә бал кебек;
Гәүдәң зифа яшь тал кебек,
Йөзең тулган ай кебек.

Аерылганда, кулың бирдең,
Син миңа салкын гына;
Салкын кулың йөрәгемдә
Тудырды ялкын гына.

Җир җиләге ачы була,
Җыйнама кызармыйча;
Һәрвакытта сине уйлыйм
Исемнән чыгармыйча.

Имән яна, имән яна,
Имән яна, көл кала;
Онытырлык ярым түгел,
Онытмам гомергә дә.

Талдан тартма ясар идем,
Тал кабыгы суелмый;
Синең күңелең ничек икән,
Минем күңелем суынмый.

Кызыл батист кульяулыгым
Җилферди җилдә генә;
Күңелләрем күтәрелә
Син булган җирдә генә.

Алма өзеп, епкә тезсәң,
Балавызлы епкә тез;
Син юк җирдә мин дә түзәм,
Мин юк җирдә син дә түз.

Агыйделнең талларына
Таяна торган идем;
Нурлы йөзләреңә карап
Юана торган идем.

Кульяулыгым күп иде,
Берсен җилдән алдырдым;
Яшьлек белән белә алмадым,
Хәтереңне калдырдым.

*Мунчәли авылында Мәхмүтов Вәзих*
*Ишмөхәммәт улыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

Агыйделнең аръягында
Җырлап утын кисәләр;
Әллә миңа, әллә сиңа,
Кульяулыгы селкәләр.

Юбкасында, кофтасында
Тасма куйганнар хәзер;
Кемнең йөзе ачыгырак,
Шуны сөяләр хәзер.

Ак келәтнең алларында
Калды минем дилбегәм;
Калмады минем дилбегәм,
Калды нечкә билгенәм.

Яшел башлы, яшел түшле,
Кайдан алдың ул кошны?
Җәйләрен бергә үткәрдем,
Ничек үткәрим кышны.

Егетләр илнең былбылы,
Кызлар былбылның гөле;
Гөл былбылын, былбыл гөлен
Сагынасы билгеле.

Ал гөлләрем бар иде,
Бакчаларым тар иде;
Ал чәчәк букетларыдай,
Сөйгән ярым бар иде.

Җырлагыз, кызлар, җырлагыз,
Җырламыйча тормагыз;
Бергә булганда җырлагыз,
Ялан бергә булмабыз.

Өй түрендәге агачның
Аты миләүшә икән;
Сандугач сайрый, дип торам,
Дустым сөйләшә икән.

Алма булса, ал булсын,
Безгә агы кирәкми;
Булса, булсын ударница,
Безгә ялкау кирәкми.

Апрель җитми, агып китми
Агыйделнең бозлары;
Су сорасаң, бал бирәләр
Безнең авыл кызлары.

Җилфер-җилфер китмәсә,
Җилләр алып итмәсә;
Төскә матур, эшкә батыр,
Ударница, җитмәсә.

Әнә килә автомобиль
Төягәннәр таш күмер;
 Эшлибез дә, укыйбыз да,
Бушка үтми яшь гомер.

Тубылгы агач озын булмас,
Тубылгы аша юл булмас;
Кайда булсаң да, тырыш бул,
Тырыш егет хур булмас.

Утырабыз да китәбез
Агыйдел бозларына;
Күрсәгез, сәлам әйтегез,
Безнең ил кызларына.

Ап-ак кына, бик вак кына
Урманда куак кына;
Күпсенмәгез, күп тормамын,
Мин монда кунак кына.

Өстәл өсләрем тигез,
Өстәл аягым сигез;
Безнең колхозның кызлары
Бар да матур, бер тигез.

Биек икән тавыгыз,
Каршы ява карыгыз;
Без килдек тә, кунак булдык,
Инде үзегез барыгыз.

Өй түрендә талыгыз,
Әйләндереп алыгыз;
Өзелеп-өзелеп чакыргачтын,
Иртәгә үк барыгыз.

Ак перчаткаң бар мәллә,
Бармакчасы тар мәллә?
Әйләнсәң дә карыйсың,
Әйтү сүзең бар мәллә?

Җитеннәр элдем читәнгә,
Җилфер-җилфер итәргә;
Дусларым йөри китәргә,
Белмим нихәл итәргә.

Ерак җирләрдән күренә
Агыйделнең ак ташы;
Кайда барып, кайда йөрмәс
Уңган егетләр башы.

Челтәрле күпер астында
Юына үрдәккәем;
Чапкан атлар гына ярсый,
Ярсыма йөрәккәем.

Су буйларын тал алган,
Тамырлары таралган;
Без дошманнан курыкмыйбыз,
Йөрәк таштан яралган.

Ал бәйлиләр, гөл бәйлиләр
Талган беләкләремә;
Ут салалар, су салалар,
Янган йөрәкләремә.

Биек тауга чыклар төшкән,
Ник төшмәгән үзәнгә;
Йөзе чытык, күңеле сүрән,
Ни булган бу гүзәлгә.

Тал өяләр, тал өяләр,
Нигә өяләр икән?
Их үзәгем, яшь йөрәгем,
Нигә өзелә икән?

Агыйделдәге аккошны,
Чуммасаң, ала алмассың;
Яшь гомерең үтәр китәр,
Кайтарып ала алмассың.

Кульяулыкны тузмый, диләр,
Почмагыннан туза икән;
Яшь гомерне узмый, диләр,
Искән җил күк уза икән.

Сандугачлар юк әле,
Карлыгачлар югары;
Бу дөньяда безнең кебек
Пар килгәннәр юк әле.

Аклы ситса күлмәгемнең
Сәдәпләре алтыннан;
Сандугачларга охшатып,
Карап калам артыңнан.

Су буена төшкән идем,
Су өсте күбек кенә;
Син бит минем якын дустым,
Күз нурым кебек кенә.

Комсомолка син үзең,
Карадан кара күзең;
Эшне сөеп үскәнгәме,
Ай күк балкыган йөзең.

*Мунчәли авылында Шаһиева*
*Җәмилә Имәт кызыннан (1935 елгы)*
*язып алынды*

Ник сагынам бу чаклы,
Ник саргаям бу чаклы;
Сагынмасам, саргаймасам,
Язмас идем бу хатны.

Сайрый сары сандугач,
Очып китә кагынгач;
Әйләнәм дә хатлар язам,
Син иркәмне сагынгач.

Биек тауларга менгәндә
Кемнәргә ябышырмын;
Йә үләрмен, йә бик каты
Чирләргә сабышырмын.

Ефәк яулыклар бөркәнмәм,
Базарлардан алсам да;
Ташладың, дип, суга төшмәм,
Ялкыныңда янсам да.

Утка каршы ялтырыйдыр
Башымдагы тарагым;
Мәхәббәтең саф булмагач,
Ник күземә карадың?

Утырып киттең, карап калдым
Һава флотларына;
Шуннан торып яндырасың
Мәхәббәт утларында.

*Иске Кәкерле авылында Шәрәфиева*
*Таһирә Расих кызыннан (1937 елгы)*
*язып алынды*

Сирень чәчәк аткан чакта,
Яратам сирень исен;
Әй, бәгърем, син белмисең,
Саргаям синең өчен.

Сары матур, сары матур,
Сары матур сайласаң;
Әллә кайлардан танырмын,
Кошлар булып сайрасаң.

Аклы ситса күлмәгемнең
Пояслары бушаган;
Ике былбыл талга кунды,
Берсе сиңа охшаган.

Тәрәзәмнең төпләрендә,
Зәйтүн дигән гөлләр бар;
Сиңа охшатып сөяр идем,
Сиңа охшаулы кемнәр бар.

Өй түрендә гөл түгелгән,
Сандугачлар күмелгән;
Тиңең сөйгәч, гаҗәп икән,
Һич тә чыкмый күңелдән.

Ап-ак каен урман саен,
Яфрак яра ел саен;
Сәгать саен, минут саен,
Күрәсем килә көн саен.

Иртә торып тышка чыксам,
Ишек алларым томан;
Шул томаннар эчләрендә
Син басып торган сыман.

Уфалардан алып кайттым
Асылмалы зур көзге;
Якты йолдызлар сүнгәнче
Уйлап ятам мин сезне.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлҗиян;
Язга чыксам, сезгә охшаулы
Алсу чәчәкләр җыям.

Алты пара алтын чашка
Алып куйдым шкафтан;
Җырламый ничек түзәсең
Сез дусларым кушкачтан.

*Иске Кәкерле авылында Әхмәтова*
*Рузалин Латыйп кызыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

Турыбызда зәңгәр чәчәк,
Саклап үстергән кебек;
Бик бәхетсез бала булдым,
Каргап үстергән кебек.

Сандугачым, сизәсеңме,
Ишәләр бәхетеңне;
Кайдан эзләп табыйм икән,
Югалган бәхетемне.

Агыйделнең аръягында,
Сары чәчәк күп була;
Бәхетлесе сирәк була,
Бәхетсезе күп була.

Агыйделнең аръягына,
Әллә чәчтеңме бодай?
Кыз балага шунсы яхшы –
Бәхет өләшсә Ходай.

Корып куйган мылтыкны
Якын җирдән атмыйлар;
Бәхет белән мәхәббәтне
Магазинда сатмыйлар.

Мин бәхетсез, мин бәхетсез,
Мин бәхетсез бер үзем;
Бәхетле кешеләргә карап,
Тилмерә ике күзем.

Бәхет күлләрендә йөзә,
Бар минем иптәшкәем;
Минем генә юк бәхетем,
Түгелә күз яшькәем.

Мин бәхетсез, мин бәхетсез,
Мин бәхетсез, ник болай?
Түкмә яшең, күз яшең,
Ходай язгандыр шулай.

Мин бәхетсез, мин бәхетсез,
Мин бәхетсез булганмын;
Әнкәемнең иң кайгылы
Көннәрендә туганмын.

Безнең авыл, зур авыл,
Каерыр әле җил-давыл;
Булма матур, бул бәхетле,
Бәхетсезлек бик авыр.

Челтәрле күпер өстендә
Каз канатын төзәтә;
Булма матур, бул бәхетле,
Бәхетлелек көн күрсәтә.

Кашың кара булганчы,
Күзең кара булсачы;
Бәхетсезгенәм булганчы,
Гомрем кыска булсачы.

Өстемдәге күлмәгемнең
Итәге тигез түгел;
Бәхетләр дә шулай уктыр,
Бармак та тигез түгел.

Агыйделнең аръягында
Комнан дарья булмый ул;
Бар – бәхетле, бар – бәхетсез,
Дөнья тигез булмый ул.

*Иске Кәкерле авылында Зөбәйдуллина*
*Маерә Зартдин кызыннан (1907 елгы)*
*язып алынды*

Түгәрәк күл уртасына
Гөл утырттым үрергә;
Ике кулым канат булса,
Барыр идем күрергә.

Талдан тартма ясар идем,
Тал үзәге суырылса;
Бүтән ярлар сөймәс идем,
Синнән күңелем суынса.

Чит илләрдә йөреп адашмам микән,
Ерак китте минем юлларым.
Әллә тәкъдир язмышлары шулай,
Әллә тапмыйм бәхет юлларым.

Агыйделкәйләрне, әй, кичкәндә,
Бер җырладым ишкәк ишкәндә;
Бер җырладым, дустым, бер җыладым
Яшь гомеркәй искә төшкәндә.

Җәй көнендә урак урган,
Тирләмәгән, пешмәгән;
Бер матурга гашыйк булып,
Чүт суларга төшмәгән.

Асламчылар туктаган,
Эшлиясе чуклаган.
Минем бәхет килми, китми,
Бер тар җирдә туктаган.

Уфа, диләр, Уфа, диләр,
Уфаның бар күлләре;
Әллә инде корыды микән,
Бәхетемнең гөлләре.

Иртә торып серем сөйлим,
Сандугач бәбкәсенә;
Ул да шулай минем кебек
Аерылган әнкәсеннән.

Языйм микән, җитәр микән,
Язып файда итәр микән;
Аерылган җәрәхәтем
Йөрәгемннән китәр микән.

Очар идем, китәр идем,
Теләгемә җитәр идем;
Ходай сабырлык бирмәсә,
Мин адашып китәр идем.

Балаларым, чәчәкләрем,
Калдырамын сезләрне;
Кайчагында искә алыгыз
Хатлар белән безләрне.

Бу дөньяларда күп йөрдем,
Эчтем дә суларын, туймадым;
Әйтер сүзләремне әйтә алмадым,
Тагын күрермен, дип уйладым.

Аргы якта гөл үлән,
Бирге якта гөл үлән;
Шундый авыр хәсрәттән
Вакыт җитмичә үләм.

Нинди алсу, нинди гөлсу,
Шулай да моңсу җир йөзе;
Дүрт ягымны чорнап алган
Кайгы-хәсрәт диңгезе.

Очар кошым, очар кошым,
Очып киттең авылга;
Син очып киткәч авылга,
Мин әвереләдем авыруга.

Әнә килә паровозлар,
Парлары артка кала;
Хатка язып сүзем бетми,
Тагын сүзләрем кала.

Әнә килә автомобиль
Сары яр буйлап кына;
Үтә минем гомерләрем
Сезләрне уйлап кына.

Биек тау башында таш тегермән,
Әйләнәдер җилләр тимичә;
Сез сөйлисез кошлар телечә,
Без белмибез сезнең телегезчә.

Биек кенә сарай вак баскыч,
Мендем, keләләрен элмәдем;
Кызыл гөлдин маяк кадый идем,
Сез киләсе юлны белмәдем.

Башкынама яулык бәйләр идем,
Сибәләп үк яңгыр яумаса;
Синең гыйшыгыңнан үләр идем,
Ходай сабырлыгын салмаса.

Әнекәем, ике күзем,
Сөйләргә күптер лә сүзем;
Солдатларга чыгып киттек,
Ходай бирсен инде түзем.

Карагыз ла сез аланга,
Баладан аерылган казга;
Кунып сайрыйдыр ла сазда,
Дивана булып ялгызга.

*Мунчәли авылында Мәхмүтова Фәхриҗамал*
*Гыйльметдин кызыннан (1896 елгы)*
*язып алынды*

Ай янында якты йолдыз,
Чакрым ярым арасы;
Күзләреңнең нурларында
Кашларыңның карасы.

Яңа изба син салдырсаң,
Куй урамга каратып;
Дошман әллә ни сөйләсен,
Мин сөямен яратып.

Кулымдагы йөзегемнең,
Исемнәре Нурулла;
Күтәрелеп карый алмыйм
Йөзеңдәге нурыңа.

Чәчләрем озын булса да,
Чуалтып үргәнем юк;
Сахраларда сезгә охшаулы,
Кошлар да күргәнем юк.

Биек тауның башларында
Сирень утыртучылар;
Син бит болай түгел идең,
Бардыр котыртучылар.

Кырым тавының башлары,
Быел яшәрде микән?
Әгәр икәү тормыш корсак,
Бергә яшәрбез микән?

Ике яшел хат кыстырдым
Мәйдан баганасына;
Нинди җырлар җырлыйм икән,
Сандугач баласына?

Аккош балалары йөзә
Сания күлләрендә;
Аерылуны уйламадым
Танышкан көннәремдә.

Һавадагы йолдызларны
Стаканга тутырам;
Ярым да юк, кайгым да юк,
Спокойно утырам.

Самовар куйдым кайнарга,
Кунактагы агайларга;
Нинди җырлар җырлыйм икән,
Яңа тулган айларга?

Колхозчылар иген суга,
Игеннәре тук кына;
Минем ярны каратырсыз
Ударник булып кына.

Сиксән сигезенче номер,
Колак алкаларымда;
Нинди сүзләр ишетмәдем,
Синең аркаларыңда.

*Мунчәли авылында Измайлова*
*Зифанур Мифтах кызыннан (1936 елгы)*
*язып алынды*

Алтын пәкемне сындырдым
Гөл тамыры кискәндә;
Сәламнәремне җибәрәм
Кичке җилләр искәндә.

Биек тауның башларында
Арыш үсә бөгелеп;
Сез сагынмый торгансыздыр,
Мин сагынам өзелеп.

Агыйделнең аръягында
Камышлар чабып өздем;
Камышлар кебек саргайдым,
Чәчәкләр кебек идем.

Ап-ак, ап-ак миләүшәләр,
Таптап китүләреңдер;
Таптап китүең дә түгел,
Ташлап китүләреңдер.

Урманнардан җыйма чәчәк,
Сахралардан алырсың;
Мәңге онытмам, һич ташламам,
Үлсәм генә калырсыз.

Алъяпкычлыр мин тектердем,
Каралар кыйбатлангач;
Сагынсам да түзәм инде,
Аралар еракланган.

Зәңгәр кара тамган иде
Күлмәгем буйларына;
Әй дускаем, гомер буе
Булырсың уйларымда.

Машиналарга утыргач,
Билетсыз да китәрсез;
Дустым, дошман сүзләренә
Ышанучан икәнсез.

Чәчләремне үреп салдым,
Алты, җиде, сигезләп;
Сахраларга чыгып китәм,
Ялгыз башым сине эзләп.

Кулымдагы йөзегемнең,
Исемнәре Гөлнурым;
Насыйп булса, күрешербез,
Хуш, бәгырем, күз нурым.

*Иске Кәкерле авылында Нуретдинова Наилә Канәфия кызыннан (1938 елгы) язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Рәхилә;
Рәнҗеткәнмен, рәнҗегәнсең,
Рәнҗесәң дә бәхиллә.

Аклы ситса күлмәк киеп
Урамнарда йөрисең.
Ник бу кадәр якын булдым,
Күңелемнән китмисең.

Карлыганның куаклары
Тулган карлыган белән.
Күңелләрем аерылмый
Үзем аерылган белән.

Кызыл чия тәмле була
Ал чәйнектә пешерсәң;
Шушы хатларны укырсың
Мине искә төшерсәң.

Тәрәзә төбендә тора,
Алмагачның чәчәге;
Алдан билгеле булса иде
Тормышның киләчәге.

Сандугачлар матур сайрый
Арча болыннарында;
Сине уйлаган яшь күңелем
Тормый урыннарында.

Ал тарелкаларга салам
Җыйган җир җиләгемне;
Син генә бит якын дустым,
Өзәсең үзәгемне.

Юк, дускаем, түзә алмыйм,
Син мәхәббәт бирмәсәң,
Мәңге сүнмәс эчтәге ут,
Син килеп сүндермәсәң.

Бөгелмә син, тал булсаң,
Сыгылма син, тал булсаң;
Ал чәчәктән гөл чәчәккә
Үрелмә син, яр булсаң.

Дустым сине төштә күрдем,
Ай-кояштан шат идең;
Мин карап туялмадым,
«Хуш!» – диден дә баш идең.

Агыйделкәй агасың,
Дулкыныңны кагасың;
Әй, мәгънәсез яшь йөрәгем,
Бер дә белми янасың.

Гөлдәй булсын гомер юлың,
Адашма да юлыңнан.
Бәхетле бул, дип кысамын,
Дустым, синең кулыңнан.

Матурлык ул гади нәрсә,
Матурлыкка кызыкма;
Матурлыкның соңгы чиге,
Алып бара хурлыкка.

Ул килмәде бик күптәннән,
Шуннан бирле күрмәдем.
Айлы кичләр килгән саен
Сагындырды күзләре.

*Иске Кәкерле авылында Шиһапова*
*Наилә Дәүләтша кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

Һаваларда ямьнәр биетә,
Матур кошлар очмаса;
Мин сагынып җырлар язам,
Укы, эчең пошмаса.

Сандугачлар куна алмый –
Тәрәзәбез өлгесез;
Хәзерге көннәр күңелсез,
Алдагысы билгесез.

Кулымдагы йөзегемнең,
Исемнәре Лотфулла;
Әй бер күреп сөйләшергә,
Дигән көннәр күп була.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Нәгыйм;
Бирмә ятка, сал суларга,
Син карап тор, мин агыйм.

Алтын йөзек кияр идем,
Кашы фирүзә түгел;
Сагынганда барыр идем,
Якын-тирәдә түгел.

Яңа чыккан паровозны,
Яшелгә буяталар;
Йоклап яткан сандугачны,
Син, диеп уяталар.

Кисәм дә тар, салсам да тар,
Каерыла кулбашкаем;
Янсын дошманнар йөрәге,
Сайра, сандугачкаем.

Кибетләрдән шешә алдым
Чәч мае тутырырга;
Яннарыңа барыр идем
Сөйләшеп утырырга.

Сандугачлар кунып сайрый
Идел камышларына;
Иртән торсам, бер моңаям
Былбыл тавышларына.

Пыяла шкаф эчләрендә
Сары күбәләк уйный;
Минем керсез күңелләрем
Гел сезне генә уйлый.

Ике метр ак бүз алдым,
Тәрәзә пәрдәсенә;
Караган саен, сокланып,
Карыймын гәүдәсенә.

Ак тапочка, күк тапочка,
Ник кигәнең булмасын;
Шушы матурлыгың белән
Ник сөйгәнең булмасын.

Агыйделнең аръягында
Җил казыган ком базын;
Аерылганны шуннан белдем –
Ялгыз күрдем кыр казын.

Ал да кушам, гөл дә кушам
Зәңгәрле күлмәгемә;
Мәңге сүнмәс утлар салдың
Кайгылы йөрәгемә.

Агыйделнең аръягында
Балта чапкан талым бар;
Бу дөньяда ни кайгым бар,
Сандугачтай ярым бар.

Аллы-гөлле чәчәк ата
Безнең бакчада гөлләр;
Әй, дускаем, онытылмый
Бергә утырган көннәр.

Ай югары, ай югары,
Айда кеше рәсеме;
Күңелемдә гел син генә,
Бәгырем, беләсеңме?

Машиналар бер туктаса,
Бензинсыз кузгалмыйлар.
Хәсрәт күлләрендә йөзәм,
Дусларым чыгармыйлар.

Кулымдагы йөзегемнең,
Исемнәре Фәездер.
Мәхәббәтең күлләрендә,
Бәгырем, мине дә йөздер.

Кулымдагы йөзегемнең,
Исемнәре Исле гөл.
Эчтәге сүзләр беткәнче
Сөйләшербез микән бер.

Өстәлләргә җыеп куйдым
Кофта, юбкаларымны.
Сине уйлап өчкә бүләм
Татлы йокыларымны.

Магниталы кайчы белән
Чәчемне кисәр идем.
Син торасы урыннарга,
Җил булып исәр идем.

Алсу алмалар төядем,
Тартыр микән атларым.
Үзем кебек ачык итеп,
Сөйләр микән хатларым.

Өстәлләрдә ике шешә,
Берсендә алма пешә.
Күңелем уйлый, кулым яза,
Күземнән яшьләр төшә.

Өстәлләрең уртасында,
Майлы гөлчәчәк түгел;
Дошман әллә ни сөйләсен,
Күңелем бизәчәк түгел.

Шәл бәйлимен, шәл бәйлимен,
Шәлем җебе нечкәдер;
Бу кадәр якын күрүем,
Бәгырем, үкенечкәдер.

Асыл карават өстенә
Йокым килеп ятмадым.
Бу дөньяда синең кебек
Чәчәкләр дә тапмадым.

Сары каеш, киң перәшкә,
Алар була билләрдә.
Үзегемне өзә торган
Ярларым чит илләрдә.

Шахталарның күмерләрен
Кемнәр алыр исәбен;
Җаннарымны алсалар да,
Ташламам җан кисәгем.

Уфа тараклары кебек
Минем үз тарагым да.
Мәңге сүнмәс гашыйк булдым,
Йөзеңә карадым да.

Әй дускаем, яратамын
Кара киемнәреңне.
Алдан язып белдерәмен
Янып сөюләремне.

Чәйләр салып, чәйләр эчтем,
Чынаяк эчләренә;
Былбыл булып, гөлгә кунып
Керәсең төшләремә.

Атларымны җибәрәмен
Камыш болыннарына.
Ышанып та бетерә алмыйм
Таныш булуларыңа.

Йөзегемнең кашы төште,
Малинадай каш кирәк;
Мин үзем дә яшь бит әле,
Яшькә каршы яшь кирәк.

Кулымдагы йөзегемнең,
Исемнәре Миңниса;
Берне түгел, сөй икене,
Күңелләреңә сыйса.

Алтын пәке ал кисәр,
Көмеш пәке гөл кисәр.
Син дускаем баскан җирдә
Ал чәчәкле гөл үсәр.

Хәзер инде язга чыктык,
Таллар яфрак яра.
Сагынганда күреп булмый,
Ерак бит безнең ара.

Патефонның табаклары
Әйләнә киңгә күрә;
Син дустымны мин сөямен,
Үземә тиңгә күрә.

Әй дускаем, тирләгәнсең,
Костюмыңны салгансың.
Табигатьнең матурлыгын
Гел үзеңә алгансың.

*Иске Кәкерле авылында Мәүләтшина*
*Фәрдәния Рәисә кызыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

И, матурым, яратамын,
Бирмәм кеше кулына;
Бәхет гөле чәчәк атсын
Йөри торган юлыңа.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле иллене;
Җырламас идек иллене,
Аерылышулар билгеле.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле кырыкны;
Җырламас идек кырыкны,
Әйләнәбез кругны.

Сандугачның балалары
Түтәлдә буламыни?
Кеше баласы кешегә
Кадерле буламыни?

Әнкәй, мине тапкансың,
Тапкансың да озаткансың.
Мине озатып, ниләр таптың?
Газиз баласыз калдың.

Гармуныңны уйнаганда
Сания көен уйнама;
Минем кебек саргаерсың,
Баскан саен уйлама.

Ник болай яратам икән
Гармун уйнаучыларны?
Үзем кебек тиң күрәмен
Бик күп уйлаучыларны.

Санасаң, санамасаң да,
Гармун теле унике;
Уйнасаң, уйнамасаң да,
Яшь гомер ике килми.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Вәлиәхмәт;
Гармунчыда артык була
Җиде өлеш мәхәббәт.

Уйнат әле гармуныңны
Мин җырлаган көйләргә;
Син уйнаган, мин җырлаган
Калсын сагынып сөйләргә.

Ворошилов портретын
Күргән саен карыймын;
Армиягә баруымны
Зур бәхеттән саныймын.

Китәм инде, китәм инде,
Китәм армияләргә;
Службам беткәч кайтырмын
Сине тәрбияләргә.

Кcallилә-килә килеп җиттек
Казанский портына;
Килеп җитәр һәм сизелмәс
Күрешү минуты да.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Фәсәхәт;
Сезне уйлап утырганда
Моңлы сугадыр сәгать.

Сәгатьләр келт-келт итәдер,
Төн уртасы җитәдер;
Ятсам, йокыларым килми,
Күңелем сине көтәдер.

Алларым, диям сине,
Гөлләрем, диям сине,
Ал-гөлләрдән, былбыллардан
Якын күрәм мин сине.

Сандугачлар су дип эчә
Үзәндәге чыкларны;
Гомерем буе оныталмамын
Бергә булган чакларны.

Күп эзләдем, табалмадым
Күлмәгемнең ишләрен;
Гомерем буйларына сине
Оныталмасам, нишләрмен?

Исле гөлләр арасыннан
Яратам мин кынаны;
Яратмас идем кынаны,
Сиңа охшатам мин аны.

Сандугачым, килгәнсең,
Җитәр көзләр, китәрсең;
Җаның теләмәгәннәргә
Әгәр булсаң, нишләрсең?

Ал итәләр каланы,
Гөл итәләр каланы;
Теләмәгәнеңә биреп,
Хур итәләр баланы.

Самоварны тиз кайната
Кызыл миләш күмере;
Очып киткән тузан кебек
Кыз баланың гомере.

Ир бала туса, шатлык туа
Ат башында уйнарга;
Кызлар туса, кайгы туа
Ят башында еларга.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Габдулла;
Һәркемнең үз сөйгәне
Үзенә якын була.

Исеңдәме, искән җилләр
Туздырды чәчләремне?
Исеңдәме, авыр чакта
Түктем күз яшьләремне?

Яшьлек бит ул, яшьлек бит ул,
Яшьлек бит ул сөйкемле;
Матур яшьлек беркемнән дә
Узып китмәс шикелле.

Машинасы, машинасы,
Машина шүресенә;
Дошман әллә ниләр сөйләр,
Ышанма күбесенә.

Дошманнар безне күрә алмый,
Юлга читән үрә алмый;
Үрә бара, сүтә бара,
Барыбер рәхәт күрә алмый.

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар тайгага;
Күптән түгел алмашынды
Кайгыларым шатлыкка.

Китә казлар, китә казлар,
Китүләредер инде;
Шулай итеп, яшь гомернең
Үтүләредер инде.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гамбәрем;
Син киттең дә, алып киттең
Бөтен дөнья ямьнәрен.

Кулымдагы яулыгымның
Тирәләре ал-зәңгәр;
Кулларымнан куймас идем,
Ал чәчәк булсаң әгәр.

Кулымдагы яулыгымның
Тирәләре ал гына;
Сагындым сине, сагындым,
Ярый килдең алдыма.

Исле гөлләр арасында
Роза чәчәге куе;
Озак аерым яшәсәк тә,
Онытмам гомерем буе.

Колак алкаларым сынды,
Алырсың микән алка,
Булырсың микән үземә,
Калырсың микән ятка?

Колак алкаларым сынды,
Вакларын ташламыймын;
Ташламыйм, дустым, ташламыйм,
Ташларга башламыймын.

Исле гөлләргә буялган
Исле гөл утыртучы;
Элек болай түгел идең,
Бар сине кайгыртучы.

Минем иркәм таңнан тора,
Таң йолдызы шикелле;
Үзе уңган, үзе булган,
Үзе шундый сөйкемле.

Минем иркәм ялкын кебек,
Яндырмый кемне генә;
Яндырса да кемне генә,
Ярата берне генә.

Минем иркәм эштә уңган,
Күкрәгендә медале;
Казанда да, Мәскәүдә дә
Белмәгәннәр юк аны.

Уфа, диләр, Уфа, диләр,
Уфа күренә мени?
Аерым торуларга карап,
Күңел сүрелә мени?

Безнең урам түбән таба,
Алма тәгәрәтергә;
Җанкаемның хәтере калган,
Ничек бәхилләтергә?

Безнең урам аркылы
Ага суның салкыны;
Су сипсәң дә басылмыйдыр
Янган йөрәк ялкыны.

Чәчләремне үрәм, дисең,
Шулмы чәчеңне үрүең;
Якын күрәм, дия идең,
Шулмы якын күрүең?

Бакчадагы алмагачлар,
Бер санадым – туксан өч;
Үзебез аерылганнар,
Аерылганнар кызганыч.

Безнең бакча уртасында
Каен үсә каерылып;
Канатсыз күгәрченнәр күк
Без яшибез аерылып.

Аклы каеш дилбегәләр
Безнең атларда гына;
Иртә торсам, ике күзем
Безнең якларда гына.

Зәңгәр күлмәк, кызыл яулык
Мин киямен яз булгач;
Карамыйм дошман сүзенә,
Үземнең күңелем булгач.

Агыйделдә йөрсәң иде,
Камыштан көймә үреп;
Былбыл булып, гөлгә кунып
Сөйләшсәң иде күреп.

Сайрый былбыл, сайрый былбыл,
Сайрый былбыл гөлләрдә;
Дустым, бергә булсак иде
Без киләчәк көннәрдә.

Сахраларга чыктым исә,
Ал чәчәкләргә карыйм.
Ул чәчәкләр синең төсле,
Алып, түшемә кадыйм.

Былбыл булсам, бакчаларда
Бер агач сайлар идем;
Шул егеткә, сине мактап,
Иртә-кич сайрар идем.

Кулларыма чәчәк җыйдым
Аллы-гөллесен генә;
Исләремдә гел син генә,
Дустым, белмисең генә.

Түгәрәк чишмә, суы салкын,
Куйдым гөлләр үрергә;
Ике кулым канат булса,
Барыр идем күрергә.

Кызарып кояш чыкканда
Алсулана пәрдәләр;
Уф, дигәннең мәгънәсен
Белми кайсы бәндәләр.

Агыйделгә төшкәнем юк,
Суын да эчкәнем юк;
Синнән башка кешеләргә
Серемне чишкәнем юк.

И, дускаем, хат язгансың,
Энҗе кебек тезгәнсең,
Энҗеләр кебек тезгәнсең,
Үзәгемне өзгәнсең.

Ак бизәкле ситсаларны
Кисә белми кисәләр;
Кара урман кичәр идем,
Сине шунда дисәләр.

Тальян гармун уйныйлар
Безнең урам буенда;
Ятсам, торсам, чыксам, керсәм,
Тик син генә уемда.

Җирән кашка күк атларның
Тарап куйдым ялларын;
Синнән башка ярлар сөймим,
Борчылмасын җаннарың.

Һавадагы йолдызларның
Санамадым исәбен;
Актык күрүләрем ахры,
Сау бул, бәгърем, кисәгем.

Аклы ситса күлмәгемнең
Җеп очлары кушулы;
Аерылырга булган икән
Эчләремнең пошуы.

Ак өемә элеп куйдым
Алмалы паласымны;
Өзелеп сөйдем, белеп сөйдем
Аерылып каласымны.

Усак яна, усак яна,
Яна да күмерләнә;
Онытырлык яр түгелсең,
Онытмам гомергә дә.

Түгәрәк күл эчләрендә
Эчерәм атларымны;
Барыннан да артык күрәм
Җибәргән хатларыңны.

Һавалардан мамык ява
Агыйдел күбегенә;
Башкаларны сөяр, диеп
Китермә күңелеңә.

Һаваларда мамык оча
Күгәрчен кагынганда;
Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда.

Аллы-гөлле чиләгеңнең
Сулары түгелмәсен;
Дошман сүзләренә карап,
Күңелең сүрелмәсен.

Чыгыйм тышларга микән?
Басыйм ташларга микән?
Эч серемне кемгә сөйлим,
Очкан кошларга микән?

Минем чәчем үзе озын,
Ленталап үрмәсәм дә.
Син иркәмне оныта алмыйм,
Җиде ел күрмәсәм дә.

Маңгай чәчем бигрәк калын,
Икегә үрәм инде;
Син иркәмне күрә алмыйча
Саргаеп үләм инде.

Апрель җитсә, яз җитәр,
Яз җиткәчтен кар китәр;
Бу дөнья барыбер үтәр,
Дус яшәүгә ни җитәр.

Суга барам, су алам,
Су алам да кузгалам;
Әллә үзем аерылганга,
Аерылганны кызганам.

Ак укага энҗе тездем,
Бер бөртеккә калганчы;
Озатканда карап калдым,
Күз керфегем талганчы.

Исле гөлем булмаса да,
Бар бит башка гөлләрем;
Үзем синнән аерылсам да,
Аерылмый күңелләрем.

Су буенда казлар уйный
Канатларын кагынып;
Ярты төннәрдә уянам,
Син дустымны сагынып.

Димдә тудым, Димдә үстем,
Җиләк җыйдым тугайда;
Бик күп хәсрәтләр күрдем,
Сер бирмәдем шулай да.

Ике былбыл җиргә төшә,
Әйләнеп очкан чакта;
Хатларыңны алып укыйм,
Эчләрем пошкан чакта.

Ефәк яулыклар бөркәнмим,
Базарлардан алсам да;
Ташладың, дип, суга төшмим,
Ялкынында янсам да.

Сандугачның балалары
Күп түгел, өчләп кенә;
«Чын күңелдән сөям», – дигән
Сүзләрең пустяк кына.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әҗәт түгел;
Сөйсәң, бәгърем, гаҗәп түгел,
Сөймәсәң, хаҗәт түгел.

Җыйдым чәчәк, җыйдым чәчәк,
Җыйдым да кайталмадым;
Сиңа охшаулы алсу чәчәк
Эзләдем, табалмадым.

Уфаларда бер генә бит
Ак энҗеләр тезүче;
Син генә бит, бер генә бит
Үзәгемне өзүче.

*Иске Чокалы авылында Низамова*
*Фәсәхәт Сәлах кызыннан (1929 елгы)*
*язып алынды*

Байның улы нинди була?
Өйрәнмәгән тай кебек.
Ярлы кызы – җан кисәгем,
Йомарлаган май кебек.

Суда йөзгән пароходның
Трубасыннан пар чыга;
Бай кызлары – чирле чебеш,
Ярлы кызы – карчыга.

Теләмә син һичбер байлык,
Теләмә син таҗ-тәхет;
Һәм дә телә рәхәт тормыш,
Һәм дә телә ак бәхет.

Сандугачлар басып сайрый
Җәй көннәре җылы, ямьлегә;
Җәйләр килер, тагын китәр,
Безнең дуслык калыр мәңгегә.

Буй-сыннарың бигрәк матур,
Исемнәрең Габделхай;
Телең – энҗе, йөзең – көзге,
Күзең – йолдыз, кашың – ай.

Аклыситса күлмәгемнең
Кайсы буйлары кыйгач;
Былбыл булып кил каршыма,
Китәрсең – күреп туйгач.

Ай катында Зөһрә йолдыз,
Ай калыкты, бат инде;
Чит илләрдә күп йөредең,
Сагындырдың, кайт инде.

Исемем минем Галия,
Нигә булмаган Ракыя;
Аерылганга һич үкенмим,
Гөл дә чәчәген коя.

Исемем минем Галия,
Нигә булмаган Сабира;
Сабыр итми ни хәл итим,
Сабыр итә сабый да.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәрен кырганнар;
Йөзгә, меңгә бер генә ул –
Илләрендә торганнар.

Мин урамда ялгыз йөрдем,
Җанга тынлык эзләдем;
Ал чәчәкләр алда күрдем,
Нигә микән өзмәдем?

Яшь йөрәгем, ник тибәсең,
Нинди хәсрәт сизәсең?
Күргән хәсрәтең очсын инде,
Тагын бармы күрәсең?

Мин үзем дә боек түгел,
Шаяра, көлә идем,
Киләчәктә бәхетемнең
Булуын көтә идем.

Алмагачның алына
Былбыл кунган талына;
Егет алсын, кызы барсын
Үзе сөйгән ярына.

Агыйделгә сал килгән,
Чыгар җире тар микән?
Эзләмә дә, сайлама да,
Бу кыз сиңа пар килгән.

Аклы ситса күлмәгемнең
Җиң очларында кара;
Аерылышу безнең шушы,
Үзең кебекне кара.

Хәзер инде кадерен белеп
Сөючеләр бик сирәк,
Шуңа күрә үз-үзеңне
Тота белергә кирәк.

Су буена төшәр идем,
Су юллары гөл булса;
Һич дигәнем калмас иде,
Үз дигәнем яр булса.

Суга барам, су алам,
Су алам да кузгалам;
Әллә үзем аерылганга,
Аерылганны кызганам.

Ай да ялгыз, мин дә ялгыз,
Син дә ялгыз – өчебез;
Әй, дускаем, кайда икән
Ул кадерле кичебез?

Тәрәзә төпләребез,
Үрмәле гөлләребез;
Күп дошманнар йөрәгенә
Ут сала көннәребез.

Зәңгәр күлмәк, биш бала,
Зәңгәрен кояш ала;
Безне дошман нишли ала?
Сөйләсә, сөйләп кала.

Зәңгәр кара матур яза,
Зәңгәр матур, сайласаң;
Тавышыңнан таныр идем,
Былбыл булып сайрасаң.

Сад-бакчада гөлләрдә
Тургай канат кагына;
Тургай сайрый, былбыл уйный,
Күңелем сине сагына.

*Татар Бизнәсе авылында Бакиева*
*Галия Шәрәф кызыннан (1931 елгы)*
*язып алынды*

Агасың, су, агасың, су,
Көтәмен тынганыңны;
Алга килми белеп булмый
Бәхетсез булганыңны.

Эзләдем, кичтем җиһанны,
Бәхет, рәхәт тапмадым;
Мәгънәсез тормышка корбан
Булды ла яшь чакларым.

Ялгыз яшим, ялгыз уйлыйм,
Ялгыз тормыш караңгы;
Караңгылык дөньясында
Әллә мәңге каламмы?

Кызлар нигә моңаймасын,
Сөйгән егетен сагынгач;
Йөрәктәге саф мәхәббәт
Сүнми ул, бер кабынгач.

Чын дуслыкны булмый, диләр,
Булса да, сирәк кенә;
Чын дуслыкны саклый ала
Ялкынлы йөрәк кенә.

Кичләрендә матур була
Пароход барулары;
Айны болыт каплаган күк
Аерылып калулары.

Сине төшләремдә күрдем:
Сәхрәдә кош атасың;
Эчеңдәге серләреңне
Кемнәргә таратасың?

Сәхрәләрдә синең белән
Мин дә кош аткан идем;
Эчемдәге серләремне
Сиңа бушаткан идем.

Тәрәзәмнең төпләрендә
Кошлар чукый гөлемне;
Сөйлим серемне кошларга,
Ул да белми серемне.

Автомобиль кызу килә
Трамвайны узарга;
Нигә юкка танышырга,
Яшь йөрәкне бозарга?

Агыйделнең ярында
Былбыл уйный якында.
Кулдан кулга күчкән хатка
Язып булмый барын да.

Сикертмә каш, серле күз,
Үпкәләмә, үпмәгәч.
Үпкәләсәң, ни хәл итим
Ходай насыйп итмәгәч.

Агыйделләр киң булганга
Аркылыга чыга алмыйм.
Яшь күңелем сине уйлый,
Ләкин эзләп таба алмыйм.

Тәрәзәмнең рамкасы
Чыршы булмасын икән;
Иң яратып сөйгән ярың
Читтә булмасын икән.

Камчыдай кара чәчләрең,
Карлыгандай күзләрең.
Йөрәгемне яндырадыр
Өзелеп әйткән сүзләрең.

Ак каенның яфраклары
Өзелеп төшә гөлләргә;
Өзелеп төшкән гөлләр кебек
Син минем күңелләрдә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәдинә;
Чәнечкеле сүзләр белән
Кадама йөрәгемә.

Биек тауның башында
Төлке ята чирәмдә;
Акылын, фигылен сынамыйча
Кызыкмагыз чибәргә.

Агыйделнең буеннан
Казлар килә суыннан;
Яр өстенә яр сөймә икән,
Үкендерә соңыннан.

Елтыр-елтыр ут күренә,
Бездә түгел, конторда.
Минем күңелем зурда түгел,
Кечкенә генә матурда.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр гел чылбыр;
Булмаганны сөйләмиләр,
Ятны сөюең чындыр.

Бу, бәгърем, билләреңне
Яшел тасмалар белән.
Мин танышырга теләмим
Синнән башкалар белән.

Сандугачлар су ташый,
Кайда икән су башы?
Минем иркәм ялгыз башы,
Кояш булсын юлдашы.

Әйдә, дустым, буяучыга,
Көянтә буятырга.
Сандугач күк йоклап ята,
Кызганыч уятырга.

Синең истәлегең итеп,
Кулъяулыгыңны үбәм,
Киткән юлларыңа карап,
Сине көтәм, гөлгенәм.

Пароходны дулкын какмый,
Идел суы какмаса.
Алдап йөрмә, бәгырькәем,
Гомерлеккә булмаса.

Әйдә, бәгърем, алып барыйм
Уфага, киендереп.
Бер башлагач, нигә ташлыйм,
Дошманнар сөендереп.

Мин ташладым ал чәчәкне,
Әйдә, дошманнар алсын.
Яшь йөрәгем чыдар әле,
Яшь чакта янып калсын.

Безнең клуб шуңа матур,
Тәрәзәләре биек.
Яшь йөрәгем сине уйлый,
Кайчан күрермен, диеп.

*Татар Саплыгы авылында Хәйруллина*
*Нәкыя Сәмигулла кызыннан (1932 елгы)*
*язып алынды*

Өстәл өстендә машина
Төрле җөйләр җөйләми.
Карточкаңа карыймын да,
Теле юк шул, сөйләми.

Тимгел-тимгел кара төшкән
Күгәрчен түшләренә.
Ятып күземне дә йоммыйм,
Керәсең төшләремә.

Карлыганнар ашар идем,
Тия шул тешләремә;
Сары сандугачлар булып
Керәсең төшләремә.

Бөгелеп калды, сыгылып калды
Пароход идәннәре;
Сандугачтан һич ким түгел
Аның үз дигәннәре.

Агыйделгә туры бар,
Ике ягы кызыл яр.
Онытма, дип әйтмә, дустым,
Онытылмый сөйгән яр.

Электр яктыларында
Утюклыйм кергләремне;
Йөрәгемнең саф җирендә
Саклыйм исемнәреңне.

Кара сатин була диеп,
Казаннан алдырамын.
Чынлап әйтәм, син бәгыремне
Ятларга калдырмамын!

Эссе җирдә эри микән
Минем гәрәбәләрем?
Синнән башка яр сөймим, дип
Бирде вәгъдәләрен.

Казанканың суы бетми,
Айлар, еллар акса да;
Синең кебек булмас инде,
Гөлләр чәчәк атса да.

Өстәлләрдә кара торсын,
Кулларым яза торсын.
Үзен күреп сөйләшкәнче,
Хатларым бара торсын.

Бал каптырыйм үзеңә,
Балкып чыксын йөзеңә;
Балкып чыккан кояш кебек
Күренәсең күземә.

Безнең урам телеграмм
Баганасын кем куйган?
Китәсем килеп китмәдем,
Туган илдән кем туйган?

*Татар Саплыгы авылында Зарипов*
*Сабирулла Садыйк улыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

Алтын-көмеш уймагым
Өстәлләргә куймадым.
Хат эчендә барыр идем,
Хат эченә сыймадым.

Ал мәрҗәнең алты кат,
Чын мәрҗәнең җиде кат;
Алмам каләм, җибәрмәм хат,
Бик сагынсаң, үзең кайт.

Алмачуар ак үрдәк
Килә йөзеп су буйлап;
Авырып ятып саргаймадым,
Мин саргайдым күп уйлап.

Зәңгәр чәчәкләр үсәләр
Сәхрә өсләрендә.
Авыр сулаулар суладым
Аерылган кичләремдә.

Биек тауга менгән чакта
Таянам тезләремә.
Суга тилмергән кош кебек
Тилмерәм сүзләреңә.

Бакчаларда йоклаганда
Җил алды юрганымны;
Коштан сорыйм, кош та белми
Ни хәлдә торганыңны.

Минем чәчем җиде толым,
Җидедән үрмәсәм дә;
Дусларымны оныта алмыйм,
Җиде ел күрмәсәм дә.

Әнә, дустым, төш тә җитә,
Кайталар утаучылар;
Кемнәр икән, белергә иде,
Араны бутаучылар.

Талдан тартма ясар идем,
Тал чыбыгы сузылмый;
Синең күңелең, белмим, ничек,
Минем күңелем суынмый.

Фикус гөлем чәчәк атмый,
Яфрагы киң булганга;
Син дустымны гөлгә охшатам,
Шул гөлгә тиң булганга.

*Татар Саплыгы авылында Хәйруллин*
*Рәхимҗан Хәернас улыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

Өстемдәге күлмәгемнең
Җиң очы кара челтәр;
Хатка каршы хат язарга
Бер тамчы кара җитәр.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Илгизәр;
Үзе чибәр, үзе усал,
Күрсәң, җаннарың бизәр.

Йөгерә-йөгерә җиләк җыям
Яшел тарелкаларга;
Ышанып тор, кавышырбыз
Җәйге ярминкәләрдә.

Өй түрендә салкын чишмә
Чылтырап ага кичләрдә;
Көндез уйлап йөримен дә,
Төнлә күрәм төшләрдә.

Базарлардан алып кайттым
Сандугачлар читлеген;
Хатым баргач, сөйләп бирер
Хәлемнең ничеклеген.

Казан урамы – таш урам,
Күренә вагон утлары.
Аерылган көннән авыр
Сагыну минутлары.

Ике каен бер төптә,
Ике энә бер ептә;
Ачуланма бер дә юкка,
Постой, погоди, тукта!

Ямьле иде, матур иде
Безнең йөргән юлыбыз.
Шуның белән тәмам итәм,
Хуш, исән-сау булыгыз.

*Татар Саплыгы авылында Вафина*
*Зәйтүнә Гафият кызыннан (1933 елгы)*
*язып алынды*

Зәңгәр күлмәк тар әле,
Мәскәүдә ише бар әле.
Син дә өйләнмә, мин дә китмим,
Безгә вакыт бар әле.

Уникегә берне суга
Кремль сәгатьләре;
Сөеп кара әле ятларны,
Ничектер гадәтләре.

Минем кашым җем-җем кара,
Синеке дә карамы?
Агымсу дулкыны кебек
Бутыйлар бит араны.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Җырлап утырыйм әле;
Туксан тугыз сөйгәнем бар,
Йөзгә тутырыйм әле.

Шәлем аклы, шәлем аклы,
Шәлем аклы, шакмаклы.
Кеше сүзләренә карап,
Мин сине ташлаячакмы?

Йөгереп кердем магазинга,
Аннан алдым зәңгәр шәл;
Яр сөйсәгез, җәлләмәгез,
Ташлаганда булыр җәл.

Минем шәлем башта тормый,
Булавка кадамасаң;
Син – минеке, мин – синеке
Ятларга карамасаң.

Кама, диләр, Кама, диләр,
Кама чайкала, диләр;
Мәхәббәт картаю белми,
Яшь килеш кала, диләр.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме унике түгел.
Яшь вакытында мин сөйдем,
Хәзер минеке түгел.

Биек тауның башында
Сикереп бии бер аю;
Кешедән калган ярларны
Пока не принимаю.

Биек тауның башларында
Кәбестә түтәлләре;
Люблю тебя, не забуду,
Кирәкми бүтәннәре.

Быел җәйне урак урдым
Чыршы күләгәсендә.
Безне дошман аера алмый,
Лучше сөйләмәсен дә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нәсимә;
Бер ташлагач, сөйгән ярны
Кире кайтарып сөймә.

Кыш көне булса да, үсә
Минем үрмәле гөлем;
Бер аерылгач, күрә алмам, дип
Уйлыйдыр яшь күңелем.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Харисым;
Без бит әле аерылмаган,
Нигә салкын карыйсың?

*Иске Чокалы авылында Йосыпова*
*Мөнирә Аниятулла кызыннан (1934 елгы)*
*язып алынды*

Агыйделләргә катнашкан
Безнең дә күлләребез;
Хатлар белән сөйләшергә
Калды бит көннәребез.

Искән җилләр дә алалмый
Кара урман томанын;
Кемнәр уйлап чыгарды икән
Аерылу планын.

Ачы була, ачы була,
Ачы була борычлар;
Миннән китте, сиңа калды
Хат язарга бурычлар.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Бәрия;
Яшьтән сөеп куймасам да,
Чыгар әле бер ия.

Кулларыма кияр идем
Мәрьям исемле йөзек;
Суга төшсәң, була йөзеп,
Аерылсам, булмый түзеп.

И, дускаем, өсләреңә
Бик килешә сарафан;
Кай җиреңдә мәхәббәт бар,
Ник бу кадәр яратам?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әминә;
Син дустымны охшатамын
Ал чәчәк бәйләменә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Луиза;
Сине сагынып, сине уйлап,
Минем көннәрем уза.

Зөлхәбирә көлтә бирә
Арбадан кибәннәргә.
Тормыш үзе баш идерә
Үзеңнән түбәннәргә.

Өстемдәге күлмәгемнең
Бизәкләре чуп-чуар;
Янсын дошманның йөрәге,
Баскан саен ут чыгар!

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Люция;
Җаным, тәнем, табигатем
Сине яратып сөя.

Бакчалардан табып алдым
Күкерәк сәгатемне;
Синең кебекне табармын,
Табалмам гадәтеңне.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Ислам булсын;
Йөреп-йөреп кавышмасак,
Теләкләр бергә булсын.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әнисә;
Исәнмесез, дигән кебек,
Сезнең яктан җил исә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мингосман;
Кеше ярын тартып алмыйм,
Сөймим дә мин, курыксам.

*Иске Чокалы авылында Низамова*
*Фәсәхәт Сәлах кызыннан (1929 елгы)*
*язып алынды*

Бишмәтеңдә биш төймә,
Алтынчысын каптырма;
Сыйлаганны күтәреп бир,
Инде югын таптырма.

Әйдә, дуслар, сыйланаек,
Гаепләштән булмасын.
Җырга каршы җырламаган
Күз алдында тормасын.

Кашың белән күзеңә,
Гөл сибәем йөзеңә.
Йөз сум акча, бер матур кыз
Синең әйткән сүзеңә.

Талдан тартма ясап бирим,
Сырын үзең сырларсың.
Сыйлаганда сыйланып кал,
Җырын үзең җырларсың.

*Каракитә авылында Азизов*
*Зәки Юныс улыннан (1932 елгы)*
*язып алынды*

## Туй җыры

Талдан тартма мин ясадым,
Тар буласын белмәдем.
Каршы утырып чәй ясадым,
Кода буласын белмәдем.

Бөтен колба – бар да бар,
Алтын төсле берсе юк.
Бар кодалар – бар да бар,
Сөйгән кода берсе юк.

Аклы ситса күлмәк киеп,
Чәй салам, җиң сызганып.
Җырлыймын да, җылыймын да,
Кодалар, сезне кызганып.

Стаканның төбе алтын,
Аның сабы җиз алтын.
Шул кодалар җыелсалар,
Бер-бер җыры – мең алтын.

Уйнагыз да, җырлагыз да
Аккордеон бар чакта.
Ашыйбыз да, эчәбез дә,
Пока байлык бер чакта.

Атым арык, юлым ерак,
Җитә алмам, дип куркамын.
Кодалар баерак, үзем ярлы,
Ярамам, дип куркамын.

Чит бөртеге сары икән,
Аракысы бар икән,
Аракысы да бар икән,
Исертә торган икән.

Җиккән атым озак торса,
Камытыма көч килә.
Килгән кунак озак торса,
Кодаларга көч килә.

Абау, дисең, авырыйм, дисең,
Башың авыртмаса да.
Кода, дисең, кодагый, дисең,
Җаның яратмаса да.

Стаканның төпләре
Ак күгәрчен сөтләре.
Безнең ашаган-эчкәннәр
Бары да кодагый көчләре.

Стаканымны сырларга
Ике төрле сыр кирәк;
Кодалар алдында җырларга
Сандугачтай тел кирәк.

Ник утырыйм көймәгә,
Идел тулы булмагач?
Нигә килим шул йортка,
Кодалар күңеле булмагач?

Каралы күлмәк каралы,
Кара киеп кара әле.
Кода булу бигрәк кыен,
Кода булып кара әле.

Көмеш йөзек язуына
Нәрсә дип язган икән?
Без сездән чыгып киткәчтен
Ниләр әйтеп калырлар икән.

Ал минем күбәләгем,
Гөл минем күбәләгем.
Яшәгез, кодалар, рәхәт кенә,
Шул сезгә теләгәнем.

Алма бакчасына кереп,
Алма өзеп ашама;
Дошман сүзенә ышанып,
Кодалар, безне ташлама.

Җырла, җырла, дип әйтәсез,
Җырларга авыр ялгызым.
Давай, кодалар, бергә булыйк,
Бик күңелсез ялгызым.

Күгәрченнәр гөрләсеннәр,
Гөрләми тормасыннар.
Кешенең кодасы кирәкми,
Көнләшеп тормасыннар.

Чабып чыктым урамга,
Баш күтәрми буранга.
Йөгереп килдем, кода, сиңа,
Әйтер сүзем булганга.

Өстәл өстендә җәймәләр,
Клеёнка түгелме?
Әйдә биик, әйдә җырлыйк,
Күтәрик без күңелне.

Әй, куаклар, куаклар,
Куактан чыга күп атлар,
Сыраларга салган колмаклар,
Ник җырламый эчәсез, кунаклар?

Ак ызбаның эчләрен
Бакыр белән батырган.
Ай-һай, шушы безнең кодалар
Бал эчәргә генә чакырган.

Алмагачы барында
Таянмабыз талларга.
Үз кодаларым барында
Ялынмабыз башкага.

Агыйделнең буйлрын
Буйлаганым юк иде.
Без кодалы булабыз, дип,
Уйлаганым юк иде.

Уйлый кода, уйлый кода,
Уйлый кода барысын да.
Уйлама, кода, барысын да,
Кайсы-берсе калсын да.

Кара пальто киям, дисең,
Кигәннәрең бармы соң?
Кода, мине «сөям» дисең,
Сөйгәннәрең бармы соң?

Ботинкасы, ботинкасы,
Ботинкасы уела.
Сез, кодалар, искә төшсә,
Күз яшьләрем коела.

Ак өемнең матчасын
Бу ягыннан сырлыйбыз.
Кодабызның ничеклеген
Бер карауда сыныйбыз.

Өстәл өстендә йомырка,
Агарттык та ыргыттык.
Шушы авылның кызына
Яратканга иш булдык.

Ап-ак, ап-ак йомырканы
Ашамыйча кем калмас?
Шушы авылның матурын
Теләп биргәч, кем алмас?

Алмагачны утырталар,
Алмасы булмаса да.
Кодалар белән йөреп кал,
Үзеңә булмаса да.

Ак яулыкны бөркәнәләр,
Чәчәге булмаса да.
Әйдә, дуслар, ашыйк, эчик,
Кодалар булмаса да.

Сары ат җиктем яратып,
Маңгай чәчен таратып.
Ашадык та, эчтек тә без,
Кода, сезне яратып.

Сары ат җиктем кайтуга,
Сары май эчтем катуга.
Уйлыймын да куанамын
Коданың җырлавына.

Эскәтерләр җәйдем мин өстәлгә
Мәкәрҗәдән килгән кешеләргә.
Уйлыймын да исем китә
Уйламаганда булган эшләргә.

## Кыз сату җыры

Стенадагы көзге
Алсу күрсәтә йөзне.
Күз керфегем каккан саен
Искә төшерәм сезне.

Стенада сәгать суга
Телефон белән бергә.
Әйдә, дуслар, теләк телик
Гомер итәргә бергә.

*Татар Бизнәсе авылында Миначева*
*Шәмсеҗиһан Кәлимулла кызыннан (1910 елгы)*
*язып алынды*

## Җырлар

Киң яфраклы зәңгәр чәчәк үсә икән кырларда,
Сагынганда укыр өчен языйм әле җырлар да.

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Гөлсинә,
Бу дөньядан сайлап алган якын дустым син генә.

Зәңгәр чәчәк ата торган гөлләр дә була икән,
Дөнья булгач, аерым торган көннәр дә була икән.

Китәм, дисең, китәм, дисең, калдырма мине генә,
Уң беләгемә таянып уйлыймын сине генә.

Китәм инде, китәм инде, калдырып кырларымны,
Аерылу моңлары белән ерлыйм бу ерларымны.

Ак тапычкаларың бармы, бакчада кия торган?
Син бит минем роза гөлем, гомергә сөя торган.

Зур көймәләргә утырып, Агыйделне буйладым,
Гомеремнең буйларына син дустымны уйладым.

Син бит минем якын дустым, бар серем сиңа сөйлим,
Миннән аерылып киткәч, шат яшәвеңне телим.

Кулымдагы йөзегемнең исеме – матур Касыйм,
Син гөлләр бул, мин шул гөлгә сандугач булып басыйм.

Шарыфымны элеп куйдым бүлмә такталарына,
Исемеңне чәчәр идем алма бакчаларына.

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Корбандыр,
Яшьли сөйгән яр якындыр, онытылмый торгандыр.

Аерылабыз, аерылабыз, аерылмас кебек идек,
Ай тирәсенә тезелгән йолдызлар кебек идек.

Биек тауның башында күренәдер Истамбул,
Гомер булса, күрешербез, күрешә алмасак, исән бул.

Ай да карый моңсу гына, белгән кебек уемны,
Мин телимен алгы көндә синең белән булуны.

Агыйделнең зәңгәр бозын бәкегә җимерәбез,
Дөнья йөзләрендә яшәп, күрешергә тилмерәбез.

Бирми бәхет, бирми бәхет, бәхеткә туялмадым,
Алда да бәхетем булмаса, таралмам, туганнарым.

Һәр кеше дә яшь чагында рәхәт гомер кичерә,
Ләкин алар күпкә бармый, тормыш агу эчерә.

Тормыш бит ул, тормыш бит ул, тормыш бит ул аера,
Безне түгел, кошларның да канатларын каера.

Зур суларның буйларында йөрмә бер үзең генә,
Яшь йөрәгем уртасында  калды бер сүзең генә.

Аклы ситсы күлмәк киеп сепарат әйләндерәм,
Бер «сөям» дип, бер «сөймим» дип, башларын әйләндерәм.

Аклы яулыгымны юдым Мәйсәрә елгасында,
Актык йолдызым да сүнсә, яшәмим дөньясында.

Уйлый күңелем, уйлый күңелем, уйлый да, тарсына да,
Тормышым авыр булганга, баш иям барысына да.

Зөлхәбирә көлтә бирә арбадан кибәннәргә,
Тормыш баш ияргә куша үзеңнән түбәннәргә.

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Кадерлем,
Югары алма тиз өзелә, шулай булма, бәгырем.

Кулымдагы йөзегемнең исемен Һаҗәр кушканнар,
Түбән имә башларыңны, сынамасын дошманнар.

Дошман дошманлыгын итә – арада сүз йөретә,
Арада сүз йөреткәчтен, мәхәббәтне киметә.

Исле май, дип алган идем, скипидар кушканнар,
Хәлләреннән килгән кадәр сөйләсеннәр дошманнар.

Сөйләсеннәр, сөйләсеннәр, сөйләсеннәр, түзәрмен,
Ике араны су алса да, балык булып йөзәрмен.

Дошман сөйли, дошман сөйли, сөйләп бетерә алмаслар,
Безне сөйләп, жалование алып, пальто тектерә алмаслар.

Нигә мин яратам икән гармонь уйнаучыларны,
Үзем белән бер тиң күрәм тирән уйлаучыларны.

Уйна, дустым, гармонеңны үрләргә менгәндә дә,
Уф, йөрәгем, сөйгән ярым, диярмен үлгәндә дә.

Гармонь бәләкәй булса да, авыр тирбәтүләре,
Читендер ул кеше ярын «иркәм» дип әйтүләре.

Кара урманда төлке йөри, төлке эзендә кар эри.
Китмә, дустым, гармоньчега, гармоньче төннә йөри.

Кулымдагы йөрәгемнең исеме Әхәт аның,
Гармоньченың бармак баскан саен мәхәббәт аның.

Мәхәббәт ул шундый нәрсә, бәйләнмәсен кешегә,
Ихтыярсыз баш иярсең ян сөймәгән кешеңә.

Ерлыйм әле, ерлыйм әле, ерлыйм әле бишләрне,
Ерламас идем бишләрне, сагынам дус-ишләрне.

Әй, дусларым, сезгә әйтәм, яр сөймәгез яшь чакта,
Матур булып гөрләп үсә ялгыз үскән чәчәк тә.

Әй, дусларым, сезгә әйтәм, яшь гомердән туймагыз,
Вакыт җитми яшь гомернең чәчәкләрен коймагыз.

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Рәшидә,
Дошман дошманлыгын итә, очраганда, яшми дә.

Агыйделдә алма юдым, суы калды ал булып,
Кайчанга бергә булырбыз гомерлеккә яр булып.

Икебезнең арабызга тимерчыбык сузармын,
Көлмәгәнемне белгертмәм, көлемсерәп узармын.

Кошлар кая оча икән, канат очын талдырып?
Иркәм бик еракка китте, мине ялгыз калдырып.

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Гөлкәем,
Карап күренмәслек җиргә китте бит бәгырькәем.

Өй түрендәге гөлләрем алсу чәчәген атты,
Минем иркәм армиядән дошманны җиңеп кайтты.

Виноград, виноград, виноград үзәкле,
Бер танышып аерылгач, өзә икән үзәкне.

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Ибрай,
Яшьли сөйгән ярың белән торсаң торырсың бер ай.

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Бари ла,
Гыйшык тортып, утын йотып кавыша алсаң ярый ла.

Батинкасы, батинкасы, батинкасының бавы,
Дошман белән уртак ярның соңыннан була давы.

Ике метр бүз алдырдым сөлгегә, эскәтергә,
Сөйгән ярым матур минем кешегә күрсәтергә.

Батинкасы, батинкасы шыгырдап бирә тавыш,
Сознательный ярлар булсаң, бер белән генә таныш.

Ачык итеп ялтырыйдыр гармоньның бакалары,
Урам аша күренә ак күлмәк якалары.

Тал бөдрәсе, тал бөдрәсе, тал бөдрәсе имәндә,
Кадерләремне белмәдең башларымны игәндә.

Кулымдагы йөзегемнең исеме Габделбарый,
Чәүкә кебек бер ярым бар, ул да ятларга карый.

Безгә каршы сугыш ачты Германия каласы,
Дусларыма ярдәм итеп, әллә үземә барасы.

Әнә килә автомобиль төпчекләргә абынып,
Күрәсем дә килми иде, үлә яздым сагынып.

Аклы яулык кара тирә костюмым кесәсендә,
Суган тураганда елыйм, исемә төшәсең дә.

Кулымдагы йөзегемнең исеме матур – Зями,
Яшьли сөйгән ярларыңнан аерам безовсяки.

*Кече Чынлы авылында*
*Алимов Зөфәрдән*
*язып алынды*

## Сагыну бүләге, күрешү теләге

Безнең урам якты була, унлы фонарь яндырсаң,
Үзеңә дә оят булыр, сөеп ятка калдырсаң.

Кашларың кара булса да, карадым кашларыңа,
Сине сөеп, зур кимчелек китердем башларыма.

Алтын йөзегем сындырдым рояльләр уйнаганда,
Быел миңа еллар моңлы, күп уйлар уйлаганга.

Аклы ситсы күлмәгемә ал буена ал тамган,
Аерылганда эч өзәрлек әйтәсе сүзем калган.

Тәрәзәмнең эленгесе, анық ефәк элгече,
Күрешүен күрешербез, авыр ла бүгенгесе.

Сандугачның балалары берсе тирән елгада,
Бер аерылгач, күрешеп булмый айда түгел, елда да.

Агыйделнең аръягында йөрмә берүзең генә,
Яшь йөрәгем уртасында калды бер сүзең генә.

Кульяулыгым төшеп калды бакчалар әйләнгәндә,
Син дустымны сагынамын кичен күз бәйләнгәндә.

Чишмәләрдә сулар бетми, айлар, еллар акса да,
Сезнең кебек гөлләр дә үсми рәшәткәле бакчада.

Әй, бәгырем, аерылабыз, ничек итеп чыдармын,
Чарланып үскән гөлләргә карармын да елармын.

Алмагачка элеп куйдым алмалы паласымны,
Мин алдан ук сизгән идем аерылып каласымны.

Ай югары, ай югары, айлар да батар инде,
Чит илләрдә ялгыз башым шулай моңланыр инде.

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Рауза,
Сагыну хәле авыр икән, авыр булса да уза.

Көньяклардан искән җилләр гөл яфрагын каера,
Тормыш бит ул һич җәлләми, туганнардан аера.

Күзләремне, күзләремне, күзләремне күзләмә,
Минем күзем – төпсез диңгез, андин серләр эзләмә.

Агыйделне буйлап чыктым җиде яшьлек ат белән,
Безне тормыш мәҗбүр итте сөйләшергә хат белән.

Сабыр ит, дустым, сабыр ит, сабырлык – сары алтын,
Мин дә сабыр итәр идем, эчләрем тулы ялкын.

Аклы ситсы күлмәгемне кара белән алыштым,
Бик яратып сөя идем, соңгы көндә ялгыштым.

Кыр казлары йөзеп йөри, йөзеп йөри күлләрдә,
Әй, туганнар, авыр булды аерылышкан көннәрдә.

Сибелә чәчем, сибелә чәчем, сибелә чәчем җилләргә,
Мин китәм, якын дусларым, кайталмам инде илләргә.

Кисәм, кисәм каеннарны, кисмимен талларымны,
Гомерем булса, ятка бирмәм җан сөйгән ярларымны.

Әй, дускаем, гармонеңда уйныйсың төрле көйләр,
Ышанма дошман сүзенә, дошман әллә ни сөйләр.

Биек тауның башларында былбыл бала уйната,
Мәхәббәтең йөрәгемдә ал чәчәк булып ята.

Әнә килә автомобиль, төягәннәр чи арыш,
Атналык булса – танышма, гомерлек булса – таныш.

Кырга чыктым кыр күрергә, кыр чәчәге үрергә,
Ходай насыйп итәр микән син дустымны күрергә.

Әй, дускаем, Агыйделне бер дә буйламадыңмы,
Якын дустым кала, диеп бер дә уйламадыңмы?

Сандугачның балалары китә бездән көз генә,
Үтә көннәр һич туктамый, ләкин күңелсез генә.

Кара урманга барып керсәм, табалмыймын юлларны,
Аерылганда кулын бирде, оныталмыймын шуларны.

Гөлләремә су сибәләр Наил белән Наилә,
Аерылабыз, дигән идек, ахры туры килә.

Пароход килә, пароход килә, пароход күрмичә узам,
Сезнең яктан кошлар килсә, хат бирә, дип кул сузам.

Бөгелмә син, тал булсаң, сыгылма син, тал булсаң,
Чәчәкләрдән чәчәкләргә үрелмә син, яр булсаң.

Алма чәчәген өзеп ал, күкрәгеңә кадарсың,
Бик сагынган көннәреңдә шул чәчәккә карарсың.

Биек тауларның башында кемнәр салган кыек юл,
Исәпләмәсәм – түзәрмен, исәпләсәм – кыен шул.

Алларың булам инде, гөлләрең булам инде,
Уйламаган көннәрем юк, дивана булам инде.

Уфа кайда, Уфа кайда, Уфа Урал ягында,
Кошлар булып очар идем, бик сагынган чагында.

Тау башында пар каен яфрак яра ел саен,
Яфрак кебек саргаямын, сезне сагынган саен.

Сары, диләр, сары, диләр, сары чәчәк шушы икән,
Сагыну, диләр, саргаялар, сагынышулар шушы икән.

Ал матурмы, гөл матурмы, кайсы матур шикелле?
Күтәрелми күңелләрем томанлы көн шикелле.

Ишек төбең яшел чирәм, иртә бар да ат җибәр,
Бу хатларны алу белән, озакламый, хат җибәр.

Ал сабын белән юынсаң, яшь килмидер күзеңнән,
Шушы хатым бару белән хат көтәмен үзеңнән.

Тау башыннан поезд уза, аның яныннан мин узам,
Һавадан очкан кошлардан хат юкмы, дип кул сузам.

Күпер башы күк томан, бу илләрдә күп тормам,
Язын торсам, көзен тормам, сагынсагыз да булмам.

Иртә торып сулар сиптем, матур үссен гөлләрем,
Хуш, дускаем, рәхәт яшә, тыныч үтсен көннәрең.

Ап-ак, ап-ак кар каплаган быел безнең кырларны,
Сагынганда бер укырсың, язам шушы җырларны.

Бакчаларга кергән чакта кулларыңа чәчәк ал,
Аерылгач та бергә булган вакытларны искә ал.

Сезнең янга барма келәп, ала алмыйм күземне,
Очып барган кош артыннан әйтер идем сүземне.

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Карлыгач,
Елап карадым сагынгач, күреп булмый аерылгач.

Бакчабызда виноград тәмле, тәмле җимеш ашагыз,
Миннән сиңа шушы теләк: мәңге рәхәт яшәгез.

Ай яктысы бигрәк якты, чагыла минем күзләрем,
Хуш, дускаем, сау бул инде, шушы актык юлларым.

Биек, биек, бик биектә Астрахань күперләре,
Нигә моңсу үтә икән кыз бала гомерләре?

Биек тауга менгән чакта, таймас дага булса иде,
Бергә тору бик күңелле, аерылмаска булса иде.

Коммунизм бакчасында ленинизм чәчәге,
Синең белән үтсә иде тормышның киләчәге.

Уфа, диләр, Уфа, диләр, Уфа матур ил икән,
Бу дөньяда бигрәк авыр аерылышу бар икән.

Бу җырларны язган чакта сүнеп китте утыбыз,
Килешмәгән җире булса, килештереп укыгыз.

Кара бәйлим, кара киям кайгылы көннәремдә,
Җырым тәмам, күрешү телим алдагы көннәремдә.

Аклы ситсы күлмәгемнең итәкләре аркылы,
Йөрәгемә утлар салды аерылышу ялкыны.

Агыйделдән су алганда ак чиләгем күмелде,
Әй, дускаем, синең белән торулары күңелле.

Аллы-гөлле чәчәк ата, сулар сипсәң гөлләргә,
Ак бәхетләр теләп калам алдагы көннәреңә.

Язга чыккач, бик күп була төрле чәчәк кырларда,
Кабул итеп, укыр булсаң, языйм әле җырлар да.

Биектауга менгән чакта тартып ал кашлы йөзек,
Агым суларга төшсәң дә, төшәм артыңнан йөзеп.

Кара кошлар вәгъдә биргән очмаска, кагынмаска,
Мин дә сиңа вәгъдә бирәм гомергә аерылмаска.

Челтәрле күпер астында кульяулыгым юдым мин,
Башкаларга күңелең салма, синең өчен тудым мин.

Су буенда туктап юдым саргайган эзләремне,
Хуш, бәгырем, сау бул инде, бетерәм сүзләремне.

Йөзләреңнән күзләремне бер минут алмас идем,
Әгәр алтын балдак булсаң, кулымнан салмас идем.

Алтыным син, былбылым син, көмешем, сандугачым,
Хәтереңне калдырмамын, гафу ит, карлыгачым.

Син кадерле йолдызым, син минем бәхет таңым,
Синнән башка бу дөньяда кемнәрне сөйим тагын?

Салкын чишмә суларыннан су аласың киләме?
Миннән башка бүтәннәргә сер саласың киләме?

Өстәл өстендә гөлләрем, янында киемләрем,
Минем күңелләрем кебек булса иде күңелләрең.

Әй, матур син, матур син, матур син, күгәрчен син,
Кимә шушы күлмәгеңне, күз тиеп үләрсең син.

Бакчаларга су кермәсен, әфлисун черемәсен,
Күңелеңне нык тот, бәгырем, дошман сүзе кермәсен.

Һаваларда мамык оча кыр казы кагынганда,
Бер-ике җыр языйм әле, укырсың сагынганда.

Иртә торып тышка чыктым, ике былбыл ашаттым,
Шул былбыллар арасында берсен сиңа охшаттым.

Тәрәз төбендә роза гөл пута белән буйлыймын,
Сәгатенә 60 минут, минутка алты уйлыймын.

Биек тауга менәлмим, алмагачны бөгәлмим,
Алмасы пешкән – өзәлмим, сезне күрми түзәлмим.

Йөзегемнең кашы төште, үзем куялмам инде,
Инде сине көн дә күрсәм дә, күреп туялмам инде.

Каен каты, каен каты, аералмас берәү дә,
Синең кебек сандугач, тик, була алмас берәү дә.

Җирән атның ялларын әкрен искән җил тарый,
Син иркәмнең исәнлеген очып килгән кош сайрый.

Аклы ситсы күлмәгемне сандыкларга саламын,
Очып киткән кош артыннан сәлам әйтеп каламын.

Утырдым да хатлар яздым кәгазьнең яртысына,
Кәгазь китте, үзем калдым, хат көтеп каршысына.

Бакчабызда сары чәчәк, сарысын сабын итәм,
Сагынмый, дип әйтмә, бәгърем, сагынып сабыр итәм.

Иркәм безне «кайда» дисәң, Агыйделдә салда без,
Аерым кошлар ничек яши, шундый ук мисалда без.

Өстәл өстендә ике шешә, берсендә җиләк пешә,
Бергә-бергә булган чаклар өзелеп искә төшә.

Аклы ситсы күлмәк тектем, итәкләрен өч итеп,
Сандугачлар моңлы сайрый сагынганда үч итеп.

Чыгыйм тышларга микән, басыйм ташларга микән,
Эч серемне кемгә сөйлим, очкан кошларга микән?

Кара урманның уртасында чәчәк ата алмагач,
Йөзең якты, сүзең татлы, сайрый торган сандугач.

Чылтыр-чылтыр су агадыр безнең артта елгада,
Синең кебек берәр матур тагы бармы дөньяда.

Тау башында салкын чишмә, алган саен су арта,
Сөям, иркәм, сөям, иркәм, сине яннарым тарта.

Быел-быел, дигәнем, быелгы ел көйгәнем,
Кулларына гармонь тоткан егет минем сөйгәнем.

Ал бизәкле аклы ситсы – минем сөеп кигәнем,
Кара кашлы, кара күзле комсомолец – сөйгәнем.

Алма бакчасына керсәм, бадиан түтәлләре,
Ал булса да, гөл булса да, кирәкми бүтәннәре.

Кара урманны яктырта кара ат кашкалары,
Алтыннардан бизәнсә дә, кирәкми башкалары.

Кызарып чыккан кояш виноградны пешерә,
Матур көннәр, ямьле кичләр сезне искә төшерә.

Сулар ага, су селкенә көймә килүләренә,
Ышанасыңмы, дускаем, минем сөюләремә.

Аргы якның үләнен ат ашамый көрәнен,
Иртә уйда, көндез истә, кич төшемдә күрәмен.

Сандугачның сайравына ямансулама, дустым,
Синең алларыңа басып, үзем сайларга куштым.

Аклы ситсы күлмәгемне киям каралмаганга,
Искән җилгә сәлам әйтәм, үзем баралмаганга.

Сахраларда төрле чәчәк, төрлесендә төрле ис,
Иркәм, миңа бик ямансу, хәлемне белмисең ич.

Бакча ишеген ачып куй – кояш төшсен түтәлгә,
Күзем төшсә, күңелем төшми синнән башка бүтәнгә.

Утырамын, уйга батам, күк күгәрчен уйнатам;
Син иркәмә барырмын, дип, яшь күңелемне юатам.

Иртә буран, кич тә буран, мамык шәлемне юам;
Кигән киемеңне күрсәм, үзеңне күргән күк булам.

Астраханьның чиясен үзем җыеп өләшим;
Бик сагындым, бик саргайдым, каян күреп сөйләшим.

Тәрәзәмдә ак чәчәк, уртасында гөл чәчәк;
Минем сөю артык булыр, үлчәүләрдә үлчәсәк.

Сандугачның балалары басып сайрый чәчәккә;
Тормышымның сандугачы булырсың киләчәктә.

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Нуретдин;
Минем өстән ярлар сөеп, башларыңны хур иттең.

Алларың булыр әле, гөлләрең булыр әле;
Нигә ятны сөйдем, дигән көннәрең булыр әле.

Агыйделдән көймә килә кылдан нечкә эз белән;
Бәгърем, нигә хәтерең калды уйнап әйткән сүз белән?

Биек тауның башларында бәйләмәгән ат йөри;
Мин саргаеп үләр идем, арабызда хат йөри.

Аргы яктан бирге якка басма салдым киң итеп;
Гомерлеккә яр булсын, дип сине сөйдем тиң итеп.

Колхоз басуына барып трактор көйлисеңме?
Сөям, җаным, ташламам, дип, син дөрес сөйлисеңме?

Кулымдагы кульяулыгым җилфердәсен җилләрдә;
Минем дә торасым килми сез булмаган илләрдә.

Өстәл өсләрем түгәрәк, өстәлем түгәрәккә,
Җылый-җылый хатлар язам син сары күбәләккә.

Сибелә чәчем, сибелә чәчем, чәчем сибелеп бетте инде;
Чәчем сибелер, яшем түгелер көнем килеп җитте инде.

Утырдым өстәл янына, кулымда карандашым,
Ни язарга да белмәдем, тәмам әйләнде башым.

Алмагачның бакчасында чәчәк атмады чиям;
Ятны сөяр, дип уйламыйм, үлгәнче сине сөям.

Дускай, синең торган җирең таш пулаттан салганмы;
Бу хатыңны бик аз язган, әллә кәгазь кыйбатмы?

Күлмәгемә кадар өчен ал сәдәпләр алдырам,
Гомерлеккә бүләк итеп, җырлар язып калдырам.

Уйларым күп, уйларым күп, барсын уйламыйм гына,
Син дустым исемә төшкәч, утырып еламыйм гына.

Алсу иде йөзләрең, зәңгәр иде күзләрең;
Исләремнән чыкмас инде синең әйткән сүзләрең.

Сахраларга чыгып карыйм, күренмидер сезнең як;
Әллә җилгә очты микән безнең бергә булган чак?

Сандугачның баласын тот кечкенәсен булса да;
Хатка каршы хат язарсың өч кенә юл булса да.

Автомобиль ник туктаган, сүнде мәллә утлары?
Сине уйлап кына үтә кадерле минутларым.

Син дә кара, мин дә карыйм һавадагы болытка;
Бик сагынып хатлар язам, син дә мине онытма.

Әй, бәгырем, җан кисәгем, киясеңме алларны?
Исеңә алсаң, бер уйларсың бергә булган чакларны.

Тәрәзәмнең эленгесен ал лента белән чукладым,
Синең җибәргән хатыңны учыма учлап йокладым.

Бәгырькәем, тәрәзәңә алсу пәрдә кормадың,
Сынаттың бит дошманнардан, вәгадәңдә тормадың.

Аклы ситсы күлмәгемнең җиң кушулары җитми;
Аерылганда өзелгәнем әле дә онытылып бетми.

Кара күлмәкләрең бар бит, нинди көнне киясең?
Кичкә кереп, ут алганда күз алдыма киләсең.

Аккош кунган имәнгә, талпынадыр китәргә;
Хат язмыйча озак торма, бик озак бит көтәргә.

Өй түрендә куш каен, сайрый матур кошкаем;
Шуның белән тәмам итәм, сау бул, якын дускаем.

*Кече Чынлы авылында*
*Вәлиева Рәшидәдән язып алынды*

## Таш ташыйлар, ком салалар

Таш ташыйлар, ком салалар
Машина юлларына.

*Кушымта:*

Трәйләй, ләй, ләй,
Машина юлларына.

Алып укы, ертып ташла,
Бирмә ят кулларына.

*Кушымта:*

Трәйләй, ләй, ләй,
Бирмә ят кулларына.

Уникегә борылып суга
Кремль сәгатьләре.

*Кушымта:*

Трәйләй, ләй, ләй,
Кремль сәгатьләре.

Сөеп кара әле ятларны,
Ничектер гадәтләре.

*Кушымта:*

Трәйләй, ләй, ләй,
Ничектер гадәтләре.

Ак сусарлар хәбәр бирә
Судагы кондызларга.

*Кушымта:*

Трәйләй, ләй, ләй,
Судагы кондызларга.

Мин, сагынсам, айга карыйм,
Син кара йолдызларга.

*Кушымта:*

Трәйләй, ләй, ләй,
Син кара йолдызларга.

*Татар Саплыгы авылында Хәйруллина*
*Хәния Сәнәтулла кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

## Поезд килә, поезд килә

Сандугачым, дип сөйсәм дә,
Гөлгә кунмассың инде.
Үлгәндә дә син диярмен,
Ләкин булмассың инде.

*Кушымта:*

Поезд килә, поезд килә
Кырыклы вагон белән.
Дүртенче вагонда кайта
Иркәм гармоны белән.

Сандугачлар су дип эчә
Урмандагы чыкларны.
Уйлыйсыңмы, сагынасыңмы
Бергә булган чакларны?

*Кушымта*

Сандугачларга кунарга
Унике булсын киртәң.
Нәселегездә бер булып
Үсәсең икән, иркәм.

*Кушымта*

## Там тарека там, там

Кашың кара, кашың кара,
Кашың кара кыйгачтыр;
Синең сөйгән ярларың да
Үзең күк сандугачтыр.

*Кушымта:*

Там тарека, там, там,
Там, там, там. } 2 кат
Трәлә әләләй, ләй,
Ләй, ләй, ләү. } 2 кат

Алма бакчасына кереп,
Алма ашыйсым килә;
Син – агачы, мин чәчәге
Булып яшисем килә.

*Кушымта*

Бакчаларга кергәнем юк,
Гөлләр тигез үсәме?
Җил аркылы сәлам әйтәм,
Җилләр сезгә исәме?

*Кушымта*

*Татар Саплыгы авылында Хәйруллина*
*Фәймә Абдулкадыйр кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

## Пролетариатка

Сания көе чыккан, диләр,
Ота алсам ярар иде;
Уйлап, дивана булганчы,
Оныта алсам ярар иде

*Кушымта:*

Вагоннары, эшалоннары
Китә Ленинградка;
Шул вагоннар алып бара
Пролетариатка, пролетариатка.
Өзелеп сөйгән яшь ярыңны
Калдырма җиде ятка.

Биек тауга менәм әле,
Бик арысам, талсам да;
Алсу алмам, сине оныта алмам,
Кай җирләргә барсам да.

*Кушымта*

Сандугачым, ник сайрыйсың,
Сайрама, дигән саен?
Күз алларыма киләсең,
Уф, Аллам, дигән саен.

*Кушымта*

## Сария

Гөлләреңне еш утыртма, Сария,
Яфрагы сирәк булыр, сандугач баласы; } 2 кат
Онытма якын дустыңны, Сария,
Бер вакыт кирәк булыр, сандугач баласы. } 2 кат

Алмагачта алма ничә, Сария,
Талда яфрак кына, сандугач баласы; } 2 кат
Венера йолдызы кебек, сандугач баласы,
Яшә ялтырап кына, Сария. } 2 кат

Карап торам килгәнеңне, Сария,
Каралы кигәнеңне, сандугач баласы; } 2 кат
Марс йолдызына охшатып, Сария,
Елмаеп көлгәнеңне, сандугач баласы. } 2 кат

## Ай-ли, аппагым ла, ни теләгең бар тагын?

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Фәйрүзә.

*Кушымта:*
Ай-ли, аппагым ла,
Ни теләгең бар тагын ла,
Ни теләгең бар тагын?

Сезгә охшаулы зәңгәр күктә тулган ай гына йөзә.

*Кушымта*

Ишекләрдән күренәсең, гөлләргә үреләсең.

*Кушымта*

Гөлгә карыйм, сиңа карыйм, син матур күренәсең.

*Кушымта*

## Иеләдер, бөгеләдер беләгем

Өстемдәге күлмәгемнең
Бизәге бил турында;
Менә моны мәк чәчәге,
Дип әйтсәң дә урынында.

*Кушымта:*
Иеләдер, бөгеләдер беләгем,
Синең өчен өзеләдер үзәгем.
Матурлыгың, мәхәббәтең сөйдерә,
Әрсезлегең, чаялыгың көйдерә.

Колагымның алкалары
Җилкәләремә тия;
Ике араның ераклыгы
Теңкәләремә тия.

*Кушымта*

Кашың кара, кашың кара,
Кашың кара кыйгачтыр;
Синең сөйгән ярларың да
Үзең күк сандугачтыр.

*Кушымта*

## Алсу алма, кура җиләк, чияләр

Аклы ситса күлмәгемнең
Якалары тар икән.
Агымсуны туктатырлык
Мәхәббәтең бар икән.

*Кушымта:*

Алсу алма, курак җиләк,
чияләр;
Сизәсеңме, ярларыңны сөяләр?

Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Фәсәхәт;
Сине уйлап утырганда
Моңланып суга сәгать.

*Кушымта*

Алма тутырып җибәрәм,
Тарта алмый гына атым;
Нинди фикердә яшисең
Син, сөекле җанашым?

*Кушымта*

Өстеңдәге күлмәгеңнең
Якалары кыйгачтыр;
Синең сөйгән ярларың да
Үзең күк сандугачтыр.

*Кушымта*

Өстеңдәге күлмәгеңнең
Якалары тар икән;
Агымсуны туктатырлык
Мәхәббәтең бар икән.

*Кушымта*

*Татар Бизнәсе авылында*
*Миначева Гөлинә Хәсәнҗан кызыннан*
*язып алынды*

## Мәкаль һәм әйтемнәр

Бәхет теләктә түгел – беләктә һәм йөрәктә.
Ялганчының өе янган, берәү дә ышанмаган.
Үзем өчен туганмын, илем өчен үләрмен.
Тырышлык – зурлык, ялкаулык – хурлык.
Алтынга омтылган – югалган, белмичә омтылган – юл алган.
Уйлама үлем турында, уйла илең турында.
Батыр яуда беленер, куркак дауда беленер.
Боз кузгалгач, елга аша чыкмыйар.
Тимерне кызуында сугалар.
Янгынны, сүндергәнче, булдырмау яхшырак.
Тиле «тиле» дигән саен, тигәнәк буе сикерә.
Тырышкан табар, ташка кадак кагар.
Беләге юан берне егар, белемле булган меңне егар.
Балыкка кармаксыз бармыйлар.

Калган эшкә кар ява.
Эт этлеген итәр.
Ир егет үзе өчен туар, иле өчен үләр.
Бер тиенлек куян, биш тиенлек зыян.
Курыкканга куш, коерыгы белән биш.
Май ботканың күзен бозмас.
Коры кашык авыз ерта.
Иренгән ике эшләр.
Иелмәгәнгә бөгелмә.
Сукыр тавыкка бар да бодай.
Ни чәчсәң, шуны урырсың.
Язның бер көне ел туйдыра.
Оялмаган боермас (хурлыкка калмас).
Белгән белгәнен эшләр, белмәгән бармагын тешләр.
Эт өрмәсә, башы авырта.
Эшләмәгән ашамый.
Бии белмәгән аюга урман тар.
Озын сүзнең кыскасы.
Күп сөйләвең көмеш булса, тик торуың алтын.
Кыңгыр булса да, юл булсын.
Без капчыкта ятмый.
Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленер.
Акыл сатма.
Буй белән су үлчәмиләр.
Чәче озын – акылы кыска.
Алдыңнан артың.
Кул белән бирсәң, аягың белән эзләп алырсың.
Әз аша, тәмле була.
Матурлык туйда кирәк, акыл тормышта кирәк.
Батырлар үлмәс, ялкау көн күрмәс.
Әрем төбенә гөл үсмәс.
Алма агачыннан ерак төшмәс.
Акыллы – ашын мактар, акылсыз – хатынын мактар.
Акылсыз баш – аякка тынычлык бирми.
Алдыңда ялтырый, артыңда калтырый.
Аз сөйлә – күп эшлә.

Иелгән башны кылыч кисми.
Атны чыбыркы белән кума, солы белән ку.
Туйга барсаң – туеп бар, куеныңа күмәч куеп бар.
Гаеп атта да бар, тәртәдә дә бар.
Киселгән икмәк кире ялганмас.
Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.
Усал тел кыш кебек, яхшы тел яз кебек.
Йокы ястык сорамый.
Эшнең башын башлаганчы, аның ахырын уйла.
Начар – йокыңны ачар.
Түшәгеңә күрә – аягыңны суз.
Чүлмәгенә күрә капкачы.
Гөл төбенә кычыткан үсми.
Салма ашагач, татарга акыл кирә.
Әйткән сүз – каккан кадак.
Көтү кергәндә, көтүче хатынының тырагы таша.
Асыл кош аягыннан эләгә.
Үземнең киленем усал, кызымның кайнанасы усал.
Күл шайтансыз булмый.
Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга.
Язык казык башында, кызык язык башында.

## Табышмаклар

Казанда пешми, табакка төшми, аны ашамаган үсми. *(Ана сөте)*
Ай кашлы, яшел башлы. *(Көнбагыш)*
Үзе җирдә – аяклары күктә. *(Төтен)*
Өй түбәмдә яшел каз, яшел казның башы таз. *(Себерке)*
Үзе ялангач, дөньяны киендерә. *(Инә)*
Үлгәнче үзең белән, күрмисең күзең белән. *(Иңсә)*
Диңгездә бар – суда юк, абзарда бар – өйдә юк. *(«З» хәрефе)*
Аттан биек, эттән тәбәнәк. *(Ияр)*
Үзе атланган, аякларын артка салган. *(Күзлек)*
Өй артында тарым бар, күтәрә алсаң, барын да ал. *(Туфрак)*
Өй артында ак тана,
Мөгезем бар, дип мактана. *(Тәрәзә капкачы)*

Җанлыдан җансыз туа, җансыздан җанлы туа. *(Йомырка)*

Үзе бара, уймак-уймак эзе кала. *(Таяк)*

Үләннән тәбәнәк, таяктан озын. *(Юл)*

Келт-келт итә, бер урында гомер итә. *(Сәгать)*

Выр-выр вырылдый, зыр-зыр зырылдый,
Күккә менә, җиргә төшә, нәрсә кушсаң – шуны эшли. *(Самолет)*

Урманнан чыгар, түше белән шуар. *(Елан)*

Ите бар, сөяге юк. *(Сөлек)*

Төнен туа, көндез үлә. *(Чык)*

Үзеннән авырны күтәрә. *(Кырмыска)*

Көзен ята, язын торып китә. *(Кар)*

Үзе үкерә, үзе сөрә. *(Трактор)*

«Тыр» дисәң туктамый, печән салсаң ашамый. «На» дисәң атламый. *(Трактор)*

Биш бишең биш төштә,
Ике бишең бер төштә;
Бер сигез, бер тугыз,
Бер егерме, бер утыз. *(202)*

Ике сигез – уналты,
Тагын сигез, тагын алты. *(30)*

Муек, муек мүкерәгән, мөгезен күккә күтәргән. *(Кое баганасы)*

Агач, агач саен ботак, ботак саен йомырка. *(Борчак)*

Урманда бар, кырда юк; мунчада бар, өйдә юк. *(«Н» хәрефе)*

Җәен дә егет, кышын да егет, кайчан карама гел егет. *(Нарат)*

Бер тавык астында 60 күкәй. *(Сәгать, минутлар)*

Борыннан керә, авыздан чыга. *(Сулыш алу)*

Бер төп борчак, 366 (365) кузак, шулар эчендә унике борчак. *(Ел, көн, ай)*

Дөбер-дөбер дүртәү, силләзине икәү,
Шикай бабай тик ялгыз. *(Сыер)*

Урманда агач киртекле. Киртеклесе – минеке, киртексезе – синеке. Киерелеп тарткан чакта тузып төшә минеке. *(Киндер туку)*

Тәрәзә төбендә бер рус сикереп-сикереп боз казый. *(Тамчы)*

Биш балта, бер кыз ептән бура бурыйлар. *(Бәйләвеч)*

Ары лап-лап, бире лап-лап,
Сөңге саплап, киез каплап. *(Тәрәзә капкачы)*

Ике туган бергә торсалар да, берсен берсе күрмиләр, үзләре аерылып та тормыйлар. *(Күзләр)*

Алпавытның бакчасы,
Бакчасында мунчасы,
Мунчасына су ташыйдыр
Нечкә билле марҗасы. *(Умарта корты)*

Урманда бөктем, өйдә тектем,
Уртасында иха-хай. *(Иләк)*

Озын рус сузылып ята,
Балалары тезелеп ята. *(Матча һәм түшәм)*

Кечкенә генә коем бар,
Эчендә алтын суым бар. *(Лампа)*

Үзе сызгыра, үзе күренми, үзе бар нәрсәне пыр туздыра. *(Җил)*

Марҗасы үрдәк мае ала, русы җылап кала. *(Су алу)*

Аркылы да торкылы Андрейның ындыры. *(Тәрәзә рамнары)*

Эче кара күмер кебек, тышы сары калкан кебек. *(Самовар)*

Ялт-йолт итә, ялмай китә. *(Көзге)*

Бер бүректә кырык ямау. *(Мунча ташы)*

*Иске Чокалы авылында Йосыпова Миңсылу*
*Әхмәтҗан кызыннан (1906 елгы)*
*язып алынды*

Аягы юк – үзе йөри, теле бар – сөйләшми. *(Сәгать)*

Алтын багана өстендә ак күгәрчен. *(Чәйнек)*

Аягы юк, кулы юк, үзе күлмәк кия. *(Мендәр)*

Көндез салынып тора, төнен урынына керә. *(Ишек элгесе)*

Агач пулат, аның эчендә таш пулат, таш пулат эчендә тимер пулат, тимер пулат эчендә түгәрәк күл, түгәрәк күл эчендә сөяксез балык. *(Өй, мич, казан, су, коймак)*

Марҗасы тыга, урысы кычкыра. *(Коедан су алу)*

Чалт аязда болыт юк, чал тәкәдә мөгез юк. *(Көзге, куян)*

*Иске Чокалы авылында Шәйхаттаров*
*Риза Сафиулла улыннан (1936 елгы)*
*язып алынды*

Урманнан чыгар, курич очы чуар. *(Юкә)*

Урманга сыймый, кырга сыя. *(Тырма)*

Өч нүешле (почмаклы) келәттә ак абыстай утыра. *(Карабодай)*

Пәҗи (сүс) келәт, мунчала йозак. *(Капчык)*

Эләктергеч, тарттыргыч,
Татарский атна кич,
Карабодай мука есть. *(Табагач)*

Ызба артында ак тана,
Мөгезем бар, дип мактана. *(Боз сөңгесе)*

Ызба артында коем бар,
Ике төрле суым бар. *(Йомырка)*

Үзе бара бикәдәй, эзе кала тәңкәдәй. *(Таяк)*

Дүрт карт берсен-берсе куалар, ләкин тота алмыйлар. *(Тәгәрмәч)*

Келт-келт итә, алга китә. *(Сәгать)*

Кара битле кызым бар, өйдән өйгә йөридер. *(Таба)*

Чылтыр-чылтыр чылактин (кунча),
Чалып алдым беләктин. *(Богау һәм аның йозагы)*

Тышы яшел, эче кызыл,
Нокта-нокта карасы. *(Карбыз)*

Кечкенә генә болыттан ап-ак кар ява. *(Он иләү)*

Кырдан кайтты, бер ел өйдә ятты. *(Урак)*

Кечкенә генә пелде
Миңа карап көлде. *(Көзге)*

Аю акыра, йонын коя. *(Тегермән)*

Котырган куышта котырган елан кычкыра. *(Гармонь)*

Киштә тулы ак тавык,
Барысы да карт тавык. *(Теш)*

Ялт-йолт ябыша,
Йозаксыз бикләнә. *(Күз)*

Ызба тирәли сары ефәк әйләндердем. *(Мүк)*

*Иске Чокалы авылында Йосыпов*
*Таһир Юныс улыннан (1900 елгы)*
*язып алынды*



1 стр.

СССР Фәннәр Академиясе Казан Филиалы Т...
фольклоры экспедициясе вакытында 2-отряд ч...
тарафыннан язып алынган материаллар саны. ...
Экспедиция 1955-елның 21 июненнән июль ук...
Чүпрәле р[айоны]

| 0 | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 Жанр төре | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| № | чыгып киткән пункт исеме | нинди пунктка килгән | колхоз исеме | ике пункт арасы | транспорт төре (ат, машина, җәяү) | әкият | сөйләк | бәет | җыр | сюжетлы җыр | халык уены | йола җырлары | мәкаль вә әйтем | табышмак |
| 1. | Казань | ст. Бурундуки. | – | 200 клм | тим. юл | – | – | – | – | – | – | – | – | – |
| 2. | ст. Бурундуки | Алешкин | | | | – | – | – | 106 | – | – | – | – | – |
| | | Саплык | Каминин | 38 | автомаш. | 1 | – | – | – | – | – | – | 10 | 7 |
| | | Тат. Сап- | колхозы | | | – | – | 1 | – | – | – | – | – | – |
| | | лык авылы | | | | – | – | 3 | – | – | – | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | – | – | – | – | – | 3 |
| | | | | | | – | – | – | – | – | – | – | 2 | 2 |
| | | | | | | – | – | – | 86 | 2 | 1 | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | – | 2 | – | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | – | – | – | – | 28 | – |
| | | | | | | – | – | – | – | – | 1 | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | – | – | 2 | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | 13 | – | – | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | 34 | – | – | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | – | – | – | – | 146 | 40 |
| | Барысы | а/с | буенча | | | 1 | – | 4 | 239 | 4 | 4 | – | 186 | 52 |

394–399 битләрдә Чүпрәле районына оештырылган фәнни экспедициянең (1955 ел, 21 июнь – 20 июль) башкарган эше турында хисап. Экспедиция җитәкчесе – Х. Х. Ярмөхәммәтов. Отряд әгъзалары: К. М. Миңнекиева, М. Х. Зәбиров. Колл. 55, п. 1, сак. бер. 1



13

Тел, әдәбият һәм тарих институтының 1955 елгы
...ләннары. (Миннекиева К.М., Зәбиров М.Х.)
Экспедиция җитәкчесе Х. Ярмухаметов.
...елның 20-июленә кадәр җыелды.
й о н ы   б у е н ч а

Институт языка, литературы и истории Казанского филиала АН СССР
Рукописный фонд
Коллекция 55
Папка 1
№ ед.хр. 2 (5)

| 7 Кемнән язып алынган (фамилиясе, исеме, атасының исеме) | 8 туган елы | 9 белеме | 10 профессиясе | 11 партиялелеге | 12 искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| Зарипов Сабирулла Садык улы | 1939 | 7 кл | укучы | комсом. | |
| Нуруллин Шәмәрдән Шакир улы | 1936 | 10 кл | -"- | -"- | |
| Гыймадетдинов Шәйхелислам Гыймади улы | 1871 | | колх. чл. | — | гр. ур. кадим[illegible] |
| Сабируллина Нафия Сабирҗан кызы | 1914 | 4 кл | -"- | — | |
| Нуретдинова Роза Минннали кызы | 1939 | 5 кл | -"- | — | |
| Сабиров Шамил Хәснулла улы | 1937 | 10 кл | укучы | комсо. | |
| Хәйруллина Нәкыя Сонгатулла кызы | 1932 | 5 кл | колх. чл. | — | |
| Исмәгыйлева Фәридә Хәкимҗан кызы | 1933 | 3 кл | -"- | — | |
| Хәмидуллина Энҗә Гайнулла кызы | 1938 | 5 кл | -"- | — | |
| Хәйруллина Әнисә Абдулкадыйр кызы | 1938 | 7 кл | -"- | — | |
| Хәйруллина Нәкыя Сәгыйтулла кызы | 1940 | 7 кл | -"- | | |
| Вафина Зәйтүнә Тарикать кызы | 1933 | 4 кл | -"- | — | |
| Хәйруллин Рәхимҗан Хуҗанас улы | 1938 | 10 кл | укучы | комсом. | |
| Авыл яшьләре һәм укучылар | | | | | |
| 13 | | | | | |

| • | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | | | | № | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Айшкин | Иске | Киров | 15км | маши- | – | – | – | – | – | – | – | 8 | – |
| | Сапмык | Чокалы | колхо- | | нада | 1 | – | 1 | 38 | 1 | – | – | 23 | 22 |
| | авыл | а/с | зы | | | – | – | – | 153 | 4 | 23 | – | – | – |
| | советы | | | | | – | – | – | 243 | 814 | – | 8 | – | – |
| | | | | | | – | – | – | – | – | 3 | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | – | – | – | – | – | 20 |
| | | | | | | – | – | – | 30 | – | – | – | – | – |
| | Барысы | а/с буенча | | | | 1 | – | 1 | 464 | 19 | 26 | 8 | 31 | 42 |
| 3. | Иске | Татар | Кага- | 10км | ~~атта~~ | – | – | – | 59 | 2 | – | 17 | – | – |
| | Чокалы | Бездәнәсе | новичъ | | | – | – | – | 269 | 1 | – | – | – | – |
| | а/с | а/с | колхо- | | | – | 2 | – | 16 | – | – | 17 | – | – |
| | | | зы | | | – | – | – | 140 | 3 | – | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | 40 | – | 6 | – | – | – |
| | | | | | | | | | | | | 8 | | |
| | Барысы | а/с буенча | | | | – | 2 | – | 524 | 6 | 6 | 46 | – | – |
| 4. | Тат. | Маре | Мичурин | 8км | ~~ат~~ | – | 8 | – | 4 | – | 14 | – | – | – |
| | Бездәнә | а/с | колхозы | | | – | – | – | – | – | 9 | – | – | – |
| | а/с | Югары | | | | – | – | – | – | – | – | – | 6 | – |
| | | Иня | | | | – | – | – | 24 | – | – | – | – | – |
| | | Түбән | | | | – | – | – | 109 | – | – | – | – | – |
| | | Каракитяв авылы | | | | – | – | – | 31 | – | – | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | 129 | – | – | – | – | – |
| | Барысы | а/с | буенча | | | – | 8 | – | 297 | – | 23 | – | 6 | – |

| 7 | 1 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|
| Фәсхиев Фатых Фәсхи улы | 1894 | – | тимерче | – | – |
| Юнусов Тахир Юнус улы | 1900 | – | инвалид | – | – |
| Юсупова Мөнирә Гайниятулла кызы | 1934 | 8 кл | колх.чы | комсом. | – |
| Низамова Фәрхәт Сәләх кызы | 1929 | 9 кл | пион.вож. | –"– | – |
| Низамова Мөнирә Мобиновна | 1932 | 7 кл | колх/чы | – | – |
| Юсупова Миңсылу Әхмәтҗан кызы | 1906 | – | –"– | – | – |
| Сафиуллин Иршат Арифуллович | 1937 | 7 кл | курсант | комсо. | – |
| 7 | | | | | |
| | | | | | |
| Бакиева Галия Шәриф кызы | 1931 | 7 кл | колх.чы | – | – |
| Хамаламова Бибинур Камал кызы | 1934 | 7 кл | –"– | – | – |
| Хамилов Габделгалим Хамидулла улы | 1874 | – | –"– | – | – |
| Саликов Ибнигабдин Нигъматулла улы | 1924 | 10 кл | –"– | – | – |
| Минаева Галима Хәсәнҗан кызы | 1934 | 7 кл | –"– | – | – |
| Минаева Шәмсекамал Камилулла кызы | 1910 | – | –"– | – | – |
| 6 | | | | | |
| | | | | | |
| Хәертдинов Әмир Гайниятулла улы | 1930 | 7 кл | колх.чы | комсом. | – |
| Азмуханова Мөслимә Хисаматулла к. | 1936 | 6 кл | сыерсавучы | – | – |
| Гайнетдинов Шихап Гайнетдин улы | 1896 | – | колх.чы | – | – |
| Якупова Рауза Харис кызы | 1934 | 6 кл | –"– | – | – |
| Якупова Сөмбел Фәсхи кызы | 1936 | 10 кл | укучы | комсом. | – |
| Шайдуллина Гөлшат Закир кызы | 1937 | 5 кл | колх.чы | – | – |
| Азизов Әкъи Юнус улы | 1932 | 10 кл | укытучы | комсом. | |
| 7 | | | | | |
| | | | | | |

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | | | | м. | 6 | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Марс | Мочалы | Пар- | 7км | ат | – | – | – | 64 | – | – | – | 3 | 18 |
| | а/с | авыл | ти- | | | – | – | – | – | – | – | – | 4 | – |
| | Кара- | советы | зан | | | – | – | – | 58 | – | – | – | – | – |
| | китт | Мочалы | кол- | | | – | – | – | 72 | – | – | – | – | – |
| | авылы | авылы | хозы | | | – | – | – | 7 | 4 | – | 6 | – | – |
| | | | | | | – | – | – | – | 2 | – | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | – | 1 | 4 | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | 36 | – | – | – | – | 3 |
| | | | | | | – | – | – | 52 | – | – | – | – | – |
| | Барлысы а/с буенча | | | | | – | – | – | 289 | 7 | 4 | 6 | 7 | 21 |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| 6. | Мочалы | Иске | Ялкын | 12км | ~~ат~~ | – | – | – | 16 | – | – | – | – | – |
| | а/с | Кичерле | колхозы | | [illegible] | – | – | – | 6 | – | – | – | – | – |
| | | а/с | | | | – | – | – | 1 | – | – | – | – | – |
| | | Иске | | | | – | – | – | 28 | 1 | 3 | – | – | – |
| | | Кичерле | | | | – | – | – | 18 | – | – | – | – | – |
| | | авылы | | | | – | – | – | 125 | – | – | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | 32 | – | – | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | 7 | 1 | – | – | – | – |
| | | | | | | – | – | – | 25 | 2 | – | – | – | – |
| | Барлысы авыл советы буенча | | | | | – | – | – | 258 | 4 | 3 | – | – | – |
| | Иске Кж. Чүпрәле | | | 12км маш. | | | | | | | | | | |
| | Барлысы район буенча | | | | 346км. | 2 | 10 | 5 | 2061 | 40 | 66 | 39 | 230 | 115 |
| | Иске Чүпрәле ст. дан | | Буртас дуки | 44км | | | | | | | | | | |

| 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|
| Махмутов Вәзих Ишмөхәммәт улы | 1941 | 7 кл | колх.ч. | комс. | – |
| Исмәтов Шәйхул Исмәт улы | 1892 | | а/спиц. | член КПСС | ук. суг.-да булган. |
| Алмакбаров Марсель Фатых улы | 1938 | 7 кл. | укучы | комс. | – |
| Шагиева Җәмилә Исмәт кызы | 1935 | 7 кл | колх.ч. | –"– | – |
| Галикова Оркыя Абдрахман кызы | 1921 | тиеш б. [illegible] уку йорты | укытучы | – | – |
| Алмакбирова Фәхрелбанат Ногман кызы | 1900 | урта белем. | укытучы. пенсияд. | – | – |
| Хафизова Зөбәйдә Кәрим кызы | 1935 | 7 кл. | колх.ч. | комсом. | – |
| Махмутова Фәхриҗамал Гыйлметдин кызы | 1896 | – | –"– | – | – |
| Измайлова Сылу Мифтах кызы | 1936 | кл | –"– | – | – |
| 9 | | | | | |
| | | | | | |
| Шәрифиева Таһирә Рәсих кызы | 1937 | 9 кл | укучы | комсом. | |
| Салахова Хания Касыйм кызы | 1938 | 10 кл | –"– | –"– | |
| Насретдинова Зәйтүнә Габдрәшит кызы | 1941 | 7 кл | колх.ч. | – | |
| Әхмәтова Рузалия Латыйп кызы | 1939 | –"– | укучы | – | |
| Зөбәйдуллина Мөһер Зарретдин кызы | 1907 | – | колх.ч. | – | |
| Мөхәммәтшина Фәрдания Рәис кызы | 1939 | 7 кл | укучы | – | |
| Нуретдинова Наилә Ханәфия кызы | 1938 | –"– | колх.ч. | – | |
| Хәйруллина Фәузия Зиннәтулла кызы | 1938 | –"– | –"– | – | |
| Шиганова Наилә Дәүләтшина кызы | 1938 | 7 кл | колх.ч. | – | |
| 9 | | | | | |



Институт языка, литературы и истории
Казанского филиала АН СССР
Рукописный фонд
сектора народно-поэтического т-ва
Коллекция 55
Папка 6
№ ед. хр. 69

Таһир - Зөһрә көенә җыр

1. Чәч үргечем, чәч үргечем,
Чәчемне үрер өчен;
Таһир үлгән Зөһрә өчен - (ике кат)
Мин үләм синең өчен.

2. Таһир мескен Зөһрә өчен
Зинданнарда кичләгән;
Башын кисәрне дисәләр дә - (ике кат)
Вәгъдәсеннән кичмәгән.

3. Таһир белән Зөһрәне
Агызганнар суларга.
Йөреп - йөреп кавыша алмасак - (ике кат)
Без дә охшыйбыз шуларга.

4. Әнә килә матур поезд,
Безне алабызмы инде;
Таһир белән Зөһрә ничек - (ике кат)
Шулай калабызмы инде?

Чүпрәле районы Аксинкин Саплык авыл советы Тат. Саплык авылы Калинин исемендәге колхоз члены 1932 нче елда туган, 5 класс белемле Хәйруллина Нәкыя Сәхәтулла-

Татар Саплыгы авылында Нәкыя Хәйруллина язып тапшырган халык авыз иҗаты үрнәкләре. Колл. 55, п. 6, сак. бер. 69




Татар Саплыгы авылында Роза Нуртдинова язып тапшырган халык авыз иҗаты үрнәкләре. Колл. 55, п. 6, сак. бер. 71

Институт языка, литературы и истории
Казанского филиала АН СССР
Рукописный фонд
Коллекция 23
Папка 2
29.IX.48

Соңгы сүзләр

Беләм, әнкәй, авыр шуңа саргайгансың,
Газиз балаң хатлар яза диеп хатларымны көтә йөргансың.

Көтмә инде, әнкәй, минем хатлар, үлем килде миңа – балаңа
Әнкәй, яшь йөрәгем чиксез әрни түзә алмыйм авыр ярага.

Минем хәлне сез белмисез үлгәнемә инде ничә көн,
Мин үлгәнлеккә военкоматтан булыр сезгә кара печатем.

Тимер пуля аугач җиргә кемнәр өчен анда син хәлне,
Әнкәй күрсә өзелер инде кан эчендә аккан бу хәлне;

Йөрәк әрни ярам авыр бер туктаусыз җиргә кан ага,
Озакламый тәнем суыныр үлем килә яп-яшь балага.

Әнкәй, мин юк балаң хатлар килмәс хәзер улыңнан,
Синең улың авыр яраланды немец-фашист аткан пулядан.

Актык минут актык секунд соңгы каным тама ярадан
Хуш инде, әнкәй, хушыгыз, туганнарым, күрә алмыйм сезне яңадан.

Ике кашым бергә тартып күрмешем өчен тарткан,
Немец кулларыннан үләр өчен яшьлегем чәчәк аткан.

Бирәк яшьләй үлем килде үләсем бер һич тә килмәде,
Башымны җиргә куеп җан биргәндә су бирергә кешем булмады.

Әнкәй, җаным, рәхмәтемә булмадым эшегезгә,
Ти... җан биргән чакта кергәнмен төшегезгә.

402–404 битләрдә 1945 елда Институтның фольклор экспедициясе вакытында Кече Чынлы авылында Халидә Гатина язып алган бәет кульъязмасы. Колл. 23, п. 2, сак. бер. 48

(Соңгы сүзләр-2:

Алсу каным җиргә тамган саен яшь йөрәгем әрни сызлана,
Рәхәт күрми үләм инде диеп яшьлегемне җаным кызгана.

Яшь гомеркәй үтте гүя кайдың нигә җитте синең башыңа,
Их, кызганыч яп-яшь егет башын куйды кабрлар йортына.

Газиз әнкәй, үле гәүдәмне санитарлар кая ташларлар,
Үле гәүдәм шунда черер инде гәүдәм итеп кортлар ашарлар.

Их, әнкәем, бәлки мине кайтыр диеп өмет итәрсең,
Зинһар бүтән йокламыйча алсу таңда мине көтәрсең.

Беләсеңме, әнкәй, мин үзем дә телим идем илгә кайтырга,
Туган илгә кайтып, шат тормышта тагын матур чәчәк атарга.

Илгә кайту булмады ул миңа, юкка чыкты теләкләрем,
Балкып кайткан күзләр сүнде инде тибеп янган йөрәгем.

Ярам авыр чиксез әрнесә дә мин бер ышанмадым үлемгә
Җаннарымның бирер вакытта да телмердем мин сезне күрергә.

Германия сугыш ачкан безнең башка җитәргә,
Үләсемне белмәдем бер бәхилләшеп китәргә.

Кара күзем сүнде хәзер күмелеп калды җиргә уенгыз,
Әнкәй, хәзер минем өчен дога гына кылыгыз.

Яшь егеткә кызганыч ул алсу канын түгәргә,
Мин бәхетсезлеккә булган җеназасыз күмелергә.

соңгы өзләр-3

Ничек кеше исән калсын уклар ява җирдән, күгеннән,
Кемнәр кызганмасын яшь егетне күмелгәнен җиргә бүгеннән.

Яшьлек вакыт, матур вакыт туган илдә чәчәк атасы,
Яшь егетнең бүгеннән үк ничек килсен җиргә ятасы.

Шунда язган һәрбер сүзләремне үзе сөйли дисгез,
Минем калган гармонымны Фидиямә бирегез.

Өйдә чакта гармонемны бүтәнгә уйнамадым,
Туган илгә кайтырмын дип күкрәгемдә уйламадым.

Җан биргәндә салкын җилләр исә шундый җилләр сездә исәме,
Минем гармонь уйнап йөргәннәрем, әнкәй, исегезгә төшәме.

ТАССР, Буденный районы,
Кече Чынлы авылы башлангыч
мәктәп укытучысы Валеева
Рәшидәдән алынды.
Язып алучы Х. Гарина

23/XI-45

## АВТОРЛАР ТУРЫНДА КЫСКАЧА БЕЛЕШМӘ

**МИҢНУЛЛИН Ким Мөгаллим улы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы.

**ӘХМӘТҖАНОВ Марсель Ибраһим улы** – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш фәнни хезмәткәре.

**БАЯЗИТОВА Флера Сәет кызы** – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

**БУЛАТОВА Миңнира Рәхим кызы –** филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәре.

**ГАЙНЕТДИНОВ Айдар Марсель улы** – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәре.

**ГАЛИМОВ Салават Фәрәгать улы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты кече фәнни хезмәткәре.

**ГАФАРОВ Иршад Әхмәт улы** – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры.

**ИСЛАМОВ Рәмил Фәнәви улы** – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире.

**МУЛЛИН Илдар Рамил улы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты.

**РАМАЗАНОВА Дария Бәйрәм кызы** – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш фәнни хезмәткәре.

**САДЫЙКОВА Айсылу Хөсәен кызы** – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш фәнни хезмәткәре.

**СУБАЕВ Рафаил Сиражетдин улы** – Чүпрәле районы тарихын өйрәнүгә караган хезмәтләр авторы.

**ФӘРРАХОВА Илүсә Рәсим кызы –** Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм сәнгать институты студенты.

**ХИСАМОВ Нурмөхәммәт Шаһвәли улы** – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш фәнни хезмәткәре.

**ШАКИРОВА Зөһрә Камил кызы –** Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм сәнгать институты студенты.

**ЯМАЛТДИНОВ Илмир Илдар улы –** филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире.

## ЭЧТӘЛЕК

СҮЗ БАШЫ
5

КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР
9

ГОРЯЧЕЕ ДЫХАНИЕ ХОЛОДНЫХ КАМНЕЙ
21

ИЛҺАМЛЫ ЕЛЛАР, ТАБЫШЛЫ ЮЛЛАР
35

ИСКЕ БУЛСА ДА, ИЗГЕ МИРАС
39

МУНЧӘЛИЕМ, ГАЗИЗЕМ
45

ТАРИХЫ БУЛГАН АВЫЛНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ БАР
51

ТАТАР ТЕЛЕННӘН ТАНЫР
85

СҮЛӘМӘ КЕЛИМ, ТЫҢЛАУЦЫ БУЛСА...
137

ГЫЙБРӘТЛӘР АЛАСЫ БАР…
161

«МӘЗӘК ҖЫРЛАРЫ» ТУГАН ЯКТА
183

ПОЮЩЕЕ ДЕРЕВО
265

«ИМЕ-ТОМЫ ШУЛ БУЛСЫН»
273

КҮҢЕЛ ЧИШМӘЛӘРЕ САЕКМАС
279

ҮТКӘННӘРГӘ КАЙТУ
303

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

Девятая книга

**Национально-культурное наследие**
**ДРОЖЖАНОЕ**

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән»* сериясе

Тугызынчы китап

**Милли-мәдәни мирасыбыз**
**ЧҮПРӘЛЕ**

Редакторлар *Я. М. Абдулкадыйрова, А. В. Әбдриева, Д. Э. Нигъмәтуллина*
Компьютерда биткә салучы *Н. Т. Абдуллина*
Китапта *М. И. Әхмәтҗанов, А. М. Гайнетдинов, И. Р. Муллин, И. Р. Фәррахова* фоторәсемнәре файдаланылды

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде

Басарга кул куелды 15.12.2016
Форматы 60×84 $^1/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табыгы 13,07. Шартлы басма табагы 23,72.
Тиражы 500 д. Заказ